# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1995



# Указ
# «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында.



Татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен шагыйрь **Идиятуллин Шәүкәт Гали** улына **(Шәүкәт Галиевкә)** «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

Казан, Кремль.
1995 ел, 2 июнь.

Татарстан Республикасы
Президенты **М. Ш. Шәймиев.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

**(873)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

И. ЮЗЕЕВ. Сандугачның бишек жыры. *Шигырьләр* . . . 3
А. ГЫЙЛӘЖЕВ. Камыш бармак, көмеш тырнак. *Повесть* . . . 10
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр . . . 45
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Өч хикәя . . . 54
Л. ЗАКИР. Инша. *Кара хикәят* . . . 74

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. ЗАКИР. Бисклек. *Шигырьләр* . . . 71

ӘДӘБИ МИРАС

Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты . . . 93

ДРАМАТУРГИЯ

Р. МИНГАЛИМ, Р. ХӘМИД. Идегәй. *Нәфис фильм өчен драма* . . . 108

ШИГЪРИЯТ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Шигырь кемгә кирәк? . . . 139
Р. МОСТАФИН. Шигъри публицистика . . . 142
М. ВӘЛИ. Тәнкыйтьчеләр кая качкан? . . . 146

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Р. РАХМАНИ. Халкыбызның көрәшче галиме *(Әбрар Кәримуллинга 70 яшь тулу уңаеннан)* . . . 149

СӘНГАТЬ

Татарның Туишевы . . . 156

ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Англиядә «Ислам энциклопедиясе» *(АКШ галиме Сирил Гласс әфәнде белән әңгәмә)* . . . 161

КИТАП КҮЗӘТҮ

Н. ХАНЗАФАРОВ. Заман дәреслеге . . . 164

«КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН

Өч рәсем — өч мизгел . . . 166

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

С. МИХАЙЛОВА, Г. МӨХӘММӘТҖАНОВА. Тарихи һәм матур әдәбиятта Алтын Урда . . . 168

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Миңһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

ӘДӘБИ МИРАС

Шигырьле сулышлар *(Сибгат Хәкимнең Наҗар Нәҗмигә язган хатларыннан)* . . . . . . . . 174

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Г. САТТАР-МУЛИЛЛЕ. Татар телле Татарстан? . . . . . . . . . . . . . 177

З. ДОНИС. Динозаврлар нигә беткән? *Хикәя* . . 185
Бер сорауга — бер җавап . . . . . . . . . . . 184
Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повесть А. ГИЛЯЗОВА, рассказы З. ЗАЙНУЛЛИНА, повесть Л. ЗАКИРА; стихи И. ЮЗЕЕВА, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, М. ЗАКИРА.
«Литературное наследие»: «Литература древнего и среднего веков»
«Драматургия»: драма для художественного фильма Р. МИНГАЛИМА и Р. ХАМИДА «Идегей».
«Разговор о поэзии»: статьи Т. ГАЛИУЛЛИНА «Кому нужно стихотворение?», Р. МУСТАФИНА «Публицистика в поэзии», М. ВАЛИЕВА «Где спрятались критики?»
«Выдающиеся личности»: статья Р. РАХМАНИ посвящена к 70-летию академика А. Каримуллина.
«Искусство»: статья посвящена творчеству музыканта, композитора Ф. Туишева.
«Религия и жизнь»: «Энциклопедия ислама в Англии» (Беседа Саратовского ученого, кандидата философских наук Л. Солодовниченко с американским ученым Сирил Гласс).
«Книжное обозрение»: Н. ХАНЗАФАРОВ рецензирует новую книгу А. Ахматуллина.
«Из архива журнала»: «Три фотографии — три мгновения».
«К истории народа»: статья С. МИХАЙЛОВОЙ и Г. МУХАМЕТЗЯНОВОЙ «Золотая Орда в исторической и художественной литературе».
Письма С. Хакима адресованные Н. Наджми.
«Острая проблема»: статья Г. САТТАРОВА посвящена дальнейшему развитию татарского языка в Республике Татарстан.
Рассказ З. ДОНИСА «Почему исчезли динозавры?»
На наших обложках: «Шахгали» — картина художника Р. Мубаракзянова; известный драматург Р. Хамид.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 30.05.95 ел. Басарга кул куелды 20.07.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 945. Заказ Д-173.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Илдар Юзеев

### САНДУГАЧНЫҢ БИШЕК ҖЫРЫ

* * *

Әллә инде Күктән иңгәнгәме:
жырда — илһам,
тылсымлы көч,
ашкын хыял,
серле хис...
Күкне Җиргә тоташтырган
моң күпере — җиде төс...

Әллә Җир туфрагын сизгәнгәме:
жырда — шатлык,
кайгы-хәсрәт,
омтылыш,
яшәү көче...
Күктән куылган Адәмнең
мәңгелек үкенече...

*20.3.95.*

* * *

Үз теләгем белән бу дөньяга
Килмәгәнмен,
Табигатькә кирәк булганмын,
Якты җиргә сөенеп бага-бага,
Көлмәгәнмен,
Сөрән салып елап туганмын.

Үз теләгем белән бу дөньядан
Китмәмендер,
Олуг көчне зурлап китәрмен,
Чиксез яшәтүне Җир-анадан

Кѳтмәмендер —
Илаһи моң тыңлап китәрмен.

...«Юктан бар иттең, дип,
Бардан юк иттең...» дип,
Тып-тын гына җырлап китәрмен...

*5.3.95.*

## ИКЕ СОНЕТ

* * *

Ана сандугачлар ник сайрамый?
Җир гамьнәрен алар оныта.
Оясыннан аерыла алмый,
Туар балаларын җылыта.

Ата сандугачлар сайрый нигә?
Аяз таңнар чыгын эчкәнгә.
Алар сайрый сѳенечле кѳйгә —
Аналарның моңы күчкәнгә.

Шул чагында китә күңел тулып,
Сихри моң тирбәлә тирәктә.
Сандугачның бишек җыры булып,
Оялый ул безнең йѳрәктә.

Ана үзен хистән тыяла.
Моңның чыганагы — ояда.

* * *

Кѳтмәгәндә генә килде ул яз,
Кырларда да карлар аз иде,
Мәхәббәтем — кояш, күңел — аяз,
Ташып килгән иртә яз иде.
Әмма ул яз үкенечле булды:
Җылыдан соң салкын китерде.
Аерылдык, җаннарыбыз туңды,
Кырлардагы уҗым шикелле.
Күпме еллар килде язлар алып,
Күпме ташу кайтты ярына.
Күңел оча һаман канатланып
Тәүге мәхәббәте янына.

Чын мәхәббәт — иртә йә соңмы,—
Сафландыра җанны — суынмый.

*1995.*

## Без

*«Без һәммәбез Гогольнең «Шинель»еннән чыктык...»*
Дәресләрдә еш кабатланган тәгъбир

Сез шулайдыр, ә без — башкачарак,
Ертык ыштаннардан атлап киттек.
«Туган тел»ле Казаннарга карап,
Такташ «Мокамаен» ятлап киттек.
Без Гогольнең «Шинель»еннән түгел,
Әтиләрнең шинеленнән чыктык.
Корчагиннар сезгә яттыр бүген,
Ә без «корыч булып чыныктык».
Павел Морозов та үрнәк иде...
Шәп анадан, шәп атадан чыктык.
Без тормышка (кырыс сабак бирде),
Үзебез үргән чабатадан чыктык.
Заман безнең үзәкләрдән үтте,
Назламады рәхәт тынычлыкта.
Корал биреп, походларда йөртте,
Ярап куйды кайчак корычлык та.
Тимер иләк аша чор үткәрде.
Бик аз калган буын-нәселле без.
Яшерсәк тә яра авыртканны,
Күңел йомшаклыгын яшермибез.
Гел-гел хәсрәт диңгезендә йөзеп,
Әллә бабайларның каны кучкән:
Күнеккәнбез кайгыларга түзеп,
Елыйбыз тик шатлык-сөенечтән...

*4.3.95.*

* * *

Ис китәрлек булмаса да
Башымда акылларым,
Чит итмәде, якын күрде
Дусларым, якыннарым.
Йолдыз алып кайтам диеп,
Күкләргә атылмадым,
Йөрәк кушканча яшәдем:
Сатмадым, сатылмадым.
Белсәм дә рәхәт яшәргә
Өлешем-хакым барын,
Читләтеп үттем дөньяның
Көмешен-алтыннарын.
Башкортларның сәсәннәрен,
Казакъның акыннарын
Юлдаш иттем. Юлбаш иттем
Йөрәгем ялкыннарын.
Әкрен генә сөйләдем мин,
«Тыңла!» дип акырмадым,
Ишетте ерак тарафлар,
Үз итте якыннарым.
Ис китәрлек түгел дә соң
Башымда акылларым...

Әүлия үк булмасам да,
Дәрвишләр затыннанмын...

*23.2.95.*

* * *

Озын төннәр йокламадың,
Күзләреңне йоммадың.
И эрләдең, и эрләдең
Гомереңнең йомгагын.
Бәйләп бардың ялганганын,
Читкә аттың ялганын.
Өзеп ташлый алмаганын —
Нишләтерсең калганын?
Җиңел генә чиштең кебек
Катмарлы төеннәрен,
Юкка гына түгел микән
Чиштем дип сөенгәнең?
И бәйләдең, и бәйләдең
Утырып, боек кына.
Әллә инде бәйләгәнең
Бияләй, оек кына...
Көндезен дә, төннәрен дә
Тырышып, онытылып
Ни эрләдең, ни бәйләдең
Җаннарны җылытырлык?

*11.3.95.*

* * *

Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам.
Соң аңладым илһамымның
Күкләргә бәйләнгәнен,
Илаһи шагыйрь икәнен
Мөхәммәт пәйгамбәрнең.
Шик ярала иң-иң тирән
Җирендә күңелемнең:
Табигатьнең бик үк камил
Баласы түгелмендер...
Рәхмәт, тәңрем, әле дә мине
Бу җирдә Адәм иттең.
Тик кызганыч, гомеремне
Заяга әрәм иттем.
Үкенсәм дә артта калган
Имансыз елларыма,
Сыялмыйм шул Мөхәммәтнең
Катгый кануннарына.
Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам...

*8.2.95.*

* * *

Ул даһины исән вакытында
Нигә, нигә сакламадык соң,
Җаны рәнҗетелгән, туңган чакта,
Нигә, нигә якламадык соң?
Читкә сөрелгәнгә, кагылганга
Ярдәм кулы сузу — бик кирәк...
Хәзер — һәйкәл... чәчәк, алкыш, хөрмәт...
Җылы караш ташка ник кирәк?

*1.2.95.*

## Үзгәрәм

Мин элекке түгел инде,
Үзгәрдем.
Бик өз күрәм, нуры сүрән
Күзләрнең.
Мин элекке түгел инде,
Үзгәрдем,
Дуслар сизә йомшаклыгын
Сүзләрнең.
Дошманнарга карата да
Үзгәрәм:
Таш урнына шигырь белән
Сүз бәрәм!

*1995.*

## Яшик әле...

*Фасил Әхмәткә*

Яшьлек елларыбыз — җан өшеткеч:
Җайсыз-көйсез иде,
Беребезнең — кияр киеме юк,
Беребез — өйсез иде.
Язмыш безнең баштан сыйпамады,
Үзе күргән — аңлар.
Гарипләнде — тәннәр, сүнде — шәмнәр,
Исән калды җаннар.
Җанны эшкә кушып, тешне кысып,
Горур атлап киттек,
Берәүне дә өйле итәлмәдек,
Әмма көйле иттек.
Һәр мәҗлестә аек булмасак та,
Аек булдык — җырда.
Шаккатырлык эшләр кылмасак та,
Лаек булдык чорга!
Бер көй тапкан кебек җиде нота:
До-ре-ми-фа-соль-ля-си...
Сирәк-мирәк тостлар тота-тота,
Тормыш агуларын йота-йота,
Илдар, Фасил яши.
Кайберәүләр, бәлки, «мескеннәр» дип,

Көләләрдер бездән.
Без рух белән, дустым, көчлерәк бит
Хәтта үзебездән!
Яшик әле тормыш агуларын
Шактый киметкәнче,
Йөрәк — телгәләнеп, үзәк — өзгәләнеп,
Җанда — көй беткәнче!

*1993.*

## Бу нинди җир?

Бу нинди җир:
Ауган нарат, сулган каеннардан
Тамыр исе килә.

Бу нинди җир?
Өзгәләнгән, корган тамырлардан
Тимер исе килә.

Бу нинди җир?
Кемгә генә барып кагылсаң да,
Хәмер исе килә.

Бу нинди җир?
Сайрап-җырлап торган табигатьтән
Кабер исе килә...

*20.9.93.*

## Авыру уй

Хуш исен гөлләр чәчәр дә
Сәхрә-болынга дәшәр.
Бездән соң кемнәр килер дә
Бездән соң кемнәр яшәр?
Алар да уйларлар микән
Үзебез уйлаган кук?
Кабергә чәчәк куймаслар...
Үзебез куймаган кук...

*1993.*

## Бурлаклар

Идел буендагы бурлаклардай,
Тормыш йөген тартып барасың.
Хәлдән таеп арып каласың да
Сүгенәсең туктап: «Анасын!..»
Бар да, бар да халык җилкәсендә:
Кемнәр генә анда менмәгән...
Миллион — өзелә-сузыла аркан тарта.
Кәеф-сафа кора — мең адәм.
Мин дә тарттым алар пароходын,
Мин дә бераз гына бурлакмын.

Гамьсезлегем шулай арта-арта,
Яшьлегемне иртә югалттым.
Бар да, бар да халык җилкәсендә,
Бик соңарып шуны аңладым.
Мин акчарлак булып күтәрелдем,
Бурлаклардан һаман калмадым.
Акчарлакның ачы авазларын
Тыңлый-тыңлый, халкым, уйлап бар:
Өзелерме аркан йә түземлек,—
Булырбызмы мәңге бурлаклар?..

*1.2.95.*

* * *

Әзерлиләр заман давылының
Җимергеч зур хәрабәләрен...
Бик сагындым инде авылымның
Сандугачлы әрәмәләрен.
Әллә җаным тарткан туган якның
Кошы булып кына сайрыйсы?
Әллә инде Ирек дошманына
Калкан булып, кылыч сайлыйсы?
Ишетерсезме соңгы җан авазын
Әрәмә йә мәйдан ягыннан:
Шатлыктанмы, әллә ярабанмы
Сандугачның җаны ярылган?..

*3.2.95.*



## ШИГЪРИЯТ



**Аяз Гыйләҗев**

# КАМЫШ БАРМАК, КӨМЕШ ТЫРНАК

ПОВЕСТЬ

**Валлаһи газыйм: һәр әсәрнең үз язмышы! Бу повестьны 1969—70 нче елларда язганмын икән. Журналга илттем — басмадылар, җыентыкларга керттем — төшереп калдырдылар. Повесть Майя Ганина тәрҗемәсендә урысча дөнья күрде. Заманында мәшһүр урыс язучысы М. Ганина әсәрне яратып тәрҗемә итте, җыелышларда булсын, радио-телевидениеләрдә булсын, гел мактап сөйләде һәм аның В. Распутинның шушыңа охшаш темага язылган әсәреннән күп элек алда иҗат ителүен дә искәртергә онытмады. Беләм, тема тирәсендә Мирсәй ага Әмир дә йөреп алды. Нишлисең, без барыбыз да бер үк кырдан уңыш җыйдык ләбаса! Урысча кат-кат басылган повестемны татар укучысына җиткерергә ниятләдем. Яратып, чын күңелемнән дулкынланып язган идем мин аны, хәзер дә яратам. Чын ата бар балаларын да тигез ярата ич.**

**АВТОР.**

1

Ярты төн авышкач, Рәмзия дерт итеп сискәнеп уянды.

Бераз калкынды, биленәчә сыерылып төшкән калын юрганын кузгатырга да шүрләп, уң беләгенә таянып, тыңлана башлады. Шылт иткән тавыш ишетелмәде, дәү, караңгы өйнең бер-бер почмагында ичмасам ник таракан кыштырдасын!

Өйнең җылысы качкан иде, Рәмзия туңа башлады, калтыранды, ияге дерелдәвен һич тыя алмады, тавыш-кара ишетелмәгәч, түшәгенә шуышты, салкын юрганын муенына шае тартып меңгерде.

Инде өченче әтәчләр кычкырып, сүрән эңгер дөньяга иңгәндә, аның шик-шөбһәләр тулып авырайган мие томаланды, ул тирән, караңгы упкынга очкан сыман булды һәм тагын сискәнеп уянды. Торып караваттан аякларын салындырып, ялт-йолт ишек-тәрәзәләргә каранды, бу юлы зиһене тиз ачыкланды, ул сикереп төште дә боздай салкын ялангач

идәнгә басты. Идән паласы белән кичтән ишек ярыкларын томалаган иде.

Җаны чак сакланган мич кашагасыннан тиз-тиз карманып, лампа эзләп тапты, шырпы чыртлады, аның матур уелган нәзек борын яфраклары ачы күкерт исеннән мелт-мелт итеп селкенеп куйдылар.

Ул җиделе лампаның филтәсен мул итеп күтәрде, куркак яктылык артыннан ияреп өй эчен урап чыкты, ят бер нәрсә дә шәйләмәде. Сак тыңлана-тыңлана ишек катына килде, иелмичә генә аякларына киез каталар эләктерде, суыкта ябышып каткан ишеккә үкчәсе белән ике-өч тапкыр типте.

Өйалдында да шикләнерлек нәрсә-кара сизелмәде. Ишеккә аркылы салынган имән бастырык урынында, тимер келә күтәрелмәгән. Чолан ишеге дә элүле. Ул чолан ишеген ачты да, авызын учы белән каплап, артына чигенде, бераз көтте, шуннан соң гына эчкә атлады.

Зур агач сандык... Төрле күләмдәге тәпән-кисмәкләр... Җилпуч... Һәммәсе дә тиешле тәртип белән киштәләрдә, идәндә тезелешеп утыралар. Түшәм такталары бәсәргән, кисмәк-чапчак кыршаулары сыкылы, бер почмактан сөңге булып сызылып кар кереп тулган, аның еш-еш күтәрелгән күкрәгеннән чыккан тын идәнгә төшеп җитә яза.

Ут артыннан йөргән күз шуны раслады: барысы да ул куйганча, үз урынында.

Тик нигәдер күңел шикләнә. Рәмзиянең куркулы күзләре белән янәшә шушы бәсәргән почмакларга тагын бер пар ят күз дә карап, эзләнеп торган сыман тоела...

Кузгалырга бик иртә булса да, ул яңадан ятмады, тиз-тиз, әмма бөртекләп үз урынын җыештырды, мендәр-түшәкләрне кат-кат кабартты, һаман тыңланды, күзләре бер яктан икенче якка сикерделәр. Өзмәс нидер көтсә дә, берни үзгәрмәде, берни сизелмәде, көндәгечә иренеп кенә авыр кышкы таң атты.

Мичне ягарга кирәк иде, ул сырмасын киде, яулык почмакларын кыстыра-кыстыра өйалдына чыкты, бастырыкны күтәрде, келә шалтырады.

Эңгер-меңгер сыекланып килә. Күршеләрнең кече як тәрәзәләрендә сүрән ут яктысы, акшары купшакланган чуар морҗаларыннан юка гына төтен күтәрелә. Ул Мәфтуха апасының ишле гаиләсен, шуның аркасында иртә-кичен ял белмәс мәшәкатьле көнкүрешен уйлап, кат-кат көрсенде.

Кичтән кар сибәләп торган иде, хәзер аязыткан, яшь кар артыннан тынга кабынырлык суытып җибәргән. Ул кар шыгырдавының рәхәтен тоеп, тамагын нәзек кенә кыргалап, йортыннан бер-ике сажин ераклыктагы курага таба китте. Кураның бирге башы сарай сыман бүленеп, стеналары нечкә бүрәнәләрдән салынган, балчык сылап җылытылган. Рәмзиянең бар булган аяклы малы — дүрт баш сарыгы һәм унике тавыгы шунда яшәп ята. Кураның аргы башында лапас, анда хуҗалык әйберләре, йорт кирәк-яраклары кузласы, «Уфалла!» арбасы, утыны-мазары саклана. Ата-бабадан калып, чормада аунап туйдырганнан соң, лапаска чыккан киндер станы да, йоны-саламы тузган каз оясы да шунда.

Сарай ишеге турын узып, утынлыкка борылыйм дигәндә генә, ул, куркынып, туктап калды, хәле китеп, җиргә иелде. Өй ишеге яныннан ындыр капкасына кадәр, дәү-дәү эзләр калдырып, кемдер узып киткән иде. Эзләре дә өр-яңа, чекерәеп ярылып яталар.

Ул, тиз-тиз борылып килеп, сарай ишеген ачты, борынга җылымса абзар исе килеп бөркелде, куначада зарыгып утырган тавыклар да пыр-пыр аның аяк астына очтылар. Сарыклар берсен-берсе этә-этә муеннарын сузып, аның кулына үрелделәр. Ул, өйрәнелгән гадәте буенча, бишмәт кесәсеннән ипи катылары чыгарып, хайваннарга сузды, җиңел сулап куйды. Бер, ике, өч, дүрт...

Ишеккә аркылы таяк элеп, ындыр капкасы янына ашыкты, карга баткан капканы иңе белән күтәрде, ачты. Зәңгәрсу тирән эзләр ындырда

тагын да ачыграк уелып калганнар иде. Кемдер койма аша гына элдергән дә, су буена төшеп киткән.

Ул Метри елгасы аша, теге якка, Кәҗә башы урамына, болай таба артлары белән утырган сирәк йортларга карады. Курку-каушаудан кемгәдер кычкырасы, ярдәмгә чакырасы килде.

Кем йөрер?

Нигә?

Урам капкасы бикле үк, койма аша йөргәнне Мәфтухаларның Сарбае ишетми калмас иде.

Ялгыз хатынның сарыгын урларга кергәннәр дисәң, яшь кар артыннан ук эз салып кем йөрсен? Аннары соңгы елларда якын-тирәдә бер дә андый этлек ишетелми бит!

Ни уйларга да аптырап, башы тәмам исәнгерәгән Рәмзия өенә керде, тагын чыкты, сарыкларны куып кертеп, сарай ишеген япты, эзләр артыннан ияреп, ындырга юнәлде. Иелеп-иелеп җентекләп карагач, ул узучының аягында күнитек булуын абайлады, әнә, эре-эре кадак эзләре ярылып ята.

Ул, кочагына утын төяп, өйгә керде, чыра телде, мичен кабызды, самовырына шаулатып су тутырды. Болар барысы да аның ихтыярыннан тыш эшләнделәр. Гүяки, ул шушы иртәнге мәлдә икегә бүленде, аның бер яртысы тилмереп, интегеп табышмакка җавап эзләде, икенче яртысы, үз җае белән чираттагы көндәлек вак-төяк эшләрне башкара торды.

Коры усак утыны чатыр-чотыр яна башлады. Ул, бишмәтен салмыйча гына, идәнен себереп чыгарды, күмер төшкәч, самоварын куйды. Мичен тарткач, исен алсын дип, ишеген каерып ачып, чәчрәтә-чәчрәтә бусагага каткан бозны чапты, өйалдыннан шыкраеп каткан керләрен кертеп элде.

Чынаягын авызына китереп чәй йотам дигәндә, капка кактылар, бая, каушавыннан ул аның тимер чөен суырып чыгарырга онытып кергән икән.

— Кем бар анда? — диде ул ят тавыш белән.

— Кемнәр йөрсен синең капка төбендә? — диде теге яктан хатын-кыз тавышы.

Рәмзия бригадир Хәтимәнең шәл чуклары арасыннан юаш кына елтыраган зәңгәр күзләренә нидер көтеп, сагаеп карады.

— Әллә кеше дигәнең торып кына килә инде? — диде Хәтимә, каушаган чыраен күреп.

— Юк ла... Торуыма байтак иде дә, таңнан аңгы-миңге йөрим шунда. Әйдә, кер.

— Чирләп китмә тагын. Рәхмәт, керә тормыйм. Бүген яңа эскерт ачабыз, зират тавы өстенә менәрсез. Тимер кәрәгеңне онытма дип әйтергә керүем, иртәрәк кузгалсагыз да ару булыр. Юл читенләшкәндер, яуды...

Яланөс чыкканга аның җилкәсе чемер-чемер итте, ул күңелен курыккан шикле эзләр турында бригадирга әйтергә теләде, ни дисәң дә идарә әгъзасы, олырак кеше, бер-бер киңәш әйтә алмасмы, дип уйлады. Әллә ничек, кыймады, дөньясының эте-бете бар, кем йөрмәс, ялгыз хатын тәрәзәсе янынннан кем иснәнеп узмас, белер-белмәс чаң сугып, үз даныңны сатарсың, дип, үзен-үзе тынычландырырга да тырышты...

Тамагына аш үтмәде, бер чынаяк чәен суытып капыл-копыл эчте дә, ишегалдына чыгып чапты, мал-туарына ашарга салды, тавыкларга җим болгатты. Аннан шәлъяулыгын ябынып, билен каеш чөелдерек белән кысып буды, күршеләре Мәфтухаларга кереп китте.

Күршесе абзар ишеген ачык куеп, сыерына башак болгата иде. Олы малае Мирхәйдәр балта белән салам тураклап тора. Мәфтуха аны улакка тарата да кап-кайнар комган суы белән пешекләп, учлап-учлап көрпә катыш он сибә. Улак өстендә бөтерелеп пар уйный, иелгән Мәфтуханың йөзе күренми дә иде.

— Таш тешәгәннән соң салган иым арышымны... Мич башында киптереп, ипигә генә тотармын инде дип җилләтеп, арулап алып барган ашлыгымны әрәм итеп бирде теге чулак нәләт! Арышын күрсәң иде син, Рәмзия, бөртеге-бөртеккә, корылыгын әйтәсеңме, кетердәп кенә тора иде... Шундыен арыштан четердәп торган зыянлы он ясады шул, исерек крич. Җитмәсә, әллә каян әрем тәме дә сеңгән. Чүп-чарның, әрем-мазарның орнатын да калдырмадым югыйсә. Ипи пешерсәм дә, ашамыйлар малайлар, токмач-күмәчкә кушуны уйлаган да юк инде.

— Вак иләктән үткәреп карарга иде,— диде Рәмзия, чиләктән онны чеметеп алып.

— Уздырдым, уздырдым, уздырмаган кая ди ул, җиз иләктән дә иләдем, үзем белән шушы йортка иярә килгән бик һәйбәт борынгы кыл иләгемнән дә үткәрдем, өч пот он бит, гөнаһ шомлыгы!.. Шулайга китәр инде ул отыры, Рәмзиякәй! Толны — тол итәләр, санламыйлар. Таш тешәгәннән соң фураж-мазар үткәреп алалар ие элек, хәзер ярар, дигәннәрдер, безнең ише кыек авызга бара дигәннәрдер, төртелмәс, дигәннәрдер.

— Ул-бу сизелми тагын,— диде Рәмзия онны ике учы арасында ышкып.

— Кул сизмәсә дә авыз тоя! Ичмасам, сөте мулрак, куерак булсын дип, сыерыма башакка кушам.

Абзар почмагына мөгезеннән бәйләнгән кола сыер баядан бирле мөгрәп тора иде. Мәфтуха аны ычкындырып, улак янына алып килде, сыер, башын чөеп, күзләрен йомып, шундук башакны умырырга тотынды.

— Иплəп! — диде аның арт санын сөеп Мәфтуха.— Чәчеп бетерәсең, явыз!

— Ашказанына утырмас микән бу нәмәстәкәй, Мәфтуха апа?

— Нәрсәне әйтәсең?

— Вак таш дияоем... Сыер малының корсагы дәү булса да, нәзберек бит ул, инә-мазар йотса да, корсагында йөртә, ди. Син онынны ашаткан-ашаткан тавыкларыңа җим итеп тот.

Мәфтуха сыерының күәстәй җиленен коры чүпрәк белән сөрткәләп тора иде, калкынып ботын чапты:

— Яшь кенә башыңнан әллә ниләр беләсең, Рәмзия... Тормыш көтә башлавыңа кайчаннан дигәндәй, үзең, ипидер, миннән остарак. Шулай итим әле, бүгеннән ашатмам, боерган булса, йә эчәгесен-мазарын тишкәләп бетерер. Бар карап торганыбыз сыер, башы сау булсын!.. У-у, чулак нәләт! Илайлар нәселе шул... Әрәмнәр итте арышымны, ризыгымны кисте...

— Бәланең башы-ахыры шул булсын, балаламасын, диген дә, май кап, Мәфтуха апа.

Иртәрәк купкан иде Рәмзия, күршесе сыерын савып бетергәнче абзар-кура арасында йөренгәләп көтеп торды. Шыпырт күзәткәләп ындыр капкасы тирәсен урап килде, шикле нәрсәләр күзгә-башка чалынмагач, бераз тынычлангандай булды. Икәүләп өйгә керделәр. Мәфтуха мичкә бәрәңге тәгәрәткән икән, өйгә тәмле ис таралган. Берсеннән-берсе чак кына олырак дүрт малай, күзләрен елтыратып, өстәл тирәсенә тезелешкәннәр. Һәркайсының алдында калын ипи телеме. Малайлар күрше апаларын чын сөенү белән каршыладылар. Бәләкәй Мәрдән генә:

— Рәмзия апа кергән! — дип кычкырып куйды.

— Утырып җибәр,— диде Мәфтуха Рәмзиягә.— Бәрәңге күп, бергә-бергә ашарсың. Әле, аллага шөкер, кары явып китте, тышкы базымның өсте юка дип куркып тора идем. Хәзер мул булса да, язга саегыр әле ул бәрәңге!

Мәфтуха артыгын кыстамады, күршесенең кыланырга яратмаганын ул яхшы белә, сөтен сөзеп, чынаякларга салып өстәлгә тараткач, малайлар берәм-берәм бәрәңгеле калай табакка үрелделәр. Рәмзия аларның ашауларын карамас өчен чуар-чабар боз туңган тәрәзәгә борылды.

Ашап-эчеп алгач, малайлар пыр туздылар, бишмәт, киез итек, шарф, бияләй бүлеш китте, бәргәләшеп тә алдылар, тузан туздырып шаярыштылар. Барын хәстәрләп, малайларны мәктәпкә озатканда Мәфтуханың иртә саргайган маңгай тирәләренә бөрчек-бөрчек кайнар тир бәреп чыкты.

— Уф,— диде ул, сәке йөзлегенә арты белән терәлеп.— Шушыларны әзерләп чыгару ярты гомерне ала.

— Мәшәкатьле булса да, жаның тыныч, алдагы көнгә өметең бар,— диде Рәмзия көнләшеп.

— Әйтмә инде, дүрт бала белән тол калуның бәхетен ходай күрсәтмәсен, диген!

Аның шулай әрнеп әйткән сүзләре Рәмзиягә бик авыр ишетелде, ул:

— Анысы рас инде, тик ялгыз башка да бик авыр ла,— диде.

— Бигрәкләр дә аз торып калдың шул... Ике ай тулдымы?

— Ай да унсигез көн.

— Һай, бигрәкләр дә бәләкәй шул. Ни тойган да, ни белгән әле син, хатын диярлек тә түгел. Без менә, мәрхүм Миңлебарием белән, ундүрт ел яшәдек! Һай, гомерләр!..

— Ничек телең барып «мәрхүм» дип әйтә аласың?..

Мәфтуха бәбкәле каз сыман, аяк өсте генә бәрәңге капкалады, сөйләнә-сөйләнә табынлыкны жыештырды, көрсенә-көрсенә киенде, тәрәзәләргә карый-карый, яулык өстеннән калын шәл урады. Урамга чыктылар.

Рәттән ике өй көне буена кешесез кала иде, икесе дә шуны уйлап, бер-берсенә караштылар.

— Син тагын йокысыз яттыңмы?

— Гел шулайга әйләнде бит, Мәфтуха апа.

— Жүләрләнерсең алайса,— диде тегесе аны әрләп.— Исән икән, бер кайтыр, үлгән икән, кыяматкә тиклем күрешмәк юк.

— Күңелнең ышанасы килми, кайтыр кебек.

— Күңел ышанмый да бит, нишлисең... Тик болай кайгырып жүләргә сабышырсың.

Алда да, артта да тупчындай калын киенгән, тиз атлаудан бөкерәешкән хатын-кызлар күренсә дә, аларны куып та житмәделәр, үзләре дә житкермәделәр, икәүдән-икәү генә сөйләшенгән гәпнең кадерен саклап, тар сукмактан бер-берсенә юл биреп бардылар.

Рәмзия үз тәрәз төбен кемнеңдер сагалавын Мәфтухага әйтергә теләде, икеләнде, бары:

— Төне буе дерт-мерт итеп ятам шунда. Исламгәрәйнең үлгән хәбәре килгән көннән юньле йокы күргән юк,— дип зарланды.

— Алайса, сиңа шул,— диде кискен итеп Мәфтуха.— Алдын-артын уйлап тормыйсың, тотасың да безгә күченәсең. Болын дәүмәлеге өендә ялгыз башың саташып бетәрсең, аллам сакласын... Хәзер аның утыны да чутлы, керәчине дә агып тормый, сугышның башы гына, әле аның азагын белгән кеше юк... Ике солдатка өйдәш булып ничек тә тырмашып кышны чыгарбыз, язга күз күрер. Мартка — күңел шарт, диләр!

— Килешерме соң ул?— диде Рәмзия шатланганын сиздермичә.— Үзегез биш жан дигәндәй...

— Биш янына алтынчы сыяр, әй!..

Алар ишек тирәләрен калын кар сарган клуб турына життеләр. Клуб белән бер ишек алдында идарә йорты. Ул арада Югары очтан төшеп килүче атлы күренде. Чана үрәчәсенә ялгыз ир таянган. Дилбегәсен сыңар куллап тоткан бу ир авылның беренче карлыгачы — сугышны үз күзе белән күреп, яраланып кайткан Зәбир иде.

Егет чик сагында иде, кадровойда. Немецлар белән беренче таңда ук бик каты бәрелешеп, шушы сугышта уң кулы каты яраланган Зәбир, һич исәптә-санда югында, ир-атларын озатып авыл иңрәп ятканда, шинель итәген сөйрәп, кайтып төште.

Клуб турында үзенә юл биргән Рәмзия белән Мәфтуханы күргәч, ул кырын яткан җиреннән калкынды, атын тыйлыктырды, тегеләр утырырга ашыкмагач, ияген кагып, сәлам бирде дә, идарә ишеге төбенә үк барып тукталды. Бүрек колакчыннары күтәреп куелганга, Зәбирнең дәү колаклары иртәнге кояш төшкән клуб тәрәзәләре төсле кызарып яналар иде.

Барып җиткәч, Рәмзия күтәрелеп карады, агарынып китте. Салам арасыннан Зәбирнең эре-эре кадаклар чуарлаган калын табанлы, зур күнитекләре тырпаеп күренеп тора иде...

— Берәүләрнең кадерлесе гүргә кергәндә, бәбәген акайтып шушы иблис кайтты бит,— дип, әрнеп пышылдады Мәфтуха.

Зәбир — авылның иң затсыз, Сабан туе саен җыен агай-энe — тиле таз җыелып сугыша торган атаклы Илайлар нәселеннән иде. Хәзерендә төп йортларында хәлсез карчык әниләреннән башка кеше дә калмады инде, Илайларның олы-кечесе бәхет-тереклек эзләп, чит өлкәләргә таралышып беттеләр. Бу җәфалардан да котылыр көн бар икән дип, Кәҗә башы урамы кешеләре җиңел сулап кына торганда, күр менә, Илайларның кечесе сугыш башында ук котылып кайтты. Монысын авылда бер дә өнәмәделәр.

— Юньсезгә юл бирүче бер шайтандыр,— диде карт-коры.— Ишле гаиләдән берәрсе кайткан булсачы...

Мәфтуханың ярым әрнеп, ярым әрләп әйткән сүзләре шул фикерләргә куәт иде.

Әмма Зәбир, абыйлары күк күрше тавыгын урлап, тол хатыннар белән көмешкә чөмереп азапланмады, ерак дәдәсе янына тегермәнгә дә үрләмәде, агай-энесе белән тыйнак күрешеп, ил агаларына түбәнчелекле сәлам биреп, бер-ике көн кунак булгандай итте дә, эш сорап колхоз идарәсенә барып керде.

— Ниндиерәк эш табыйк икән? — дип, идарәдәге хатын-кызлар аның яралы кулына карамаска тырыштылар.

— Атлы эш,— диде Зәбир.

Элегрәк елларны, әле күрше авылдан килеп, җиденчедә укып йөргәндә кинәт буынга сикергән Зәбир Рәмзияне авыл очына хәтле озата баргалаган иде. Үсә төшкәч, кичләтеп Рәмзияләр авылына кичке уенга да төшкәләде. Тирә-як халкын дер селкетеп торган Илай токымыннан Рәмзия бер дә куркып тормады:

— Йөрер исәбем юк та юк, эзәрлекләмә, Зәбир абый,— дип, егетнең юлын һәм сүзен кырт кисте.

Исламгәрәйнең үлгән хәбәре Зәбир авылга кайткач килгән иде. Авыл советыннан налог түләү квитанцияләрен алып кайтканда, кичке эңгердә Зәбир яшь солдатканың юлына аркылы төште, әмма кыеп сүз-кара әйтмәде. Баскан урыныннан кыймшанмыйча, күзе белән аны зарыгып озатып калды. Зәбирнең күзләренең соры икәнлеген, борынының туры, килешле булуын Рәмзия беренче тапкыр шунда абайлады...

Армиядән дә хатлар язып караган иде, шул убыр йөргәндер аның тәрәз төбендә, шиксез, шулдыр...

Атлылар, җәяүлеләр акрынлап идарә янына җыелдылар, бригадир Хәтимә аларга соңгы сүзен җиткерде:

— Кичәгенәк председатель белән карап әйләндек, эскерт бозланып каткан. Иплән ачыгыз, бик әрәм-шәрәм итмәскә тырышыгыз.

Зәбир сау кулы белән атының камыт тирәләрен, ыңгырчак асларын капшап торды да, хатын-кызлар чаналарга төялә башлагач, тагын Рәмзияләргә эндәште:

— Утырасызмы, саламның иң йомшагын җәйдем,— диде.

Мәфтуха: «Утырмыйк шул Илай тәресенә»,— дип пышылдаса да, Рәмзия Зәбир чанасына менеп, салам арасына кереп чумды.

Шау-гөр килеп, кысылышып чаналарга төялешкәч, Зәбир дә чанага килеп тезләнде, ат, хуҗасының әзер икәнлеген күреп, җайлап кына кузгалды, чана табаннары күңелле генә чожладылар. Башка олаулар Зәбир аты эзеннән тезелештеләр.

Рәмзиянең кыска бишмәт итәгеннән шундук ат җиле оргылып керде, ул саламга тирәнрәк чумып, Мәфтухага елышты.
Кәҗә башы урамын үтеп, инешкә төштеләр. Елга ярлары бөтенләй беленерлек тә түгел, кар каплаган, тик кайсыбер тушлый-тушлый каткан урыннарны җил ялап, сөяк кебек ялтыратып бетергән. Көрткә бата-чума инеш аркылы чыктылар, бераздан Зәбирнең көрән алашасы фыр-фыр сулап, зират тавын менә башлады. Хатыннар чанадан коелдылар. Зәбир дә дилбегә башын чанага ташлап, җәяүләде.
— Әй,— дип кычкырды ул хатын-кызлар төркеменә.— Хәзер кемнең күпме бәрәңге лыгынганын беләбез!
— Май ашаганны да беләсеңме?..
— Оста,— диештеләр хатыннар.
— Кем артта кала, шул — бирән корсак.
Берәүнең дә шундый яман кушаматны аласы килмәде, чананың тар гына сызылып калган эзенә басарга тырышып, юлда бөялештеләр. Арттагы чанадагылар, юанлыгы, таза беләкләре өчен «бояр» кушаматы алган тимерче кызы Нурдидәне карга төртеп аудардылар, җыйнаулашып аркан тарткандагы кебек тотынышып тартып торгыздылар, кар сибештеләр, китте шау-шу, китте көлеш, күңелләр ачылып, элекке көзләрне, ашлык суккан чакларны, рига тирәләрен тутырып утырган биек-биек эскертләрне хәтергә төшерделәр. Көн җылынды. Гадәттә сагышлы юл булган зират яныннан шаулашып-көлешеп узып киттеләр.
Менеп җиткәч, барысы да ухылдап чаналарга аудылар, тыннары буылды, сүзләре киселде. Ул арада офыктан шактый калкынган кояш нурлары, тау киртләчләрен сарган кар кикрикләре энҗе-мәрҗән ябынган патша кәләшләре күк елкылдадылар.
Мәфтуха, мышнап туйгач, Зәбирдән: «Сыңар кул белән ничек эшләп йөрисең, сиңа болай да паюк чыгадыр бит?» — дип төпченеп барды.
Рәмзия шау-шу аралаш Зәбирнең җавабын ишетеп бетермәде, егетнең күнитекләренә күзе төшкән саен, үзенең ындырын кисеп узган куркынычлы тирән эзләр хәтеренә килде. Кемнеңдер аның йокысын сагалап, җәбер-җәзасыз гына аның хуҗалыгын таптап йөрүе күңелне бик рәнҗетә иде.
— Сине сугышка яңадан алмаслармы инде? — дип төпчендe Мәфтуха һаман.
Бу юлы аның җавабын Рәмзия дә ишетте:
— Алсалар, бара беләм... Юлы таныш!
Мәфтуха, Зәбирнең Илайлар нәселеннән икәнлеген тагын бер кат искәртми булдыра алмады:
— Коры куык,— диде.— Бик атлыгып торасыңдыр инде...
Түбән очның Фәрихә дә:
— Юкны сөйләмәсәнә, Зәбир акыллым, күк капусы ачылып, аягыңкулың, дүрт саның сау килеш, үз нигезеңә кайтып элгәшкәнсең икән, алай шапырынма. Әнкәңә куаныч, агай-энеңә юаныч дигәндәй, безнең тишек авыз ни сөйләмәс! — дип торды.
Калган хатыннар да аңа кушылдылар:
— Әйе-әй, безгә дә күз ял итәргә ир-ат калсын.
— Каныңны койгансың, Гитлерны кырырга кеше бетмәс,— диештеләр.
Мәфтуха гына тынмады:
— Шулай да, тегеләрнең берәрсен кәңкәйттеңме? — дип сорады.
— Сугышта терәп атышу юк, апа,— диде Зәбир тыйнак кына.— Алар ата башлагач, карап тормадык. Кулда таяк түгел ие, мәгәр, йә бардыр, йә юктыр.
Аның мактанмавына, тыйнаклыгына, сугыш турында сүз чыкканда олыгаеп китүенә Рәмзия генә түгел, башкалар да гаҗәпсенеп бардылар. Зәбир күп сөйләшмәде, хатыннар аның авызыннан сүзне келәшчә белән тартып кына алалар иде.

— «Дыр» белән «бугай»ны егерме беренче елны чәчкәннәр иде дә, басуларда шымытыр гына үсеп чыкты,— дип, чәнечте Мәфтуха егетне.

Тик Зәбир аның белән дә бәхәскә кереп тормады.

Эскерткә житәрәк кар сизелерлек тирәнәйде, җил сызып-сызып сыртсырт көртләрне тыгызлап өйгән, бозлы тауга охшаган тәбәнәк эскерт юаш кына ялтырый иде. Ул арада эскерт төбеннән ыргылып үр куяны атылып чыкты, аны ай-һайлап, үр-рә кычкырып, озатып калдылар.

Хатын-кызлар дәррәү эскерт тирәсен, кәрәсе-чыгасы юлларны көрәргә кереште, башкаларның ай-ваена куймыйча, өскә Зәбир менмәкче булды. Бояр Нурдидә өч җәпле үткер сәнәген бар көченә эскертнең боз бүксәсенә кадады, икенче сәнәкне эчкәрәк батырдылар, шушы баскычка баса-баса Зәбир сыңар кулы белән өскә үрелде, яралы кулын түшенә кысты, ниһаять, аралап, югары ниргәдәге көлтәгә ябышты. Бозланган көлтә арадан суырылып чыкмады, егетне чыдатты, хатыннар егеткә көч биреп, «һай» диеп акырдылар, Зәбир гәүдәсен селтәп, өскә ыргылды. Менеп баскач, аңа тимер көрәк ташладылар, ул тиз-тиз өсне кардан арчырга керешге.

— Колакчыныңны төшер ичмасам,— диделәр ана астан.

— Ничава! — Зәбирнең авызы колакта.— Түзәрлек!

Аның сыңар кул белән җайсыз селтәнүен, көрәк сабын корсагына терәп каерылганда кып-кызыл булып көчәнүен караштырып торган хатыннар түзмәделәр, ярдәмгә Рәмзияне меңгерергә булдылар.

— Арада иң җиңел сөяклебез син, очып кына мен,— диде Мәфтуха.

Зәбир көрәген сузып торды, хатыннар шаулап аны кул очына күтәрделәр, Рәмзия чырылдый-чырылдый очып китте, менеп житкәч башы әйләнде, чак тәкмәрләмәде, Зәбир көрәген ташлап, аның биленнән кочты.

— Карама аска! — диде йомшак кына.

Рәмзия исенә килеп, аның кочагыннан ычкынды, нәзек, матур кашлары җыерылды:

— Мин сине! — дип янады ул.

— Нишләтерсең? — диде мутланып Зәбир.

— Тәрттем төшердем булыр, ранный дип тормам.

Ашыгып эшләгәч, Зәбир бияләен тез арасына кыстырып, учлапучлап кар ашарга тотынды.

— Ашама, бетәрсең,— диде Рәмзия, олыларча кисәтеп.

— Солдатка кар куркынычмы, һәй.

— Син солдат түгел инде, безнең шикелле үк авыл кабартмасы.

Зәбирнең соры күзләрендә усал ут җемелдәвен Рәмзия үзе генә күреп калды, астагылар шаулаша башладылар.

— Ятрәк кыланыгыз, аякны таракан кытырдата.

— Утырмага килмәгән монда.

Зәбир белән Рәмзия тагын да җәһәтрәк көри башладылар, итекләре белән карны эшереп аска койдылар, типкәләп, таптап карадылар. Ниһаять, почмактан беренче ниргәне тузгыттылар.

«Ничек, ни хәлдә?» — дип, астагылар бер турга килеп сөрлекте. Зәбир белән Рәмзия манма тиргә төштеләр, икенче катны куптардылар, һаман тоташ яңгыр үткән иде, дүртенче ниргәгә хәтле эскертнең үзәгенә су төшкән булып чыкты. Башаклары гына түгел, саламына тикле бурсып, күгәреп тора иде. Хатыннар боектылар, Зәбир кычкырып ук җибәрде:

— Бетсенгә эшләнгән эш бу! Кем куйды бу эскертне?

Шактый бәхәсләшкәч, Нурдидә: «Имән урамының бәләкәй Хәйбери куйган эскерт булырга тиеш»,— диде.

— Итегенә олтан сала белмәгән ләчтә кабартмага эскерт тикле эскертне ышанганбыз икән,— диде әрнеп Мәфтуха.

— Белгечне күрше авылдан чакыртып булмады шул, вакыты шундый иде,— дип офтанышты хатыннар.

Тагын истәлекләр, тагын хәтергә төшерүләр китте...

— Кәрлә Садыйк куя иде ул эскертне, биш-алты егет көлтә атып торыр иде, үрепләр дә барыр иде менә, талдан кәрҗин үрәмени, шонның...

— Аны әйтәсеңме авызыңны кыеш-мыеш китереп, чат Карамның атасы Сөләймән картны хәтерлисезме икән, ун ел торсын эскертең, егерме ел, яңгыр суы каз өстеннән шыбырдагандай агып кына төшәр ие...

Зарлансаң, зарланмасаң бер авыз, моннан болай акыл булсын, дип, биш чананың бишесенә дә бозланган көлтәләрне төяделәр.

— Болар ни, аллага да ярамас, мулла да ошатмас, дигәндәй, чәчүгә бармас, хайван ашарлыгы да калмаган,— диде әрнеп Мәфтуха, үзенең әрәм булган өч пот онын хәтерләп.

— Кырда калдырып булмас, хөкүмәтнең тишек-тошыгы күптер, берәр җиргә ямауга үтәр әле,— диде бояр Нурдидә.

Төштән соң йөкчеләр үзләре генә киттеләр, калган хатыннар рига янындагы сушилка калайлары өстенә бозлы көлтәләрне тезеп, мичкә кабызып җибәрделәр. Икенче олау белән кайткач, Зәбир җылынырга дигән булып сушилкага керде, тик ачы соры төтен куелыгында Рәмзияне күрә алмады. Алар бер-берсенең тавышларын ишетеп, кычкырып сөйләшүләрендә ниндидер эчке мәгънә сизенеп, уңайсызланып тордылар.

Кышкы кысыр көн узып та китте. Кайтканда Зәбир иртәгедән дә ныграк ымсынып, көтеп торса да, Мәфтуха белән Рәмзия аңа утырмадылар, җәяү кайттылар, юл уңаенда кибеткә кагылдылар. Кибетче Зәйнәп, сыткылы битенә кат-кат алсу кершән яккан, урта яшьләрдәге, мул артлы хатын, калын түше белән буш прилавкага яткан да, аякларын шакы-шокы бер-берсенә бәреп, лач-лоч сагыз чәйни иде.

— «Барина»га биетәме?— диде Мәфтуха, сыкылы кибет почмакларына ишарәләп.

— Көен сайлатып тормый...

— Ни хәбәрләр ишетелә?— дип сорады Рәмзия.

Кибет уртасындагы түшәм терәү баганасына радио табасы эленгән иде, Зәйнәп кечкенә, майлы күзләре белән аңа карап алды.

— Әйбер-кара юк.

— Сөйләмиме?

— Сөйләштергәли.

— Безгә файдалы сүзләр ишетелмиме?

— Рәмзиянең Исламгәрәе белән Мәфтуханың Миңлебарие кайтыр дигәннәре юк. Сугышалар да сугышалар.

— Синеке исән-сау йөреп кайтсын, Зәйнәп,— диде Мәфтуха сабыр гына.

— Минем бүлтереккә ни булсын?

Хатыннар, рәнҗеп, урамга чыгып киттеләр.

— Тозсыз,— диде Мәфтуха ишек шартлап ябылуга.— Лесник Фәйзерахман белән типтерә башлаган, диләр. Бар икән агай, туймас тән дә булыр икән, кыз чагында ук килгән кунак егете Зәйнәп куеныннан чыкмады.

Ул бу сүзләрне җирәнеп, нәфрәт белән ачу катнаштырып сөйләде, Рәмзия уңайсызланып, озак кына дәшми барды. Мәфтуха кинәт ашыктыра башлады, сыер савасы бар, малайлар сугышып бетмәделәрме икән, җил күтәрелсә, өйнең коты калмас, мичкә дә якмый булмас, дип, туктаусыз сөйләнеп кайтты. Һич көтмәгәндә:

— Илай тәресе күзен синнән алмый,— дип кыстырды.

Рәмзия дә нәкъ шул турыда уйлап килә иде, гаеп өстендә тотылган кешедәй, ык итеп куйды.

Көндәлек кечке эшләрне караштырып, кош-кортларны барлап, сарыкларга ашлы сулар эчерткәч, аны тагын ялгызлык сагышы биләде. Ләкин бүген ул хискә эчкәрге куркыну, шөбһәләнү өстәлгән иде.

Башлап куйган оекбаш бар иде, шуңа тотынды, инәләре авыраеп, бармаклары бик тиз талдылар.

Бүгенге таңда ул үзенең яклаучысыз, ялгыз һәм көчсез икәнлегенә тагын бер кат төшенде, гомергә шулай булып калачагын исәпләп көяләнде, янды. Кемгә барып сугылсын былтыр гына чит авылдан килен булып төшкән Рәмзия? Йомышың төшсә дә, кайгың инсә дә, уртаклашырга бер Мәфтухаларга йөгерәсең. Тагын аларга барып керде.

Дүрт малай өстәлнең дүрт ягын сарып, дәрес әзерлиләр. Урталарында сыек кына яктылык сирпеп, бишле лампа яна. Рәмзия кергәч, малайлар чышын-пышын нидер сөйләшеп алдылар, ул аларга комачауламас өчен кече якка узды.

Мәфтуха ипи изә иде, беләкләрен сызганып ташлагач, кызарынып яшәреп киткән, кулларына күз иярми. Аны-моны сөйләшкәләп, вакыт кыскарттылар. Рәмзия, килеп кергәндәге төсле үк читенсенеп, кабылтибел генә саубуллашып, чыгып китте.

Капкасын бикләргә дә онытып өенә керде, озаккарак сузарга тырышып чишенде, урынга яткач, киерелде-сузылды, тиз генә йоклап китә алмады.

Җәяүле буран кузгалып тора иде, өе турындагы бер генә чыбыклы телефон баганасы сызланып-сызланып чожлады, ул, берни ишетмәс өчен, колакларын калын юрган белән томалады, берни күрмәс өчен чытырдатып күзләрен йомды. Җил көчәйгәннән-көчәйде, телефон чыбыгы тагын да ныграк гүләп, аның йокысыз уйларын бик еракларга алып китте...

Өе Мәфтуханыкыннан суыграк, түшәге сап-салкын иде. Шулай да үз өеңдә үз көең, дип уйланды ул... Өйдәш булып керсәң, җайлы яклары да бар, җайсыз яклары да җитәрлек... Мөгаен, кермәс Рәмзия. Язга тиклем түзәр, аннан төннәр кыскара... Күз күрер әле тагын... Шуңа да, кеше гомере, диләр ич аны...

## 2

**И**шекне кат-кат кактылар.

Рәмзия байтактан уянса да, торырга ашыкмады, гүя, ул күптән бу дөньяның ыгы-зыгыларын ташлап киткән кеше, бу шакылдатуда, ишек төбендәге җан иясендә аның бернинди эше, мазасы калмаган иде.

Тагын дөп-дөп итеп шакыдылар, ул айнып китте, төш кенәме әллә дигән сыман, маңгаен сыпырып карады, тавыш тагын кабатланды. Рәмзия бүген бер тамчы да курыкмады, ашыкмыйча гына ишек катыннан эзләп алып, киез катасын киде, иңенә бишмәтен салды, яулык бөркәнде.

— Кем йөри анда?

— Мин идем әле.

Шунда гына ул: «Капка ачык калганмы, әллә тагын?..» — дип уйлады.

— Кем ул — син? — Рәмзия үзе теләгәнгә караганда йомшаграк тавыш белән үз итеп сорады.

— Танымыйсыңмы әллә: койрыклы җен! — диде тавыш шат кына.

— Ю-ук, — диде ул, күптән таныса да.

— Зәбир мин, Зәбир, ач.

— Ач булсаң, туеп кил!

Аның ярым уенлап әйткән сүзе егетне дәртләндерде, бөтен гәүдәсе белән ишеккә ятып, тагын бер кат дөбердәп алды.

— Бусагаң янынннан борма, Рәмзия, — диде ул йомшак кына.

Хатын калтыранган куллары белән бастырыкны суырып алды, аны почмакка сөяде, келәне теге яктан Зәбир үзе күтәрде.

— Кара төндә нигә кеше куркытып йөрисең? — диде Рәмзия тачылдатып.

Егет һаман үзенчә аңлап, сүзне җинелчәгә борды:

— Көндезен чакыруың булдымы бусы?

— Көндез ичмасам кеше төсле керер идең, кара төндә бакча шүрәлесе күк аркылы-торкылы йөрмәс идең...

Егет караңгыда карманып, көлеп җибәрде:

— Көндез ярамый, язык була.

— Тол солдаткаларны чүпләргә керештеңме? — диде кинәт ярсып Рәмзия. — Муен тамырыңа берне тамызырмын!

Хатын юан бастырыкны элдереп караңгыга кизәнде, саллы күсәк егетнең кайсы төшенәдер тиеп китте.

— Чү, чү, Рәмзия, ипи шүрлеген җимермә, — диде ул җылы гына.

— Чыпчыклар көләр бит, чынкый уйласаң... Кеше-мазар күреп калса, гел юкка исемеңне сасытырлар... Кичә нишләп йөрдең тәрәз төбендә?

— Нишләп дип... Шакырга кыймадым...

— Бүгенгесе — соңгысы шушы, Зәбир абый, үпкәләштән булмасын, моннан болай keләмә кагылсаң, разбуй салып күршеләрне җыярмын, бел. Ир хатынын үлчәү табасына салырлык итмә, егет.

— Эх, — диде чын күңеленнән әрнеп Зәбир. — Мин бит кеше төсле бер сөйләшеп утырырга дип кенә килдем... Дөньяныкын белмәссең, әллә бар гомер, әллә юк гомер... Начарлык эзләсәм, башка капкаларны кагар идем, әрсез алабайга җим табыла!.. Үзләре авызга керәм дип торалар. Рәнҗетергә, кимсетергә сине сайлар идемме? Ни начарлыгыңны күрдем? Куйчы, Рәмзия, үз-үземә урын тапмаганга йөз суымны түгеп килэм ихатаңа... Киләм дә кайтып китәм... Бүген менә шакылдаттым, чыдарым калмады.

— Кирәкмәс, Зәбир абый, — диде йомшап Рәмзия. — Моннан болай йөрмә, берүк.

— Начарлыкта түгел уем, — дип, ышандырырга тырышты солдат.

— Кеше карбыз түгел, аны ярып карап булмый. Мин — ир хатыны.

Һәм ул күңеленең йомшап китүеннән куркып, тагын бастырыкны кулына тотты, егетне этеп диярлек болдырга чыгарды.

— Куасыңмы?

— Җитәр, Зәбир абый, артыгы кирәкми. Маемлатмасын.

— Хуш, алайса, — диде аптыраган Зәбир.

— Хуш, хуш.

Икенче көнне ригада Зәбир белән Рәмзия тагын очраштылар. Төндә очрашмаган да төсле сәлам алыштылар, егет бер-ике уен сүз әйтеп көлдерде, Рәмзия Зәбиргә карамаган да кебек иде, Мәфтуха соңыннан:

— Аның гына түгел, синең дә күзләр яна башлады, кызый. Капкаңа буяу якмасыннар, сагай, — диде.

Бу сүз Рәмзиягә бик авыр ишетелде, ул күрше апасының сизгерлегенә рәнҗеде. Чыннан да ир белән ай да унсигез генә көн торып калган тол солдатканың күңеленә нининдидер вәсвәсә, эзләнү, ризасызлык салып калдырган иде Зәбир төнлә... Әле монысын ят күзләр сизенеп алдылар, әгәр эш зурга китсә?..

Кичкә таба аның карары бер иде:

— Инде шундый шигең дә тугач, иртәгәдән сезгә күченәм, Мәфтуха апа! — диде ул.

Күршесе куанды:

— Бары — бергә, югы уртак булыр, Рәмзиякәй, ачкүзләнеп кагышып-сугышып тормабыз, икебез — ике тол, уртабызга җил кертмәсәк, бер җай алып яшәрбез, — диде. — Тик иртәгә күченмәссең, иртәгә чәршәмбе, җомга көн башлаган эшнең ахыры ару була, тагын бер тәүлеккә чыдарсың, иншалла.

Йолаларга исе китмәсә дә, Рәмзия бу юлы тиз ризалашты.

Чәршәмбе көн авыр узды, көлтәгә киткән атлылар, бата-чума кичкырын гына кайттылар, өзмәс җил, туктаусыз әче тотен кайтарып торганга сушилкадагы хатыннарның күзеннән елгадай яшь акты. Икенче юлга барып тормадылар, атлар да, йөкчеләр дә хәлдән тайган иде.

Авыл советыннан чыккан дежур урам буйлап йөрде, кемне урамда, кемне ишек алдында тотып алып, кайберәүләрнең өенә үк кереп, яңа хәбәрләр таратып чыкты:

— Ишетмәгән ишетсен, ишеткән күршесенә җиткерсен, ягъни, бүгенгесе кичтән, хәтерләп кала күр, бүгеннән, тәрәзәләрегез нык томаланган булсын. Саламнан юрган сырасызмы, иске-москы белән ябасызмы, анысы шәхсиян сезнең иректә, иллә мәгәр, кем йортыннан тычкан уты хәтле яктылык күренсә, ул дошман самолетларына хәбәр бирүче булып саналачак, ут иясе сугыш заманасы закуннары нигезендә каты җәзага тартылачак. Районнан шундый әмер килде, Авыл советының боерыгы шул, белеп торыгыз, ишетми калдык димәгез.

Рәмзия бу яңалыкка бик гаҗәпсенде, фронттан бик-бик еракта булган, таулар-урманнар артында утырган, кышын кар көртләре арасыннан морҗалары гына күренеп калган Югары авыл тәрәзәләрендәге чепи утның дошманга ни хаҗәте булсын? Кем белә аны Югары авылны? Әллә сугыш дигән афәт монда ук килеп җитәргә итенәме?..

Кулыннан эш төште хатынның, күченергә дип әйбер-караларын барлап, хәстәрләп йөргән җиреннән, барын ташлап өстәлгә таянып, байтак миңгерәүләнеп утырды.

Әнә ич, имеш-мимешләрне ничек мул тараталар, Мәскәү киткән икән, дип тә сөйләнделәр... Тәрәзәләрне капларга закон үзе куша, димәк, монысы хак, хәвеф артканнан-арта бара дигән сүз...

Пошынып, Мәфтухаларга керде.

— Нихәл итим икән? — дип киңәш сорады.

— Бүгенгә ут яндырып азапланмассың. Минем малайлар лапаста салам мата үрәләр. Иртәгәдән бездә буласың,— дип тынычландырды аны күршесе.

Ул, ут яктысы төшәр дип, кече учагына ут та кабызмады, салкын аш ашады. Итле токмач суык булса да, тәмле иде. Ятыр алдыннан гадәтенчә ишегалдына чыкты, абзар-кура тирәсен әйләнде. Буран һаман тынмады, бөтен дөнья, җир-күк тереклек сүнгән кебек дәһшәтле караңгылыкка чумган. Көндәгедән дә ныграк шомланган Рәмзиянең шушы буран белән котырынасы, түбә кыегыннан аска очасы, авылны, үзләрен кара язмышка дучар иткән фашист мәлгуньнәрне әллә ниләр эшләтәсе килде.

Мендәрен изеп такталагач кына, йокыга талды Рәмзия. Төшенә тәмуґтагы сумала казаннары, эссе таба ялатучы койрыклы җеннәр керде, шулар янында сельпо рәисе, кызыл танаулы өч иякле Мөхәммәтгали басып тора, имеш... Мөхәммәтгали симез йодырыгы белән Гитлерның башына алагаемга берне кундырды, аннан бер якка ямьсез сыйпалган чәченнән эләктереп алды. Сумала казанында әле батыра, әле калкыта... Казаннан чыкканда Гитлерның тешләре шакы-шокы киләләр, имеш...

Шак-шок...

Ул иң элек урам тәрәзәсенә барды. Телефон баганалары сыкрыйсыкрый сызланалар, буран әче, ачы тавышлар чыгарып, өй бүрәнәләрен төрле яктан капшый иде. «Әй, әйләнә кыл дилбегә»,— дип кабатлады Рәмзия, ярым саташып.

Тәрәзәгә тагын чирттеләр. «Авыл советынннандыр! Исламгәрәй турында хәбәр бардыр!» — дип уйлады ул кинәт айнып. Киез катасына кар тутыра-тутыра җилдә өшеп, калтырап утырган капка янына килде, шакучының кемлеген сорашмады, көч-хәл белән ачты, ургылып кергән җил чак кына аны бәреп екмады.

— Уяттыммы, Рәмзия?

— Ни кылануың инде бу, Зәбир абый? — диде ул бердән тузынып.— Ни мыскыллавың бу?

— Әйдә, керик,— диде Зәбир аны кызганып.— Туңасың.

— Кермәгән кая, керәбез! — диде ул ярсып. Үзе туңып, бөкшәеп, өйгә атлады, Зәбир аңа иярде. Кучкардан шырпы эзләп тапкач кына, бүген ут яндырырга ярамаганлыгы исенә төште. Кар яктысы белән сүрән

яктыртылган өйдә икәүдән-икәү генә караңгыда утыру читен иде читенен, нишләмәк кирәк, заманасы шул... Ул, ярдәм эзләгәндәй, аркасы белән мичкә килеп сөялде.

— Кызлар йөзек салабыз дигәннәр иде... Берсе юк... Урамнар тазартылмаган моржа кебек караңгы... Борчымам дигән идем... Башымны алып олагыр почмак юк...

— Нигә шуның үчен миннән аласың, Зәбир абый?

— Синең янга нигә килүемне беләсең... Күптән, яшь чактан ук... Тик ул чакта җүләр булынган...

— Исламгәрәйне яратып чыктым, Зәбир абый.

— Беләм... Ләкин, авылда булсам, кемгә тияр идең, анысын карар идек... Армиядә калдым.

— Бу хәсрәт сөйләшүнең беребезгә дә хаҗәте юк ләбаса! — дип өзгәләнде хатын, сердәше җылы мичтән җылы көч алып.

— Шул кадәрле үк күңелең катканмени?

— Мин — ир хатыны, Зәбир абый. Күрәчәгем шулдыр. Исән булса, бер кайтыр, кайтмый калса... Кайтмый калса...

— Кичер, Рәмзия.

Бусага яныннан кузгалырга да базмый торган олы гәүдәле егетнең тавышында шулкадәр наз, якынлык бар иде, Рәмзия чак кына кычкырып җылап җибәрмәде. Бер генә минутка аның күңелен икеле-микеле уйлар биләп торды да, хәтер дулкыннары өстенә ап-ачык булып Мәфтуханың кисәтүле сүзләре калыкты. Ул идәнгә шуып төшкән шәлен иелеп алды, салкын, коры тавыш белән:

— Башкача ярамый, Зәбир абый,— диде.

Шулай да егет кулын сузмыйча булдыра алмады, бармаклары Рәмзиянең яңагын эзләп тапты, сөйде, калтыравыклы тавыш белән:

— Кусаң да, кумасаң да, ниләр генә әйтсәң дә, барыбер син минем йөрәк түремдә... Сау бул, Рәмзия, кичер!.. — диде.

Аз үттеме вакыт, әллә шактый ук уздымы, тәшвишкә төшкән хатын анысын абайламады, нәкъ баягы кебек үк итеп тәрәзә чирттеләр. Тик бу юлы урамнан түгел, ишек алдыннан, ул ята торган караватъ янындагы тәрәзәгә кагылдылар. Рәмзия юрганына ныграк төренде, тавыш чыгармады, чиртү эре яңгыр шыбырдагандай кабатланды, тагын, тагын. Ул тәрәзәгә таба күтәрелә төшеп:

— Йөрмә, ачмыйм,— дип кычкырды.

Ул арада шакылдатучы ишеккә киткән булып чыкты, өйалды ишеген дөбердәтте, Рәмзия ачуына буылып, сикереп төште:

— Йөрмә дип бәбәгеңә бәреп әйткән бит инде, тагын ни кирәк сиңа, ачарбак?! — диде ул өй ишегеннән башын тыгып.

— Рәмзия,— диде ишек артындагы карлыккан тавыш.

— «Алла» дип ялынсаң да, юк, кит!

— Мин бит бу, ач тизрәк.

— Оят кирәк, ыштыр бит! — дип яман сукрана башлаган хатын, кинәт шып тукталды, өйалдына чыкты, тыңланды.

— Рәмзия, Рәмзия дим, бу мин, Исламгәрәй.

— Ах, яхшыдан яман туган көчек! — дип чәрелдәде хатын.— Авыл советына явит иткәнне теләдең ахры син, бүре?! Тимерчегә барып телең таптатып килдеңме? Мин сиңа тинтәк кәҗә бәтие түгел!

Үзе шулай дия-дия бастырыкны күтәрде, кабаланудан аягына төшерде, ухылдады. Ишек артындагы житү сакаллы, шинельгә төренгән сәер кешене күргәч, «әнекәчем» дип кычкырды, дөртләп артка тайчынды, арты белән ишекне терәде. Ишек биреште, көчле куллар аны эләктереп алдылар. Ул суган, тәмәке исе аңкып торган сакал арасыннан Исламгәрәйнең коры авызын көчкә эзләп тапты.

Ачык калган ишектән өйгә әрсез суык кереп тулган иде, Рәмзия дер-дер калтырады, тиз-тиз ут яндырды, үзенең күлмәкчән генә икәнен

күреп оялды, җәһәт-җәһәт өстенә киде, яулыгын чөйде. Шуннан соң гына, аркасын мичкә терәп, әрсез түземсезлек белән үзенә текәлеп торган ирен чишендерә башлады.

Исламгәрәй танымаслык үзгәргән иде.

Кара-соры таплы-таплы шинеленең итәге чачакланган, шинель астында юкарак кына гимнастерка, аның да терсәк төпләре каткат ямалган, муенына ураганын шарф димәссең, бозау муенчагы кебек шомарып, ялтырап беткән. Гимнастерка якасын ычкындырганда күкрәгендәге төк бөртекләре арасында кыймыл-кыймыл килеп йөргән җирән, эре бетләр күренде. Бер мизгелгә җирәнеп күзен йомды Рәмзия, аннан ирен кызганып, башы белән аның күкрәгенә капланды.

— Бетергәннәр икән, бетергәннәр сине!

— Монда кайтып җитә алгач, кая инде бетү!.. Унбер көн кайттым. Вокзал идәне белән вагон идәне булды урын... Бит юган юк...

— Ә Бөгелмәдән ничек?

— Караталлар спирт илтә барганнар... Алар Түбән авыл аша йөриләр икән... Шунда кадәр аларга утырдым, аннан җәяү...

— Ничек адашмадың?..

Ул аны этеп диярлек идән уртасына чыгарды, шүрлектән иске газет алды, аны идәнгә җәеп, иренең кием-салымнарын шунда ташлый барды. Кергәч тә ире идәнгә ташлаган шактый саллы капчыкны да шунда китереп куйды.

— Үрмәләп дигәндәй кайттым... Син мине кем дип белгән идең?

— Ә?

— Ачуланып, сүгеп ташладың ич.

— Ә-ә... Зәбир абый дип белдем.

Исламгәрәй чишенүдән туктады, хатынының кулын иңбашыннан этәреп куйды:

— Нинди Зәбир ул тагын?

— Бар бит, Илай Зәбире... Ул ранный булып кайтты.

— Шә-әп! — диде зәһәр генә чалшаеп Исламгәрәй. — Сезнең хәлләр монда әйбәт икән! Җылы өй, йомшак түшәк... Без анда ил-җир өчен кан-яшь коеп ятабыз, Илай төреләре монда кайтып солдаткаларны кымтырыкларга тотынган. Мужет син аны үзең дәшеп китергәнсеңдер, айгырны ярсытып әвәл бия кешни торган була!

— Ни сөйлисең син, Исламгәрәй? — Рәмзия коелып төште. — Ни хакың бар?

— Әйтәләр иде аны иптәшләр, катынга ышанма, диләр иде... «Без кан түгеп яткан чакта җанкайларны кемнәр ала икән кочакка?!» — дип җырлыйлар иде. Рас икән!..

Исламгәрәйнең кызарган кабаклы, эренле күзләрендә моңарчы ул бер чакта да күрмәгән ямьсез ут кабынды, ул куркынып иренең калак сөякләре шырайган арык тәненә, эре-эре кыеш кабыргаларына, искергән пужар пумаласыдай шыксыз, шакшы сакалына, ят сүзләренә шаккатып карап торды, өшепме, куркыппмы һаман калтыранды.

— Исламгәрәй, җаным, җитәр дим, телгәләмә бәгыремне! Хәләхвәл сорашу юк, тотындың ямьсезләнергә!.. Үле хәбәрең килгәнгә ни чаклы вакыт узды, ышанмасам да, кыйналдым... Ансатмы әллә! Инде үзең күзгә күренгәч, тагын да читенрәк.

Рәмзия бер җылады, бер көлде. Исламгәрәй «үле хәбәрең» дигәнне ишеткәч, хатынын ямьсез кабаландыра башлады:

— Килдемени?.. Кая аның язуы? Китер тизрәк!

Рәмзия ул язуны Исламгәрәйдән килеп калган дүрт хат белән бергә сандык төбенә үк салып куйган иде, актарып табып, шуларны алып бирде. Ире шатланып, сөенеп, күзен уйнатып шуңа ташланды, кәгазьләрне әүвәл кат-кат иснәде, юка кәгазьләр аның әрлән чокырыдай танау тишекләренә чак кереп китмәделәр...

— Әһә!.. «Батырларча үлде» дигән... Кая күмелгәне әйтелмәгән. «Батырларча»... Бусы яраган! «Үлде» дигән, мено моның белән килешеп булмас!.. Үлми торсын әле Исламгәрәй... Үләргә дураклар да җитәрлек анда... Камалышта калдырып чыгып киткәч, үлде дип уйлаганнардыр... Үлмәдек!.. Батальоннан сигезәү булса да чыктык... Алар бит безне ташлап киттеләр... Полк! Танклар, пушкалар чигенде... Үлми торсын әле Исламгәрәй!..

— Синең тамагың ачтыр?.. И-и, сорамый да торам... Караталларны үзең белән алып менәсең калган, чәй эчеп җылынып кунарлар иде.

— Менми торсыннар әле... Мин аларга үземнең Югары авылдан икәнлегемне әйтмәдем дә.

— Нигә, Исламгәрәй?

— Белмирәк торсыннар... Миндә бер исәп бар... Кая ниең әзер?

— Хәзер аш җылытам.

— Нинди җылытып тору, китер ятьрәк!

— Кабаланмасана. Башта юынып, тазарып ал, карачы бу тырнакларыңны, тәмамысы сабан төрәннәренә әйләнгәннәр.

— Үз кулым үземә, ятьрәк китер... Баш исән калгач, ярар! Әнә бит, үлде, дигәннәр... Штабы-ние белән безне сазлык арасында камалышта калдырып киттеләр бит, тәреләр!..

Ул коштабакны хатыны кулыннан тартып диярлек алды, ипи телемен ике-өчкә сындырып, өресе туңган шулпага салды, аннары коштабак читеннән голт-голт итеп чәйнәми-нитми генә йотарга кереште. Шакшы сакаллы, йотлыгып аш шопырдатучы солдат гаиләдә бердәнбер бала булып үскән, иркә һәм шактый тәрбияле Исламгәрәйгә бер дә охшамаган иде.

Рәмзия аның алдына пар күгәрчен чигелгән сөлге китереп салды, Исламгәрәй өстәлдә бер сынык икмәк калдырмады, сөяк кимекләренә тиклем чәйнәкләп, йотып бетерде. Чиста сөлгегә өреле сакалын сөртте, аннан учларын тезенә ышкыды, көчләп диярлек Рәмзияне тезенә утыртты, үбәргә үрелде.

— Кабаланма,— диде хатын ишетелер-ишетелмәс кенә.— Юынып, тазарып ал башта.

— Юк,— диде аяусызланып Исламгәрәй. Аның каткан тырнаклары, йонлы сыртлы бармаклары хатынның тәнен рәнҗетеп күкрәк, бил тирәләрендә буталыштылар.

— Йә инде, ошамаганны кыланма!

Ул аның келәшчә кебек кочагыннан көчкә ычкынды, ире тоткалаган тулы күкрәкләре әрнеп сызладылар.

— Әһә, теләмисеңме? Илай Зәбирләре окоп солдатларыннан чистаракмы?

— Тиле,— диде ул чак җыламыйча түзеп,— хәзер су җылына.

Юындырганда ул ирен тагын да җентекләбрәк карады, кендектән түбәнрәк, корсакның уң ягында тулышып торган ике башлы зәңгәрсу чуанны, купшакланып-купшакланып аерылып чыккан көрәнсу тән тиресен күргәч, үксеп җылап җибәрде:

— Бетергәннәр сине, Исламгәрәй!

— Бетерми торсыннар,— дип мырлады җилкәсен комган астына куйган ире.— Юк! Болай булгач юк инде...

— Сал... ыштаныңны да...

Рәмзия аның бар кием-салымын җыештырып өйалды почмагына суыкка чыгарып ташлады.

— Иртәгә эссе мунчада барын өтеләрбез. Исламгәрәй, син озаккамы?

— Озатасың да киләме әллә?

— Авызыңнан җил алсын.

Исламгәрәй идәндә күлләвекләр ясап, балалар төсле су чәчеп, мырлый-мырлый юынды.

— Өебез бераз суыграк, утынны җәлләп ягам. Нигә кайтасыңны алданрак хәбәр итмәдең? — диде хафаланып Рәмзия.— Мунчалар ягып, әзерләнеп торыр идем... Ай, аллам, Мәфтуха апаның исе китәр инде!

— Ай, рәхәт... Арканы тагын бер ышкы әле. Шәп, шәп... Астанрак, өстәрәк, менә-менә, оясы шунда!.. Хәбәр итәргә җае булды ди сиңа!.. Менә, менә рәхәтнең оясы шунда!

Аларның кызу эшләрен бүлеп, ишек дөбердәде.

Шәрәтән Исламгәрәй, җыланга баскан кебек, мич арасына сикерде.

— Кем ул?

Аның куркуын күреп, агарынган Рәмзия:

— Кем булса да барыбер түгелмени? — диде.

— Ярты төн бит!.. Бар әле, ач, карыйк әле янына кем йөрүен! Без кан эчендә йөзгәндә өйдә тәкәләр үрчеттегезме?!

— Ачам,— диде җиңеләеп Рәмзия.— Үзең күрерсең!

— Тукта!

— Тагын ни бар?

— Ачма! Килгән юлына китәр! Олаксын!

— Ярамас. Син әллә ни уйларсың...

Ишекне нык-нык дөбердәттеләр.

— Шайтан,— дип сүгенде Исламгәрәй.— Чык инде, җай табып озат үзен. Минем кайту турында ләм-мим... Телең тешләнгән булсын, бел аны!

— Нигә? — диде бик аптырап Рәмзия.

— Анысы... хәрби сер!..

— Кайтуың да сер түгелдер инде? Анысын халыктан ничек яшермәк кирәк?

— Соңыннан, соңыннан! Ишекне җимерәме, тинтәк... Анасын!! Бар олактыр шул ач тараканны...

Рәмзия аптырап, өй эчен караштырды, кулына эләккән яулык, чүпрәк-чапракларны тастагы суга ыргытты, өйалдына чыкты, каушап, тотлыгып:

— Кайсыгыз йөри анда? — дип сорады.

— Нишләп ишек тә ачмый торасың? — диде яман чәрелдек тавыш.

— Җил гөҗли бит, ишетмәдем.

— Закун бозып ут кабызырга кем кушты? Өйдә, хәзер үк советка төш! Биш йөз штрафыңны каерсыннар әле. Кага-кага катып беттем! Әллә үз теләгемнән йөримме, закун йөртә!

— Гөлбикә апакаем,— диде каударланып Рәмзия.— Бөтенләй онытып җибәргәнмен, хәзер сүндерәм... җебетергә керләр салган идем.

Ул өстәлдә утырган лампаны алып, тиз-тиз уфылдап сүндерде.

— Җиде төн уртасында нинди кер ул? — диде Гөлбикә тыңланып.

— Йокым качты бит, апакаем...

— Шулай анысы, шулай,— диде борынын лыштырдатып дежурный хатын.— Тик онытмыйча тәрәзәләреңне хәзердән томала. Күрсәләр, икебезгә дә ару булмас, закун каты.

Ул Гөлбикәгә ияреп, капкага кадәр килде, ишекләрне җентекләп бикләде, өйгә кергәч, һушын җыя алмыйча беркавым басып торды. Күлләвекләрне лычтырдатып, аның янына Исламгәрәй чыкты.

— Рәмзия!

— Уф, котны алдың...

— Алдашырга өйрәнгән син!..

Тышта буран котырганнан котырынды, өйнең соңгы җылысын алып бетерде, телефон баганалары бер-берсен сагынышып җылаштылар. Рәмзия үз аяклары янында Исламгәрәйнең йонлач ботларын, сыйракларын сизеп чирканып, ятсынып ятты. Аңа бик җайсыз, рәхәт түгел, чамадан тыш кыен иде... Аның кичәге кебек ялгыз каласы, әнә шул ятим телефон баганаларына кушылып, үксеп-үксеп җылыйсы килде. Исламгәрәйнең назы аяусыз, иркәләве тупас, куллары чалгы янавычы сыман кытыршы иде, тимер богау кебек каты.

## 3

Төнлә Исламгәрәйнең эче авыртты, ул, авыр ыңгырашып, уңгасулга тәгәрәде, кочагына Рәмзияне алгач кына, аз-маз тынычлангандай булды.

Рәмзия караңгылы-яктылыда уянды, иренең бер якка ауган каты чәчләрен, төнлә киезләнгән каты-чәнчүле сакалын сыйпап-сыйпап карады. Битенә ялгыш кагылып китүдән Исламгәрәй чәчрәп уянды:

— Ә? Нәрсә бар? Кем?..

— Йокла, йокла!..

Рәмзия торып җыештырына башлады, су җылытып, тиз-тиз идәнне юып чыгарды. Исламгәрәй юрган астыннан күзен елтыратып, аны күзәтеп ятты.

— Рәмзия!

— Торасыңмы әллә?

— Сөйләшеп алыйк... Кил, яныма ят.

Ул ятмады, сагаеп кына ире кырыена караватка утырды.

— Без камалышта калган идек, окружениедә, аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм.

— Аңлыйсың, пычагым! — диде кинәт кызып Исламгәрәй. — Аны күрмәгән кеше аңламый да... Бөтен ягыңда кораллы немецлар! Танклар уза, самолетлар үкереп оча... Күктә дә, җир астында да сиңа котылмак юк... Коры мылтыгыңны кочаклап, тәбедәге тычкан кебек миең түнеп ятасың... Ни ашарга, ни эчәргә... Берни юк... Сине бөтен армия, командирлар, полклар ташлап чигенгәннәр. — Тәүлекләр буе баш калкыта алмый ятасың да ятасың.

Ул бераз гына сынап, чекерәеп карап торды.

— Без менә шундый җәһәннәмнән сугыша-сугыша үз ягыбызга чыктык. Яхшы ата балалары чебен күк кырылып калды... Чыккач медаль бирделәр... Капчыкта ул, әнә, калай тартмада... Вагон идәнендә аунаганда түшемә тагарга оялдым. «Батырлык өчен» дип атала... Шуннан унбиш көнгә ял бирделәр...

— Син өйдә унбиш кенә көн торасыңмени?

— Белдең, — диде авызын чалшайтып Исламгәрәй. — Унбер көне юлда узды инде аның...

— Алайса...

Ире аңа сөйләргә ирек бирмәде, учы белән һаваны ярып туктатты:

— Дүрт көннән мин Урал ягында булырга тиеш. Безнең частьны шунда җыячаклар.

— Исламгәрәй, — диде ул тагын җыламсырап. — Нигә моны кешегә әйтергә ярамасын? Батыр башың белән ил күзеннән качып ятмассың бит инде...

— Моңа кадәргесен сөйләргә була, — диде Исламгәрәй түшәмгә карап. — Менә моннан ары нишләргә?..

Рәмзия хәтеренә төшерде:

— Сакал кыра торган пәкеңне онытып киткән идең. Кайтырыңа булган икән, алып биримме?

— Кирәк түгел, — диде Исламгәрәй, ияк астын кашып.

— Урыс пубы төсле йон җилбердәтеп йөрмәссең инде.

— Тимә, торсын.

— Болай адәм танырлык җирең дә калмаган бит.

— Танымасалар, кыз ярәшергә барасым юк... Шуны колагыңа киртлә, моннан болай сиңа да, миңа да телне тыярга өйрәнергә булыр. Хәтәр заманага эләктек!

— Нишләргә уйлыйсың соң, Исламгәрәй?

Ул арада көн тәмам яктырды, ишек алдында көчле шау-шу ишетелде, кемнәрдер ур-ра кычкырып, ишеккә ташландылар. Исламгәрәй яткан җирендә ап-ак агарынып, телсез калды.

— Нинди тиләләр анда? Нардуган түгелдер бит?
— Белгән юк,— диде Рәмзия, ишекне ачып.
— Рәмзия апа! — дип кычкырдылар малайлар ишек тавышын ишетеп.— Безне әни җибәрде. Күчерешергә кердек. Ач!
— Әй, ходаем,— диде хатын аптырап.— Йоклап калганмын бит... Менә әкәмәт! Балакайлар, мин әле юньләп киенмәгән дә. Җитешкәч, үзем дәшәрмен. Әниегезгә рәхмәт дигез.
Рәмзиянең Мәфтухаларга күченергә тиешлеген белгәч, Исламгәрәй пыр туздырды:
— Нинди акылсызлык бу?! Ниндиен йорт-җиреңне ташлап, чегән сыман күченеп йөр тагын! — дип җикеренде.
— Ни эшләргә кушасың соң, Исламгәрәй? Үзең ни кылырга уйлыйсың? Син ир кеше, сүзеңне әйт... Мин берни дә аңламыйм, башым катты, әйт бер сүз!..
— Мине шул юлдан җәһәннәмгә тагын чыгарып җибәрер идеңме әллә?! — диде кинәт Исламгәрәй.
— Ир башы белән ат башы күрә, дигәннәр...
Рәмзия иренә күзен күтәреп карарга да базмады, ни әйтсә дә, Исламгәрәйгә авыр ишетелер, рәнҗеше төшәр дип курыкты. Шул ук вакытта иренең күзендә елтыраган зәһәр утлар аны тагын да ныграк борчыдылар, Исламгәрәйнең тел төбендә әле ачыкланып бетмәгән әшәке бер ният, усаллык ята кебек тоелды.
— Тездән кан эченә чыгып китеп, шунда башым олакса, сиңа җайлырак булырмы?.. Берсе китсә, әнә, икенчесе искәнеп йөри бит!
— Исламгәрәй! — дип кычкырды ул бар көченә.
— Акырма! Ишетерләр!..
— Теләгәнеңне эшлә,— диде ул ишетелер-ишетелмәс.
Исламгәрәйнең каны качкан иреннәрендә елмаюга охшаган нәрсә күренде.
— Менә ярар,— диде ул канәгатьлек белән.— Иң әүвәл, Мәфтуха апаларга кереп, аны көйләп чык, соңыннан күз күрер. Авызыңны чамалап ач!..
Мәфтуха пыр-пыр килеп ишекле-түрле өй җыештырып йөри иде. Рәмзия, бишмәт төймәләрен ычкындырып, суык бусагага утырды. Башында гаҗәп чуалчык, сүрән уйлар кайнады...
Моңарчы Мәфтуха аның таянычы, киңәшчесе, иң якын кешесе булып килде. Бер көндә ирләрен сугышка озаттылар, сентябрьнең уртасында икесе дә бер атна эчендә тол калдылар. Мәфтуха — дүшәмбе көнне, Рәмзия — җомгада... Тормышлары да, көнкүрешләре дә, кайгылары да, серләре дә уртак иде. Уртак иде, икесенә дә җиңелрәк иде.
Рәмзия киң күңелле киңәшчесен читкә тибәрергә, бергә үрелеп барган юлны кырт кисеп, икегә аерырга керде.
Уңга китсәң — уңарсың, сулга китсәң — туңарсың...
Кайда уң, кайда сул — беркемнән сорап булмый...
— Ни бар? Чирләмисеңдер лә? — диде аның мыштымлыгына игътибар биреп Мәфтуха.
— Янбашлар сызлаштыра.
— Гөнаһ шомлыгы, авыр күтәреп эшлисең бит.
— Баш та әйләнеп тора...
— Өшегән миләш кертимме? Күңелне ачып җибәрә.
— Ис тидердем, ахры...
Мәфтуха аңа ышанмыйча карады.
— Нигә малайларны бордың, озатасы кешең бар идеме әллә?
— Сөйләп тә куясың кайчак,— диде Рәмзия, коты чыгып.
— Төн уртасында ут яндырып, пәри туе ясаганыңны күрмәделәр дисеңме?.. Ак сарыгымның җилене тулган, шуны карарга чыксам, келпеткәнсең... Кереп чыкмакчы идем дә, таракан буласым килмәде.
Рәмзиянең эче жу-у итеп китте.

— Бәрәнләдеме соң?
— Күрәсең бит, юк.
— Мин мунча сорарга кергән идем, Мәфтуха апа,— диде ул, ниһаять, актык көчен җыеп.
— Турысын әйт, Рәмзия,— диде Мәфтуха яратмыйча.— Өйдәш булмаска уйладым диген.
— Ни әйтсәм дә, аптырадым инде.
— Ертылмаган җирне ямап маташма, аңлыйм.
— Әнә, шушы айда гына ничә хатынны марига урман кисәргә җибәрделәр бит, Мәфтуха апа. Окопка да хатын-кызны кыдырып алалар. Әгәр дә мәгәр сезгә күченеп яши башласам: «Өең аулак, карар кешең юк»,— дип, окопка озатсалар?.. Фатих кызы өч атна гына булып кайтты, әллә нинди яман чир эләктергән, диләр... Үтә хәтәр ди анда хәлләр!.. Бер башым яшәп ятсам, тереклегемнән аерып җибәрмәсләр дип тә уйлыйм.
Башта тырт-пырт торган Мәфтуха, аның бу сүзләреннән акыл табып, тиз үк ризалашты:
— Анысы бар икән әле, гөнаһ шомлыгы. Каян башыңа килде диген? Минем гомергә уйлап табасым юк, мөгезсез сыер күк окобына да чыгып китәр идем. Бер эләккәч, котылырсың аннан. Дус, дошманыңа ходай күрсәтмәсен. Ярар, дөнья үзе өйрәтер әле, чәй эчик тә ятрәк төшик.
— Бүгенгә өйдә калсаммы әллә дигән идем.
— Ялкау тамырың бүрттеме?
— Белмим инде, белмим.
— Мунча яксаң, бездән дә утын ал.
Ишек ябылгач та, Исламгәрәй мич арасыннан чыкмый торды.
— Капканы бикләдеңме?— диде ул кырыс кына.
— Көпә-көндез бикләнеп утырырга, әллә син, хәзер үк шиккә төшәрләр!
— Дөнья ул, Рәмзия...
— Булмас, Исламгәрәй, болай яшәп булмас!..
— Тагын мәетләр белән уралып ятырга чыгып кит, дисеңме? Бет симертергә! Үлгән атларның кабыргасын кимерергә?!
— Ил бар, көн бар!.. Халык бар!..
— Халык?.. Миңа мылтык биреп, шушында кал, сакла, диделәр. Немец урап алганда кайда иде халкың? Кайда иде илең?.. Ат тоягы эзеннән эчкән сулар!.. Теш белән чәнечкеле тимер чыбыкны кимерә идек!..
— Әллә мин әйтәм, Мәфтуха апага серне ачыйкмы?
— Тиле!— дип, көлемсерәде Исламгәрәй.— Ул хатынның болай да күзе очлы, теле — без. Мине бетертәсең киләме?..
— Болай яшәп булмас!— дип ычкындырды Рәмзия кинәт.
— Әллә мине гомерлеккә кайткан дип беләсеңме? Менә язга хәтле генә түзим, фронтка үзем чыгып китәм!.. «Батырлык өчен» медален миңа юкка гына бирмәделәр... Сугыш озакка барачак әле ул, көчле ул немец, бик көчле... Кышны гына, салкыннарны гына уздырыйм инде!..
Иртәнге төче коймактан соң, Рәмзия мунча якты, Исламгәрәйнең керләрен нығытып кыздырды, төннекне ачык тотып, кабалана-кабалана аларны юып, киптереп алды.
Мәфтуха эштән кайтканда Рәмзия мунчаны күптән булдырган, үзе юынып чыгып, малайларга, «җыйнаулашып барыгыз», дип әйтеп калдырган иде. Мәфтуха мунча хәлен белешергә үзе барды, чүмеч белән ташка су салды, борылып чыкканда бусага янындагы ярыкка кысылган ялтыравык әйбергә күзе төште. Иелеп алды — кулында солдат киеменнән өзелгән йолдызлы төймә иде. Ул, төймәне өенә алып кайтып, малайларга күрсәтте:
— Бу нәрсәне кайсыгыз төшереп калдырды?— диде.
— Без түгел,— диделәр малайлар.
— Миңа бир, әни,— диде бәләкәй Мәрдән.

Мәфтуха кече як сәкесенә утырып, шактый уйланды... Төнлә Рәмзия тәрәзәсендә уйнаган шикле күләгәләр хәтерендә иде. Өченче төн дә Илай Зәбиренең кар шыгырдата-шыгырдата турларыннан узганын күреп калган иде...

Бераздан ул балалар янына чыкты, авыр сулап, һәм кисәтеп:

— Рәмзия апагыз янына кереп йөрисе булмагыз! — диде.

...Рәмзиянең көне пешеренеп узды, казанда ит кайнады, самавыр туктаусыз җырлады, тик өй эчендә тып-тын, бәйрәмнән бигрәк, мәет күмүне хәтерләткән күңелсез тынлык, бушлык иде.

Кич белән чиста күлмәк-ыштан кигән, аруланган Исламгәрәйне кочаклап, Рәмзия бик озак җылады.

— Нигә кеше төсле генә кайтмадың? — диде ул кат-кат.

Исламгәрәй хатынын түгел, тышта улаган җил тавышын, тәрәзәләргә ябылган салам маталарның кыштырдавын ныграк тыңлый иде, тешен ыржайтып, көлеп кенә куйды.

## 4

Барган көнне барды эшкә Рәмзия, бармаган көнне юк. Мәфтуха да, малайлар да бимазалап кереп йөрмәделәр. Зәбир дә шул кичтән соң кагылмады. Исламгәрәйнең кочагында яралы аккош төсле тырпылдап яткан чакларында яшь хатынның сызланган күңеле әллә ниләр теләп бетерә иде. Өсләренә Мәфтуха килеп керсен, дип, уенда ялвара иде ул, кара төн уртасында тәрәзәне Зәбир шакысын, дип, өзгәләнә иде. Ичмасам, шушы билгесезлек, шушы ялган яшәү кырт киселер иде, азга гына булса да онытылып торыр иде. Исламгәрәй үзе дә Рәмзиянең хәлен күреп, ярсуларын аңлый кебек иде.

— Кар киткәнне дә көтә алмам, китәрмен мин! — дип, көн саен диярлек кабатлап торды. Ләкин көннәр гаҗәп акрын үттеләр... Үз хәлен кешеләрдән яшерер өчен Рәмзия мең төрле хәйлә уйлап бетерде. Исламгәрәйгә ярау гаҗәп читен иде. Берәр сүз әйтә башласаң, ул йә теләнә ни теләсә, шуны әйтеп сүгенә, йә булмаса, сабый балалар кук үкереп җыларга тотына.

Бер көнне, тотты да:

— Болай ит син,— диде.— Миңа аракы алып кайт.

— Син эчми идең бит,— диде Рәмзия, аның тәкъдимен ошатмыйча.

— Эчми идем, эчәрмен.

— Ничек итеп, кемгә дип алып кайтыйм?

— Кемгә аласың дип сорашып торганнар иде ди!

— Ил-күз бит ул, Исламгәрәй. Карт-коры бар, хатын башым белән аракы аламмы... Җитмәсә, тол башым белән...

— Сорасалар, даруга кирәк диярсең.

— Бармыйм да, йөрмим дә.

— Үләргә юлга чыгарга ята торган солдатның шул бәләкәй генә гозерен дә тыңламыйсың инде?.. Изәсең?.. Яхшы-ы... Илай мөртәтенә, мөгаен, алган булыр идең, ә?

Рәмзиянең икеләнүен күреп, ул үзенчә үгет бирде:

— Түбән авылга төшеп ал. Анда сине карап тормаслар.

Хатын бәләкәй төенчеген тотып, урта юлга да җитмәде, артыннан бастырып атлы куып җитте. Караса — Зәбир, бер үзе утырган. Көн артык суык булмаса да җилле, хәтта Зәбир бүрек колакчынын төшереп бәйләгән, бу үзгәреш аңа басынкы, юаш кеше кыяфәте керткән. Егетнең өстендә фил колагы дәүмәлеге якалы толып-чикмән.

— Утыр, әйдә,— диде ул, чикмән итәген кайтарып.

Рәмзия үрәчәгә тезләнде.

— Рәхмәт.

— Җил каршыдан исә, өшерсең. Мондарак кил.

— Мин монда. Түбән авылга гына...
— Э-э-э...
— Вак-төяк йомышлар бар иде.
— Әллә мин барасын ишетеп, юлга чыктыңмы дип торам!
Зәбир ак, таза тешләрен күрсәтеп, көлеп җибәрде.
— Түбән авылда, дим... Кибетләренә дә кагылырмын, димен...
— Менә моннан соң «алла юк» дип әйтеп кара!.. Күземә күренәсең дип торам, Рәмзия.
— Тол кешенең шул инде, бөтенесенә үзе чаба...
Сөйләшәсе дә килми иде Рәмзиянең, авыз йомып барырга да уңайсыз.
— Үзеңнең кая барыш болай, Зәбир абый?
— Безнеке билгеле инде,— диде Зәбир каядыр еракка карап.— Военкоматка барам. Әнә ич, ыжгырып килә немец. Ачы сызгыртып куа башлаганчы, барып җитәргә кирәк.
— Ә кулың?
— Кул кычыта!.. Үтереп кычыта... Бармаклар чак-чак кыймылдый башлады.
— Алмасалар, әллә доброволь китәсеңме?
Зәбирнең соңгы сүзләре мактанган сыман яңгырады:
— Нигә китмәскә?.. Китәргә исәп... Менә син бара торган Түбән авылның Сәйфелмөлекне беләсеңдер инде, заманында председатель дә булып йөрде, кызыл төпле ыштан кигән агач комиссар!.. Шул комиссиягә каралырга тәмәке суы эчеп бара, ди. Йөрәге начар дип калдыралар икән тегене. Шул Сәйфелмөлекләр белән бер юлда йөрергә хурсынам... Хатын итәгенә ябышып ятучылар бер ул гынамы?.. Ә фашистны кем тукмап җибәрер? Илне кем арулар?.. Ерткыч бит ул, ерткычтан да әшәке. Язып баралар ич, аңлатып баралар... Җылап калыр кешем юк, бала-чагам муеныма тагылмаган, сөйгән ярлардан бәхет булмады... Мин барып җиткәләгәнче кул үз урынына утырыр әле! На-а...
Аларның кабаланмавын сизенгән ат аякларын санап кына атлый иде, Зәбирнең төксе тавышын ишеткәч, арт санын сикертеп, бер-ике мәртәбә лырт-лырт юыртып алды.
Рәмзия егеткә күтәрелеп-сынап карады. Зәбирнең бер дә шапырынып бармавын аермачык күрде. Күзләре уйчан-моңсу егетнең, маңгай җыерылган, иреннәре кысылып-кысылып китә. Рәмзия шәл яулыгын чишеп җибәреп, аның янына чикмән итәгенә утырды.
— Сине ала күрсеннәр берүк,— диде ул кинәт чын күңеленнән.— Тик исән-аман йөреп кайт. Ходаем, медаленне елык-елык ялтыратып, дөп-дөп басып, түшең киереп Югары очтан Түбән очка шаее биш кат ура! Якты көндә, көндез ура! Бөтенесе күрсен... «Илай Зәбире кайткан»,— дип, районн гөж килсен!
Зәбир аның күзендә яшь күреп сәерсенде...
Авылга җитәрәк Рәмзия атны туктатырга кушты.
— Төшәсеңме?— диде Зәбир моңсу гына.
— Шушында калыйм инде, Зәбир абый.
Кырда җәяүле буран себерелә, Рәмзия чана юлына төшкәч, ат, хуҗасының сүзсез ихтыярына буйсынып, байтак кына кузгалмыйча торды.
— Сау бул алайса, Рәмзия.
— Исән-сау йөри күр, Зәбир абый, юлың уңсын!
Зәбир иркәләп кенә дилбегәне какты:
— На-а, малкай!
Рәмзия атлының урамга кереп күмелгәнен көтеп торды, шуннан соң гына буталчык адымнар белән атлап китте, бераз баргач, кибет ягына — уңга борылды. Бәхетенә каршы, кибет ачык, кеше-кара юк диярлек иде. Ул ике шешә аракы алды, аларны, кешегә сизелмәслек итеп чүпрәккә

төрде, билгән бабай тоткан кеше кебек, чайкала-чайкала, алдына-артына карамыйча Югары авылга кайтып китте.

Зәбирнең чана эзе күмелеп бетмәгән иде. Ул юл буе шул эзләргә карап уйланды... Исламгәрәй сүзләре белән Зәбирнең сөйләшүен чагыштырып карады...

Ире, ул көткәнчә, аракыга комсызланып ташланмады, башта бөтенләй чит нәрсәләр турында сорашты.

— Юлларда кеше күпме?

— Юк диярлек...

— Кая олакканнар алар, кешеләр, дим?

— Кыш бит, басуда суык кына, җиле үзәккә үтәрлек...— Ул җилнең көче, әрсезлеге, уйсу җиргә кар ташуы турында озаклап сөйләде.

— Кар байтакмы?

— Яуган болай, кашлак җирләрдә дә калын гына күренә.

— Авыл тирәләрендә милиция-мазар күзеңә чалынмагандыр?

— Юк алай. Нигә боларны сорашасың? Исламгәрәй, нигә сорашасың?

— Тәк кенә.

— Ак-кара күренмәде, йөгердем дә йөгердем.

Шуннан соң гына Исламгәрәй төенчекне чиште, шешәләрне алды, язуларын укыды, парланган пыяланы чалбарына ышкыды. Аннары эрезре итеп ике суган турады, калын-калын итеп ипи кисте, шешәнең берсен ачып, кырлы стаканга мөлдерәмә аракы салды. Бәләкәйрәк чәй йомырысы сайлап алып, аңа эчемлек койды, йомырыны Рәмзиягә таба этәрде.

Салам маталар белән тоташ томаланган тәрәзәләрдән сыек яктылык керәп тора. Маталарын көндез дә кузгатып тормый хәзер Рәмзия...

— Мә, эч.

— Эчте, ди, язмаганны.

— Син эчмәсәң, мин дә тотмыйм,— диде Исламгәрәй тискәреләнеп.

Ире шулай каты сөйләшкәч, ул эчми булдыра алмады, йөткерепбуылып сап-салкын аракысын чөмереп бетерде. Исламгәрәй аннан тизрәк исерде, куллары калтыранды, теле көрмәкләнде.

— Бетерде Рәчәйне немец,— диде ул күз яшьләрен агызып.— Яшәмәк юк хәзер безгә! Үлгән үлеп калыр, исәннәргә дә көн булмас!

— Ил бик зур бит, Исламгәрәй,— дип Рәмзия йомшак кына каршы төшеп маташса да, ныклап ук карышырга батырчылыгы җитмәде.

— Китәм! — диде Исламгәрәй өстәлгә йодырыгы белән сугып.— Сугышка чыгып китәм. Сал аракысын, әллә кайтып була яңадан, әллә юк, бәхилләшик!.. Туп-туры утның эченә илтеп тыгалар инде мине... О-ой, ул немец танкларының үкереп килүе!..

— Җибәрмим,— дип чырылдады кинәт Рәмзия.— Үз янымда тотармын!.. Баз казырбыз, такта җәярбез, шунда качып яшәрсең... Ничек тә саклап калырмын...

Исламгәрәй сиздермичә генә аның йомырысына аракы өстәде, эчми эчкән Рәмзиянең башы шаулады, чигәләре сулкылдап торды, ул уфылдап өстәлгә капланды:

— Җибәрмим, Исламгәрәй, җибәрмим! — дип үкседе.

— Куйчы, язмаганны,— диде Исламгәрәй киреләнеп.— Китәм дигәч китәм!

Үзе туктаусыз сугышта күргәннәрен сөйләде, мәетләр аша атлап йөри идек, диде, елгалар тулып адәм каны акты, диде, камалышта чакта әрекмән тамыры кимереп, аңкаулар шешеп бетте, диде.

Төнне алар тыныч диярлек уздырдылар. Рәмзия кече яктагы баз капкачын ачып куйды, лампа тотып идән астына төште. Бәрәңгеләрнең бер якка өелгән булуын күрде. Исламгәрәй баз чокырын тирәнәйтеп, бер якка ләхет кебек урын да көйләп куйган, аны калын, киң такта белән ябыла торган да иткән. Рәмзия өйдә юк чакларда эшләгәндер, мөгаен...

Баздан бик аптырап менсә дә, Рәмзия иренә аны-моны әйтмәде, дәшми-тынмый эшкә чыгып китте. Көз көне, озакка сузылган яңгырларда, хатын-кыз ашык-пошык кая эләкте, шунда куйган эскертләрне тизрәк казып чыгарып, игеннәрне сугып бетерәсе бар иде.

Өйдә читен, эштә, иптәшләре арасында тагын да кыенрак иде. Атлаган саен ялганларга, һәр сүзне үлчәп, чамалап ычкындырырга туры килә иде.

Исламгәрәйне базда асрау көннән-көн авырая барды...

Рәмзиянең һушын алган бер яңалык булып алды. Ике дус кыз — авылның фельдшеры Сәкинә белән быел гына укытучылар институтын бетереп эшкә килгән Зоя Лобкова үзләре теләп, армиягә китәргә язылганнар икән, гөрләп-җылашып шуларны озаттылар.

Зояны якыннан белмәсә дә, Сәкинә белән бер мәктәптә укыдылар, хәзер очрашканда да тәмләп сөйләшкәлиләр иде. Йомшак табигатьле, басынкы, уенга-җырга оста җыйнак гәүдәле бу кыз сугыш арасына ничек барып керер икән? Исламгәрәйнең котын алган танкларга, самолетларга каршы көрәштә Сәкинәләр, Зоялар ни майтара алырлар?

Аны тетрәткән икенче яңалык — немецләрнең Мәскәү янында тармар ителүе булды. Ригага төшкән агитатор Мәшфиканың сүзләрен ул бар хатыннардан да йотылыбрак тыңлап, кат-кат сораулар бирде. Һәм, ни өчендер, бу соңгы хәбәрләрне Исламгәрәйгә җиткермәде.

Чатнама суык төннәр...

Төн урталарында әле анда, әле монда бүреләр уларга тотына. Алмаш-тилмәш улашалар, явызлар. Тегермән тавы башында берсе улап аваз салса, аулак үзәннән, зират тирәсеннән башкалары күтәреп ала.

Куркыныч, шомлы...

Догалы авыл төннәрендә бүре авазларыннан өркегән кешеләр сугыш кырларына чыгып киткән якыннарын аерата гаҗизләнеп сагынышалар.

Рәмзиянең генә күңелендә — авыр таш, телендә — богау йозак, йөзендә — кара пәрдә.

Яңа ел төнендә Рәмзия чыдамады, йомыш тапкан булып урамга чыгып китте... Берәр генә чыбыклы телефон баганалары тынып, оеп калганнар. Ник бер җирдә күңел җирсетерлек ут чаткысы күренсен!..

Күк гөмбәзе бәләкәй генә калган, йолдызлар ишлелектән кысылышып тартышалар, кыймыл-кыймыл киләләр, алар күкне җиргә сөйрәп төшерерләр кебек тоела. Әнә алар, күпер аръягындагы талга сарылып, аның шәлбер ботакларын тагын да түбәнрәк игәннәр. Кап-кара шомлы офык сызыгы аның көчсез аяк очыннан гына уза кебек.

Исламгәрәй янына керәсе килмәде хатынның... Телефон баганасына барып сөялде, шушы сыңар чыбыкка ялганып, уйлары еракка, яшьлегенә кайтып китте. Аның бер чакта да бүгенге кебек үк бәхетсез булганы юк иде. Йөрәген телгәләгән шәхси бәхетсезлеге ил язмышына, халык бәхетсезлегенә үрелгән иде. Шуның өчен Рәмзия бер ялгызы бу серле йомгакны чишәрлек тә, аңларлык та хәлдә түгел иде...

Беркөнне ишегалдында утын ярып маташканда үзләренә кереп килүче шинельле, йолдызлы фуражка кигән ирне күреп, коелып инде.

— Беттек,— дип пышылдады аның суыктан яргаланган иреннәре.

— Нихәлләр бар, Рәмзия,— диде солдат. Аның соры күзләре иркәләп, ягымлы карадылар.

— Син икәнсең, Зәбир абый.

— Курыктыңмы?..

— Күземә күренәсең дип торам.

— Көндез кермисең дип сүгә идең, менә көне җитте, килдем.

— Әйбәт иткәнсең, Зәбир абый.

— Кичә повестка килде, Рәмзия.

Аның җылыйсы килеп китте, кунакны өйгә чакырырга теләде, кадшап, әрле-бирле сугылды.

— Шулаймыни, Зәбир абый? Саубуллашырга кергәнсең икән... Әйдә, өйгә уз, кер, жылынырсың...
— Керә үк тормам, Рәмзия!.. Вакыт тар... Аннары, жайсыз да.
— Шулай дисеңмени?.. Зәбир абый, танклардан курыкмыйсыңмы соң?
— Күзгә-күз очрашканда куркыныч... Авызыңны ачып торсаң, сытманны сытарлар. Авыз ачып тормасаң, үзең чәнчелдерерсең.
— Берүк, исән-сау йөр инде, Зәбир абый...
Күңелендә өермә булып купкан сүзләрдән ул нибарысы шуларны әйтә алды.
— Рәхмәт яхшы сүзеңә, Рәмзия,— диде солдат йөзе ачылып.— Синең сүзең миңа бик кадерле... Син минем беренче мәхәббәтем... Яшьли сөйгән дустым... Бәлки соңгысы булып та син калырсың, дөнья хәлен белү, әйтү кыен... Әмма миңа шушы яхшы теләгең өчен бик-бик рәхмәтләр яусын синә... Кайтам әле мин, кайтыр күк тоям... Мине кисәрлек кылыч коелмаган, мине тишеп үтәрлек пуля табылмаган. Шунысы бик аяныч, синең белән рәтләп сөйләшеп булмады... Аңлатып булмады... Шома сөйли дә белмим, Рәмзия, әмма күңелем тулы уй, телем тулы тәмле сүзләр...
— Нигә болай дисең, Зәбир абыкаем?..
— Син мине санламадың, Илайлар тамырыннан үсеп чыккан кәкре ботак дип кенә карадың... Беләсеңме, йомшак агач төбеннән генә вак куаклар үсеп чыга, ә каты агач — имән, өрәңге, каен орлыктан шыталар...
— Аңлыйм, Зәбир абый.
— Үләргә китмим, белеп, ышанып тор. Кояш кебек әйләнеп кайтырмын.— Егетнең яңаклары алланды.— Сирәк-мирәк кенә мине уйлаштырсаң, кош теледәй хатыңны жәлләмәсәң миңа бүтәне кирәкмәс тә!
— Язармын, Зәбир абый, берсен дә жавапсыз калдырмам,— диде Рәмзия чын күңеленнән.
— Хәзер өеңә ник кермәгәнне аңладыңмы инде?
— Юк,— диде агарынып хатын.
— Өйдә син ышанып та бетмәс идең... Башкача уйлар идең...
Зәбир жайсыз гына аның салкын кулларыннан әләктереп алды, үзенә таба тартты, Рәмзия куркынып өй тәрәзәсенә, аннары урам якка каранды, егетнең кайнар иреннәре аның борын тирәсенә кагылдылар. Ул үзе дә сизмәстән аңа талпынды, сыенды, сискәнеп ике куллап егетне капкага этәрде:
— Ак юл сиңа, Зәбир абый, бәгърем!..
— Сау бул, минем Рәмзиям, онытма!..
Капка ябылгач та, аңа үтә күңелсез булып калды, эчен ниндидер шом басты, егылып китмәс өчен ул имән кискәгә утырып хәл жыйды. Битләре ут кебек янды, картаеп, арып, авыр аякланып ярым караңгы өенә керде. Менә жанын куркытып баз капкачы шапылдады, мич арасыннан соры күләгә атылып чыкты.
— Син: ананңны фәлән-төгән, әрсез әрләнбелән ни гомер суган сатып тордың? Ә?!.
— Килгән бер кешене куып торырга, мин синең бәйдәге этеңме әллә?..
Исламгәрәй бу юлы сүгенеп кенә калмады, сөякчел нык йодырыгы белән аның касыгына китереп төртте, хатын тәкмәрләп барып төште, ире кая әләкте, шунда аны тәяргә тотынды.
Рәмзия жыламады, киресенчә, ире суккан саен аның зиһене ачыклана барды, тәнен басып торган албасты жиңелде, ире мышкылдап аның аяк очына идәнгә утыргач, елмайгандай итте.
— Жүләр,— диде ул ап-ачык итеп.
— Бирермен мин сиңа жүләреңне,— дип гыжылдады Исламгәрәй.
— Үзем жүләр, мин,— диде Рәмзия, ертылган жиңен кулы белән сыпыргалап.

— Сөйрәлчек маржа!

— Сугышка чыгып киткәндә хушлашырга дип кергән кешегә бер җылы сүз әйтми чыгардым. Якты чырай күрсәтмәдем. Илдә булмаган хәл: бер чынаяк чәй эчертмәдем... Үлемгә китеп барган батыр егеткә бер бүләк бирмәдем.

— Үтерерсең Илай малаен, бар,— диде һаман мыш-мыш килеп Исламгәрәй.— Сугышта йөреп яраланган дисеңме әллә син аны? Үз кулына үзе атып кайткандыр әле!

— Ничек? — диде шаккатып Рәмзия.— Әгәр бөтен ирләр синең төсле булсалар, ничек барыр иде бу тормыш, шуны уйлап карыйсыңмы?!

— Бик беләсең килсә, үзең барып кара!

— Сәкинәләр киттеләр, куркып тормадылар.

— Һе, алар бит ул!

Шушы көннән, шушы кичтән алар бер өйгә сыешмый башладылар.

## 5

Эшләргә, эшләргә, эшләргә!..

Исламгәрәй мөртәт өчен эшләргә, Зәбир батыр өчен эшләргә...

Рәмзия салам күтәрсә, чүмәләсе белән өерли, бишәр потлы капчыкларны үлчәү табасы яныннан чанага бер үзе чыгарып сала... Утын түмрәннәре аның балтасы төшүгә урталай ярылып китәләр...

Бүген ул эштә үтә кәефсез йөрде. Ашлык суыралар иде, алар Мәфтуха белән, кул алмаш җилгәргеч әйләндереп тордылар. Төштән соң ике тапкыр Рәмзиянең башы әйләнеп китте, күз аллары томаланды.

— Белдеңме,— диде аны битәрләп Мәфтуха.— Өзлегерсең бер дип әйтмәдемме?.. Егерме биштә чахут алып тәпи суза башласаң, исеңә төшәр, соң булыр.

Рәмзия учларына төкереп, җилгәргеч сабына барып тотынды, башы әйләнгәнне сиздермәде, иреннәрен кысып, кичкә кадәр эшен куймады.

— Туктал диләр сиңа! — дип җикеренде Мәфтуха.— Җенең котыртамы әллә?.. Бар, ял ит.

Рәмзия башын гына чайкады...

Февраль ахырлары иде инде, түбәнең кояшка караган кыегында кар челтәрләнде, тәрәзәгә кадакланган калын салам маталар көннәр яктырган саен хатынның эчен ныграк пошырдылар.

Шундый кичләрнең берсендә, кичке аштан соң, алар Исламгәрәй белән тагын сүзгә килделәр.

— Исламгәрәй,— диде ул,— әйбәтләп кенә әйт әле... Менә көннәр дә җылыга китте, бүген тамчылар тәгәрәде. Эш язга бара. Син китәргә уйлыйсыңмы, юкмы?

— Куасыңмы? — диде Исламгәрәй, кашыгын куеп.

— Ачыклыйсым килә, шуңа соравым.

— Кая бара алыйм ди мин хәзер?

— Менә бер заман сугыш бетәр...

— Тиз генә бетми әле ул!..

— Син дә, мин дә базда качып ятсак, бетмәс иде дә бәлки...

Исламгәрәй кашыгын атып ук бәрде:

— Куа алмассың! Син хәзер минем белән бер казыкка бәйләнгән!.. Үз вакытым белән чыгып китәрмен! — дип ысылдады.

Иртән ул караңгылы-яктыда Мәфтухаларның ишеген какты.

— Чыгып керче, күрше.

— Ни булды, Рәмзия, чыраең калмаган.

— Хәтимә апага әйт, бүген эшкә төшмим. Районга барам.

— Больницагамы әллә?

— Анда күз күрер...

— Вакытың булса, кибеткә кагыл, куык-мазар күренмәсме. Кичә малайлар куыгымны ваттылар...

Ул яңадан өенә кереп тормады, башын түбән игән килеш тиз-тиз атлап, район юлына төште.

Озак барды, күп уйланды Рәмзия. Районга җитәрәк аны ике атлы куып җитте, ләкин чаналарга шыплап диярлек ир-атлар төялгән иде, алар ялгыз тәпиләгән хатынга шук-шаян сүзләр кушып, такмак әйтеп уздылар.

Хәрби комиссариатны ул бик яхшы хәтерли иде. Былтырның җәендә, июнь кичендә, әнә теге койма буенда алар Исламгәрәй белән хушлаштылар...

Хәзер дә ул коймаларга атлар бәйләнгән. Чаналарга саран салынган печән тирәсендә мур кыргыры кәҗәләр. Ишек тирәсендә тулып кигән өлкән агайлар янында хәтәр генә тәмәке пыскытып, яшьрәкләр басып тора. Арада бер-ике солдат киемлесе дә бар. Кояшта эреп чыккан ат тизәген таратып, чыпчыклар туй итәләр. Чыр да чыр киләләр... Ишеккә якынрак килергә куркып, ул байтак таптанып йөрде, аяклары туңа башлагач кына, керүчеләргә ияреп, коридорга атлады. Тәмәке төтене, ыгы-зыгы, җылашкан-көлешкән тавышлар, аңа былтыргы җәйне, былтыргы Исламгәрәйне хәтерләттеләр.

Ул кешесезрәк ишекне чамалап, шуны ачты, эчкә атлады. Билен киң елтыр каеш белән буган пеләш кеше папка күтәреп чыгып килә иде, Рәмзияне күргәч тукталды.

— Абый,— диде Рәмзия оялып кына,— армиягә кайда язалар монда?

— Медперсонал?— диде пеләш авызын бөрештереп.

— Нәрсә, нәрсә?

— Врачмы, медсестрамы?

— Түгел идем шул.

— Элемтәчеме?

— Әйе,— диде шатланып Рәмзия. Җиденче классны бетергәч, авылларындагы почта бүлекчәсендә елга якын телефончы булып утырган иде ул, шуны хәтерләде.

— Әйдәгез әле,— диде елтыр башлы кеше, Рәмзияне үз артыннан чакырып.

Кечкенәрәк бүлмәгә барып керделәр:

— Янбулатов,— диде пеләш өстәл артында утырган озын, чандыр кешегә.— Тагын бер иптәш килде. Элемтәче.

— Гаризаң кайда?— диде Янбулатов.— Дипломың үзең беләнме?

— Гаризам юк, мин белмәдем.

Янбулатов күтәп торырга кушты, үзе кем беләндер телефон аша сөйләшеп алды, аннан торып, тәмәке кабызды. Шулчакны Рәмзиягә күзе төшеп, сораша башлады. Рәмзиянең аяклары җылына төшкән иде, эшем кирегә китмәсә ярар иде дип, тагын курка-туңа башлады. Аның элемтәчелегенең ташкүлчим икәнлеген Янбулатов ярты сүздән аңласа да, һич ачуланмады, киресенчә, хуплады, мактады, гаризаны үзе әйтеп яздырды. Иң ахырдан, сез ирдәме, ирегез кайда, дип сорады.

— Бар иде,— диде Рәмзия аска карап.— Сугышта үлде.

— Кәгазегезне алып калам,— диде Янбулатов.— Иптәшләр белән киңәшербез. Иртәгә комиссия. Безгә элемтәче хатын-кызлар бик кирәк. Аз-маз тәҗрибәгез булгач, шуның өстенә әйбәт теләгегез бар, бик тиз өйрәнерсез. Иртәгә сәгать сигездә монда явится итегез.

— Килермен,— диде Рәмзия кыска гына итеп.

Саубуллашып чыккач, ул, иң элек, Мәфтуханың гозерен үтәп, хуҗалык кибетенә кагылды. Куык сорагач, аннан көлделәр. Кибеттән ашханәгә керде, ике стакан кайнар чәй алып, шуны өеннән килгән ипиен ашый-ашый эчте. Ашап-эчеп алгач, туп-туры колхоз фатирына төште, авылдашларының очравыннан да курыкмыйча, шунда кунды.

Иртәнге җиделәрдә үк хәрби комиссариат ишеге төбенә килеп басты. Сигез тулгач, каралырга килгән ирләр белән бөялеп эчкә керде. Кичәге Янбулатов аны танып, иптәшләренә күрсәтте, Рәмзияне чиратсыз гына алга уздырдылар.

Врачлар янына кергәч, аңа чишенергә куштылар. Башта кан басымын үлчәделәр, йөрәген, үпкәсен тыңлап карадылар, кәгазьләргә барын пөхтәләп язып куйдылар. Элек ни белән авырдың, бала-чагаң бармы, дип сорадылар. Шуннан чыгарып җибәрәбез дигәндә генә, үзара нидер пышылдаштылар. Рәмзияне тагын өстәл янына чакырдылар. Арадагы хатын-кыз врач аны күрше бүлмәгә дәшеп кертте.

— Нигә безнең башны бутап йөрисең, күгәрченкәем? — диде ул татарчалап.

— Нишләп, апа? — диде аптыраган Рәмзия.

— Синең авырың бар ич!

— Булмас,— дип калтыранды аның иреннәре.

— Ирең сугышта үлгәнме әле синең?.. Кайчан китте дисең?.. Июньдә үк?.. Шәп, шәп!.. Шуны яшерер өчен фронтка барырга булдыңмы?..

Врачның һәр сүзе таштай авыр, һәр хөкемендә җирәнү һәм ачы нәфрәт ишетелде. Шәрәтән Рәмзия ир-ат арасына барып кергәндәй түшен, ботын капларга, ябарга тырышты:

— Булмас, булмас, юктыр,— дип кабатлады.

Үзендә барган үзгәрешне ул элегрәк тә сизенә иде, дөресрәге, соңгы көннәрдә шикләнә башлаган иде, әмма андый хәлләр аның яшь организмында элегрәк тә булгаладылар. Көзге пычракларда, Исламгәрәй кайтырдан күп элек тә, авыр, тынгысыз көннәр-төннәр йокламыйча уздырганда, аның тәне капризланып, числоларны, кагыйдәләрне бозып ташлаштыргалый иде... Соңгы сырхауларны кышкы җилләр алып килде, язгы җылылар җирдәге туң белән тәндәге җәфаларны да эретеп бетерер дип өметләнгән иде.

Коридорда берәүгә дә күтәрелеп карамады Рәмзия. Барысы да аның хурлыгын беләләрдер, мыскыллыйлардыр кебек тоелды аңа...

## 6

Ул бәкегә төшеп үләргә уйлады.

Район үзәге тау башындарак утыра, таудан көнбатышта, тирән иңкүлектә Зәй елгасы ага. Рәмзия моны яхшы белә иде, военкоматтан чыгуга туры аска төшеп китте.

Бата-чума байтак кына барды, эзләнеп, караштырып йөрде, җил кискән күзләреннән бөртек-бөртек яше изелеп чыкты, бер җирдә дә бәке күренмәде. Итек кунычыннан кар кереп тулып, ике аягы да лычма су булды, әмма ул яшәү турында, саулык турында түгел, үлем турында гына уйлады.

Елгага туры төшә торган урам уртасында марҗаларның водопровод колонкасыннан су алып маташуларын күргәч, үзеннән-үзе көлде: «Кайда ди ул монда батып үләрлек бәке!»..

Ишек алдыннан чана тарткан ике-өч бала йөгереп чыкты. Ике кыз, бер малай. Олырак кыз алдан чана тартып бара, калганнар чанага утырырга теләп, ике яклап йөгерешәләр, егылалар. Рәмзия авызын ачып, аларның чабышып, көлешеп узуларын көтеп торды һәм кинәт арадагы өченче кеше турында — карындагы бала турында уйлады. Аягым дымланды, салкын тиеп, аңа зарар булмаса ярар иде, дип хафаланды. Тиз-тиз фатирына кагылды, ипи төреп тоткан яулыгын икегә ертып чолгау ясады, оекбашларын тимер мич авызында киптерде. Шуннан соң гына юлга чыкты. Көн чалт аяз, тик һаман салкынча иде. Ирнә күперенә төшкәндә аны ике атлы куып җитте, юл сабып көрткә баткан хатынны болай гына

калдырып узмадылар, алдагы атлы аны утырырга чакырды. Сәлам алышкач, кайсы авылныкы син, кая бардың болай, дип сораштылар.

— Военкоматка ирем турында белешергә бардым,— диде ул.

Атлылар заготскотка гына баралар икән, күперне узып берәр чакрым үткәч, сулга борылып керделәр. Шулай да Рәмзия хәл алып өлгерде, моннан ерак калмый инде, ипләбрәк атлаганда да була.

Мәфтуха капка төбенә чыгып баскан да, кулын каш өстенә куеп, район юлын караштырып тора иде, Рәмзияне танып, аңа каршы китте.

— Саулыкмы, тынычлыкмы, Мәфтуха апа?

— Бигрәк озак йөрдең, куркып беттем. Кайларда булдың?

— Кибетләргә кердем... Куык сораган идем, юкны ничек бирик дип, көлделәр генә.

— Бер хат бар иде, кичәдән бирле сине көтә.

Рәмзиянең арган аяклары гәүдәсен чак тотып калдылар.

— Миңамы? Кемнән?

— Солдат хаты. Фамилиясе ачык түгел. Укырга кыймадык... Ирең Исламгәрәй турында берәр хәбәр язалармы әллә?.. Безнекеләрне белүче табылмаганмы?

Мәфтуха Рәмзиягә ияреп, өйгә үк керде.

Сап-салкын, кием-салымнар теләсә ничек ташланган. Күршесенең өенә күптән кермәгәнгә Мәфтуха тәртипсезлекне гаҗәп итте.

— Ачкычыңны калдырган булсаң, мичеңә ягып куяр идек. Әй, агай. Чиләктәге су чирый башлаган бит. Кош-кортларыңны, сарыкларыңны барлап, ашатып яптым... Әй, әйтергә онытып торам икән, ак сарыгым бәрәнләде, үзе төсле түп-түгәрәк ике бикәч бәрән китергән. Балалар бәхетеннән булгандыр инде...

Ул берни ишетмәде, берни күрмәде, чишенмичә-нитмичә җыелмаган караватка өстенә барып утырды.

Хат Зәбирдән иде. Ашыгып укый башлады.

*«Рәмзия, исәнме, авылдаш!*

*Менә фронтка килеп тә җиттек. Кулга күз тимәсен, түзәлде. Үземнең элекке частька эләгә алмаммы дигән идем, анысы ук булмады, дускай... Ничава, монда да үземә охшарлык иптәшләр җитәрлек икән. Якташлар да байтак, кичә генә Сарсаз егетен очраттым. Белмисеңме икән, Мөхәммәдиев фамилияле, җөйле иренле, Ибраһим атлы. Сезнең замандаш булгач, беләсеңдер дә, ул сине әйбәт белә икән... Авыл хәбәрләрен сорашып җанымны алды... Монда хәлләр үзгәргән, дошманны тукмарга дип атлыгып торалар... Үзең язмассың инде, исән чакта мин сызгалап торырмын. Үпкәләмәссең.*

*Сау бул, камыш бармагым, көмеш тырнагым!..»*

Иң ахырда ике генә юл җыр өстәлгән:

*«Гөл — былбылын, былбыл гөлен*
*Сагынгандыр, билгеле...»*

Кемнең гөл, кемнең былбыл икәнлегенә хәтта ишарә булмаса да, Рәмзиянең күз керфекләренә ачы яшь килеп бөялде.

— Исламгәрәең исәнме әллә? — диде түземсезләнеп көтеп утырган Мәфтуха.

— Әй, апакаем! Белмисен бит син бер нәрсәләр дә! — дип, Рәмзия аның янына сыгылып төште.

— Ирең турындамы?

Рәмзия башын селкеде һәм кинәт Исламгәрәйне хәтерләп, тыңлана башлады. Баз тирәсеннән бер тавыш-кара ишетелмәде.

— Юк ла,— диде ул шәл почмагына күз яшен сөрткәләп.— Яшь чактагы белеш егет язган.

Мәфтуха конвертны кулына алып, хатның кайчан язылуын, күпме килүен чутлап, егетнең исемен сорашып, шактый тинтерәтте. Аннан тагын суык мичне капшап:

— Бакчы, аягыңдагы кар да эреми бит, бәрәңгеләреңә суык төшмәгән булса ярый!..— дип зарланып алды. Соңыннан үзләренә кирәргә кыстый башлады.— Сөтле өйрә куйган идем, әйдә, ачыккансыңдыр. Ак сарыкның бәрәннәрен дә күрерсең.

Рәмзиянең Мәфтуханы тизрәк чыгарып җибәрәсе генә килә иде.

— Рәхмәт,— диде ул.— Мичкә ягып җибәрим инде, шунда ашарга да куярмын... Карыным ач та түгел...

Тик Мәфтуха чыгарга ашыкмады, район хәлләрен сорашып утырды. Врачта булдыңмы, ни диделәр, нигә куна калдың, дип, барын белеште.

— Исән йөреп кайткач ярый инде, югыйсә, әллә ниләр уйлап бетердем. Заманны да аңлап бетермәссең дигәндәй, яхшы кеше бар дигәндәй, яманы да тулып ята. Әнә, Кәҗә башы урамында Кайнар Гаптериләрдә берәү кунып чыккан. Солдатмы шунда, юлчымы, эт белсен. Иртән торсалар, солдаттан җилләр искән, толып тун белән ике пар итекләре дә юк икән... Чит-ят кешеләрне авыл советы рөхсәтеннән башка кертмәскә дигән әмер бар... Өй борынча тикшерү чыгачак, дип тә сөйлиләр...

Мәфтуха чыгып китеп, капка шыгырдаганга байтак вакыт узса да, ул мич каршысында басып торды да торды...

Нигә әйтте инде Мәфтуха соңгы сүзләрне?

Күреп калганмы, сизеп белгәнме? Әллә Рәмзия өйдә югында Исламгәрәй бер-бер эш кылып ташладымы?..

Ул баз капкачы өстеннән узган саен сагаебрак атлады, астан кыштырдау һәм тамак кырган тавыш көтте. Берни дә ишетелмәгәч, капкачны күтәрде, сузылып, шыпырт кына:

— Исламгәрәй, Исламгәрәй! — дип эндәште.

Тавыш-тын ишетелмәгәч, янып торган мичтән чырага ут элдереп, базга төште. Исламгәрәй качып яткан ләхетнең таза тактасы каерылган, чокыр ярым күмелерлек итеп балчык ишелгән, ишелгән балчык өстенә өч-дүрт чиләк бәрәңге сибелгән иде. «Әллә, ходаем, басылып үлеп ятамы?» Такта, тарта торгач, шуып ук чыкты, чыра зәһәр ис чыгарып сүнде, ул кулы белән балчык астын капшап карады, берәү дә юк иде...

Рәмзия баз капкачын ябарга онытып, өйне караштырды, өйалдына чыкты. Чолан идәне күтәрелгән, нигезне ныгыткан олы гына имән бүкән урыныннан тәгәрәп чыккан иде...

Бер түшкә сарык, байтак кына шикәр, ипиләр, җылы кием-салымнар, тагын шактый нәрсә-каралар урыннарында юк иде.

«Аллага шөкер,— диде ул олыларча куанып,— киткән икән, киткән, хәерле юл булсын, инде моннан болай акылын җуймасын!» — дип укынды Рәмзия.

Онытылып өйгә керде, кече яктан борылганда чак кына базга барып төшмәде. Караңгы баз авызына карап коты чыгып, узганнарны уйлап, куркынып басып торды... Әгәр Зәйдә бәке тапкан булса...

Әллә ниләр күрерсең бу дөньяда!..

Эшләре беткәч, иркенләп, озаклап чәй эчте. Зәбирнең хатын тагын бер кат укып чыкты. «Гөл — былбылын, былбыл гөлен» дигән җиренә җиткәч, үксеп җылап җибәрде.

Ләкин бу үзенең соңгы җылавы икәнен ул белми иде.

Икенче көнне иртә-таңнан, бригадир әйтмичә үк, эшкә төште. Яз җитә, чәчү җитә, аларның Куйбышев исемендәге колхозы сортлы орлык хуҗалыгы булып, Рәмзияләр, Мәфтухалар бөтен күрше-тирәләрен сортлы чәчүлек белән тәэмин итәргә тиешләр иде.

Рәмзия «ВИМ» машинасында ашлык суыртты. Иреннәрен кысып, ялны онытып эшләсә дә, анда элекке җитезлек тә, уенчалык та юк иде. Яз якынлашкан саен киңрәк ачыла барган офыкларга текәлеп, урамдатыкрыкта бәләкәй малайлар очраганда ул озаклап карап тора иде.

Төннәрен ул сагаеп-саташып йоклады, тора-бара бу сагаю онытылды, ул тәрәзәсен томалаган юешлектән авырайган, тынчыган маталарын кубарып атты.

Бер төнне кар өстеннән шыбырдап эре ләйсән яңгыр явып узды. Җылытты. Шул төндә мәктәпнең хәрби кабинетыннан мылтык һәм ике пачка патрон урладылар. Милиция килеп, сорашып та йөрде. Кәҗә башы урамында рәттән ике төн ут чыгып, дүрт йорт утырып янды. Шуларның берсе Илайларның төп йорты иде. Зәбирнең карчык әнкәсе чак-чак чыгып котылган икән, дип сөйләделәр.

Кешеләрнең: «Мөгаен гена төрттеләр боларга»,— дип сөйләшүе Рәмзиянең күңеленә тагын ямьсез, әшәке уйларны борып кайтарды.

Март урталарында аны военкоматка чакырып, повестка килде. Теге вакытта көлеп каршылаган, елмаеп озаткан Янбулатов бүген шактый кырыс иде.

— Ирегез Исламгәрәй турында хәбәр алынды... Ул «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән... Димәк, исән дигән сүз. Хәзер аның белән хәбәрләшмисезме?— диде ул.

Иренең исәнлеген ишеткән хатын күтәрелеп бәрелергә тиеш булгандыр да, Рәмзиянең ачуы, үче шулкадәр зур иде, ул күзләрен идәнгә терәп, сабыр гына тыңлап утырды да:

— Юк,— диде.— Ишеткәнем дә, белгәнем дә юк.

Күңеле тыныч та, тынычсыз да иде аның.

Әмма ике йортны бергә тетрәткән коточарлык хәл булып алды...

## 7

Калку урыннар кардан арынып, сукмаклар төшкәч, Югары авыл малайлары һәр елдагы кебек балта-борау тотып, шешәләр, банкалар асып, урманга каен, өрәңге суы эчәргә йөри башладылар. Мәктәптән яшь тайлар күк чабышып кайталар да, кояш җылысы сүрелгәнче, каен суының хуты туктаганчы дип, Чүке елгасы буйлап урманга чыгып китәләр. Сукмак тау битеннән барганда иң коры юл шул якта. Мәфтуха малайлары Рәмзияне ике тапкыр яз сые — татлы су белән сыйладылар инде.

Якшәмбе бик матур, кояшлы булды. Мәфтуханың дүрт малае гөрләшеп лапас күләгәсендәге карны чәчтеләр, ишек алды бозын вакладылар. Берочтан Рәмзияләргә дә кереп, аның ягы эшләрен караштылар. Үзе ул авыр эштән сагаеп, өендәрәк утырды, иске-москы күлмәкләрен бозып, бәбигә чүпрәк-чапрагын әзерләргә керешә. Малайлар эш бетергәндә кояш җылысы ару гына иде. Ни арада җыенып, чыгып киткәннәрдер, күз бәйләнә башлагач, Мәфтуха аптырап, Рәмзияләргә керде. Искәрмәстән тып итеп идән уртасына баскан күршесеннән куркып, Рәмзия чүпрәкләрен тиз-тиз мендәр астына яшерде, күтәрелеп карады.

— Малайлар кайтып җитми,— диде пошынып Мәфтуха.

— Уйный торганнардыр...

— Аякларын бик чылатмасалар ярый да... Урманда кар әле...

Мәфтуха борчылып чыгып китте, ул кире әйләнеп кергәндә язгы, зәңгәр караңгылык куерган, ябулы тәрәзәләр белән кичне каршылаган Югары авыл урамнарында шомлы тынлык иде. Рәмзиянең кече як тәрәзәсе эчтән одеял белән томаланган булганга, ул күбрәк кичләрен шунда утыра.

— Кайттылармы?— диде ул, Мәфтуханың аяк тавышын ишетеп.

— Инде каршы барыйкчы, Рәмзия, күңелем әллә нишли, иләсләнә...

Тиз-тиз киенеп, таякка таянып, кыптыр-кыптыр Чүке ягына таба киттеләр. Олы су аркылы салынган, язгы сулар талап хәлсезләнгән иске күпер ике хатынның авыр аякларын тыңлап, шыгырдап калды. Авылны

чыгып, күмер базлары янынннан тауга менә башладылар. Байтак баргач, каршы яктан сөйләшкән тавышлар ишетелде.

— Әнә алар! — диде Рәмзия, көчкә тын алып.

— Шулар бугай,— дип килеште Мәфтуха да, тик аның тавышында курку һаман бетмәгән иде.

— Малайлар! — дип кычкырды Рәмзия.

Менә төркемнәр бер-берсен аерырлык дәрәҗәдә якынлаштылар.

— Әнкәй,— дип кычкырды Мирхәйдәр.— Мәрдән кайттымы?

— Юк,— диде Мәфтуха хәлсезләнеп.— Сез бергә йөрмәдегезмени? Әй, улым, улым!..

Малайлар аякларын көчкә сөйрәп, арып-талып әкрен генә киләләр иде.

— Бергә бардык, бергә йөрдек, ничек аерылып киткәндер, искәрмәдек... Белгәч, эзләдек тә ни, табалмадык.

Рәмзия: «Иң элек авыл советына, идарәгә кайтып әйтик, кеше җыеп килик»,— дип үгетләсә дә, Мәфтуханы тыярлык түгел иде. Кечкенәрәкләрне кайтарып җибәрделәр дә, Мирхәйдәр белән өчәүләп урманга таба чаптылар.

Әнкәсен очратып, Мәрдәннең өйдә юклыгын белгән Мирхәйдәр, үзен гаепле санап, очып-очып бара башлады, ачыгуын, арганлыгын онытты. Рәмзиягә алар тизлегенә бару кыен булса да, аны-моны әйтеп тормады, ике кулы белән эчен тотып, терек-терек, абына-сөртенә йөгерде дә йөгерде. Мирхәйдәр юлны яхшы хәтерли икән, «әкренрәк, монда чокыр», «монда пычрак» дип кисәткәләп барды.

Күгелҗем соры урман аларны сак тынлык, шомлы бушлык белән каршылады. Уянып килгән бөре исләре, черегән яфраклардан аңкыган татлы-баллы исерткеч исләр киңәйгән борын тишекләреннән ургылып кереп, үпкәләрне кытыкладылар. Беравык тынланып торгач, Мәфтуха җан өзгеч тавыш белән:

— Мәрдән, улым! — дип кычкырып җибәрде.

Өчесе дә тын тартырга базмыйча тыңладылар, Мәфтуханың тавышы шунда ук, якындагы дымлы ботаклы агачларга бәрелеп сүнде.

— Мәрдән, Мәрдән!..

— Каен суын кайда эчтегез? — дип сорады Рәмзия.

— Аю аланында гына, әнә тегендә!

Мирхәйдәр артыннан эчкәрәк керделәр.

— Менә мин тишкән каен,— диде ул.— Шешәсе дә шул килеш тора. Тулган.

Мәфтуха белән Рәмзия йотлыга-йотлыга салкын, баллы су эчтеләр.

— Әнә тегендәге каенны аңа тишеп бирдем. Анда аяк асты корырак... Бераздан ул килеп миннән бораауны алып китте... Шуннан белмим, күрмәдем бугай мин аны...

Караңгыда агарып утырган дәү каен янында шешә дә, бораау да, малай да юк иде.

— Без моннан эзләдек инде, Күек аланына хәтле барып җиттек.

— Тизрәк, тизрәк!,— диде Мәфтуха.

Кычкыра-кычкыра Күек аланын уздылар, Яныкка барып җиттеләр. Туктап, күмәк кычкырып карадылар. Куркыныч, юеш урман караңгы һәм тавышсыз-өнсез иде.

Күек аланыннан сулда тоташ каенлык иде, хәтсез вакыт шунда әйләнделәр.

— Чүкедән ерагайсак, адашырбыз без,— диде Рәмзия.

— Тизрәк, тизрәк,— дип, ашыктырды Мәфтуха.

Куелыкка кергән саен кар тирәнәйде, чокыр-чакырларда тездән су ялтырап ята иде. Башта аларны әйләнеп-урап үтсәләр дә, соңра игътибар итми башладылар.

— Мәрдән, Мәрдән!..

Тик урман аяусыз тын, буш һәм салкын иде...

Ярты төн авышканда, Чүке ярларын чамалап, авылга кайттылар.

Иртә-таңнан бөтен авыл ду купты. Көне буе жыелып эзләделәр, кагылмаган почмак, үтелмәгән сукмак калмады. Мәрдән табылмады. Өченче көнне Мирхәйдәр үз ише олырак малайларны жыеп, тагын эзләргә керештеләр. Бу юлы аларга Сарбай да ияргән иде. Малайлар таралышып, җиде-сигез чакрым уздылар, калын, кара урманның уртасына Тугай суы якларына барып җиттеләр. Шунда Тугай суы янында, куак төбендә утырып үлгән Мәрдәнне Сарбай табып алды...

Малай бер аягыннан резин итеген салып, шуның өстенә утырган, уң кулы белән шома юкә агачына ябышкан... Суыктандыр инде, иреннәре зәп-зәңгәр булганнар, кап-кара күзләре ачык иде...

Төпчеген җирләгән көн Мәфтуха өчен иң кара, иң авыр көн иде.

— Исән-аман йөреп кайтса, әтисенә ни җаваплар бирермен,— дип, кыйналды ул...

Хәзер Рәмзия кичләрен күбесенчә Мәфтухаларда урала, аларда күңелсез булса, икәүләшеп өйнең коры нигезенә чыгып утыргалыйлар.

Соңгы ике көндә җылы яңгырлар явып узды, җир тәмам пешеп, күпереп китте, колхозлар чәчүгә чыкты.

Чәчүдән кайткан Рәмзия хәл алырга караватка яткан иде, үзендә ниндидер үзгәреш сизде. Кулы белән тотып карагач, тәне кызышыпянып китте: яңа кешенең йөрәге тибә башлаган иде.

Шул төнне таң яралганда аның ишеген кактылар.

— Кем йөри анда?— диде ул, иренеп кенә.

Эндәшмәделәр, сак кына ишекне кытырдаттылар.

Уянуы да, кузгалуы да бик рәхәт иде. Күзне иркәли шушы сызылып кына килгән язгы таңнар! Ул берни уйламыйча, борчылмыйча, тынычсалмак адымнар белән өйалдына чыкты, ишекне ачты. Болдырда шинель якаларын күтәреп, посып, бөкшәеп Исламгәрәй басып тора иде. Ул, Рәмзиянең югалып калуыннан файдаланып, мыштым гына аның култык астыннан өй эченә таба узды.

Рәмзия мич буена басты, Исламгәрәй, эре-эре пычрак эзләр калдырып, өстәл янына узды, уфылдап утырды, авыр-авыр итеп йөткеренде.

— Күкрәкне изә шушы ютәл,— дип зарланды.

— Дәваламыйлармы?

Рәмзия үзенең шушы сүз белән авыз ачуына гажәпләнеп куйды, Исламгәрәй ачуны, нәфрәтне сизмәде, һаман үз сүзен тукыды:

— Ике яктан китереп кыса, чыдап булмый...

— Тагын нигә кайттың? Каян?

— Сагындым.

— Тик хәзер качып ята алмассың, бөтен кеше күрә...

— Нәрсәне?

Ул елмайгандай итеп, корсагына төртеп күрсәтте. Исламгәрәй күз генә төшерде дә корык-корык ютәлләргә тотынды.

— Ничава, Илай тәресенә сылтарсың, барыбер себерелдегез ич!

Аның күзләре зур булып ачылдылар:

— Мәктәп мылтыгын син урладыңмы?

Ире баш чайкады:

— Юк... Нәрсәгә ул миңа?.. Яз житте, жылы... Шушы ютәлне генә бетерсәм, сугышка чыгып китәм... Ютәл белән йөрү куркыныч... Кызганмыйсың син мине, дәваламыйсың!.. Дәвалансам, юлга чыгар идем. Ютәл белән кем мине отрядка алсын?.. Партизаннар ягына үтеп чыгарга кирәк миңа...

— Ялганлап утырма, оятсыз,— диде Рәмзия, ачы яшенә тыгылып.

Исламгәрәй, алама тезенә сакалын тидерә-тидерә, үксергә кереште:

— Куркыныч!.. Эт тормышында яшим... Ни ашарга, ни эчәргә!.. Күкрәкне изә!

— Ә мин сине барып әйтсәм?

— Әйт,— диде туктаусыз җылап Исламгәрәй.— Бетер шушы дурак башымны!.. Котылыр идем каһәрле дөньясыннан!.. Куркыныч, бер башыма куркыныч!..

— Башыңның кадере булмагач, нигә аны качып асрыйсың?

Көннең яктырганнан-яктыра баруын алар икесе дә сизенделәр. Исламгәрәй сүзне-эшне кыскарак тотарга кирәклеген аңлап, тагын да катырак җыларга тотынды, аннан шып туктады.

— Чит кеше түгел лә мин сиңа!.. Йөрәк астыңда баламны йөртәсең?!. Җәллә бераз...

— Җәлләп нишли алам?

— Әйдә минем белән, күр... Хәзер вакыт тар... Әзерләнебрәк ашарга-эчәргә китерерсең...

— Бармыйм,— диде Рәмзия кинәт.

— Бармасаң, үзеңне үтереп, йорт-җиреңне көлгә әйләндерәчәкмен, миңа хәзер ике дөнья бер!..

Куркудан бигрәк, шушы мәхлукны кызгануга охшаган хис Рәмзияне баядан бирле икеләндереп килә иде, аның буш янауларын ишеткәч, ул, көлемсерәп, җыена башлады.

— Әйдә!..

Ындыр буйларыннан Метри елгасына төштеләр. Үзәннән бара-бара зират ягына юнәлделәр. Су тирәнәйткән ермаклар буйлап тау башына менделәр...

Уф... Әнә Рәмзияләр тузгыткан эскерт төпләре... Байтак көлтәләр кар астында качып калган икән. Хәтимәгә әйтергә кирәк әле, менеп җыйсыннар, мал-туарга ашатырга булса да ярар...

Тиз үк урманга керделәр. Исламгәрәй эз чуалтыр өчен генә зират тавына менгән икән, урманга кергәч тә ул, Тугай суы ягына борылды. Әле шырлыклар аша узып, әле ачык җирләрдән бара-бара байтак җир үттеләр.

— Яндырып үтерәсең,— диде Рәмзия, бер-ике тапкыр зарланып.

— Тизрәк, ерак түгел инде...

Байтак кына урап та йөрделәр, ахрысы, әллә Исламгәрәй эз бутарга гына теләдеме, ниһаять, тукталдылар. Ире кипкән иреннәрен ялап:

— Монда,— диде.

Ул берни дә күрмәде.

— Кайда соң синең өнең?

— Менә монда, нарат астында,— диде Исламгәрәй, иреннәрен канәгать кыйгайтып.— Нарат коры урында үсә... Мин аның тамырларын кистем, ике ай казыдым шушы чокырны. Ике ай балчыкны читкә ташыдым, елгага, Тугай суына. Хәзер әйбәт анда, җылы, тик дымсу... Ютәл күкрәкне изә!.. Мин сиңа турырак юл күрсәтермен... Ашарга китер, дарулар...

— Тере килеш кабергә төшеп яткансың икән,— диде хатын, әрлән тишеге кебек шомарып беткән чокыр авызына карап.

Исламгәрәй, як-ягына карана-карана, шушы урынга ничегрәк туры юлдан килергә кирәклеген өйрәтә башлады. Рәмзия кузгалып китәргә җыенгач, тыңлаучан әнчек эт кебек, аңа ияреп барды:

— Килерсеңме? Ашарга китерерсеңме?— дип кабатлады.

— Юк.

— Кил, кил, яме... Монда минем үземә генә бик куркыныч!..

— Сугышта куркыныч, монда куркыныч... Көтмә!

Рәмзия кояшны чамалап, туп-турыдан авыл ягына китте. Бераздан артында агач ботаклары шартлап сынды, күзләре акайган, ап-ак агарынган Исламгәрәй аның артыннан чаба иде.

— Әнә, ишетәсеңме?— диде ул, Рәмзия янына килеп тезләнеп.

— Нәрсә бар? Бүреме?

— Син берни дә ишетмисеңмени?

— Юк.

— Әнә ич! Тыңла әле. Әнә тагын, җылап, үксеп йөри.
— Кем?
— Саңгыраумы әллә син?
— Берни дә юк лабаса. Ник баш катырасың?!
— Бала җылый ич. Явыз рухлар мине шулай котырталар. Җеннәр, убырлар!.. Бу — Мәфтуха апа малае йөри.
— Каян беләсең син аны? — диде кинәт чәчрәп Рәмзия.
— Беләм...
— Каян?
Исламгәрәй үкереп җылый-җылый сөйләп бирде.
— Төнлә адашып минем янга килеп чыкты... Тавышын ишетеп, чәчләрем үрә торды... Җылый-җылый йөгерә...
— Ә син? Нигә янына бармадың?
— Ничек күреним ди мин аңа? Ул мине белә бит! Таныса, бетте диген!
Рәмзиянең сүзе, өне бетте. Исламгәрәйгә карата булган соңгы кызгану, җәлләү шундук юкка чыкты, үз куллары белән сөйрәп, аны Мәфтуха янына алып кайтырдай булды. Ир хатыны күңелендә нинди уйлар өермәсе тузгытканын дөрес төшенде, ахрысы, тиз-тиз сөйләргә кереште:
— Син чамалап... Безне асарга дигән бауның юкәсен бер агачтан тунаганнар... Яшерер идең, корсагыңда ябыгың бар... Әгәр, мисалга әйтим, чагам дисең икән, икебезгә дә көн юк!.. Капут!
— Кит! Якын килмә!.. Хәзер тыңла: балаңны кызганып, аңа карасы ягылыр дип кенә түзеп калам... Бүгеннән монда, безнең җирдә эзең булмасын! Теләсәң кая олак!.. Тикшерермен, әгәр икенче килгәндә монда булсаң, рәхим-шәфкать көтмә!..

* * *

Рәмзия Мәфтуханы кочаклап озак кына басып торды, җылый алмады, күңелендә күз яшен эретерлек җылы, йомшаклык юк иде...
Язгы чәчүләр бетәр-бетмәстә төньяктан бик көчле давыл килде, яшелчә бакчасының коймаларын, капкаларны аударып, телефон чыбыкларын өзеп бетерде. Гомер кузгалмаган ташлар таудан тәгәрәп төшеп, инеш буйларын чуарладылар, күпер-басмалар урыннарыннан җиңел генә кубып, агып киттеләр. Ташу икенче көнне дә тынмады...
Өченче көнне инеш аша басма салып ятучылар Рәмзияне үткәреп җибәрделәр. Яшь хатын чак кына алга иелә төшеп, тешләрен кысып, Чүке буйлап урманга таба китте. Аның чыраена карарга куркыныч иде, шуңа күрә балта осталары, кая барасың, нигә, дип сорарга да базмадылар.
Ул Исламгәрәй янына бара иде.
Җил-давыл вак-төяк агачларны гына түгел, юан-юан каеннарны да шартлатып урталайга сындырган иде. Анда-монда юл аркылы озын-озын чыршылар авып яталар.
Озак барды Рәмзия. Юлы озын булса да, уе кыска, ачык иде.
Менә билгегә алган юан каен. Моннан туры төньякка барырга кирәк. Янган урман... Моннан сукмак уза...
Исламгәрәй базының өстендә утырган нарат та тамыры-ние белән җиргә иңгән иде. Балчык-тамырлар арасыннан сыңар кул күренеп тора. Кул янында ук мылтык көпшәсе ялтырый. Таныш кул... Әнә эре-эре сары тырнаклар... Тырнак асларына кан катыш балчык каткан.
Ул, коты чыгып, беравык көтеп торды. Аннан иелде, тезләнде, кушучлап балчык алды, ашыгып-ашыгып кулны, мылтык көпшәсен күмә башлады. Кул тиз күмелде, елтыр көпшә генә бирешмичә маташты. Бераздан берни беленерлек түгел иде инде... Наратны кузгатсалар гына инде... Ул корыган яфраклар җыеп килеп чокырга тутырды...
Кичкә таба почта кыз аңа бер хат калдырып чыкты. Ул укыды да иреннәрен тешләп, Мәфтухаларга керде.

— Мә, укы,— диде ул.

— Тагын ни хәбәр икән, ходаем? — дип, Мәфтуха хатны курка-курка гына алды.

«Сезнең ирегез Зәбир Рәхмәтуллин Калинин фронтында батырларча һәлак булды... Аңа үлгәннән соң Кызыл байрак ордены бирелде...» дип язылган иде анда. Язу астына командирлары кул куйган...

Ике хатын, ике тол бер-берсенә сыенышып, байтак кына кайгырышып утырдылар. Иң элек Мәфтуха кузгалды, кече як шүрлегеннән бер нәрсә эзләп алып, Рәмзиягә сузды.

— Мә.

Аның кулында ялтырап торган солдат төймәсе иде.

— Төсе итеп тотарсың... Көзен Зәбирнең керләрен юганда мунчада төшереп калдыргансың...

— Төймә генә калмады,— диде Рәмзия ап-ачык итеп.

— Беләм... Шунысы гына аяныч, ике елда ике тапкыр тол калдың.

— Хәзер җиңелрәк...

Рәмзия, ниһаять, җылап җибәрде...

Беренче кырпак төшкән октябрь таңында Рәмзия тыпырдап торган малай тапты. Мәфтуха кендек әбисе булды.

Малайга Мәрдән дип исем куштылар. Авыл советында «Рәхмәтуллин Мәрдән Зәбир улы, туды 1942 елның 27 октябрь числосында» — дип теркәделәр.

Бәби чәе эчәргә кергән күрше-күлән:

— Шушы тиклем ошаса да ошар икән, нәкъ менә Зәбирнең үзе инде, суйган да каплаган,— дип, шатлана-шатлана Рәмзиягә күчтәнәчләрен, бүләкләрен тапшырдылар.

Тәүге карлар очкан кичләрнең берсендә Илайларның өлкәне Зәбирнең әнкәсе Миңлезифа карчык та кыптырдап аларга килеп җитте, онытын кулына алгач, озак кына текәлеп торды, тонык күзләрен яшь белән юып:

— Төпчегем, Зәбирем икән шул! — диде.

Кыш урталарында Рәмзия белән Миңлезифа карчык бергә тора башладылар...

*1969—70 еллар.*
*Займище — Казан.*



**Равил Фәйзуллин**

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### I

* * *

Кояш бата...
Нарат очларында гына
соңгы нурлар әзрәк янасы...
Тиен булып сикереп, шул нурларда
килә иркәләнеп каласы!

Әнкәй күзләрендә соңгы якты сүнә...
Ярты дөньям сүнә... Шашырлык!
Юньле гамәл кыла алырмынмы Җирдә
теге дөньяларда кавышырлык?..

### Җәй ахырында язылган шигырь
яки
### юбилейдан соң...

Качарга миңа, китәргә
бу чытык кәефтән!
Дөрес, мин картлыкның
җәтмәсенә эләккән!..

Йә, хода, мин гомеремне
ярты гасыр кичкән?
Ә кемнеңдер ул гомерен
төрмә-зиндан «эчкән»...

Гыйбрәт ал ятимнәрдән,
гарипләргә кара...
Нәселеңнең агымында
син әлегә — кораб!

Сөенә бел, бәйдә түгел
«чатлы багана»да[1].
Син һаман үзәктә әле
Җиһан яңарганда!

Кирәксә — тау бул, кирәксә —
үзән булып кал.
Кешеләрне рәнҗетмичә
Үзең булып кал!

Онытма, син Мәхәббәттә
сәбәп кенә түгел!
Шигърият язмышында
сәдәп кенә түгел!

Сулышыңа карап җырла,
күрсенмә, йә күрсен.
Язмыштан сора илереп:
җиңел үлем бирсен!

## Эз

Җир. Галәм. Дөнья үзе
тора гел хәрәкәттән.
Җанлының һәр кузгалышы —
бер эз ул бәрәкәткә,
яисә һәлакәткә...

Вакыт мәңгелек саналса,
тере матдә булса — җан,
Гомер кардиограммасына
һәрбер эзең салынган.

Күзәнәкнең күчешен дә
эз дип санарга була.
Иманлы икән максат-эзең —
хәтта яңырга була!

Бер максатка җиттем дисәң,
яңасы алга баса.
Эзләнү дә «эз» сүзеннән
алынган икән ласа!

...Сабый яңа тәпи баскан.
Җирдә беренче эзе!
Сизми — үзен күзәткәнен
бөтен дөнья күзе...

[1] Заманында хатыннарына хыянәт иткән азгын ирләрне баганаларга бәйләгәннәр дә,— аякларын ике ат белән як-якка тарттырып ботарлаганнар.

## Гомер-очкын...

Төнге учактан сикереп очкын,
иярмәкче иде дә җилгә
(җилнең җилфер ялы мәңгелек!)...
керфек тибрәнеп алганчы,
караңгыда эреп юк булды.

Тартыш-көрәш,
сөю-яну сыйган
безнең яшәү ласа бу мизгел!
Гомер сурәте лә бу очкын...

## Яңа кабер

Яңа гына соры балчык өеме иде.
Көрәкләр биегән өслектә
әнә хәзер — кызыл гөлләр...

Чын төсләр соңрак булыр:
җәен — яшел,
кышын — ак кар
җил-яңгыр иңдергән
озынча түмгәктә.

## Язгы бер тойгы

Колакка тыгылган мамык күк
чокырлар эченә кар яткан.
Ләйсән ява коеп. Шул юештә
Кызлар итәгенә ут капкан!
...Минем дә гамьле уй, онытылып,
яшендәй атылды яшь чакка!

* * *

Байлыгыңны кочаклап ят
картлык чүлмәгең белән!
Мин синең сатлык күзеңнән
кендегем белән көләм!

. . . . . . . . . . .

«Ялганчы!» сүзе дә сиңа
аз шул,— ярамас инде.
Әгәр Оятның күзе булса,
сиңа карамас иде!

...Мин исә — түбәнлегеңә
Биектән карап торам.
Тимим. Язмыш үзе сине
вакыттан талаттыра.

* * *

Төрле чагым булды —
ярлы, бай чагым...
Ә күңелдә һәрчак
ШАТЛЫК йөрттем
яшереп тә...
Ә кайчакта —
бар дөньяларга кычкырып!

Шул коткарды мине
бүгенгәчә.

## II

* * *

Дүрт кылым бар иде Сазымда.
Берсе сүзем иде — аңламадылар.
Берсе көем иде — тыңламадылар.
Берсе күзем иде — карамадылар...
Тик бер кылым калды хәзер, —
ул — Син!

Җанны аңлап карыйсыңмы?

Туры карый алырсыңмы?
Тыңлый-тыңлый арырсыңмы?

Хак тәгалә белә микән?..

* * *

Язмышымда упкынмы Син?
Әллә — төп терәк?
Ирексездән тамыр җәйдең,
җанда Гөлтирәк!

Болай да ярсулы йөрәк —
булды кушйөрәк.
Сине кисеп ташлыйм дисәң —
кушкылыч кирәк!

Теләсәм андый кылычны,
бәлки, табармын...
Тик аны үз күкрәгемә
ничек кадармын?

## Ул камышлар...

*...Без — шигырьдә кавыштык.*

Ул камышлар серлелеген
аңлар өчен яшь шул Син!
Гомерләрнең аермасын
тамырлары яшерсен.

Ул камышлар әйләндеме?
Безнең башмы әйләнде?
Күзеңдәге очкыныңнан
күңелемә нур иңде.

Ул камышлар колагыңа
миннән нинди сер әйтте?
Тәнеңнең калтыраулары
акылымны исәрәйтте...

Ул камышлар өскә ава —
билне ныграк кыс сана!
Тәннәр ялкын. Тирә-юньдә
тоташ яшел ут яна...

. . . . . . . . . . . . .

Ул камышлар сызлангандыр
сынганда, сыгылганда...
...Кыяклар кисә бәгырьне
ө-з-е-л-е-п с-а-г-ы-н-г-а-н-д-а!!!

* * *

Париж түгел, Пар-Иш! —
Безнең атамабыз!

Иш-Пар булып яратканнар
безне — Ата-Анабыз.

...Шуңа да Ир белән Хатын
диеп аталабыз!

* * *

Тапканга артык сөенмим.
Соңрак — күбрәк югалтам...
Ни бәрабәргә икән дим,
Сине бүләк итте таң?

Якты чакта көне буе
Сине уйлап егет мин.
Төнен «тота» сискәндереп
«Картлык» дигән рэкэтмен.

## Син әлегә яшьрәк бит!..

Күзгә кара төндә тамды күз яшем.
Нидән тамды?
(Ак кәгазьдә йолдыз чагылды).

Искә алдыммы —
Вакыт — бәләк-чукмар булып
тетеп, сытып киткән Гомерне?

Язгы алсу таңда тамды күз яшең.

Нидән?

## Борчылма!

Караңгы төннәрдә,
шомлы җил шавыннан
сискәнеп уянсаң,
сыену табырлык,
юата алырлык
кадерле кешең бар —
борчылма!

Кайгылар ишәйгән
борчулы көннәрдә,
күңелең тулышып,
сыгылып төшкәндә
тураеп торырга
таяныр кешең бар —
борчылма!

Акылың җуярлык
шатлыклар килгәндә,
Җир хисен югалтып,
Күккә ашам дигәндә,
кочагыңнан чыгармас
ышаныр кешең бар —
борчылма!

## Сискәнү

— Икебезгә бер очтан кистереп алдым.
— Бергә күммәсләр шул...
(фараз-диалог)

«Мәңгегә бергәбез!..» диеп
кәфенлек бүләк иттең.
«Мәрмәр!» дип йөргән гомерне
бу гамәлең көл итте.
Вөҗүдне өнсез итте.

Җавапсыз калмыйм, диеп мин
Сиңа гөл бүләк иттем.
...Соң эшем: ләхет катында —
яңа чәчәкләр көтү.

III

## Гел «Җиңү»дән торган гомерләр!

Бер матур май көнне
торабыз, имеш, Күк катларында
чиратта.

Киенеп-ясанып килгәнбез.
Тагын чыктылар медальләр:
«Әрәм үткән гомер өчен!»

* * *

Бетте ул,
          бетте ул,
                    бетте ул
Кешегә ияреп көлүләр!

Болай да артымда бер көтү
тилеләр шаркылдап йөриләр.

## .Төн

Үләксә исеннән
исәргән ялгызак бер Шакал
Күккә карап оеп улады...

Йомры Ай аяз күктән
тулышып балкып тора!

## Күренеш

Балконнан карап торам.
Күләгәң очында кош тора.

Үттең — киттең!
Кош калды — асфальтлы җирдә.
Сурәтең — калды күңелемдә.

## Бу көн...

Еланнар терелгән көн...

Сират күперен чыкмый гына
акчалыларга җәннәткә
юллама бирелгән көн.

* * *

Уйландым: минем гомерем
«ике-икең — биш»тән тора...
«Яшәдем!» дигән бер фигыль
сиксән килештән тора!

* * *

Төбенә хәтле эч син Мәңгелекне!
Шәүлә-узгынчылар ялмансын!

...Корыр чам да, шулай торадыр күк
гел яшь, яшелмен, дип алданып.

* * *

Син күргәндә яшен инде үлгән була.
Без күргәнне Яшьлек күптән күргән була...

Эч пошырып янда: «мин яшьмен» дип,
маймылланып Картлык йөргән була...

* * *

Урыска рәнҗеп туелган.
Төреккә — ерак...

...Кош булып, күңелем аша
елый туфрак.

* * *

Ялгызлык гаҗәп нәрсә ул —
Өметең исән чакта.
Иш яралган ялгыз берәү
уйласа синең хакта.

## Ятим

«Минем бер нәрсәм дә юк!
Мин гел «юк»тан торам...»

Кайдадыр бүреләр улый.
...буран котыра.

## Быелгы бу кара ел...

Апрельдә җәй булды.
Талантлар — кырылды...

Берничә бөртек калды
Шигърият кырында!..

* * *

Син мине бүтән каргама!
Каргасаң — җаным туңа.
Каргышыңнан үзеңдә дә
Яңа борчулар туа.

## Сугыш соңы еллары бу...

Букча аскан теләнче карт,
көртләр ерып,
Айга карап юл бара.

## Шулай була еш кына...

Төбәп еракка мылтыктан аттым.
Аяк арамнан бер куян чапты.

* * *

Уйнаш-көлеш, көлеш-уйнаш!..
Соңы була — җанны кыйнаш...

## Бу заманда

Хакыйкатьнең күзенә карап,
күңелдән чәчрәп яшь чыга!



## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Зәки Зәйнуллин**

# ӨЧ ХИКӘЯ

Кыз куенына кергәнче...

**1941** елның ноябрь азаклары. Тышта карлы, җилле буран. Ә землянка эчендәге мич янында җылы. Мәскәү өчен канкойгыч сугышлар бара. Урал — Идел арасыннан китереп тутырылган татарлар да бик күп бу сугышларда. Шуларның бер төркеме бүген кич мич тирәсендәләр. Сагынган авылларын, бала-чагаларын, хатын-кызларны исләренә алып, байтак утырдылар. Шул, төрле сөйләшүләр арасында берсе Гыйният Папайга мөрәҗәгать итте:

— Карале, Гыйният! Син егет чагыңда, Зәйнәп артыннан йөрегәндә, теге Югары очтагы Лотфулла Чулак йортында, аулак өйгә керәм дип, бик кызык маҗарага эләккәнсең, дип сөйлиләр иде. Шуны үзеңнән ишеткән юк, әй. Сөйләле шуны, ә?

Гыйният көлеп җибәрде:

— Кит, Сәйфи! Аны сөйләсәң, үзеңнән үзең көлү була бит, инәңнең күлмәге! Чыннан да, адәм көлкесенә калдым бит мин анда, Зәйнәп белән кунам дип...

Утка керосин салды бу. Бердәм булып шаулаштылар:

— Сөйләле, Гыйният!

— Ялындырма инде, Папай! Син кызык итеп сөйли беләсең бит...

— Тартынма, бар да үзебезнекеләр монда...

Гыйниятулла авылдашларына шаян очкыннар чәчеп торган күзләре белән карап алды:

— Ярар алайса, тыңлагыз! Сөйлим әле! Яшьлек юләрлеге бит. Ошамаса, гаепләштән булмасын...

Егерме алтынчы елның көзе үтеп, яңа гына йомшак, ак кар төшкән чак иде. Аулакка дип, авылның Югары очына менеп киттек. Ни өчен Югары оч дисәгез, сәбәбе бар аның. Минем Зәйнәп белән бик кызып йөрегән чак. Ә Югары оч Лотфулла Чулакның хатыны Зәйнәпнең үлгән әнисе белән бертуган бит инде, анысын үзегез беләсез. Киттек шул Лотфулла Чулакларга менеп. Казак Газизе гармун тарта, мин сиңәйтим, түзсен генә йөрәкләр! Мин үзем ул гармун тирәсен белмим бит инде, юк белән мактана алмыйм. Газиз, алай-болай югары очлар белән сугыш чыкса, дип караган иде, мин тегене тиз бастым. Мин әйтәм, югары очлар үзебезгә биргәләүләре ихтимал, тик мал кадерен белә торган халык бит

алар, дим. Күбесе вак-төяк белән булса да сәүдә итә торган адәмнәр, тими алар гармунга, дим. Газиз әйтә, тимәсләр сиңа, ди. Ярар, мин әйтәм, җир астыннан тапсам табармын, яңасын алып бирермен, дим тегеңәргә. Киттек менеп. Таш күперне чыкканда кычкырып җырлап җибәрдем, мин сиңәйтим, белеп торсыннар югары очлар Папай Гыйниятe менеп килгәнен. Газиздән башка тагын өчәүне ияртем: Әбеч Хәмитен, Ташкергән Һадиен, Әбеч Сәхиен. Хәмит бармаска итеп карышып караганые, сугышалар алар, дип, аңа әзрәк биргәләп алырга туры килде. «Нәрсәдән шүрлисең, минәйтәм, без бит синең белән Абсаттарлар нәселеннән!» Мин әйттерәм, миңа ияреп — болар. Һади тумыштан чатан бит инде, ике таяк моның култык астында. «Тук та тук» бу түн юлга теге таяклар белән. Вәт, чукынчык әй, анда сугышалар дип ник бер сүз әйтсә, атлавы атлау чатанның. Тавышы да көр генә. Базар урамын үттек, безгә каршы ул-бу дәшкән кеше юк. Хәниф бай кибете мөешеннән борылганыек — торалар болар. Сөйләшеп куелган буенча, Газиз гармунны тарттыра, мин сиңәйтим, чыда гына. Туктау юк, үзебез җырлыйбыз, үзебезнең баруыбыз бару. Әмма санап-барлап чыгарга да өлгердек боларны. Төп-төгәл алтаулар. Кар яңа төшкән вакыт, читән буйларында кош-корт юк бит инде. Газиз белән мин — алдан, теге өчәү — арттан. Мин чыкканда ук, сугышырга җиңел булсын дип, калын киенмәгән идем. Шуна күрә атлавы да җиңел. Бишмәтне салып очырсаң, аларга тотынырга урын юк бит инде. Сугыш башланган көйгә тәгәрәткәнче берсенә бирәсең дә, шул уңайга читкә сикерәсең. Тик бер җиреңне дә тоттырма. Тотсалар, аннан соң яткырып кыйный башлыйлар, җибәрмичә. Бик уяу булырга кирәк. Теге Хәмит Пиреч кебекләр андый чакта казыкка үрелә башлый. Эш аңа китсә, хәтәррәк инде.

Тик ул кичне сугышырга туры килмәде, йодрык белән дә, казык белән дә. Әйе, шуннан киләбез җырлап «Гәзизәкәй»не. Без килгән Кибет тыкрыгы киң бит ул. Нәкъ тыкрык уртасында Таһир Женнең, Күчер Латыйф бабайның капкалары. Шул җирдә торалар болар — алты егет. Барысы да югары очлар. Чамалап киләм тегеләрнең кем икәнен: Балак Фәррахе, Бугаз Кәбире, Әптә Миңнеәхмәте, Гршавай Зиннәте...

— Мин дә бар идем анда...

— Ы-ы! Гали дә шунда тора олпат гәүдәсе белән иң артта...

— Ярар. Килеп җиттек яннарына, кузгалмыйлар бит болар. Бастык каршыларына килеп. Дәшми үтеп китәргә ярамый, арттан бирүләре бар. Тегеләр дә — шым, без дә. Шуннан Бугаз әйтә: «Нишләп йөрисез монда, адашкансыз бит?» — ди. Мин әйтәм: «Кайтып барабыз Түбән очка, Атарванывка аша», — дим.

Тагын көлешеп алдылар. Чөнки авылның Атарванывка дип йөреткән урамы Югары очтан да өстә булып, Түбән очтан әнә шул Югары очны үтеп барасы.

— Йә, йә, Гыйният, шуннан?

— Шуннан, Әптә әйтә: «Безне дә ияртегез әле, гармуныгыз да бар икән», — ди. Сугышасы да килә болар белән, Зәйнәп белән дә кунасы килә бит, малай! Нәрсә эшләргә?..

— Кая берне кабызыйк әле, йөрәкнең әллә кайсы җирләре кузгалып китте, малай, рәхәт итеп...

— Әйдәгез, мин әйтәм, гелән генә сугышырга димәгәндер бит инде...

Алдан котыртып торырга ул кичне теге Пиреч Хәмите булмагач, болар да тынычлар. Киттек җыйнаулашып, өскә менеп. Әптәнең тавышы ниндилеген үзегез беләсез бит инде. Ул башлап алып китә «Урам көе»нә, без кушылабыз. Җыр өзә үзәкләрне! Шундый чакларда минем иллә дә яписе килә инде, егетләр!

Менеп җиттек Лотфулла чулакларга. Кердек йортларына. Тәрәзәләре эчтән томаланган, утлары күренми. Ә эчтә чыркылдашканнары ишетелә кызларның. Аллага шөкер, монда болар! Тыңлап, тыңлап карый-

быз, тик аңлап булмый, нәрсәледер уйный болар. Тәрәзәдән караучы да күренми. Әйтерсең, без юк ишек алдында. Шул хәтле җырлап килгәнне ишеттеләр бит инде, саңгырау түгелләр. Тәрәзә чиртеп карыйбыз, тавышлары бетте, тик ишекне дә ачмый болар, тәрәзәдән дә карамыйлар. Нигә икәнен азактан гына белдек. Лотфулла чулак Гәйнәгә сеңлесенә кунака киткәндә, күршеләре Шөшле Хәдичәсен калдырган икән йорт карарга. Шул албасты карчык ачтырмаган тегеләрдән: «Ачсагыз, кайткач Лотфуллага әйтәм»,— дигән. Ярар. Сәгатьтән артык булашып карадык — юк кына бит малай, кертмиләр. Шуннан әлеге Бугаз Кәбире әйтә: «Синнән дә рәт чыкмады, Гыйният, иң яхшысы сезне тыкрыктан үткәрмәскә булган икән»,— ди. Китте минем кан кызып. Чыннан да, мин, Гыйният булыйм да, керә алмыйм, имеш. Өстәвенә Зәйнәп өй эчендә бит инде. Аның, ай-һай, шәп чагы иде малай! Кочаклыйм дисәң, үзе елышып сылана да куя, берәр җиренә кул тисә, өйрәтелмәгән кырыкмыш тай кебек сикереп-сикереп китә инде...

Шуннан, бүрекне кырынрак салып уйлап тора идем, нәрсә эшләргә икән дип, теге Чатан Һади уйлап чыгармасынмы нәрсә эшләргә кирәк икәнне! «Әйдә, өй башларына менеп, морҗа төпләрен чокып төшик»,— ди бу миңа. Чатан диген инде син аны, этлеккә ясап куйган кебек. Каян уйлап таба диген. Күршеләре Шагырларның баскычларын алып кереп, өйләренә сөяп куйдык та, киттем мин менеп түбәгә. Ә дигәнче морҗа төбенең саламын йолкып, бер зур гына тишек ясадык та, мине кулдан тотып шул тишектән өй кыегы астына төшерделәр. Ярар. Вәт шунда инде аның иң хикмәтле җире башлана.

Лотфулла Чулак теге Герман сугышыннан уң кулын өздереп кайткан бит ул. Гомере буе сыңар кул белән ничек эшләсен инде авыр эшне. Көзге көннәрдә шул, халык суйган мал тирәсендә йөргәләп, эчәк-бавырны арзанрак хакка алып, шуны тазартып, кадаклап базарда сату иткән була. Шул эчәкне җыеп тутыра торган зур бер чаны бар икән моның. Аның шулай икәнен җен белсенмени инде, анда барып йөргән булмагач. Ярар. Мин хәзер салам түбә астына төшеп сәрмәләнә башладым. Караңгы тегендә, күзгә төртсәң дә күренерлек түгел. Шырпы сызар идең, шикләндерә, ут-күз чыгаруың бар. Кайда абынып, кайда сөртенеп, кайда үрмәләп, түшәм читенә килеп җиттем. Килеп җиткәнче ару гына итеп ике тапкыр маңгайны да бәреп алдым. Шуннан соң өй ишегенең кай тирәдә икәнен чамаларга итәм, юк, белеп булмый. Чөнки мин Лотфулла Чулакның өенең ишеген күрү түгел, кайсы якка ачылганын да белми идем. Ярар. Төшәргә кирәк бит инде хәзер чоланга. Кул белән ябышып, гәүдәне аска салындырып, ике аяк белән кармалап карыйм, берәр нәрсә дә юк бит, анасын саткыры. Шуннан, ни булса — шул булыр, дип, Аллага тапшырдым да, сикердем түбәнгә. Сикердем и чулт теге, сасы эчәк тутырылган чанга!

Мич эчендәге ялкыннарны селкетеп, землянка эчендә көлү авазлары яңгырады. Кайсысыдыр яткан сәндерәсеннән егылып төшә язып, көлүнең көчәюенә тагын да өстәмә сәбәп булды. Авылдан чыгып киткәннән бирле Зирекле егетләренең болай шашып көлгәннәре юк иде шикелле. Бу турыда беренче тапкыр ишеткән Абдулла Акмалов, күз яшьләрен гимнастерка җиңе белән сөртә-сөртә, Гыйнияткә ялварды:

— Шуннан, Гыйниятулла абзый, шуннан?!

— Шуннанмы?

— Ы-ы?

— Шуннан, шул инде. Түбән очның атаклы егете Папай Гыйнияте бугаздан эчәк бугы эчендә. Шул, шуннан соң...

Көлешүнең азрак басылганын көтте дә дәвам итте:

— Баш кына чыгып тора сасы судан, ә аяк чанның төбенә дә тими. Чанның кырына тотынып чыгарга итеп карыйм, кул белән тартылам, юк, булдырып булмый. Теге чанның эче аска табан киңәя икән. Төбе авызыннан зуррак. Ярар, көч-хәл белән, ничек җитте алай чыктым мин тырыша

торгач. Ярый әле, без моржа төбен чокый башлагач, Газиз гармун уйнатып егетләрне биетә башлаган иде. Өй эчендә кызлар, күрәсең, шуларны күзләгәннәрдер инде, иллә минем чанга төшкәнне сизмәгәннәр, әй. Ишектәге келәне табып күтәрдем дә, сыз ишек алдына. Ишек ачылганны ишетеп, егетләр йөгерешеп килгәннәр иде, мине күргәч, башта аптырап калдылар, аннары эчләрен тотып көләргә тотындылар. Ул өстән ага, ул үзем буялган, ул сасысы тегенең, мин сиңәйтим. Кая ди инде ул аулакка керү кайгылары! Нишләргә хәзер? Әптә әйтә, әйдә безгә киттек, берәр юнен табарбыз әле шунда, ди. Кит, мин әйтәм, монау көйгә мин ничек барыйм сезгә, дим. Газиз әйтә, әйдә елга буена, шунда юарбыз киемнәреңне, ди. Киттек төшеп. Югары очлар да безнең белән. Мин, сез егетләр, барыгыз, үз эшләрегезне карагыз, дип ычкындырган идем, Бугаз әйтә: монау хәтле кызык ташлап китәргә әллә син безне дүрәкләр дип беләсеңме, ди.

Инешкә төшеп җиткәч, мин баштанаяк чишенеп ташладым. Бүрек кенә коры, калганнары тоташ буялып беткән. Миңа кайсы тунын, кайсы чалбарын, кайсы күлмәген салып бирде. Утырам яр башында дер-дер калтырап. Әй юалар тегеләр боз ватып минем киемнәрне чайкап-чайкап, әй юалар. Нык юдылар инде, рәхмәт егетләргә. Шуннан, юып бетергәч, Әптәләргә барып, тегеләрнең мунчасын яктык та, киемнәрне киптердек. Ярты төн үткәч кенә көлешә-көлешә таралыштык...

Иртән иртүк, теге Лотфулла чулак йортында күз-колак булып калган Шөшле карчыгы безгә туп итеп килеп тә җиткән. Туп-туры безгә. Иртәнге чәйне эчеп утыра идек, килеп керде бу. Чәйгә кыстап карый әни моны, утырмый бу. «Нәфисә кызым, синдә киптергән аксыргак бар дигәннәрие, шуны әзрәк бирмәссеңме дип килгән идем, ди. Колагымның эче шешә башлады, шуңа ябарга иде»,— ди бу. Үзе сорый — үзенең күзе миндә. Әнинең җавабын көтеп тормады, тагы икенчене сөйли дә башлады бу. «И-и-и илаһикәрим, Гыйниятуллаң, чын ясау, дастуен егет булып үскән икән, ди. Өйләнергә дә вакыты җиткән инде,— дигән була.— Минем күз күргән менә дигән кызларым бар, берәрсен димлимме әллә үзенә?» — ди. Минем әни нәрсәдер сизенде, ахрысы, теге карчыкка ияреп китте. Үзе мине мактый: «Әйтмә инде, Хәдичә түти, зерәләр дә үсте, атасының кул арасына ныклы керде монавы ике-өч ел эчендә, ди. Бүген дә караңгылыяктыда чыгып киткән ие, бөтен мал-туарны карап, эчереп, абзарларны тазартып керде әле»,— ди. Янәсе, минем өйдә кунганны белдерә инде теге убырлы карчыкка. Әни тегене кыстый-кыстый табынга утыртты. Бер самавыр чәйне эчеп бетереп, кайтып китте теге.

Атнага якын белә алмадылар теге чанга кем төшкәнен. Югары очлардан да чыкмады, бездән дә. Чыгар иде, Лотфулла чулак әтиләргә әйтеп, барыбызның да кирәкне бирдертә бит инде аннары. Бер атнадан артыграк вакыт үткәч, теге эш барыбер килеп чыкты бит, әй! Бер көнне кич бәрәңге ашап утыра идек, әти мәрхүм миңа болай ди: «Син, малай актыгы, төнлә нәрсә эшләп барып кердең анда Лотфулла чулакның сасы чанына?» — ди. Мин дәшмим инде, кая ул дәшү. Аңардагы кул бит. Үзегез белә торган идегез инде нинди кеше икәнлеген. Бүген сукса, иртәгә дә яңаклар кызышып йөри торган иде. Мин дәшмәгәч, әзрәк басылды да әнигә әйтә: «Мин хәзер чыгып ятам, сөйләш малаең белән үзең генә. Өйләндерергә вакыт бу юньсезне,— ди.— Әгәр үзенең күзе төшкән берәр нәрсәсе булмаса, иртәгә мин үзем табып бирәм аңарга менә дигәнен,— ди бу.— Җитәр аңа, минем йөземә кызыллык китереп, Югары очта моржа төпләре тишеп йөрергә»,— ди. Аныкы сукты да, күпте дә бит инде, әйтте — бетте. Әнигә, иртәгә әйтермен, дип, киттем чыгып. Бардым инде эзләнеп Ике Су арасы Төхфәтнең өе янына. Байтак йөредем Зәйнәпне сагалап, юк бит, малай. Шуннан киттем башка чыккан абзасы Ибәткә. Чатан булса да, ир-егетнең шәбе ул минем Ибәт кайнага. Өенә кереп сөйләштем моның белән икәүдән-икәү генә. Җибәрде бу хатынын Зәйнәпне алырга.

Шунда сөйләшеп килештек икәү. Киттем кайтып. Әллә җирдән, әллә күктә очып кайттым, әле дә белмим шуны. Икенче көнне үк яучылар җибәреп, сүз дә куешты әтиләр. Ай үтүгә гөрләтеп туй да ясап ташладык. Зиреклене дер селкетеп...

Гыйният сүзен бетереп, дәшми утырды да янчыгын чыгарып, тәмәке урый-урый, өстәп куйды:

— Менә калды инде хәзер Зәйнәбем минем дүрт бала белән бер ялгызы. Фәридә, Халит, Фәрит, Флүрә. Ниләр генә күрәселәр бардыр инде егетләр, Ходай үзе сакласын. Арка белән Мәскәүгә килеп терәлдек бит. Моңарчы бөтен мәмләкәтләрне җиңеп килде бит бу Гитлер мәлгунь. Танклары, самолетлары, автоматлары күп нимеснең. Нык кырыла безнең халык...

Землянкада тынлык урнашты. Әле генә шартлардай булып көлешкән кешеләрнең һәркайсы үз уена батып, үз кайгысында йөзәргә тотынды...

## Фатыйма

Нурислам үзләренең Каенүзәк мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, атасы аны Пугач патша вакыйгаларыннан элек үк тирә-якка даны таралган Зиреклебаш мәдрәсәсенә укырга илтеп бирде. Кышын ул шунда ятып укыды, җәйләрен үзләренең авылында атасына булышып үткәрде. Мәдрәсәдә укыганда икенче кышны ук Фатыймага күзе төште аның. Балалыгы үтеп, буй җитә башлаган Фатыйма авылдагы иң чибәр кызларның берсенә әйләнеп бара иде шул. Зифа буйлы, эшкә дә уңган булып, уналтысы тулып килгән чакта кызый Нурисламнан гыйшык хаты алды. Имәндәй таза гәүдәле Нурисламның аны язарга сүзе дә, башы да җитмәс иде, мөгаен. Үзе дә шуны аңлап, сабакташы, ышанычлы шәкерт дусты Тәтер Арслан егете Зөлкарнәйгә гыйшык серен ачты. Тегесе мәсьәләне тиз аңлады. Шул көнне кич үк алар икәүдән-икәү генә Зөлкарнәй атасының солдатташ дусты Ситдыйк Бүреләрнең мунчасына кереп утырдылар да Мөхәммәт Шакир мәхдүм кибетеннән сатып алган шәм яктысында Фатыйма чибәргә хат язарга тотындылар. Зөлкарнәй нәрсә язасын хатның башында Нурисламга әйтте. Тегесе, аңлап бетермәсә дә, ризалыгын белдереп баш какты. Зөлкарнәй аннан соң гына, кәгазь битенә ул сүзләрне тезәсе итте. Нурислам әле дә аптырый: шулкадәр йөрәктән чыккан ялкын кебек гөлтелдәп торган сүзләрдән ничек ул кәгазь битләренә ут капмаган икән дә, ничек үзләре шул мунчада янып үлмәгәннәр икән?!

«Кайсы җирләре ошый соң кызның?» — дип сорады Зөлкарнәй, сәлам сүзләрен язып бетергәч. «Чишмәгә суга барганы»,— диде Нурислам. Шуңардан соң, Зөлкарнәй хатка болайрак итеп тезде: «Синең иртән искән җилләрне ияртеп, тәңкәләреңнең чыңлаган тавышлары белән безнең ки яшь йөрәкләребезнең мәхәббәт кылларын кузгатып үтеп китүеңә түзәр әмәлләребез калмады».

«Тагын нәрсә эшләгәне ошый?» — диде Зөлкарнәй. «Тешләрен күрсәтеп елмайганы»,— диде тирләп чыккан Нурислам. Шуңардан соң Зөлкарнәй болай дип язып куйды: «Энҗе кебек ап-ак тешләрең арасыннан чыккан сүзләреңне ишетеп, елмайганыңны да күреп калсам, ул көнне дәрестә хәлфәләр сөйләгәнне аңламыйча тал чыбык белән сугыласымны белеп барам мәдрәсәгә. Аркам буйлап тал чыбыгы чыжылдап йөрегәндә дә, һәрчак синең шул елмаюларыңны уйлап назланам». Мәхәббәт тирәсендә тәҗрибәсе күп булган Зөлкарнәй, хатка шундыйрак җөмләләрне тезә-тезә, бер утка тыкты Нурисламның зур гәүдәсен, бер суга салды. Хатны язып бетергәндә Нурислам шабыр тиргә төшеп, берәр нәрсә аңлаудан узган иде инде. Азаккы җөмләне, шунлыктан, Нурисламнан

сорамый гына Зөлкарнәй үзеннән өстәп куйды: «Ай туган күк йөзендә. Тик, ул Ай тулганда, сиңа булган мәхәббәт утларында янып бетеп, мин көлгә әйләнгән булырмын инде».

Зөлкарнәй кебек ир-егетләрнең асылы сирәк дөньяда. Тик япун сугышыннан кайта алмады. Порт-Артур дигән калада ятып калды башкайлары...

Шул хаттан китте инде Фатыйма белән качып-посып күрешүләр, тәрәзәләре эчтән томаланган өй эчләрендә сирәк-мирәк очрашулар, ул гыйшык хатлары, ул янчык-кулъяулык, алка-йөзекләр алмашу. Өйләнү турында сүз кузгаткач, Нурисламның атасы, кырма сакал-мыегы астыннан елмая төшеп, азрак уйланып эндәшми торды да бер генә сорау бирде:

— Эшкә уңганмы соң?

Нурисламның тотлыга-тотлыга биргән җавабын тыңлады да, эшне озакка сузмыйча, Зиреклебашка яучылар да җибәрде. Тик эшләре уңмады: Фатыйманың атасы Калтай Вагыйз яучыларны кире борды. Килгән яучыларның тәмле телләрен тавыш-сүз чыгармыйча тыңлады да:

— Санга сугып килгәнсез, рәхмәт. Сүзегезне тыңладык, аңладык. Тик гаепләштән булмасын. Миндә Чуаш Тавы ягына бирә торган кыз юк. Бердән, тискәре як, икенчедән, бездә — Зиреклебашларда сезнең якларга моңа кадәр кыз бирү йоласы булмады. Өстәвенә, ни олы урманыгыз, ни юньле суыгыз юк. Сезгә биреп, кызымнан гомер буе тизәк таптатасым килми,— дип сүзне бетереп куйды.

— Соң бит кем, кода буласы кеше, Вагыйз кордаш, ике яшь күңел бер-берсен ошатканнар икән, без аларны кавышудан мәхрүм итмик инде. Аннан кызыңның төшә торган җире дә бик әйбәт. Ул ата-анасы егетнең: киң күңелле, инсафлы, мал йөртә белә торган кешеләр. Ул агай-энесенең зыялылыгы, уңганлыгы! Сезгә кода була торганнарның дөньялары бөтен, мал-туарлары бик тә күп, йорт-җирле кешеләр...

— Ул нәрсәләр безнең үзебездә дә җитәрлек. Кешегә сорап чыкканыбыз юк, Аллага шөкер, эшлибез. Сүз безнең яктан шуның белән бетте, йәгез, амин тотып, хуш иттек...

Яучылар китте...

Алар киткәч, күзләрендә өмет сүнде Фатыйманың. «Кызың егетләр белән чуала, син, күзең чыккан, нәрсә карадың?» — дип, Фатыйманың әнисенә дә āру гына эләкте. Тик ишек алдыннан йөгереп кергән энесе Кәрим атасының кулыннан чыбыркыны тартып алып, гәүдәсе белән әнкәсен каплады. Ундүрт яшьлек малай гына булса да, курыкмый иде Кәрим атасыннан. Әнкәсенең аркасындагы чыбыркы эзләренә балавызлы май белән сөрткәндә, әнисе, Фатыймага әтисенең яучыларны нигә кире боруының сәбәбен ачты:

— ...Каһәр суккан Калтай! Мәртәт! Үзенә шул Каенүзәктән кыз бирмәделәр аңа егет чагында. Йә, инде, шуны онытмаган бит, бөтен очраган каенүзәклеләрдән гомере буе үч ала. Сине анда биргәч, кодакодагый дип барып йөрешергә кирәк була бит инде. «Кайсы Вагыйз?» — дисәләр: «Соң теге елны безнең авылдан кыз бирмичә борганнар иде бит, шул Вагыйз инде»,— диячәкләр. Шуңа күрә бирмәде ул сине. Ярар инде, кызым, язмыштан узмыш юк, дигән бабайлар. Өлешеңә тиеше чыгар әле, Алла бирсә, елама! Син ул Каенүзәк егетен берүк оныт инде...

Чыкмады бүтән Фатыйма аулакларга да, кич утыруларга да. Нурисламнан хат алып килгән малай-шалайны да кире борып җибәрде. Курыкты әтисеннән Фатыйма, аннары әнкәсен дә кызганды. Язмыштан узмыш юк, дигән сүз белән килеште.

Тик Нурислам аны оныта алмады. Яучыларның юлы уңмыйча, буш кайтып киткәч, Нурислам мәдрәсәне ташларга уйлаган иде дә, вакыйгалар исә бүтәнчә килеп чыкты. Эшне көтелмәгән якка Зөлкарнәй борып җибәрде. Барысын да ул оештырды...

...Февраль бураннары кузгалгач, урладылар алар өчәүләп Фатыйманы. Әнкәсе үлгәч кенә белде Фатыйма ул эшләрнең серен. Мәрхүмәгә

гомере буе атап намазлар укыды, корьән чыгартты, гарип-горәбәгә хәерләр бирде, кергән теләнчеләрне һичкайчан да буш чыгармады. Үз кызын урларга ярдәм иткән ана кеше. Яратмаган ир белән гомере үткәнгәме, әллә яши башлаганнан бирле кызу канлы Вагыйзның йодрыкларын татып яшәгәнгәме, кем белеп бетерсен, Бибигайшә картыннан үзенчә үч алгандыр, бәлки. Ут күршесе, әхирәте Шүрәле Хәсбиямалы белән серләште дә, шуның аркылы Нурисламга әйттерде: «Урласын да куйсын!..»

Төштән соң башланган буран, ут алуга ныклап котыра башлады. Шул кичне мич алдында кыстыбый пешереп маташкан Бибигайшә намазлыкка менеп кунаклаган картына мич мөешеннән үрелеп карады да кызына эндәште:

— Кызым, бар, тиз генә сыерларны савып кер әле!

Тавышы тонык, сәер иде Бибигайшәнең шул сүзләрне әйткәндә. Тик намазлык өстендә оеп утырган Калтай Вагыйз да, кызы Фатыйма да аны-моны сизенмәделәр. Кыз зур агач чиләк, комган белән җылы су, сыер җиленен сөртергә йомшак чүпрәк алды да киенеп, чыгып китте. Чыгып китте дә, шул көе гаип булды. Инде савып бетереп, керер вакытлар үтте, ә Фатыйма юк та юк.

— Бу бала нишләп керми икән, бик озаклады бит? Бар әле, улым, апаңны карап кер, әллә сыер тибеп, чиләген аудардымы икән? — дип, Бибигайшә Кәримне чыгарып җибәрде. Аягына башмак чабата эләктереп, Кәрим кабаланып чыгып китте. Кире әйләнеп кергәндә аның хәле-тыны бетеп, йөзе ап-ак иде.

— Апа юк анда. Чиләк белән комганы гына аунап ята! — диде ул, көч-хәл белән.

Намазлыкта озын муенын бер уңга, бер сулга боргалап, намазын очлап килгән Вагыйз Калтай песи җитезлеге белән ыргылды тышка. Абзарда Фатыйма, чыннан да, юк иде. Читән аша көрт ерып чыгып киткән, инде буран карлар өеп каплый башлаган берничә кеше эзләрен генә шәйләп алды Вагыйз. Күп уйлап тормады, энесе Сәләхнең иң шәп атларын җиктерде дә, чанага күсәкләр тутырып, ике озын сүс аркан салып, алты кеше кыз каракларын куа чыктылар. Вагыйз тиз аңлады бу кем эше икәнне. Атларын февраль бураннарында ак күбеккә төшереп, Чуаш юлы белән куды алар. Тик юллары уңмады. Качкыннарны таба алмадылар. Чуаш Калиновкасын чыккач, каршы очраган юлчыдан төпченеп карадылар: тик бушка. Юлчының өшегән иреннәреннән чыккан сүзләрне ишеткәч, атларын кире бордылар. Чөнки качкыннарның Каенүзәккә бармыйча, бүтән якка киткәннәрен аңлады алар. Арадан берсе:

— Син, Вагыйз кордаш, күңелеңә авыр алма, ай-һай, ул егет кызыңны ерак алып китеп тормагандыр, күптән җылы түшәктәдер инде алар...— дип ычкындырды.

Шул сүзләрне ишеткәч, Вагыйз Калтайның ачуыннан тешләре шыгырдады. Атларны кире Зиреклебашка кудылар...

Уйлары шул җиргә җиткәч, Нурислам һәрвакыт күңелләнеп китә. Фатыйманы эләктергәч, ул төнне алар Каенүзәк ягына түгел, бөтенләй икенче якка сыптырдылар. Күчердә — карчыгадай җитез Тәтер егете Зөлкарнәй иде. Аллы-артлы җиккән ике ат, Зиреклебашны чыккач, Тәтергә хәтле булган егерме биш чакрым араны әллә җирдән үтте, әллә күктән очты. Атлар шәп, чана башындагы Зөлкарнәй кулында озын чыбыркы, ә Нурислам куенында, зур толып эчендә өнсез калган назлы Фатыйма...

Ә мажара болай булды. Кыз сыер саварга чыкканда өч егет читән артында толып тотып, көрт эчендә көтеп яталар иде. Фатыйманың кар яктысы абзар эченә төшсен дип ачык калдырган капкасыннан аңарга Нурислам башта иплән кенә дәште. Эндәште дә, аннан соң нәрсә әйтергә белмичә каршысында басып торган кызны кочагына алып күтәрде һәм читән ягына ыргылды. Фатыйма куркуыннан, бигрәк тә куанычыннан, калтыраган куллары белән егетнең муеныннан кысып кочаклады. Оныт-

маган иде шул ул да сөйгәнен. Фатыйманы тиз генә читән аша алып, егетләр авылның икенче урамына чыктылар. Бүре Садрыйларының ишек алдындагы җигүле чанага тиз-тиз төренеп утырдылар да атларны Тәтер юлына кудылар. Буран улаган карлы урамнар буш иде. Нурислам куенына кереп сыенган Фатыймада әтисеннән курку әсәре бөтенләйгә юкка чыкты. Бер мизгел эчендә ул дөньяда атасыннан да көчлерәк, тәвәккәлрәк ир-егетләр барлыгын аңлады. Бөтен авырлыкны үз өстенә алып, күзгә-күз зур йодрыклы ире белән торып калган әнисе турында да ул: «Берәр юне чыгар әле. Кәрим өйдә бит»,— дип кенә уйлап куйды. Фатыйма өчен артка юл киселгән, алда аны сөйгәне белән яңа тормыш көтә иде инде.

Тәтернең Абдулла мулла аларга никах укып, зөфаф кичәсен рөхсәт итте. Зөлкарнәй шул төнне үк кире Зиреклебашка кайтып китте; ә качкыннар, Зөлкарнәйнең атасы белән әнкәсе йортында калып, шунда атнадан артык тордылар. Ахырда Зөлкарнәй яшьләрне Каенүзәккә илтеп куйды.

— Булды, тынды Зиреклебаш. Бабаң буласы кеше, ике көн элегрәк Әмәтгали дигән берәүне яллап, Каенүзәккә җибәргән. Әтиең шуңа сиздергән: «Улым килен алып кайтты, өйдә инде», дип. Иллә шәп кеше икән, каян белгән, каян ишеткән диген. Кичә чуашлар Калиновкасыннан бабаңның энесе Сәләх белән өч кеше кайттылар. Сине эләктерергә дип, саклап ятканнар. Юл ачык хәзер, өйдә илтеп куям үзегезне»,— диде Зөлкарнәй аларга.

Карлы юллар белән, Зиреклебашны уңда калдырып, урыс авыллары Артюховка, Барановка аша латышларның Банковкасына чыгып, Каенүзәккә кайтып төштеләр. Шул көннәрдән соң Нурислам мәдрәсәне ташлады. Атасы да каршы килеп тормады:

— Без игенче халык, дөньяда шуңардан да изге эш юк. Йөрмә башкача! — диде.

«Калтай Вагыйзның кызын урлаганнар икән»,— дигән хәбәр Зиреклебашта өйләр, урамнар, утырмалар, сиртмәле кое яннары, тыкрыклар буйлап шау-гөр килеп йөреде. «Кем икән? Нинди курыкмас йөрәкле егет икән? Ничекләр итеп урлады икән?» — дигән сорауларны җавапсыз калдырып, авылны гөж китерде. Ай-һай, елгыр иде дә соң ул елларда Нурислам! Өч ел буена Вагыйз Калтай аларны күзенә дә күрсәтмәде. Каенүзәккә үзе дә бармады, Зиреклебашка аларны да китертмәде.

Өч ел тулып үткән бер вакытта Вагыйз әче суык төндә Дидү ягыннан кайтып төште. Йөк тарткан атны, капка ачкан Кәримгә тоттырды да, шыкырдап каткан чабаталарын бер-берсенә бәрә-бәрә, өенә юнәлде. Бусага аша үткәч, иярел кергән суык томаны аша хатыны Бибигайшәнең тантаналы итеп боерган тавышын ишетте:

— Тизрәк яп ишекне, балага суык кертәсең!

«Нинди бала тагын?» — дип уйлап алды Калтай. Суык болыты таралгач, күзе күргәненә үзе дә ышанмыйча телсез калды: Бибигайшә янында аяк-кулларын төрле якка салып, төпсез ыштанлы, ялтырап торган такыр башлы ике яшьләр чамасындагы йоклап яткан малайны чамалап алды. Бу — Фатыйманың улы, ягъни Вагыйзнең оныгы иде. Юлдан арып-талып, өшеп-туңып кайткан Вагыйз аның шулай икәнен хатынының йөзен күргән уңгайга ук аңлады: Бибигайшәнең бите каз мае белән майланган кебек тантаналы ялтырый иде. «Картәтәй» буласы кеше карлы киемнәрен салырга да онытып, сәке йөзлегенә килеп утырды да елап җибәрде. Егерме биш елга якын бергә торып, гомергә иренең күз яшен күрмәгән Бибигайшә түти дә йомшарып китте. Лышык-лышык танавын тарткалап, чыкмаган яшьләрен сөрткәләп, картының тула оегы өстеннән бәйләгән чабата киндерәләренең очын эзләде. Үзе шул вакыт эченнән генә белгәннәрен укыштырып, ходаеннан иренә миһербанлык бирүен сорап ялварды.

Тора-бара шул төпсез ыштан кигән малай Вагыйз картның күңелен йомшартып, яңа гына ачыла башлаган ярты-йорты теле белән «та-тә-ти,

та-тә-ти» дип такылдап картәтисенең башына атланып йөри торган булды. Дүрт көн үтүгә, икенчегә авырлы хатынын артлы чанага утыртып, Зиреклебашка Нурислам килеп төште. Әрләшү-үпкәләшүләр булмады. Сагынышкан хатын-кыз мич артында елашты, пышык-пышык серләште. Ирләр, әз-мәз сүз белән бер-берсен сынаша-сынаша, алгы якта утырдылар. Хатын-кыз кичен күршеләргә чәйгә кереп киткәч, Калтай Вагыйз бисмилласын әйтмичә генә мич башындагы унбиш чирекле мичкәдән әче бал агызып алды да, Бибигайшәсе пешереп куйган итне табагы белән сәкегә китереп утыртты...

## Дәшмәс Хәсән

Төхфәтулла бабай капкадан кереп килгән баҗасы Хәйбулланы ачык йөз белән каршы алды.

— Әйдүкләр киләсең, баҗа! — дип, ике кулын исәнләшергә сузды.— Әйдә уз!

— Әссәламмәгаләйкүм! — диде тегесе.— Исән-имин яшәүме, баҗаабзый!

— Аллага шөкер! Әйбәт кенә, сезнең хәер-фатихада яшәп ятабыз. Сүз тыңлап килүеңә рәхмәт, Хәйбулла. Урамнар бик көртле, үзем бара алмадым сезгә. Инде сиксәнне куам бит — атлаулары авыр кар ерып. Ә йомыш зур сиңа... Ишек алдында сөйләшә торган сүз түгел, әйдә керик өйгә. Шунда киңәшербез.

Төхфәт бабай, яше байтакка карамастан, үзеннән шактый яшьрәк баҗасына ярарга тырышып сөйләшкән кебек иде. Утны-суны кичкән, кырык беренче елгы каты сугышларда да үлмичә кала белеп, исән кайткан Хәйбулла шунда ук карт баҗасына үзенең кирәген тоеп алды. Дөнья көтеп, барлык җирдә иң башта үзенә файда чыгара белергә өйрәнгән мие эшли башлады: «Нәстәгә дип чакырды икән бу мине? Бик кирәгем чыкса, азрак әче балын авыз итеп булмасмы икән моның?»

Төхфәтулла баҗасы карт булса да, япун сугышыннан алып кайткан, урыс солдатларыннан өйрәнгән, үзе дә бик үк яхшы түгел инде дип исәпләгән, гадәте буенча, бик арыган чакларында, сирәк кенә табыннарда әче балны салгалый иде. Чөнки, көннәр буена, пима төпләп, тишек итек-читек төзәтеп, яңаларын тегеп, кәкрәеп каткан карт сөякләрне азрак кына булса да язып җибәрергә файдасы тия кайчак шул әче балның.

Өйгә керделәр. Анда әзерләнеп бетә язган аш табынына зур таба белән бик тәмле исләр чыгарып, кабартып пешерелгән гәрәбәдәй сапсары тары коймаклары китереп куйды Төхфәтнең хатыны Газзә түти. Кечкенә, йомры гәүдәле, дәшмәс, үзе бик тә эшчән, уңган хатын ул. Ире Төхфәт белән яшь аралары утыздан артык булса да, алар бик тату һәм бердәм яшиләр. Газзә түти — Төхфәтнең икенче хатыны. Беренчесе дүрт баласын ятим итеп калдырып, арыш урагында колхозлар чыкмас борын ук, басуда капылт кына үлеп китте. Шуннан соң Төхфәт, күрше башкорт авылыннан, ире үлгәч, кире атасы йортына кайткан Газзәне соратты. Газзә, башкорт иреннән чуен кебек кара ике малаен ияртеп кайткан иде. Атасы ул малайларны үз йортында калдырды да, бирде Төхфәткә кызы Газзәне. Дүрт ятим бала өстенә килде Газзә. Ирен карт диеп тормады, теге дүрт балага өстәп, тагын дүрт бала тапты Төхфәткә. Ятим калган нарасыйлар үсеп җитеп, барысы да башлы-күзле булып, дөнья көтәләр инде. Тик бер улы белән бер кияве генә сугыштан кайта алмады Төхфәтнең. Инде менә Газзәдән туганнары да үсеп җитеп, башлы-күзле булырга вакытлары җитеп килә. Шуларның иң олысы, улы Хәсәннең инде солдат хезмәтеннән кайтканына да ике ел тулып, өченчегә китте.

Кул юып, бисмилланы әйтеп, табынга утырыштылар. Хәйбулла йөгерек күзләре белән ашъяулыкка тезгән нигъмәтләрне тиз генә барлап чыкты. Тик табында әче балны таба алмыйча, күңеле сүрелә башлады.

Газзә түти табынга кирәк ашамлыклар китереп бетергәч, киенеп, тавышсыз гына чыгып китте. Бажалар мул табында икәүдән икәү генә утырып калдылар.

Төхфәт бабай сәкегә үрмәләде. Гөжләп шаулап утырган самавырга, аның янында утырган зур гына, сары фарфор чәйнеккә канәгатьлек белән карап, елмаюын басты.

— Ярар, Хәйбулла! Ходайга шөкер итеп, чәй эчеп алыйк. Шунда сөйләшербез дә.

Хәйбулла тамагын кыргалап алды да, һәр сүзенә үзенә кирәк мәгънә биреп, теләгән бажасына җиткерергә тырышты:

— Чәй эчкән бар ла ул. Әле генә чәй яныннан торып килү иде. Син чакыргач, бик кирәктер дип ашыгып килгән идем лә ул...

Төхфәт карт, елмаюын ап-ак сакал-мыегыннан чыгармыйча, самавыр янындагы сары чәйнеккә үрелде. Шул чак Хәйбулланың борыны үзенә кирәк исне сизеп алды. Ул таныш, йомшак, күңелне күтәреп җибәрә торган әче бал исе иде. Аның күзе тиз-тиз табын өстеннән тагын бер кат йөгереп үтте дә, Төхфәт кулындагы сары фарфор чәйнеккә текәлде. Ис шуннан иде, мөгаен. Әллә чыннан да инде...

Бажасының өметен аклап, Төхфәт ике кулына тоткан сары чәйнектән үзбәк касәләренә «сары чәй» — әче бал агыза башлады. Икесе дә кеткелдәп куйдылар.

— Тот, бажа! — диде өлкән бажасы Төхфәт. — Алла үзе ярлыкасын, бала умарта балы гына. Сиңа атап койган нәстә бу. Зур йомыш кушарга ниятлим үзеңә. Бер-икене алыйк, барын ашыйк, аннан соң киңәш-уңаш итәрбез. Синең ярдәмгә мохтаҗ без карчык белән...

Бер касә әче балны эчү белән, ул чажлап баш миенә барып та керде һәм әче бал исеннән рәхәтләнеп утырган Хәйбуллага тагын да күбрәк итеп ләззәт өстәде. Олы бажасын тагын да ныграк хөрмәт итеп, аны тагын да ныграк яратып карады аңарга.

Төхфәт үзенең бүгенге сүзләрен, хәрәкәтләрен алдан ук хәстәрләп, барлап куйганга, бик белеп эш итте. Кече бажасына тагын берне салып бирде. Үзен дә онытмады. Шуннан соң гына сүз башлады. Хәйбулла, сәкедә җәелеп утырып, бажасын тыңларга әзер иде. Чөнки гөжләп утырган самавыр яныннан Төхфәт бажасы алдына күчеп утырган сары чәйнекнең эче тулы шатлык, кинәнү иде. Ходай кушып, олы бажасына бик кирәге чыккан булгач, ул чәйнекне бүген ныклап эшкә җигәргә була.

— Бөтен өмет синдә инде, бажа...

— Ай, кулдан килсә, эшлибез аны, җимертеп. Нәстәң бар, сөйлә дауай!

— Менә бит нәстә! Минем олы малай Хәсән бит инде...

— Әйе. Үзе каяле ул?

— Эштән кайтмаган. Әртилдә итек тегә, пималар төпли..

— Ы-ы, эшләсен әйдә! Без дә эшләдек яшь чакта җимертеп.

Төхфәт сүз барышының читкә китүен теләми иде.

— Анысы шулай, эшләсен. Тик минем сөйлисе сүзем аның эше турында түгел, бөтән хакта.

— Сөйлә, бажа, сөйлә.

— Менә инде, иншалла, салдаттан кайтканына да өченче ел китте. Эшкә уңган, төс-кыяфәте дә бар...

— Ы-ы, малай шәп синең. Тач үзең, бажа.

Хәйбулла, сүзнең кай тарафка таба агыласын чамалап, сәкедә тагын да ныграк итеп җәелеп утырды. Үрелеп, Төхфәт артында, дивар янына өелеп куелган дүрт мендәрнең иң зурысын, иң астагысын тартып алды, терәлеп утырасы килә моның.

— ...Инде бу ел шушы Хәсәнем егерме алтысын тутыра. Башлыкүзле итәргә вакыт җитте. Үтеп китүе дә бар вакытының...

Хәйбулла кыска гына итеп көлде:

— Әйдә, әзрәк гүләйт итеп алсын. Өлгерер әле камыт кияргә...

Төхфәтнең күзләрендә ризасызлык чагылып үтте. Тиз генә аны яшерде дә, үрелеп касәләргә бал койды. Дәвам итте:

— Алай дисең дә бит әле син! Алай түгел шул. Ходайныкы башкача шул. Йөреми беркая да ул бала. Кич алтыдан соң кайта эшеннән. Юына. Ашый-эчә дә тагын шул итек-читеккә, пима төпләргә утыра...— Көрсенеп алды: — Ә теге чыркылдык кызлар уенда да юк. Ярар, кылубларына теге урысча кочаклашып биегән тансы-мансыларына бармасын да, ди. Аулак өйләргә барырга була бит инде. Юк...

Күбрәк сөйләп ташлап арыды Төхфәт. Шунлыктан мәсьәләнең төбеннән тотып чишәргә булды:

— Тот бажа, җиппәр!

— Киттек, бажа!

— Сине чакыру шул малай өчен. Яшь чагында син би-ик зәһәр егет идең. Ул Югары оч, ул Түбән оч, ул Ясаклы, Чишмә башын әйткән дә юк. Син шуларның кызларын би-ик,.. э-э... әййе, күргән егет идең бит, мин әйтәм. Әййе. Инде, кырыкны узсалар да, сине һаман сагынып сөйлиләр бит шул озын чәчләр. Кыскасы, бажа, минем бу дәшмәс малайны өйләндерергә булышлык ит инде син. Югыйсә, Ялманнарның Ибәт картлары кебек буйдак булып торып кала бит бу мәхлүк җан.

Хәйбулланың беркайчан да форсатны кулдан ычкындырганы юк иде. Касәне бушатты да, аны Төхфәткә табан сузып, хуҗаларча боерды:

— Тутыр, җәлләмә! Кешесенә туры килдең бүген, бажа! Булдырабыз моны, Алла боерса!

Голтылдатып балны эчте дә, табадагы өелеп торган коймакларның иң астына тыгылып, майлары агып торган ике коймакны тартып чыгарды. Тиз-тиз чәйнәп аларны йотты да Төхфәттән сорады:

— Киленнең ниндирәге кирәк сезгә, дауай, сөйлә!

Төхфәт азрак уйланып торды.

— Килен буласы нәстә, иң әүвәл, эшкә уңган булсын...

— Шуннан?

— Икенчедән, төсе-башы да кешегә күрсәтерлек булсын инде. Кеше белән аралашып, дөнья көтәргә бит Хәсәнемә.

— Ярар да ди. Шуннан?

— Аннан кеше кебек сөйләшә белә торган да булсын инде. Ике дәшмәс бергә туры килсәләр, аларның баласы ничек итеп сөйләшергә өйрәнсен, ди.

— Өйрәнерләр. Исән булсыннар. Ә белем ягын ничек күз алдыңа китерәсең.

— Белем ягынмы?

— Әйеме!

— Хәсәннеке биш класс инде. Моныкы алты, җиде тирәсе булса җиткән. Күп укыган кирәкми. Борынын чөя башлый.

— Беттеме, теләкләрең?

— Нәселе ышанычлы нәсел булсын. Даны чыккан кирәкми — малай юаш.

— Булды, җитте. Сал, дауай, балыңны. Бар андый кыз сезгә! Бар! Һәр яктан да сез теләгән кебек. Тик үткенлеге дә бар инде. Ата баласы.

— Мин беләмме?

— Һи-и, белмичә тагын! Әптер кызы!

— Кайсы Әптер ул?

— Соң белмәскә! Хатыны үлгәч, биш ел элек бездән өч чакрымдагы Дәминбай авылына ике кызын ияртеп барып, йортка керде. Башкорт Сәхипҗамалга. Бик тату торалар. Әййе.

— Ә-ә, теге Байморат Хәйбрахманы энесе Габдеррәхимне әйтәсең икән.

— Самай үзе. Зур кызы читтә, Ташкин ягында. Ә кечесе, Вәсиләсе үзе белән тора. Буй җитеп килә инде. Унҗидедә, ди. Калхузда кыяр,

кәбестә, кишер үстерә. Әптернең үзенә охшап, иллә дә унган инде. Үзе чибәр, үзе унган, үзе үткен...

Төхфәт уйга калды. Аннан соң борчылулы тавыш белән сорады:

— Без юашларны тыңлар микән соң ул?

— Анысы Хәсәнеңнән тора инде. Синнән, миннән түгел. Хатын-кыз шәп, уйнаклап торган ат кебек бит ул. Аңарга яхшы йөгән, көчле кул кирәк. Тыңла-ар, тыңлата белсә-ә...

Ут алынгач кына Хәйбулла ава-түнә кайтырга дип чыкты. Капка төбендә саубуллаштылар.

— Иртәгә көндезге берләр тирәсендә мин ат җигеп килермен. Хәсәнеңне әзерләп куй! Өч ярты ак аракы булсын, бер чирек бүгенге кебек балың булсын. Бер каз куй. Барып, килешеп кайтырбыз, дип уйлыйм. Әптер үзебезнеке. Шунлыктан, башкорт бичәсен көйләргә генә кала инде...

Икенче көнне өйлә тирәләрендә бурлы бия җигелгән, хуш исле яшел печән тутырылган чанада Хәйбулла белән Хәсән, Дәминбай авылына карап, юл тоталар иде. Кыйбла ягыннан искән җил яуган карны бергә җыйнап, юлга аркылы йөгерек буран чыгарып, юлга ак кар телләре тезгән. Көр бия йомшак кына юыртып, чананы җиңел генә итеп тартып бара. Юл тын һәм буш. Шул тынлыкны тик Хәйбулланың сөйләнгән тавышы гына боза. Ул каеш дилбегәне тотып утырган Хәсәнгә, булачак бабайларында үзен ничек тотарга кирәклек турында «әйбәт күрсәтмәләр» бирә.

— Син, дәшмәсләрдән булсаң да, анда ялгыш күп сөйләп җибәрмә. Күп ашама, күп эчмә. Ул нәрсәләр бар да минем өскә йөкләнәләр. Ни күрәсен мин күрермен. Шунлыктан, иң авыры минем башка төшә. Кыз яшь, шәп. Шуңа күрә син аңарга кыска гына итеп бер генә текәләп кара. Шул җитте. Синең вазифаң шул...

Исенә төште:

— Синең ул кызны хет күргәнең бармы соң?

— Юк.

— Исеме Вәсилә. Йомры гына, түгәрәк, тулы гына кыз. Бар нәстәсе дә Ходай биргәнчә, барысы да үз урынында. Егет куенына кирәклек булып үсеп җиткән. Сиңа тагын ни кирәк. Тик күбрәк сөйләнеп, эшне боза күрмә. Югыйсә, сез дәшмәсләрнең дә теле ачыла бит кызлар күргәч. Аңладыңмы?

— Ы-ы!

— Менә шулай диген син. Калганын булдырабыз аның. Тик Ходайдан Хәйбулла абзаңның исәнлеген сора. Бүген ничек кенә булса да, килешеп кайтыйк. Атна үтүгә үзем барырмын тагын, кәнкрит сөйләшеп, туй вакытын билгеләргә.

Ике авыл арасындагы Гайшә куагы дигән җиргә килеп җиттеләр. Дәминбайга барып җитәргә тау төшәсе генә калды.

Башкорт авылына барып кергән уңайга, килгән юлга аркылы сузылган бердәнбер урамны кисеп үттеләр дә, кечкенә тыкрыкка кереп киттеләр. Аннары атны уңга, елга яры буйлап сузылган урамга бордылар. Татар Әптер абзалары йортын елганың уң ягына, иркенгә чыгарып салган.

— Гомере буе иркенне яраттылар алар Байморат нәселләре. Ай-һай, абзасы Хәйбер белән йодрыклап сугышырга шәпләр иде алар. Минем малайчак шулай...

Сөйләп алып китә алмады — килеп җиттеләр. Әптернең капка астыннан кечкенә гәүдәле, кәкре аяклы, җирән бер эт кисәге тәгәрәп чыкты да, эш тапканына сөенгәндәй, болар тирәсендә бөтерелә-бөтерелә өрергә, чәбәләнергә тотынды.

— Кит әле, кит моннан! — диде Хәйбулла чанадан төшешли. — Синең кайгың юк бездә. Безгә бүтән нәстә кирәк.

Эт тавышын өйдә дә ишеттеләр. Киң итеп ишек ачылып китте дә, анда инәнә туп салган тәбәнәк гәүдәле, юантык бер ир күренде.

— Кем йөри анда? — диде ул хуҗаларча. Танып алды. — Син инде әллә, Хәйбүш? — диде ул. — Ни эш бетереп йөрисең? Әйдүк, уз әйдә.

Ике авыл бер колхоз булганлыктан, Хәйбулла Дәминбай авылы очындагы Чишмәле аландагы умарталыкта эшли. Шунлыктан Дәминбай башкортлары аны яхшы беләләр.

Хәйбулла бусаганы атлый-атлый сәлам бирде:

— Әссәламегаләйкем бу йортка. Исән-имин яшисезме?

Сәкедә аякларын бөкләп утырган, азрак кара-кучкыл йөзле, инде олы яшьләрдә булуына карамастан, чибәр генә хатын аларны ачык йөз белән каршы алды. Урыныннан да кузгалды:

— Ходайзың рәхмәт төшкере йәндәре! Кунактар лабаһа! Узыгыз, сишенегез, утырышыгыз. Кунак былырһыгыз!

Хатыннан башка тагын, сәке йөзлегенә утырган, алсу йөзле, кара чәчле, йомры гына, килешле җыйнак гәүдәле яшь кенә бер кыз да бар иде.

— Менә калхуз һолоһо — әпсүген сүпләй инек әле. Кызым Вәсилә менән икәү генә. Әптерәхимде кушып булмай, ир булгас. Сабата тукый Әптерәхим.

Кызга мөрәҗәгать итте:

— Ал, кызым, был һолоны ла, паднусты ла. Бар теге якка сык. Шунда сүплә. Без монда килгән кунактарза карайык.

Кыз килгәннәргә соры-коңгырт күзләрен сирпеп кенә алды да, тиз генә җыйналып, чыгып та китте.

— Нәмә эшләп йөрөйһегез кышкы буранда өйзә генә утырмайсак?

— Эй-лә инде. Эт өрер, бүре йөрер, дигәндәй инде без. Сезнең авылга йомыш төште дә, килдек әле менә. Хәсән белән икәүләп.

Башкорт бичәсе сораулы күзләрен Хәйбуллага текәде:

— Һуң беззең авылга йомош тип килгәс, туры безгә килеп тә кергәс, ул йомошогыз беззәмени инде?

Башкорт бичәсе үткен зиһенле булып чыкты, сөйләшүне үз кулына ала да башлады. Хәйбулла башын арткарак биреп көлгәндәй итте.

— Ай, сездәдер инде. Әптер абзый белән бергә күп эшләдек, минәйтәм, башкорт еңгәне дә күптән күргән юк. Барып хәлләрен белеп кайтыйк әле, дим, Хәсәнгә. Менә килдек...

Әптер, мыегы астыннан гына елмаеп, дәшмәде. Бичәсе табын әзерли-әзерли сөйләнде:

— Шулайдыр инде, әйе, шулайдыр. Йәй көндәреңдә эрәдем торган умарталыктан керергә вакытың юк. Һине бөгөн нәмә кысып китерзе икән... — Ул Хәсәнгә сынаулы итеп карап алды. — Был кустым кем балаһы булды һуң әле? Мин бер зә күргән кеүек түгелмен.

— Бу теге итек-читек тегүче Төхфәт абзый малае. Хәсән.

— Нишләп мин белмәем аны. Ситтә күп йөриме әллә?

— Юк ла, үзебезнең авылда яши. Солдаттан кайтканына ике ел булды инде. Күп эшли, чыгып йөреми, шунлыктан күренми.

— Кайда эшли? Калхуздамы?

— Ю-у-ук, нишләп калхузда булсын ди?! Әртилдә, акчага эшли. Итекләр тегә, пималар төпли. Читек тегүнең иң шәп остасы ул районда...

— Э-эй, шулаймыни! Беззең авылда менә Морзагыл агай үлгәннән һуң итек, ситек остаһы калманы. Бима төпләргә лә кеше юк. Байтак йыйналды тишек бималар, һезгә биреп йебәрергә кәрәктер мөгаен?!

— Хәсәнгә эләксә, төпли инде ул аларны. Тик безнең йомыш иске пималар җыюда түгел бит әле.

Башкорт бичәсе нәрсәдер сизенә башлаган кебек иде. Ул Хәсәнгә карап-карап алды да, Хәйбулланы тыңламыйча аңардан сорады:

— Һин, Хәсән кустым, әллә һөйләшә лә белмәйһең инде. Бер һүз әйтмәнең кергәннән бирле.

— Тартына ул...

— Һуң тартынырга ни? Урын юк ла. Кыз һорарга килмәгәндер бит инде, тартынып утырырга...

«Чукынган гына башкорт бичәсе икән бу!» — дип уйлап алды Хәйбулла. Карчык сүзләреннән соң бүлмәне тынлык басты. Шул тынлык карчыкка күп нәрсәне аңлатты. Ул инде «был татарзарзың юньле эш белән йөремәгәннәрен» аңлады. Аларны сөзеп карап чыкты

— Хәйбулла, һине күргән көйөнсә һул күзем тартыша башлагайне. Аннан һуң йөрәгем һикерергә тотондо. Һинең тәккә генә йөрөмәгәнеңде без бөтен авыл менән беләбез. Бу татар юньле эш менән генә килгән булһа ярар ине тигәйнем мин, эсемнән генә. Һин монда...

— Тукта, бичә,— диде Әптер абзый.— Китер итенне, ашынны. Күп сөйләп ташладың. Кирәкмәгәнне. Ашатып, эчерик кунакларны. Аннан белешербез...

Бичәсеннән каршы бер сүз дә чыкмады. Тик хәрәкәтләре кискенләште. Кул юып, утырыштылар. Хәйбулла, Хәсән алып кереп ишек төбенә куйган, кара букчага үрелде.

— Һин, Хәйбулла, токсаеңа үрелми тор әле!..

Үзе, елмаеп утырган картына үтерә торган караш ташлап алды:

— Һез әллә беззең кызды самалап, әллә ысыннан да бирәр нәмә кылырга уйлайһызмы? Әйт Сасыктан асык! Токсаең калып торһын! Әйт!

Хәйбулла, каршы якка ниятләре ачылганны күреп, турыдан-туры атакага күчте:

— Без бик изге эш белән килдек сезгә, чыннан да. Менә шушы егеткә кызыгыз Вәсиләне сорарга дип килдек.

Күрше бүлмәдә нәрсәдер чылтырап идәнгә төшеп тәгәрәде. Сәхипҗамал аны ишетмәде дә, сәрмәнеп сәке йөзлегенә утырды. Күзләре очкынланып, зәһәрләнделәр һәм берничә тапкыр ачып яба торгач кына, калын иреннәреннән сүзләре килеп чыкты:

— Һез, шыкылдап торган татарзарга кыз бирергә, әллә монда дивана башкорт бисәсе бар тиеп белдегезме?! Ә? Һы-ы! Хәтта татарса ла бер һүз һөйләй белмәгән бер пәпәне алып килгән дә, кыз һорай! Ошонарга кызымды биреп, кейәү тиеп кайһы йеренә эндәшеп була?! Ә? Йу-ук, үз кызымнан ла артык итеп карап үстердем мин аны, бирмәйем!

Әптер килеп кысылды:

— Туктале бичә! Шаулама! Сөйләшик, сорашыйк!

Бичәсе басылмады:

— Так та ток килеп татарса гына булһа ла һөйләшә лә белмәгән бер... и-и... ошоңа кыз бирергә, әллә! Йук та, булмай за, болашмагыз за. Бирмәй-йем! Бетте, китте. Ултырыгыз, ашагыз, токсаегызга кермәйһегез.

Аштан зур булып булмый. Тавышсыз гына утырдылар. Шапоршопыр китереп, ачуланган күңелләрен басарга тырышып, токмачлы ашка тотындылар. Тик Әптер генә Хәйбулланың күз карашын эләктереп, аңарга нәрсәдер аңлатмакчы булды бугай. Ләкин Хәйбулла барлык өметләрен юк итеп, башын күтәрмичә токмач ашый иде инде. Өметсезлектән гәүдәсе дә кечерәеп калды. Ул күрше әтәче белән сугышып, җиңелеп читән тишегеннән качып кайтып кергән мескен әтәчне хәтерләтә иде...

— Булмады бу эш,— диде ул.— Юлга чыкканда ук теге Чатан Гариф очраган иде, шуңа уңмады юл. Ярый әле атны тугармаганыек. Җиген торасы була иде...

Хәсән аз гына уйлап торды да, кинәт кенә сикереп торды һәм букчасыннан ике ярты аракы китереп чыгарды. Башкорт бичәсенең авызы ачылганчы аларны табынга китереп утыртты:

— Сезгә ризыкка дип алып килгән нәстәне, кире алып кайтып булмый инде аны. Шушында тәгәллик тә, аннан соң хуш иттек. Гаепләштән булмасын.

— Бә-ә-әй! — диде башкорт бичәсе.— Матур итеп һөйләшә белә лабаһа бу егетең һинең, Хәйбулла!..

Кыз алудан өметен өзгән Хәйбулла җавап бирмәде. Хәсән Әптер абзыйга эндәште:

— Бу йортның хуҗасы син инде монда, Габдеррәхим абзый. Кая, хатыныңа, яисә кызыңа стаканнар китерергә куш.

Хәсәннең телгә килүенә, аның сүзләренә исе киткән Сәхипҗамал карчык, Әптернең әмерен дә көтмичә, сәкедән арты белән шуып төште дә теге якка чыгып китте. Ул аннан бик зурдан булмаган бәллүр стаканнар тотып килеп чыкты.

— Сал, Габдеррәхим абзый! Без бик озак утырмабыз. Юлчының юлда булганы яхшы!

Әптер дә көттереп тормады, яртыны ачты да, беткәнче дүрткә бүлеп, стаканнарга тигез итеп салып чыкты. Берсен бичәсенә тоттырды. Хәсәнгә карап, барлык зәһәрлеген җуйган Сәхипҗамал карчык, иренә буйсынып, бәллүр стаканны калтыраган бармаклары арасына кысып, өнсез калды.

— Исән-имин яшәгез! Картлык көннәрегездә тыныч, имин итеп, муллык белән яшәргә язсын! — диде дә Хәсән, кабаланмый гына салганны эчеп куйды. Хәйбулла аның кыйланышына авызын ачкан көенә карап катты. Ул Хәсәннең әлегә кадәр бер тамчы да эчмәгәнен белә иде. Аннан да битәр, егетнең түгәрәк-түгәрәк сүзләр сөйли белүе шаккатырды Хәйбулланы. Хәсән исә аңарга карамыйча, алдындагы зур табактан бер кабырга алды да, аны шатырдатып кимерергә тотынды. Табындагылар да сүзсез генә эчеп куйдылар. Хәсәннең тик торганнан ике яртыны әрәм итүенә ачуы чыккан Хәйбулла моны хуҗаларга сиздермәскә тырышты. Шулай да аның һәрбер хәрәкәтендә ризасызлык чагылып-чагылып куя иде.

Башкорт бичә янә телгә килде:

— Йә, картлас! Һуңыннан ашарһың! Кой тагы ла берәрзе! Булгасбулгас парлы булһын...

Хәйбулла һушына килә башлады. Гаҗәпләнеп, Хәсәнгә карап алды: «Менә сиңа Төхфәтнең дәшмәсе! Үтерде бит бу мине!» Карчыкка ияреп җөпләде:

— Әйе шул! Өчәү дә итәрбез, дүртәү дә, ризыкка язган булса!

Хәмерне йотып куйгач, башкорт бичәсе татар картына боерык бирде:

— Һин, бар, сыгып аттарын карап кер. Тугарып, бесән һал. Әйбәтен һал, тугай күрәне булмаһын...

Сугыш еллары узып, беренче башкорт ирен шул сугыштан кайтара алмаган, шул елларда һәм сугыштан соң күп нужалар күреп яшәгән башкорт бичәсе Сәхипҗамал түти кайвакыт кәефләнеп алырга ярата иде. Дәшмәс Хәсән аның шул ягын ничектер чамалап алган күрәсең. Ул арада Хәйбулла абзасы да һушына килеп, такмак әйтә-әйтә, башкорт бичәсен биетергә тотынды. Кыза башлаган бичә бармакларын шарт-шорт китереп, сәкедә азрак селкенеп утырды да, сикереп үк төште. Сәке астыннан бик чибәр кызыл итекләр тартып чыгарып, аякларына киде:

— Йәле, Хәйбулла! Әйт әле такмактар! Бер басып алайык әле! Йөрәккәйзәр басылмасмы икән лә!!!

Хәйбулла такмак әйтте, Сәхипҗамал бармакларын шарт-шорт китереп, кызыл итекләр белән такмак көенә идәнне шакылдатып, бик матур итеп биеп китте. Карчыкның йөзендә хәрәкәттән, эчкән хәмердән матур булып алсулык йөгергән. Биегән җиреннән такмаклаган кебек итеп тезеп тә китте:

— Йәшерәк сактарымда-а, аяктарым авыртмаган сактарда-а, менә ошолай итеп баса торгайны-ым ми-ин!!!

Дер селкетте идән такталарын Сәхипҗамал — башкорт бичәсе... Анары итекләрен салмыйча гына урынына менеп кунаклагач, Әптергә эндәште:

— Ай-һай, шәп тә татарзар бит болар карт, карале! Әллә уйлашаекмы икән, ә? Һин нәрсә әйтерһең, ә?

Әптер үз бичәсен шәп белә иде. Аның уена ут өстәде:

— Хәйбулласының шәплеге синең белән миңа кирәге юк. Ә егете чыннан да шәп, ахрысы, карчык.

— Әйе шул, карт! — диде бичә. — Үзе күп тә һөйләшмәй бит әле ул. Ә төптән эш итә белә. Карале нисек итеп китереп сыгарзы бит: ризыкка язганны, ти бит! Йомарт кеше был, тас ысын башкорт менә!

Чирегe белән әче бал кара букчадан килеп чыккач, карчык үрелеп, Хәйбулланы битеннән үпте:

— Үзең дә маладис, егетең лә маладис! Бигрәк безгә кулай кияү алып килгәнһең. Әйзә тагын әйттер әле теге башкорттар тураһындагы такмагыңды!

— Була ул, нигә әйттермәскә ди...

Шулчак теге яктан Вәсиләнең тавышы ишетелде:

— Әни, бирегә чык әле!

Карчык бер минуттан кире чыкты.

— Һәке астында ярты капсык һоло бар икән. — Шуны һорай.

Хәсән сәке астыннан солылы капчыкны үрелеп тартып чыгарды да карчыкка карады.

— Бар, кертеп бир, кустым, — диде Сәхипҗамал. — Күреп булһа ла китәрһең. Кызыбыз шәп беззең.

Хәсән кереп киткәннән соң, Хәйбулла карчыкны сөйләндерергә тотынды. Сәгатьтән артык вакыт узгач кына, хуҗабикәнең исенә Хәсән килеп төште. Тиз генә теге якка кереп китте. Авызы ерык хәлдә кире әйләнеп чыкты:

— Һе! Ул дәшмәһең һинең һоло сүпләшеп, кызыбыззы көлдереп ултыра. Алар анда пар күгәрсендәр кеүектәр илаһым...

Иренә аптырап карады:

— Куаекмы әллә боларзы, карт? Бу дәшмәс нәмәстә алып китә бит кыззы — һизә минем йөрәгем! Ай-һа-ай, татар тиген инде һин моны. Башкорттан ла шәберәккә сыгып бара был Төхфәт малае Хәсәнегез...

— Төхфәтулла абзый нәселенә бирсәк, хур булмабыз, бичә! Аның балалары бик тә эшчәннәр...

— Шулай тиһеңме, карт?

— Шулай дим, карчык.

— Э-эй-лә-ә...

Авыл ут алып, тагын ике-өч сәгать вакыт узгач, Әптер картның ишеге алдында җигүле чанага Сәхипҗамал карчык Вәсилә кызына әйберләрен төяшә иде. Төяп бетергәч, Хәсәнгә ике куллап ябеште:

— Һөйләшенгәнчә, ике көннән беззе килеп алырһың. Әйе. Атаең-әсәең менән туй тураһында һөйләшеп, килешеп куярбыз, кияү. Күңелемә бикләр зә охшаның, шунлыктан кыз — һинеке...

Чанада башын иеп утырган, инде ныклы гына исергән Хәйбуллага кулы белән төртеп алды:

— Ошо тиклем яхшы эште сак юкка сыгарманы бит бу исәнтәй! Сак калдык! Ярый әле үзең тотондоң, кияү. Исән-һау кайтып етегез, Аллага тапшарзык! Кыз — һинеке!

Капканы ача башлагач, сларга ук тотынды.

— Ай-һай, үткер татарзар икәнһегез! Бирмәм тигән инем татарга — юк каршы тороп булманы.

Ире Әптергә тотынып, кызны алып киткән атлы чанага елый-елый карап торып калды.

Кузгалып киткәч, шактый гына исергән Хәйбулла үзенекен сукалады:

— Мин килгәч була ул. Әйе... була ул... Әйттем бит мин була дип... була ул. Була дигәч, була!

Хәсән алда, дилбегә тоткан. Хәйбуллага дәште:

— Авылны чыкканчы Вәсиләне, әйберләрен карап бар. Төшеп калмасыннар. Таута менер алдыннан әйбәтләп утыртырбыз. Сине дә...

— Калмый! Төшми! Ни эшләп бездән төшеп калсын! Һы...

Елга бозына төшкән урыннарда юл сикәлтәле иде. Елганы чыккач, Бурлы бия кыска гына текә ярга юл белән үрмәләгәндә, Хәсән, арттан кычкырган тавышка борылып карады да, көлеп җибәрде. Анда, чананы куып җитәргә ашыгып, бер кочак печән күтәргән Васил͏ә йөгерә иде. Үзе көлә:

— Туктатыгыз атыгызны! Мине калдырып, кая киттегез?! Исерек булса да, Хәйбулла да чана артыннан йөгергән «килен»не чамалап алды:

— И-и-и, Хәсә-ән! Хатынның шәбе эләккән бит, әй, сиңа. Карале, печәнне дә җыеп алып өлгергән, үзе йөгерек тә икән әле. Үз ризыгы белән йөгерә бит әле ул. Булды бу! Булды!


## ИГЪТИБАР!

**«Татарстан хәбәрләре» газетасы җирлегендә оештырыла торган «Мәдәни җомга» исемле атналык басмага язылу башланды. Һәр атнаның җомга көнендә 24 битле булып чыгачак әлеге газета тулаем республикабызның әдәбият һәм сәнгать тормышын яктыртуга, шулай ук тел, әхлак, тәрбия, дин, уку-укыту, фән, тарих, рухи мирас мәсьәләләренә багышланачак һәм аның сәхифәләрендә мавыгып укырлык проза һәм шигърият әсәрләре, тирән мәгълүмат бирүче кызыклы язмалар киң урын алачак.**

**Газетаның индексы — 54129; ярты еллык бәясе — 13 мең 200 сум. Татар дөньясында әлегә бердәнбер булган мондый атналык басма сезнең өйләрегезне тагын да нурландырып җибәрер.**

**«Мәдәни җомга»га язылырга ашыгыгыз!**



# Марат Закир

## Биеклек

Сүземнең чиштем бәен —
Һичнигә карамадым.
Үрләде аралап ул
Вак куак араларын.

— Син, әле, имән, бик яшь...
Куаклардан биектә
Имәнне сукты яшен.
— Кара күмергә калгач,
Ничек инде мин дәшим —
Дәшмим, дәшмим, дәшмим, дәш...

— Биегрәк,— димәк,— көчле,—
Дигән кеше кая ул?
Биегрәк булган саен,
Арта бара кыйналу...

Аһ, бу сихри биеклек!
Биеклектә — жир яме.
Алыштыра яшь үсенте
Яшен орган имәнне...

## Халәт

Тышта — кыш,— диләр.
Ә мин ышанмыйм.
Язгы киңлеккә,
Назга очам мин.

Канатларым да
Йолкынган үзе.
Ак каурыйлары
Тышта ни эзли?

---

Марат ЗАКИР (1969) — *яшь шагыйрь, «Идел» журналының бүлек мөхәррире. Шигырьләре һәм проза әсәрләре белән көндәлек матбугатта күренеп килде. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

Очалмагач әгәр,
Нигә соң канат?!
Ат син аны, кыш,
Ат йолыккалап!

Безләргә очу...
Күмеп дөньясын,
Каурыйларым хет
Кар булып яусын.

Керфеген тапсын
Пакьләрдән пакьнең —
Урамнан барган
Сөйкемле затның.

Чылансын күзе
Ул гүзәл затның.

Мин бу халәттә
Пакьләрдән пакьмен.

Хәл-халәтем шул —
Төтенсез морҗам.
Бу халәттә мин —
Нәзберек бер җан...

Кыш — кыш икәнен
Үзем дә беләм.
Назны күмде кыш
Карлары белән.

Тышта — кыш,— диләр.
Һаман ышанмыйм.
Халәт-очагымда
Назга очам мин.

## НОКРАТ

*(Мәдхия)*

Халкым сыман булдың сабыр,
И Нократ — Көмеш елгам!
Гасырларның төпкелендә —
Син үткән озын юллар...

Ил телендә — Көмеш елга,
Кем телендә — башкача...
Үткәннәрен онытканның
Туган телен таш баса.

Телне дә, әйе, таш баса,
Ятса әгәр ил йоклап.
Саф килеш сакла чишмәңне,
Егәрле бул, и Нократ!

Сабырлыкның чиге чыга
Зилзиләләр башланса.
Ярларыннан куба Нократ,
Чишмәләрен таш басса!

Янганда безнең йөрәкләр
Сыкрап, сыкрап, әй, сыкрап,
Дулкын кага ярсып-ташып
Чулман, Идел һәм Нократ.

Килер әле безгә дә бер
Иманлы, гадел шөһрәт.
Типсеннәр гаярь чишмәләр,
Мең яшә син, и, Нократ!

Бул син мәңге-мәңгелеккә
Көзгесе — якты вә пакь —
Мамадыш дигән төбәкнең,—
И Көмеш елгам-Нократ!

* * *

...Ашыктыра алсу җиләк:
— Тизрәк, тизрәк, әй, тизрәк!
— Печәннәрем оча җилгә —
Җайлап куяр җай сирәк.

Ак күлмәкле алсу җиләк
(Булса була — ымсыну)!
Кирәк шәйдер дә бит үзе
Бу сылуга буйсыну —

Болытларга аша башым
(Булса булыр — очыну!)...
Җиләк ае түгел юкса —
Җәйнең кибән очы бу...

Аның да берзаман (көтәм)
Толымнары сүтелер!
Һәм кибән очыннан җиләк
Болыт-күлгә сикерер.

Болыт-күлгә сикерер дә,
Төнбоектай су керер.
Шунда гына төнбоектан
Назлы нурлар сирпелер...

Инде җәйнең кибән очы —
Җиләк ае, аһ, үткән...
Ашыктыра алсу җиләк:
— Яңгыр килә — төш күктән...

Үтеп китте болыты да,
Очланды ла кибәне.
Хәтерләтеп торыр мәңге
Кипкән җиләкнең тәме...

## Чәчмә әсәрләр



**Локман Закир**

# ИНША

КАРА ХИКӘЯТ

**Редакциядән.** Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезгә тәкъдим ителәчәк бу әсәрне укып өйрәнгәннән соң бездә киңәшү, сөйләшү, икеләнүләр байтак булды: басаргамы-юкмы бу язманы? Чөнки бик тә көтелмәгән, күнекмәгән, безнең татар халкы күңеленә ят нәрсәләр күп монда. Мондый хәлләр бездә хас түгел дип, әсәрне читкә тибәрсәң, тормыш-яшәешнең күпләрдән яшерелгән «караңгы» почмаклары, ачы чынбарлык бер читтә кыелып калачак... Тормышның кояшлы ягы күбрәк дип ышаныйк. Ләкин дөньяның кырыс-ямьсез яклары да житәрлек — бүгенге тормыш калейдоскобы моны ачык раслый.

Менә шуңа да бу язманы укучылар хөкеменә тапшырырга булдык. Истән чыгармыйк: автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Тагын шунысы да бар, әсәрдәге вакыйгалар, мөселман мохитенә караганда, барыннан да элек бүтән кавем милләтләр хәятенә, җәмгыять череклегенә төбәлгән.

Әсәрнең 1976 елда язылган булуын да истән чыгармыйк.

### Өй эше

Вакыйга юктан гына башланып китте диярлек.

«Нинди начар сүз бит, ә! Аны башкасы белән алыштырып булмас иде микәнни,— дип нәфрәтләнде өендә өлкән классларның өй эшен тикшереп утырган яшь, тол хатын, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Мира Сергеевна.— Һәр сүзнең әллә ничә синонимы бар, ә ул әнә, ахмак, нинди шаяру тапкан! Мондый җөмләне ул үзе уйлап таба алмас иде, берәр китаптан күчереп алганы көн кебек ачык. Язучылар ни язмас... Укучыларга ирекле темага сочинение бирәсең, шаккаттырып куялар кайчагында. Толстой, Горький, Шолохов, Маяковский әсәрләре буенча инде миллион инша язылгандыр, хәтта аларның типографик ысул белән басылган шпаргалкалары да җитәрлек. Кулдан-кулга күчеп, елдан-

ел «шомара» барып, алар инде әдәбият классиклары дәрәҗәсенә күтәреләбаралар. Бүгенге утыз иншаның яртысы диярлек әнә шул йөремсәк шпаргалкалардан күчереп язылган, һәм, артыгын тикшереп тә тормыйча, берничә җөмләдән соң ук күбесенә күз йомып та «бишле» куярга мөмкин».

Мира Сергеевна, шулайрак уйланса да, вакыт инде соң булуга карамастан, әле һаман теге сүзнең синонимын таба алмыйча интекте. Якынча синонимнар күп булса да, аларның берсе унынчы класс кызы Лена Соловьева язган иншадагы сүз мәгънәсенә якын килми иде.

Кул аркасы белән иягенә таянып, язу өстәле каршында ярым йокымсырап, укытучы йомык күзләрен ачарга кыймыйча, ирексездән үткәннәрен хәтерләде: «Минем Николайда күпме була иде ул! Кесәсе саен берничә пакет. Никадәр киргә чыкса да, аны беркайчан үз исеме белән атамадык. Менә шуңа да хәзер мин аның синонимын таба алмыймдыр әле. Кызык, Николай табар иде микән? Юктыр. Хәзер ул, бәлки, пакетлар урынына, кесәсендә валидол йөртер иде. Йөрәге шаяргаласа да, ул миннән темпераментлырак иде, үбешү дигәндә сөлектәй ябышыр иде. Нинди татлы чаклар! Саклангансы, миңа иң дөресе бала табасы булган икән бит! Хәер, ул чакта без нибары студентлар идек, тулай торакта яшәдек. Әйтәсе дә юк, теге пакетлар безне нык коткарды ул чакта. Юкса кырыс заманнар иде, безне институттан сөреп чыгару берни булмагандыр. Бала белән кая барып сыеныр идем мин?»

Уналты яшьлек Лена Соловьеваның нәфис куллары белән дәфтәр битенә язылган әлеге уңайсыз, алты хәрефле сүз, әгәр телдән әйтелсә, янәшәдәге теләсә кемнең ачуын китерер, хәтта кайберәүләр канлы бәрелешкә хәтле барып җитәрләр иде, мөгаен. Сүгенү-тиргәшү сүзенә үзенең мөнәсәбәтен күрсәтергә теләгәндәй, Мира Сергеевна сүзнең астына кызыл карандашы белән сызды. Монардан исә сүз тагын да усалрак, мәгънәлерәк, тагын да күзгә бәрелеп торучан кыяфәт алды.

Әгәр менә хәзер укучылары арасында булса, Мира Сергеевна үзенең интим хатирәләре уңаеннан нык кына кызарыр иде, мөгаен. Чөнки бу хәтерләү — гыйлемле, утыз яшьлек укытучы белән уналты яшьлек кызны дәфтәр битендә «чәкештергән», әмма үзенең килеп чыгышы белән икесенә мәгълүм булмаган баягы сүзгә барып тоташа иде.

Ялгызлыктан туйган Мира Сергеевна бу юлы, киресенчә, ялгызлыгына куанды һәм, Николайның рәсеменә карап, аның җылысын һәм иркәләвен тойды шикелле. Ул, Ленаның әле тикшерелеп тә бетмәгән иншасын бер читкәрәк этәреп, өстәл яныннан торды һәм янәшәдәге диванга ятты. Күзләрен йомып, арканча яткан Мира Сергеевна бу минутларда, Колясына тиңләп, теләсә кайсы ирне куенына алыр иде сыман. Әлеге уйларыннан оялып, үзенә кул сузучы ирне терсәкләре белән этеп җибәргәндәй итте дә диваннан күтәрелде, барган уңайга халатын рәтли-рәтли китап шкафыннан рус теленең орфографик сүзлеген тартып чыгарды.

Мира Сергеевна иң элек «Г» хәрефенә башланган «Ган...» Гон...» тирәләрендә бармагы белән йөреп карады, аннары синоним буларак туры килә торган «П» хәрефеннән бер сүзне эзләде. Сүзлекнең монысын читкә куеп, рус теле синонимнары тупланмасын кулына алды. Лена язган уңышсыз сүз бер генә китапка да кертелмәгән иде.

«Бәлки, чит телдән кергән сүздер», — дип фараз кылды укытучы, сүзлекләрне киштәгә урнаштырып. Аның ышануынча, ул бүген ямьсезкүңелсез сүзне алыштырырдай синоним табарга тиеш иде.

Мира Сергеевна берничи чит телне белмәсә дә, күңеле сизгәнчә, бу сүз, һичшиксез, француз теленнән кергән булырга тиеш. Менә шуңа да француз язучыларының хикәяләрен карап чыгарга ниятләде. Әмма ни Мопассан, ни Виктор Гюго, ни Александр Дюма, ни Стендаль, ни Бальзак, ни Мериме, ни Эмиль Золя әсәрләрендә андый сүз очрамаганлыктан, янә диванга ауды. Анык кына ышанычы булмаганлыктан, французларны гаепләргә дә ашыкмады.

«Бу сүзнең грекчадан яисә итальянчадан булуы, гомумән, мөһим түгел. Моны соңрак та ачыклау мөмкин. Мин, рус теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, орфографик хаталарга күбрәк игътибар итәргә тиешмен. Ә бәлки Лена белемемне тикшерергә, класс һәм мәктәп алдында хур итәргә теләп, «о» урынына «а» дип махсус язгандыр. Дөресен әйткәндә, минем бу сүзне әдәбиятта очратканым булмады, институтта да болар хакында сөйләшү юк иде. Күрәсең, ул медицина әдәбиятында гына кулланыла. Анда да әле латинча, бөтенләй башкача әйтеләдер ул... Һәрхәлдә, Ленаның хәреф хатасы чекерәеп тора. Тагын берничә хатасын табам да, «икеле» чәпим үзенә. Һәм класска бөтен текстны кайсыдыр китаптан күчергәнлеген исбат итәчәкмен. Кайсы китаптан күчергәндер, хәзергә ачык кына әйтә алмыйм. Бу минем кимчелегем. Әгәр кайсы китаптан икәнен белмәсәм — укучылар каршында хурлык! Әдәбият укытучысы теге яки бу фразаның кайсы романнан икәнен белмәсен әле... Толстой, Горький, Шолохов әсәрләреннән булса, мин аларны күз йомып та чамалар идем. Бу, күрәсең, тыелган әдәбияттан яисә 1964 еллардан соң күренгән китаплардан алынган. Хәрби-патриотик теманың көчәйгән чагы... Миңа тәнкыйтьләү дә кыен, чөнки немецларны яклыйсың дип, берәр статья чәпәп куюлары да мөмкин! Соң бит әлеге «нәрсәкәй»не Сталинград янында һәлак булган немец офицерының саквояжыннан табып алганнар. Һәрхәлдә, немецларның этлеге ягыннан кызыклы факт... Андый нәрсә сугышта нигә кирәк? Сугыш хәлләрен чагылдырган роман һәм кинофильмнарда немецлар хатын-кызны дорфа төстә көчләгәннәр, аннары атып үтергәннәр. Алайса теге саклагыч нигә кирәк аларга? Хатын-кызны көчләгәндә берәүнең дә гондон кулланганы юк ич. Ул бит бары яхшы ният белән кулланыла. Немецлар рус хатыннарына яхшылык бүләк итәргә теләделәр микәнни? Югыйсә, ни өчен саквояжларында алар презерватив йөрткәннәр? Менә табышмак. Ирләрнең күбесе хатын-кыз кайгысы турында баш ватмый бит. Кызык, сугыш темасына ирекле сочинение язган Лена Соловьева бу хакта үзе ни уйлый икән? Бу сүзнең чын мәгънәсен аңлый микән ул? Ә бәлки, гондон дигәнне дошманга каршы кулланыла торган граната, мина, яисә нинди дә булса яңа төр корал дип аңлагандыр ул? Көлке бер хәл... Ярар, немецларны куеп торыйк, үзең турында уйларга вакыт. Юкса иртәгә Сталинград янында мөшкел калган немецлар хәленә төшүең бик ихтимал... Укучыларым миннән: «Сугышта гондон нигә кирәк?» — дип сорыйлар икән, ничек дип җавап бирергә? Укучыларыңа үзең уйлаганның барысын да әйтеп бетереп буламы соң... Әгәр, яхшымы-начармы, бер язучы фронтовой гондоннар турында мактап язып чыккан икән, аңа каршы әйтүдән ни файда? Тискәре әйттеңме, бу бит — соцреализмга каршы чыгу булачак. Мине эштә тотмаячаклар аннары. Юу-ук! Өйдә үз-үзең белән сөйләшү бер хәл, класс алдында җавап бирү — бүтән нәрсә. Үзеңне борчып, акрынлап җыйналып килгән уйларыңны ачыктан-ачык әйтеп салдыңмы — хуш, мәктәбем, диген. Укучыларың, бәлки, «сатмаслар» да, әмма инде әти-әниләре, әбибабайлары — җай гына чыксын — кыйблаң өстәгеләр кушканча булмаса, бик тиз тәгәрәтәчәкләр. Син куйган «икеле»ләр яисә ата-аналар җыелышында катырак әйтелгән сүзләр бик тиз исләренә төшәчәк...

Мира Сергеевна төнге бердә генә йокларга ятты. Аның әле беркайчан да мондый ук кыен хәлгә төшкәне юк иде, шуңа да, авыр-ямансу уйларын читкә куарга теләп, мендәр өстендә байтак бәргәләнде. Аның ачуын иң нык китергәне теге хәерсез сүз генә түгел, ә бәлки югары класс укучысы Лена Соловьева язган иншадагы фикерләрнең кайсы әдәби әсәрдән алынганын төгәл генә белмәвендә дә иде.

Укучысы күбрәкне белдеме — бу инде укытучы өчен үлемгә тиң бер нәрсә. Урын-җир өстендә аунаганда Мира Сергеевна үзенең мораль үлемгә якынлашуын сизде. «Сочинениесен күтәреп, әллә директорга керим микән? — дип газапланды ул, кул-аяклары белән юрганны читкә

бәргәләп.— Директор сугыш турында нәрсә белә соң, армиядә булмаган, 29 яшен төгәлләп кенә килә... Бәлки, дөньяда андый әсәр юктыр ул? Ихтимал, Лена аны уйлап чыгарган яисә идән асты самиздатында чыккан берәр китап кисәгеннән файдалангандыр! Самиздатта чыккан әдәбиятны, кулга эләксә, мин укырга тиешме? Моның өчен эшеңнән колак кагу гына түгел, статьяга килеп кабуың бик ихтимал... Юк, юк! Иң яхшысы, сугыш ветераннарының берәрсе белән әңгәмә корып карарга! Инша хакында берни әйтмичә генә. Ләкин ул ветеран үз укучыларының әтисе яисә бабасы булырга тиеш түгел...»

Мира Сергеевна әнә шундый уйлар белән ятып йоклады. Күпмедер вакыттан соң ул, җиңелчә пышылдау һәм Колясының таныш иреннәрен тоеп, үзе дә сизмәстән диярлек эчке киемнәрен салып ташлады. Аркасына яткан килеш, ислемай исе сеңгән мендәрен үпте, кочаклады, татлы хиссияткә бирелде... Саташып уянганнан соң гына бу хәлләрнең татлы төш икәнлеген тойды һәм Николайның янәшәдә булмавы күңелен үкенеч белән тутырды. Үз-үзеннән оялды ул, үз-үзен нәфрәт белән кыйнады. Татлы-саташулы тойгылар аңа тирән яра ясаган иде. Менә шуңа да, бу халәтеннән тизрәк котылырга теләп, киенде, төшендәге үбешүләр, ә бәлки инде исән дә булмаган Коляның сурәте артка чигенгәч кенә күңеленә күпмедер тынычлык килде аның.

Бу тынгысыз кичтә Мира Сергеевна икенче кат йоклап китте. Бу юлы Лenaның өй эше турында уйламаса да, төшендә дөнья буйлап гизде: әле Сталинград яны сугышларында катнашты, әле ниндидер концлагерьга эләкте, әле ниндидер немецның саклагыч нәрсәсез генә көчләвенә юлыкты... Уянганда тәмам курыккан һәм кара тиргә баткан иде.

## Консультация

Икенче көнне, эңгер-меңгер төшкәч, Мира Сергеевна бер ярты тотып Ватан сугышы ветеранына — чатан аяклы ялгызак картка, эчү белән даны чыккан инвалид өенә килде.

Инвалид агай шактый кәефләнеп өлгергән иде инде, күчтәнәч яртыны күргәч, тәмам айныды, очрашу хөрмәтенә ярты стаканны рәхәтләнеп каплап та куйды. Аракыдан баш тарту аның өчен фаҗигагә тиң бер хәл иде.

— Иван Федотыч, сез сугышта хатын-кызларны яраттыгызмы? — дип, турыдан-туры көтелмәгән сорауны биреп ташлады кунагы, чөнки ул сүзне нәрсәдән башларга белмичәрәк тора иде.

Мира Сергеевна уртача матурлыкта булса да, сыңар аяклы, сакал баскан, ярым чиста сәрхүш карт өчен генә түгел, хәтта яшь-булдыклы егетләргә дә дөнья гүзәлләренең берсе булып күренерлек иде.

— Мин хатын-кызларны һәрвакыт яраттым, сеңлем. Хәзер дә шулай... Сугышта бит янәшәңдә үлем йөри, ә үлем алдыннан хатын-кыз турында уйламыйсың инде. Андый чакта иң әүвәл якын туганнарың искә төшә. Туплар атканда музалар тик тора, диләр. Кино караганың бардыр. М-да, анда хәтта мәетләр арасында да үбешүләр мөмкин... Болар барысы да саташу, сеңелем... Моны ярты юләрләр генә эшли... Мин моның мисалларын күп ишеткәнем, күргәнем бар. Сугыш — хәтәр нәрсә, тирәягыңда гел мәетләр, үзең дә көннәрнең берендә мәет булып куймагаең, дип уйлыйсың... Госпитальдә исә хәлләр бөтенләй башка, анда инде тормыш-яшәү хисе аңкып тора! Миңа 30 яшь иде. Мин анда яшь кенә шәфкать туташы белән ихластан якынлашып киттем. Болар, әлбәттә, минем аякны кискәч һәм яралар төзәлгәч булган хәлләр. Аңа кадәр минем башымда хатын-кыз үе бөтенләй юк иде... Ул чакта минем койка янәшәсендә бер галим яткан иде. 40—50 яшьләр тирәсе, һәрхәлдә, бездән

картрак инде. Мәхәббәт хакында, әй, фәлсәфә корып күрсәтә бу! «Хат ің-кызга мәхәббәт гомер буе дәвам итә. Ә инде гомер уза торгач, гамәлдән теориягә таба авыша башлый»,— ди торган иде ул. Мин ул чакта аның әйткән хикмәтле сүзләрен аңламый идем. Менә сез — гыйлемле кеше, мөгаен, тәҗрибә белән теориянең аермасын яхшы беләсездер... Белмисез-ме? Ха-ха... Менә монысы гаҗәп?!.

— Мин, әлбәттә, чынбарлык һәм теориянең нәрсә икәнлеген чама-лыйм,— диде Мира Сергеевна, югары белемле икәнен аңлатырга тыры-шып.— Билгеле булганча, кеше тәҗрибәгә үзе белеп-тотып караган нәр-сәләр аша ирешә. Кулы гына түгел, күз һәм колаклары да шушы эшкә ярдәм итә. Кыскасы, кеше бөтен авырлыкны үз җилкәсе аша үткәрә, тәҗрибә туплый. Теория исә — тәгълимат ул. Аның аша алынган белем-нәрне гамәлдә сынап, тикшереп карарга кирәк. Гомумән, Иван Федотыч, теория белән гамәлне аерып карау бик кыен. Алар күренмәс җепләр белән үзара бик тыгыз бәйләнгән. Теория — аңга, кеше күңеленә бәйле нәрсә. Ә инде уйлый белмәгән организмнар бары гамәл белән яши... Кайсыдыр акыл иясе әйткәнчә, сөюнең дә теоретик һәм гамәли яклары бар. Биредә мәсьәлә күпкә катлаулы, чөнки сөю формуласын әле берә-үнең дә төгәл генә әйтеп бирә алганы юк. Тәнең белән тоймаган, ләкин янәшәңдә диярлек торган мәхәббәтне теория дип билгеләргә мөмкин-дер...

Инвалидның инде сүнәргә таба барган күзләрендә тере очкын кабын-ды: Мира Сергеевна мәхәббәт хакында сөйләү өчен нәкъ менә аңа керсен әле! Алар бүлмәдә икәүдән-икәү генә булу сәбәпле, бу хәл аңа төрлечә уйларга урын калдыра иде. Ул әледән-әле иске дерматин белән тышлан-ган какшаулы урындыгын рәтләгәндәй итте, култык таякларына таянды да Мира Сергеевнаның рөхсәте белән стакан төбенә янә бераз аракы салды. Шуны авызына койганнан соң, арыш ипиен иснәде дә, тигез хокуклы әңгәмәдәш роленә кереп, сорау бирергә ашыкты:

— Шулаен шулай да, баш бит үзе дә кеше тәненең бер өлешенә керә. Адәм баласы баш миен кыймылдата икән, димәк, ул тәне белән дә эшли дигән сүз. Шуңа күрә теория белән практиканы ничек аерырга соң? Мин аптырап калдым...

— Әйтәм ич, укытучы өчен, мәсәлән, дәрес бирү — практика, ә инде булачак шоферларга машина төзелешен аңлату — теория. Димәк, баш мие белән генә ярату шулай ук теориягә керә. Гамәли мәхәббәт өчен исә тәннең башка әгъзалары да катнашу сорала... Бу мәсьәләләрдә, Иван Федотыч, сез генә түгел, башка бик күпләр дә бутала. Диамат аңлатуын-ча, аң — баш мие продукты, димәк, материянең, ягъни безнең тәнебез продукты. Шушы мисалда диамат материянең — беренчел, аңның икен-чел икәнен исбатлый. Ә рухны кая куясың? Аң материядән аерыламы, рух тәннән аерыламы — әле моңа бер генә галимнең дә җавап бирә алганы юк.

Инвалидны баштарак мәхәббәт темасы кызыксындырса да, хәзер инде Мира Сергеевнаның аң һәм материя турындагы фәлсәфәсе аны туйдыра башлаган иде. Шунлыктан ул, кирәксә-кирәкмәсә дә, искергән-таушалган борынын имән бармагы белән угалады, урындыгын күче-ргәләде, аның уйлавынча, ул әле кетмәгәндә килеп кергән бу хатынга яратуга сәләтле икәнен гамәли яктан да раслап бирә алыр шикелле иде. Әңгәмә темасын үзгәртәсе килеп, шуңа да Мира Сергеевнаның тукталганын көтә иде. Сүз әйтергә теләп, берничә тапкыр талпыныш ясавы күгелҗем иреннәрен кыймылдату һәм өзек-өзек иҗекләр чы-гарудан уза алмады. Ниһаять, тол хатын тәмәке төтене исеннән төчкерә башлады һәм менә шул чакта инвалидка үз фикерләрен әйтергә мө-мкинлек ачылды.

— Мәхәббәт ул, кадерлем, катлаулы нәрсә. Әйе, рухка бик якын ул. Дөресен әйткәндә, мин кайсы беренчел, кайсы икенчел дигән нәрсәләр белән беркайчан кызыксынмадым. Фән бит шулай аңлата: башта кеше

туган, аннары гына уй-фикерләре. Ләкин моның хатыннарга ни бәйләнеше бар?.. Кайчакны янәшәндә беркем булмый, ә тәнең мәхәббәт эшләренә әзер тора. Күрәсең, иң элек кешенең рухы-жаны уяна, аннары инде тәне... Салып жибәр азрак! Төчкерүне шундук бетерә ул...

— Мин бит шампан шәрабе генә эчәм, Иван Федотыч, аракы йоткаsuccessным юк...

— Төрле-төрле шәрабләргә караганда аракы файдалырак, дип саныйм. Мәсәлән, мин эчәм һәм беркайчан да авырмыйм... Хәтта төчкергән дә юк. Күз тия күрмәсен тагын, ходаем...

Хатын, бу сүзләргә ышанып, стакандагы аракыны көч-хәл белән эчеп куйды. Каршындагы әлкәш картка охшатып, өстәлдәге бердәнбер кабымлыкны — кипкән сохари кисәген иснәде. Мира Сергеевна төчкерүдән соң бүленгән сүзләрен дәвам итә башлагач, инвалид аңа аракы тәкъдим иткәненә үкенеп тә куйды. Хатын янә төчкерә башласын әле дип, тәмәкесен кабызды. Әмма хатын инде төчкерми иде, киресенчә, фәлсәфи уйларына тагын да ныграк, тирәнрәк кереп китте.

— Бу очракта сез хаклы, Иван Федотыч. Андый хәлләр хатын-кыз белән дә булгалый. Рухның беренчел, тәннең икенчел булуы мәхәббәт өлкәсендә генә түгел, жәмгыять тормышында да чагылыш таба. Коммунизм төзү этабында кешеләрне өр-яңадан үзгәртеп тәрбияләү, аның соңында сүз тыңлаучан монолит жәмгыять вәкилләре әзерләү нәкъ менә шушы күренешнең ачык мисалы. Бу очракта рух беренчел, чөнки кешене үзгәртеп кору өчен аның жанына үтеп керәләр. Хикмәт шунда ки, бу эш белән диаматка тирән бирелгән кешеләр шөгыльләнә...

Мира Сергеевна атеизм, идеализм, физика өлкәсендәге ачышлар, рухның гажәеп бер нәрсә икәнлеге хакында тагын әллә ничаклы нәрсәләр сөйләде әңгәмәдәшенә. Парапсихология һәм телепатия хакындагы яңа мәгълүматлар да читтә калмады. Кешенең уй-фикерләре ерак араларга тапшырылуы, кеше организмындагы «пси» факторы хакындагы хәлләрне карт аеруча кызыксынып, гажәпләнеп тыңлады...

Хатын артык мавыгып киткәнен чамалады, ул бит бу әлкәш инвалид янына лекция укыр өчен кермәгән иде ләбаса! Педагогларга хас булганча, ул үзе теләгән төп мәсьәләнең чишелешен эзләде, шуңа ачкыч табарга тырышты. Ничек кенә жай табып, теге сорауга ачыклык кертергә соң?

Жай чыкмаганлыктан, Мира Сергеевна бертуктаусыз фәлсәфә корды, әллә укытучылык, әллә хатын-кызлык горурлыгымы шунда, төп сорауга күчәргә ирек бирми иде. Инвалид карт хатын-кызлар турында сөйләгәндә теге сорауны кузгату уңайсыз булса, ә инде парапсихология кебек югары материялардән соң өч тиенлек презерватив темасына күчүләре икеләтә авыр иде. Мира Сергеевна кыюлык өчен берничә йотым эчемлек капты. Шуны гына көтеп торган инвалид, форсаттан файдаланып, әңгәмәгә керергә ашыкты:

— Паровозның пар белән эшләгәнен беләм. Ә менә пар белән эшли торган психологияне күз алдына китерә алмыйм. Шулай да чамалыйм. Ну, шайтан алгыры, гажәп булачак бит! Димәк, син өйдә утырасың һәм миңа үзеңнең уйларыңны жибәрә аласың. Ә син, өеңдә утырган килеш, минем ниләр уйлаганны белә аласың микән, ә?

— Галимнәр кешедә «пси» дигән матдә барлыгын исбатларга ниятләнәләр. Әгәр менә шушы расланса, сезнең дулкынга көйләнә алсам, сездәге фикерләрне, һичшиксез, укый алачакмын. Әле монысы мәсьәләнең бер ягы гына. Кешедәге «пси» кисәкчәсенә таблетка һәм уколлар ярдәмендә тәэсир итеп, аның рухы-жаны белән идарә итү мөмкинлекләре ачыла. Сез, Иван Федотыч, моның нинди сикереш, үсеш булачагын күз алдына китерәсезме! Бу — ифрат зур дәрәжәдәге фәнни-техник прогресс булачак! Миллионнарча сәяси тәрбиячеләрнең кирәге бетәчәк, әллә ничаклы оешмалар, фәнни-тикшеренү институтлары ябылачак. Ни партия, ни комсомол, ни профсоюз, ни матбугат калмаячак. Фәкать хөкүмәт һәм Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты гына калачак. Хөкүмәт башлыгы-

ның фикер һәм директивалары газета-китаплар сыйфатында түгел, пилюли һәм инъекцияләр рәвешендә дөнья күрәчәк. Димәк, хөкүмәт белән теләсә нинди чукрак яисә сукыр идарә итә алачак дигән сүз. Күпьеллык, кыйммәткә төшә торган күпме тырышлыклар, шул ук вакытта нәтиҗәсе ташкүлчим булган сәяси-тәрбияви эш бала табу йортында ук нәни гражданин өчен нибары бер укол белән алыштырылачак. Икенче укол исә хөкүмәт башлыгы алышынган очракта гына ясалырга мөмкин. Шуңа күрә бу илнең гражданнары, икенче кат укол ясалудан куркып, үзләренең юлбашчысына мәдхия укып гомер итәчәкләр.

— Алайса госбезопасность нигә кирәк?—дип, куркынган төстә сорады инвалид.

— Халык арасында уколдан качкан яисә аның йогынтысына биреш-ми торган кешеләр дә табылырга мөмкин. Госбезопасность дигәнең менә шуларны йөгәнләү өчен кирәк тә инде... Сезнең, мөгаен, коммунизмда дәүләтнең үләчәге хакында ишеткәнегез бардыр. Ленинның «Дәүләт һәм революция» дигән атаклы китабында бу хакта ачык әйтелгән. Ленин, дәүләтнең үләчәген дәүләтне ныгыту юлы эшләү мөмкин, дигән фараз үткәрә. Ленинның томанлы тезисларын бүгенге көнгә күчерсәк, дәүләтне ныгыту — деспотизм кулланып булса да, аерым бер илнең барлык халыкларын тоташ буйсындыру дигән сүз. Халыкның йөз процентын буйсындырганнан соң бу дәүләт үлә һәм тигезлек килә! Нәкъ менә шушы тигезлек тегесеннән дә рәхимсезрәк булган яңа дәүләтне барлыкка китерәчәк. Ленин биредә мәсьәләнең байтак якларын уйлап җиткермәгән. «Пси» дигән матдә-кисәкчәләрдән оста файдалана белгәндә генә сүз тыңлаучан бертөрле җәмгыять төзергә мөмкин. Марксистлар моны беләләр, әмма аларга барыбер кешенең рухы белән эш итәргә туры киләчәк.

— Ишеткәнем бар бу хакта. Коммунизмда хәтта акча да бетәчәк, диләр. Бер яктан, бу бик яхшы. Никадәр мәшәкатьтән котыласың! Үтерү, талау кебек нәрсәләр һәммәсе акча аркасында килеп чыга бит... Банк, саклык кассалары да халык һәм дәүләт өчен бер җәфа инде... Һе, коммунизмда ничек булыр икән соң? Акча бетерелә икән, аракыны ни-нәрсә белән аласы икән? Төзиләр — ә мәгънәсе әллә нәрсә түгел. Арестантларны бушка ашаткан, киендергән сыман итмәкчеләр. Нигә миңа андый тормыш! Була торган хәл түгел бу. Коммунизмга ныграк барган саен без катырак эчәчәкбез. Минемчә, дәүләт үлсә дә, аракы һәм акча беркайчан үлмәячәк...

Соңгы сүзләрен әйткәндә инвалид Мира Сергеевнага шундый итеп карады ки, өстәлдәге шешәдә калган йөз грамм аракыдан башка, аның уенча, коммунизмга барып җитү мөмкин түгел иде.

Мира Сергеевнаның юньләп аракы эчкәне булмаса да, аңлады: шампан шәрабләренә караганда монысы көчлерәк, тәэсирлерәк икән. Күбрәк сөйләшкән саен алар Мира Сергеевна ачыкларга теләгән сораудан еракләша бардылар. Юкса бер сорауга ачыклык кертер өчен генә алкоголик карт янына керде һәм аның белән табындаш булуга ризалашты ул. Кыюлык өстәр өчен әллә тагын бераз эчемлек кирәк булды микән?

Каршында утырган ханымның уйларын укыгандай, сугыш ветераны сүнеп барган «Беломор»ын читкә чиртеп ташлады да, урындык артына таяна-таяна, шкафтан бутылкалы куе сыеклык тартып чыгарды. Маймыл бананны чистарткан бер суррәттә, тешләре белән калай бөкене каезлап алды да шешәдәге тозлы сыекчаны үзенең стаканына салды. Аңа кушылып, Мира Сергеевна стаканы төбендә калган күз яшедәй чиста сыекчаны эчеп куйды.

«Зәһәр, шайтан алгыры, аракы ише генә түгел»,— дип ухылдады инвалид, стаканын каплап куйгач. Көмешкәнең сасы исеннән Мира Сергеевна читкә борылды, шул форсаттан файдаланып, сумкасындагы эчене эластик резин бәҗра салынган җәгазь пакетны капшарга өлгерде.

— Сезнең бу «штука»ны күргәнегез бармы, Иван Федотыч?—дип сорады ул, алдан ук әзерләнгән соравын, ниһаять, тышка чыгарып.

— Юньләп хәтерләмим дә инде. Онытым аны портфелендә йөртә. Минем яшьтә мина керәге юк инде аның...

Нервылары нык кына киерелгән булса да, Мира Сергеевна үзен борчыган, тынычлыгын алган сорауга җавап алырга теләп, соравының һәр сүзен иҗекләп әйтеп бирә алды: «Для че-го на вой-не гон-дон?» Инвалид, каткан һәйкәлдәй, селкенмичә утыра иде. «Әйтегезче, Иван Федотыч, сугышта нигә кирәге бар аның? — дип гайрәтләнеп китте ханым.— Сез бит өч сугышта катнашкан кеше. Орден һәм медальләрегез бер кастрюльне төбәләмә күмәрлек. Мактанган булдыгыз тагын. Ә үзегез гап-гади бала-чага соравына да җавап бирә алмыйсыз... Тагын кабатлап сорыйм: нигә кирәк икән ул? Әйтегезче шуны».

Инвалид нидер әйтергә талпынып караган иде, җавап урынына авызыннан аксыл күбек чыгып, төбенәчә диярлек киселгән сынар аягы ягына таба кинәт авып төште.

Коточкыч курку халәтен җиңеп, Мира Сергеевна урамга йөгереп чыкты. Тиз атлады, юл буе бер генә таныш-белешенә дә юлыкмады. Монысы шатландырса, шул ук вакытта чирле, ялгызак инвалидның үзен генә шул хәлдә калдырып китү аның намусын талкыды. «Нигә эчтем, әгәр аек булсам, мин аңарга, һичшиксез, беренче ярдәмне күрсәткән булыр идем. Хәтта «скорый» чакырган булыр идем әле,— дип бәргәләнде ул.— Әгәр минем, укытучының, эчкече бер картка кергәнемне белсәләр?.. Коточкыч! Нәрсәләр булачак, аерым статья белән эштән гөрләтеп куачаклар! Әгәр карт үлсә, төрмә дигән сүз. Дипломнан мәңгегә колак кагачакмын... Вәт, юләр, нигә әле шул балалар сочинениесе белән башымны әйләндердем! Ни телиләр, шуны язсыннар. Ахмак баш аякларга тынгылык бирмәс, ди. Эшләр харап... Нишләргә соң?»

Йорт почмагына сөялеп бераз еламсыраганнан соң ул, кинәт үзен кулга алып, инвалидка беренче ярдәм күрсәтү нияте белән алга таба кузгалды. Ветеран яшәгән йорт подъездында ниндидер бер хатын исәнләшкән иде, Мира Сергеевна җир тишегенә кереп китәрдәй дәрәҗәдә уңайсызлану тойды. Ирексездән баскыч култыксасына таянды, чөнки аякларын атлар хәле юк иде. Шулай да көч-хәл белән аска төште, диварга таяна-таяна урамга чыкты. Аңлады: мондый хәлдә ул инвалидка барыбер бернинди ярдәм күрсәтә алмаячак...

Төшенә иде: картның өенә керсә, андагы хәлләрдән ул йә аңын югалтачак, яки бөтенләй җан тәслим кылачак. «Аның янәшәсендә үлеп калу, җитмәсә, икәүдән-икәү, нинди хурлык булачак! — дип, томанлы гына уйлана иде ул, инвалид йортыннан ераклаша барып.— Беренче ярдәм күрсәткәндә, ихтимал, «авызга авыз» ысулы белән ясалма сулыш алдырасы да булыр иде әле. Аллам сакласын, шул хәлдә кочаклашкан килеш үлеп китсәң! Иртәгесен тикшерүчеләр, газетчылар сиңа фотога төшереп алачак. Сенсацион фельетон әмәлләп тә куярлар: утыз яшьлек ханым 65 яшьлек инвалид карт кочагында эчеп үлгән, диярләр! Ә пакет кайда соң?.. Соңгы тапкыр сорау биргәндә өстәл өстенә килеп төшкән иде, димәк, сумкасына кире салырга онытткан ул аны. Бу инде фельетонга гына түгел, чып-чын детективка тиң. Хурлыгы ни торачак!»

Шушы уйларына уралып, Мира Сергеевна черек койма белән бергә нәни бакча эченә таба ауды. Аяклары исә тротуардан бераз гына чыгып тора иде.

## Хатын-кызлар айныткычы

Сугышчан комсомол дружинасы членнары (БКД) сәрхүш хатынны якындагы айныткычка илтеп тапшырдылар. Бөгәрләнгән өске киемнәре, газаплы кыяфәте биредәгеләр өчен күпне аңлата иде. Әмма Мира Сергеевна беренче минутларда ук аңына килде һәм

бернинди дә начарлык эшләмәвен тырыша-тырыша аңлатып, җибәрүләрен үтенде. Дружинниклар белән ул баштарак тыныч кына атлап барган иде, чөнки кызыл чүпрәк бәйләгән бу егетләр, ни әйтсәң дә, жуликлар түгел сәнә. Ләкин арадан бер үткенрәге күкрәгенә кул суза башлаган иде, хатын аның яңагына чалтыратып сукты. Шушы хәлне «кабартып», БКД членнары ике битлек рапорт язганнар иде.

Айныткычта аны капшап тикшерә башлагач, хатын бер милиционерның бармагын тешләде, анысы да рапорт язды. Шулай итеп, ярты сәгать эчендә Мира Сергеевна үз биографиясенә гомер буе да эшли алмаган күңелсезлекләрне туплап өлгерде.

Сорау алганда, тәҗрибәсезлеге аркасында, янә дә чираттагы хатасын кылды: үзен төзелештә эшләүче ташчы, бүтән адрес белән яшәүче Иванова Анфиса Петровна дип танытты. Яңакка сугу һәм бармакны тешләү гаепләре янына өченчесе — рәсми документта теркәлгәнчә әйтсәк — хакимият вәкилләренә каршылык күрсәтү, кул күтәрү, рәсми хезмәткәрләрне алдау кебек күңелсезлекләр бер бәйләмгә тупланды.

Селектор кнопкасына басып, дежурный яңа кешенең адресын, исем-фамилиясен, туган елын, эш урынын күз ачып йомган арада ачыклап биргәч, Мира Сергеевна нинди хата эшләвен бик тиз аңлап алды, тик соң иде инде. Матбугат, радио, кино аша бу кызыл погонлы егетләрне үз итеп өлгергән иде ул, укучыларын да төрле тәрбия чаралары ярдәмендә милиция хезмәткәрләрен хөрмәт итә белергә өйрәтә, яшүсмерләрне БКД членнары булырга чакыра иде. Ә хәзер нәрсә?..

Ә хәзер короллы, тупас, тук кыяфәтле милиционерлар даирәсенә, рәшәткә дөньясына эләккән, махсус урындыкка бәйләп куелган Мира Сергеевнаның тәртип сакчылары хакындагы уйлары үзгәреш кичерә иде: «Димәк, Советлар Союзында барлык гражданнар төгәл исәптә тора, аларга эштә генә түгел, арестантлар сыман, милициядә дә досье-мәгълүмат тупланган. Гражданин эшкә конвойсыз йөрсә дә, аның артыннан КГБ, МВД, тагын илнең әллә ничаклы яшерен һәм яшерен булмаган оешмалары, агентлары дүрт күз белән күзәтеп тора икән... Баксаң, бу иксез-чиксез илне чорнап-саклап торган пограничниклар һәм ит ашап кына үскән овчаркалар чит ил шпионнарын һәм агентларын тоту өчен түгел, ә үзенең гражданнары, төрмәдән качкан арестант кебек, чит илгә чыгып качмасын өчен дә тырышалар икән».

Мира Сергеевнаны (хәзергә Анфиса Петровна) өске киемнәрен бер кат чишендереп, камерага кертеп яптылар. Анда сәрхүш кыяфәтле хатыннар байтак иде. Арадан берәве, почмаккарак елышкан да, күз яшьләрен чишмәдәй агызып елый. Борыныннан кан тама, күз яшьләре белән кушылып, алар икесе бергә иҗәндә әрекмән яфрагы чамасындагы карал-җым-кызгылт тап барлыкка китергән.

«Менә мине нишләттеләр тәртип сакчылары,— дип пышылдады ул кабарган, канлы иреннәрен кыймылдатып.— Үзем юләр, аларны телефон-автоматтан чакырган булам тагы. Янәсе, безнең подъезд төбендәге яшүсмерләрне акылга утыртырлар, дип. Хулиганнар исә дружинниклар белән дуслар, әшнәләр икән. Мине шаһит итеп алып киттеләр... Менә шунда хәлләр үзгәрде дә куйды! Тегеләрнең дүртесен дүрт якка чыгарып җибәрделәр, ә мине медэкспертизага өстериләр. Айныткычка җибәрүләреннән куркып, каршы киләм. Мин бит, чыннан да, бер танышымның туган көненнән әзрәк сыйланып кайткан идем... Бармадым экспертизага! Ә нәтиҗәсе нәрсә? Тотып яңакладылар, яла якты һәм каршылык күрсәтте, дип беркетмә яздылар. Мин аларны кыйнаган булып чыга, эх! Исемем Кла-ва ми-нем...»

Бу кичерешләрдән күңеле сынык Клава янә үксеп елады. Күз яшьләренә тәмам батканнан соң акрынлап тынычланды, хәтта йокымсырап китте шикелле.

Шуны гына көткәндәй, топчанга ныклап бәйләп куелган бер хатын селкенә башлады. Тәртипсез рәвештә таралган соры чәчләре аның ярты

битен диярлек каплап тора иде. Үз-үзе белән сөйләшеп, кемнәрнедер сүгә-сүгә, инде анысы сүз башлап җибәрде:

— Барысының да җанын җәһәннәмгә җибәрергә кирәк. Кешене мыскыл итүче тәртип сакчыларына суд ясасаң иде ул! Андый явызларны иң явыз ысул белән җәзаласаң иде... Әйтик, казык башына утыртып...

— Хә, хә,— дип сүзгә кушылды күршесендәге хатын.— Бездә мөмкин эш түгел бу. Алар бар тарафтан яхшы сакланган, бер бөртек чәчләре дә селкенми. Алар, ни кушылса, робот сыман шуны эшлиләр... Ә менә киноларны кара син, халыкның аңын томалау өчен уйлап табылган нәрсә инде! Син телевизордан участок милиционеры Анискинны күрдеңме? Идеаль герой инде менә! Бу рольдә уйнаган артистны СССР Эчке эшләр министры Щелоков үзе мактады. Халык чын сәнгатьтән соцреализм сәнгатен аера белми... Минем популяр театрда эшләгән чакларым бар иде, хәтта киногa да төшкәләдем. Ахыр чиктә ялган рольләр уйнау туйдырды мине. Ул чакта затлы автомобильләрдә генә йөрттеләр, чыңлап торган бокаллар белән шампанский тәкъдим иттеләр. Ә хәзер әнә, күргәнеңчә, политурадан да баш тартмас идем... Әйе, соцреализм белән чирләгән ил, болай тыштан карасаң, әйбәт кенә кебек, ә эче буш, сәламәт үсеш күренми анда. Социализм илендә канәгатьсезлек белдерүчеләр, алкоголиклар, карак һәм хулиганнар, хәтта янгын һәм су басулар да булмаска тиеш. Инде дә тугыз баллы җир тетрәү уза икән, ул бернинди җимерелү һәм корбаннарсыз гына булачак. Поездлар сафтан чыкмый, авиация фаҗигаләре күзәтелми. Соцреализм — чынбарлыкны үзең теләгәнчә күрергә тырышу дигән сүз... Колхозчы әнә утыз ел буена борыны белән җир сөрде, әмма ул крепостной крестьянга караганда начаррак хәлдә. Ни өчен эшчеләр сыйныфы алдынгы сыйныф дип атала? Чөнки ул корал һәм дубинка ярдәмендә крестьянны буйсындырды, аны бушка эшләргә мәҗбүр итте. Пролетариат диктатурасы эшчедән жандарм ясады. Авыр хезмәте өчен юньләп берни алмавы өстенә, муеннан салымга да батырдылар колхозчыны. Кечкенә генә җир биләмәсеннән һәм берничә баш малыннан дәүләткә ит, сөт, йомырка, йон, тире, бәрәңге, акча түләде ул... Шундый анекдот бар. Медицина институтында бер студенттан: «Исән чагында бу кеше кем булды икән?» — дип сорыйлар, склетка күрсәтеп. «Колхозчы»,— дигән студент, ике дә уйлап тормыйча. «Ә нигә эшче дип уйламыйсың?» Пыяла шкаф эчендәге склетның мәгълүм әгъзаларын күрсәтә-күрсәтә: «Чөнки итен, тиресен, йонын, йомыркасын тапшырган...» — дигән студент, бик ышанычлы-белдекле кыяфәт ясап.

— Хи-хи-хи,— дип көлемсерәде бәйдәге хатын.— Бәлки, бауларымны чишәрсең. Бөтен сөякләрем авырта. Теге явызлар бер дә кызгана белми мине...

— Чишә алмыйм, бауларыңны бераз бушатырга икән, анысы мөмкин. Күрсәләр, тегеләр минем үземне дә синең белән бергә топчанга бәйләп куячаклар...

## «Кыз-тәкә»

— Җитте сезгә, зәһәрегезне чәчмәгез! Кеше түгел, адәм калдыклары сез. Тапканнар урын, тукмап ташлыйм юкса, хәшәрәтләр! — дип кисәтте берәү, әзмәвердәй гәүдәсен калкытып.— Дәшмәгез, әрәмтамаклар! Сөйләшер сүз тапканнар, ә? Мондый сүзләрегез өчен атарга кирәк сезне. Политика — сезнең эше бозаулар өчен түгел ул. Мильтоннар сезне жулик һәм бандитлардан саклый, рәхмәт әйтәсе урында, алар хакында авыз чайкап торасыз тагы. Сез, еланнар, биредә елга бер тапкыр буласыз, ә мин атна саен эләгәм. Йоклагыз, мәхлуклар, миңа ял итәргә кирәк!

Әзмәвер хатын әңгәмәчеләрне яман сүзләр әйтеп тынычландырды. Аннары әлеге хәлләрдән баганадай катып калган Мира Сергеенага таба сак кына якынлашты, аның өстендәге нәфис комбинацияне һәм гәүдәсенең матурлыгын күздән кичерә-кичерә, хатын тирәсендә бер әйләнеш ясап алды. Айныткычтагы пычрак, сәрхүш хатыннар арасына очраклы рәвештә килеп эләккән Мира Сергеевна үзен әле һаман да уңайсыз хис итә иде.

— Күрче, синең өстеңдә өр-яңа ефәк комбинация икән, шайтан йоткыры! — дип, йомшак кына сөйләнде әзмәвер, әле һаман да Мира Сергеевна тирәсендә әйләнеш ясап. — Исемең ничек синең? Беренче тапкыр керүең, ахры? Мине Маша диләр!

— Анфиса — дип тын гына җавап бирде Мира Сергеевна. — Мин бирегә очраклы гына эләктем...

— Бирегә берәү дә махсус килеп керми, һәммәсе очраклы рәвештә эләгә. Мин биредә атна саен диярлек кунам, һәрчак очраклы килеп эләгәм. А ну-ка, үскәнем, чишен әле! Карыймчы. Ева костюмыннан ничегрәк күренәсең икән син. Аннары минем янымда ятарсың, җылытырмын сине, одеялымны калдырырмын... Иртән мине моннан куып чыгарачаклар, төн кунган өчен 25 сумым түләнгән инде. Курыкма, бетле түгел мин. А ну, җәһәтрәк бул, юкса ике күзеңне чокып чыгарырмын! — диде әзмәвер, ике бармагын ике якка тырпайтып. — Бишкә тикле саныйм! Бе-ер...

«Ике» дигәнне санаганнан соң, Мира өстендәге комбинацияне аерып төшергән иде инде ул. Камерада берәү дә йокламый, югалып калган, юка һәм яклаучысыз Мира Сергеевна белән көчле, биек буйлы, ямьсез хатын арасындагы тарткалашны һәркайсы кызыксынып күзәтергә керештеләр. Киң җилкәле, сары мыеклары сизелеп торган бу хатын, беркемнән дә курыкмыйча, карлыккан калын тавыш белән фәрман бирә иде.

Мира Сергеевнаны куркытса да, әзмәвер хатын аның күзләренә кагылмады, билгеле. «Дүрт» дип санаганның соңында мәче елгырлыгы белән аның билдән түбәнге эчке киемен дә ташланды. Тигезсез көрәштә Мира Сергеевна тагын җиңелде... Махмыр төшә башлаган хатыннар, тамашадан тәм табып, хахылдашып алдылар.

Бу вакытта камераның махсус тәрәзәчегеннән карап торган надзиратель, җәмәгать бәдрәфе диварларында гына очрата алган кайбер тере «сурәтләр»не инде үз күзләре белән күреп, тәмам ләззәт кичерә иде. «Яхшы хатын! — дип, авыз тирәсендәге селәгәйләрен ялады ул, комсызланып. — Әле болары чәчәге генә, лагерьга озатсак, җимешләрен алда күрерсең». — Шулай дип сөйләнгәндә, надзиратель тешләнгән бармагын җиңелчә капшап куярга да онытмады. Яңарак китерелгән бер исерек дулый башлагач, шул камерага таба күчеп китәргә туры килде аңа.

Мыскылланган һәм җиңелгән Мира Сергеевна берни дә кыла алмаслыгын аңлады һәм, каршылык күрсәтмәстән, әзмәвернең таләбенә буйсынды. Иң читтәге караңгы бер почмакта бу тупас хатынның үз топчаны бар икән...

Төн уртасында, камерадагылар барысы йоклап беткәч, әзмәвер, табышына ташланган жанвар сыман, Мира Сергеевнаны сәер хәрәкәтләр белән үбәргә тотынды. Мираның кычкырасы килде, тик әзмәвер аны атныкыдай калын иреннәре белән нык томалаган иде. Мира тешләшә башлагач, әзмәвер аның борынын авыр-кытыршы куллары белән шундый дәрәҗәдә томалады ки, буылырга да ерак калмаган иде. Мира Сергеевна, әйтерсең, үлем кочагына куып кертелгән иде, шуңа да ул алга таба юньләп ни селкенә, ни кычкыра алмады...

Канәгатьләнеп алганнан соң әзмәвер Мирага бүтәнчә кагылмады, ләкин янап куйды: әгәр артыгын лыгырдыйсың икән, буып үтерәм, дип куркытты. Мира Сергеевна өчен шулкадәр әшәке минутлар булды бу, теге инвалид карт кочагында үлүең мең кат яхшырак иде шикелле бу мизгелдә.

Әзмәвер гырлый-гырлый йоклап та китте. Корбанына арты белән әйләнгән һәм казна одеялын җилкәсенә каплаган иде. Мира Сергеевна, үлем куркынычыннан котылуына әллә сөенеп, әллә гарьләнеп, тын гына елады да елады. Һәм, ниһаять, аңлады, аның янындагы бу бәндә гермафродит (кыз-тәкә) дип атала торган ярымхатын-ярымир лабаса. Студент чакта тыелган бер брошюра укыганы исенә төште, анда гермафродитлар хакында язылган иде, ләкин тормышта андыйларны беркайчан очратканы булмады. Хурлыклы, яшерен күз яшьләре менә хәзер аны кычкырырга, камерадашларын уятырга чакыра иде. Шул ук вакытта белә: әгәр бу җирәнгеч очрак хакында тел ачсаң, хурлыгы фәкать аның үзенә генә кайтып төшәчәк...

## Хөкем

Ачыклау, «сортлар»га аеру нияте белән, хатын-кызларны иртән айныткыч башлыгына чакыра башладылар: судның хөкем карарын көтәр өчен — кайсыларын КПЗга[1], административ чара күрү өчен эшләгән җирләренә шалтыратып, кайсыларын ирекка чыгару өчен кирәк бу. Бүгенге хатын-кызлардан өчесен КПЗга билгеләделәр. Кичә төнгә кадәр елаган Клаваны, ким дигәндә, унбиш тәүлек мәҗбүри эш көннәре көтә иде, ә калган икесен — күләмле штраф.

Төш вакытларында Клаваны һәм теге ике хатынны «кара козгын» дип аталган махсус машинада, ике сакчы озатуында, район халык суды бинасына алып килделәр. Машинада тагын вак хулиганлык өчен эләккән ун ир-егет кисәге дә бар иде. Унөч кешене бүлмәгә алып кереп, стена тирәли тезеп куелган урындыкларга урнаштырганнан соң, конвоирлар бик җитди кыяфәттә ишек төбенә сакка килеп бастылар. Фәкать икәү — халык судьясы һәм халык утырышчысы утырган хөкем бүлмәсенә гаепләнүчеләрне берәм-берәм чакырып керттеләр. Хөкем эше тиз бара иде. Чөнки халык судьясы, алдан ук әмәлләп куелган төрле-төрле рапорт һәм докладлар нигезендә, гаепләнүчеләрне бик ансат кына кысрыклый, кагыйдә буларак, аларны теләсә нинди штрафка яисә мәҗбүри хезмәт шартларына күндерә иде.

— Болар бар да көлке! — Кораллы ике сакчыга карап, Клава күршесенең колагына пышылдарга җай тапты. — Нужәли, биредәге гаеплеләрнең берәрсе качарга җыена инде? Уйлап карасаң, безнең бит сукыр бер тиенлек тә гаебебез юк. Аңламыйм, нигә безне шулкадәр нык саклыйлар? Кемнән, нәрсә өчен? Болар бар да бала-чага уенын хәтерләтә. Әмма шушы уен өчен миллионнар сарыф ителә, чөнки бирсдә уен башында зур акча алучылар утыра. Бандит, жулик, хулиган һәм каракларны хөкем итәсе урында, алар эчүчеләр белән шөгыльләнә. Ә бит коммунизмны эчүчеләр төзи. Россиянең әле шушы хәтле массовый алкоголизм күренешен күргәне бар идеме? Беркайчан да! Өйдә эчәләр, эштә эчәләр, иртәкичен эчәләр, төнлә эчәләр, почмакта, руль артында, туалетта, мунчада, больницада, ресторанда эчәләр... Начальниклар эчә, ирләр һәм хатыннар, укучы һәм укытучылар, бабайлар һәм апайлар эчә... Кайгыдан да, шатлыктан да эчәләр, яңа әйбер алсалар — эчәләр, киткән һәм кайткан хөрмәткә эчәләр, янгын чыкса, җир тетрәсә, жиде класс яисә диссертация тәмамлаган өчен, беренче һәм соңгы хезмәт хакы өчен эчәләр... Юләрләр һәм акыллылар эчә, чирлеләр һәм сәламәтләр эчә, туган яисә үлгән көн уңаеннан эчәләр. Аракы, көмешкә, одеколон, динатурат, лак, келәй — тагын әллә нәрсәкәйләрне эчәләр... Кыскасы, бездә эчмәүчеләр юк диярлек. Әгәр безнең җәмгыятьтә эчмәүче табыла икән, өйрәтелгән ерткычка

---

[1] КПЗ — «камера предварительного заключения» дигәннең баш хәрефләреннән ясалган сүз.

ирекtә ничек кыен булса, аңа да шул дәрәҗәдә авыр, уңайсыз булачак. Менә минем күршем күз алдында алкоголикка әверелде. Тамчы да эчми торган талантлы инженер иде, хезмәтләре журналларда басыла килде! Бетмәс энергиясен кая куярга белми яшәде. Ике урында эшли башлаган иде — тыйдылар, закон кушмый янәсе! Кичләрен өендә яшьләрне институтка керү имтиханнарына әзерли башлаган иде — анысын да туктаттылар. Шуннан шабашкага китте бу! Көчле, сәләтле яшьләрдән һәм инженерлардан бригада төзеп, ял айларында колхозлар өчен сыер фермалары төзергә керештеләр... Үзәк матбугатта чыккан фельетон аша тетмәләрен тетеп яздылар! Үзләренә һәм җәмгыятькә файда китерергә теләгәннәре өчен пычракка салып таптадылар... Янәсе, ул, коммунизм төзүчеләргә хас булмаганча, баерга омтыла икән. Бер сүз белән әйткәндә, аңарга хезмәт хакыннан тыш өстәмә акча эшләүне бар яклап тыйдылар, шуның белән кешенең балачак хыялын үтерделәр. Ул намуслы эшләп тапкан акчасына автомобиль алу турында хыяллана иде... Үзегез беләсез, инженерның айлык акчасы ашау-эчүгә генә җитәрлек... Фельетон завод коллективы тарафыннан тикшерелде, инженерны «гаебен» танырга мәҗбүр иттеләр. Газета үзенең эшен эшләде: ир-егетне эшеннән кудылар, дус-ишләре аңардан йөз чөерде, хатыны китте! Аннары инде талантлы инженерыбыз ишегалдында, барлык коммунизм төзүчеләр шикелле, домино суга башлады, эчүгә дә сабышты. Хәзер инде ул чын алкоголик, тегеләр белән динатурат эчүдән дә тартынмый. Ул хәзер безнең ишегалдының почетлы уенчысы, аның хакында фельетоннар да язылмый. Юклы-барлы акчасын эчә, башкалар белән бер сафта атлый егет... Безнең идеологлар бүгенге алкоголизмның сәбәбен яхшы беләләр, әмма аңа каршы ничек көрәшергә икәнен чамалыйлар. Ә сәбәбе бер генә: Россиядә алкоголизм җәмгыятьне үзгәртеп кору, ягъни шәхси милекчелекне бетерү һәм гражданнарның иреген чикләү нәтиҗәсендә тамыр җәйде. Эчүчелекне идеология үзе тудырды. Хәзер инде үзе үк аңа каршы геройларча көрәш алып бара. Димәк, үз-үзең белән көрәш дигән сүз. Алай була алмый! Менә шуңа да идеология эчүчелеккә каршы бары формаль төстә, күз буяу өчен генә көрәшә. Дәүләт, үзен алкоголизм дошманы итеп күрсәтү ниятеннән, аракыга бәяне һаман күтәреп тора. Әйе, дөреслек бар кебек: кыйммәт икән — эчүчелек кимиячәк... Ә тормышта киресенчә килеп чыга: бәяләр үскән саен эчкечелек тә арта бара. Азат хезмәт кешесе исә, хаҗәте юк икән, аракыны бушка бирсәләр дә эчми... Алкашлар айлык хезмәт хакын бер атна дигәндә эчүгә тотып бетерәләр һәм шуның белән ил өчен кирәкле пролетарийга, гражданинга әвереләләр. Сүз уңаеннан, сез белмисезме, нигә халык суды дип атала икән бу тамаша?

— Шуңадыр, күрәсең, биредә бит начальник һәм җитәкчеләрне түгел, гади халыкны хөкем итәләр. Хәрби трибунал да бар әнә, аны халыкныкы димиләр ич...

Ниһаять, Клавага да чират җитте, аны судьясы һәм утырышчысы катнашындагы хөкем залы бүлмәсенә алып керделәр. Республика исеменнән судья Клавага 15 тәүлек мәҗбүри хезмәткә тартылуы турындагы карарны игълан итте. Конвоир гаепле хатынны бүлмәдән чыгара башламакчы иде, Клава үзенә кагылышлы хөкем карарын кире кагарга кереште:

— Ничек инде болай килеп чыга? Мин подъездда көне-төне эчеп ятучы хулиганнар өстеннән җалу бирдем. Тегеләр ишек-тәрәзәне вата, яшәүчеләрне кыйныйлар, бала-чаганы куркыталар, ә мин алар өчен 15 тәүлеккә утырырга тиешмен икән, ә? Юк, жалоба бирәчәкмен! Кайда прокурор, кайда адвокат, кайда шаһитләр? Кайда гадел хөкем?

— Сез бит намуслы кешеләргә яла яккансыз, милиционерга суккансыз, БКД члennарына каршылык күрсәткәнсез. Шуларны раслап, сигез имза салынган. Сезнең бу кыланышларыгыз зурга китә ала, ә без вак хулиганлык бәясе белән чикләндек. Үз эшегез, әгәр жалоба бирәм дисең икән, ким дигәндә, бер елга ирекtән мәхрүм ителүегез дә бар...

Үзенең көчсезлеген танып, Клава алга таба дәшми калуны мәгъкуль санады. Ә күңелендә ачу-хәсрәт казаны кайный һәм бу минутларда ул конвоирны яңакларга, судья һәм утырышчыны мәсхәраләргә дә әзер иде... Ләкин, хәле киткәнлектән, хатын берни эшли алмады һәм язмышы белән ирексездән ризалашты.

Вак хулиганлык өчен хөкем ителгәннәр белән бергә, Клаваны да махсус машина белән шәһәр читенә урнашкан төзәтү-хезмәт лагерена алып килделәр. Ике катлы койма, аның өстендәге өчәр катлы чәнечкеле тимерчыбыклар, овчарка һәм күзәтү вышкасындагы солдатлар Клавага бик начар тәэсир итте. Лагерь биләмәсенә кергәч тә ул күз яшьләрен яшерергә тырышып кына еларга кереште.

«Елама, апа җаным! Кешеләр әле хәтта бер сәбәпсез 15 ел буе утыралар, ә сезгә нибары 15 тәүлек кенә биргәннәр. Барысына төкерегез, узар да китәр. Бирегә көн саен диярлек йөзләгән кешене китерәләр. Минем дә срогым нәкъ сезнекечә. Тынычланыгыз, югалмабыз әле! — дип юата иде баягы әңгәмәдәше, интеллигент кыяфәтле яшь ир-егет.— Ну, җитте еламсырап барырга! Сүгенә беләсезме? Юк, әлбәттә. Монысы начар... Яшертен елауга караганда, кычкырып сүгенү күпкә файдалырак, чөнки нерваларың рәхәтләнеп бушанып кала. Игътибар иттегез микән: мин үз-үзем белән сөйләшергә яратам. Серен әйтсәм-әйтим, бу — сөйләшүем түгел, сүгенүем. Кешеләр моны белмиләр һәм минем хакта «ычкынган» дип уйлыйлар. Мин бит кешеләр барында ярым пышылдап, эчтән генә мырлыймын. Ялгызым гына булганда исә шундый ачы итеп сүгенәм ки, моңардан хәтта үләннәр саргаерга, кабер ташлары телгә килергә, күктәге болытлар парга әйләнергә, өермә кузгалырга һәм хәтта Мәскәүнең мәңгелек радиосы туктап калырга мөмкин!..»

Бу кешенең сәер сүзләреннән соң Клава, гипнозга бирелгән җан ияседәй, елавыннан туктап калды. Хатынның уйлавынча, бу — денсез кеше, диссидент яки кайбер органнарның яшерен агенты булса кирәк иде.

## Аерым ришвәт

Үзен әле һаман да ташчы Анфиса дип барганы өчен, Мира Сергеевнаны ирекkә чыгармадылар, ә бәлки төрле авыр исләр белән чорналган камерада ялгызын гына калдырдылар. Кагыйдә буларак, шәхесе ачыкланмый торып, биредән берәүне дә урамга чыгарып җибәрмиләр иде. Менә шуңа да, Мира Сергеевнаның шәхесен ачыклаганга кадәр дип, аны вакытлыча рәвештә ялгызак камерага күчерделәр. «Ялгызак» дигәннәре коридорның иң теге башында иде. Гәүдәсенә одеял бөркәнгән Мираны бу юлы надзиратель шунда алып китте. Буш камераның ишеген сыңар кулы белән ачып кергән чакта Мира Сергеевна ялгышлык белән одеял почмагына баскан иде, җиңелчә сөртенү сәбәпле, нәкъ менә шул чакта аның зифа-матур гәүдәсе ялангачланып калды. Каушавыннан, ул тизрәк камера эченә атылды, одеял исә надзирательнең аяк астында ятып калды. Тәртип сакчысы баштарак, аңышмастан, билендәге пистолетына ябышты, аннары гына кызыксынучан-йомшак тавыш белән эчке киемнәренең кая киткәнлеген сораша башлады. Бу вакытта Мира Сергеевна, кечкенә куллары белән гаурәтен каплап, бер читтәрәк басып тора иде. Кичәге уңайсыз, акылга сыймаслык хәлләрдән соң ул инде, әйтерсең лә, бернидән дә курыкмаслык сәер халәткә ирешкән иде. Аның уйлавынча, гермафродит белән йоклаган кеше — иң шапшак суны эчкән бәндәгә тиң, һәм менә шушы хәлләрдән соң ул нормаль ир-атка карата яхшы мөнәсәбәттә булырга тиешле кебек...

— Мин сезгә кичә игътибар иткән идем, яхшы киемнәрегез безгә ошаган да иде. Сез бит чип-чиста эчке киемнәрдән идегез! Төн эчендә аны кем белән һәм нәрсәгә алмаштыгыз?.. Мөгаен, картада уйнап оттырган-

сыздыр әле. Бәлки, таблеткага алмашкансыздыр? Сез наркоманка түгелме алай-болай? Йөз-кыяфәтегез андыйга бер дә охшамаган үзе. Бөркәнегез, юкса салкынча бирелә,— дип, надзиратель аңа одеялны сузды.

— М-мин нар-ко-ман-ка тү-гел, киемнәремне дә бер нәрсәгә алмашмадым...— дип елап җибәрде инде ялгыз камераның бердәнбер топчанында утырган Мира Сергеевна. Мине... төнлә чишендерделәр...

— Кем сезне шулай чишендерергә мөмкин? Ә-ә, кичә бит сезнең янда мыеклы Маша да бар иде. Шулдыр әле, мөгаен. Таза хатын, ә? Ул бездә еш булгалый...

— Әйе,— диде Мира, үзе тагын да ныграк елый башлады.

— Еламагыз, гражданка, кирәкмәс! Бүген кичкә эчке киемнәрегез табылыр. Болар өчен ул статья алачак, менә күрерсез...

— Юк, юк, иптәш милиционер! Аның белән каберең якын булмасын... Куркам мин аңардан. Үтенәм сездән, мине аның белән бәйли күрмәгез. Кыен булмаса, миңа эчке киемнәр алыгызчы. Сумкамда акчам бар, универмаг янәшә... 46 нчы размер, икенче рост... Болар өчен мин сезгә, ни теләсәгез, шуны эшләрмен... Тәртипле хатын мин, бирегә очраклы рәвештә эләктем. Әгәр азат итсәгез, бу — минем гомеремне коткаруга тиң булыр иде... Мин мәктәптә эшлим, сезнең айныткычта булу минем өчен үлем белән бер... Курыкмагыз, мин җилбәзәк хатын түгел...

— Аңлыйм, әлбәттә, ярдәм итәр идем дә, мин бит бирелә үзем генә түгел. Хәзергә айныткыч бинасы буш диярлек, начальство сирәк була, ләкин ишек катында минем хезмәттәшем утыра. Сез аның бармагын тешләгәннән соң ул рапорт язып ташлаган, 15 тәүлеккә утыртулары бик ихтимал. Телисезме, мин аның белән сөйләшеп карыйм, начальство кулына эләккәнче, бәлки, рапортын кире алыр? Дружинник язган доклад кәгазе дә хәзергә безнең өстәлдә ята... Барыйм әле, киңәшеп карыйм...

— Туктагыз, туктагыз! Сез миңа яхшылык эшләргә уйлыйсыз икән, мин дә җавапсыз калырга тиеш түгел... Нишли алам? Телисезме, миңа якын килегез...

— Гомумән, мин бик сак кеше... Бу җәһәттән минем запаска дигән «галош»ларым бар...

— Сез нәрсә, иптәш милиционер, минем беркайчан авырганым юк. Чиста мин. Уйнаш та кылганым юк... Нинди галошлар турында сөйлисез. Алар бит әллә кайчан модадан чыкты, авылда кисәләр генә инде...

— Сез мине гафу итегез... Икебез дә дөрес аңлашмадык шикелле. Мин бит... бөтенләй бүтән нәрсәне күздә тотып әйтәм...

Алар аңлаштылар. Бераздан Мира Сергеевнаның тәне тимер төймә һәм пряжка салкынын тойды. Әллә куркудан, әллә инде көтелмәгән ләззәткә тап булуданмы, надзирательнең маңгае манма тиргә баткан иде. Иркәләүләргә исе китмичә, Мира битараф бер халәттә иде. Күңеле сизүенчә, хәзергә телефон төбендә берни белмичә йокымсырап яткан кече сержант аны болай гына чыгарып җибәрмәячәк иде...

Айныткычтан киткәндә Мира Сергеевна аларның икесенә аракыга дип 20 сум акча калдырды һәм икенче атнада шалтыратырга вәгъдә бирде. Урамда ул үзен, гомер булмаганча, яңа тугандай бәхетле хис итте. Айныткычта кичергән газаплары, язмышы кыл өстендә эленеп торган сәгатьләр аңа ямьсез төш сыман гына тоелды. Үзе яшәгән йорт каршына килеп баскач, үз күзләренә үзе ышанмыйча, ул гаҗәпләнеп байтак басып торды әле.

## Язмыш көлүе

Берничә көннән Маша, сәрхүш килеш айныткычта нииндидер кызны буып үтергәне өчен, ныклап торып «янды». Кызны кичекмәстән азат итү хакында нииндидер язма һәм машина килгәннән соң гына иртән аның үлгәнлеге ачыкланды. Аракыдан агуланган дип,

ансат кына котылып та булыр иде, әмма кызның әтисе — йогынтылы зур түрә — үлем сәбәпләрен җентекләп тикшерүне таләп итте. Гермафродит гаебен танырга мәҗбүр булды.

— Сез аны ни өчен үтердегез? — дип сорады тикшерүче аңардан.

— Минем аны үтерергә уйлаганым да юк иде, үзенә үпкәләсен... Кычкырып куркытмакчы булды! Ул шаулый башлагач та, авызын кулым белән томаладым һәм ул кычкырудан туктады. Бәлки, тончыгудан курыккандыр, кем белсен... Ул бик йомшак, матур кыз, төн уртасында мин аны кочакладым, иркәләдем... Төнләме, иртәнме үлгән — белмим. Бәлки, аракыданд̆ыр әле, чөнки хәйран исерек иде ул.

— Экспертиза раславынча, үлем төнге сәгать берләр тирәсендә килеп чыккан... Дәвам итегез!

— Мин, гадәттә, кислород бирүне беразга туктатып торам, һәлакәтен сизеп, кыз һәммәсенә ризалашты. Үлем — беттең дигән сүз. Кычкырмый икән, мин аңа суларга ирек бирәм. Үпкәсенә кислород кергәч, ул янә кычкырмакчы итенә. Кислородны ябам да, куркынычны тагын исенә төшерәм. Нахалкаларны аңын югалтканчы әнә шулай тота идем. Күрәсең, бу юлы кранны ныграк япканмын... Кыз үзе гаепле, түзәргә иде, ә ул тоткан да, минем башыма үч итеп, үлеп киткән...

— Кирәген генә сөйләгез, мине сезнең эмоцияләрегез кызыксындырмый... Бу эш белән кайчаннан бирле шөгыльләнәсез?

— Хәтерләмим дә инде, байтактандыр... Аңа кадәр минем үзем шикелле иптәшем, сердәшем бар иде. Ул хатын-кыз булуны күбрәк яратты. Биш ел чамасы бергә яшәдек, ул да, мин дә канәгать идек. Берәүгә дә комачауламадык. Үлде ул, мескенкәем, ташландык бер зиратка илтеп күмдек үзен... Аннары мин исерек кызларны ишек төпләрендә, караңгы почмакларда, вокзал тирәләрендә аулый башладым... Шулай бервакыт очраклы рәвештә айныткычка эләктем, сәрхүш бер кыз минем кул астына килеп эләкте. Вәт иркенлек, дип уйладым! Ошап китте миңа бирдә, шуннан соң ешрак эләгергә тырыша башладым. Хәтерлисезме, берзаман айныткычлар, ничек әле... хозрасчетка күчтеләр, планнары да бар иде. План бар икән, аны үтәргә, хәтта ки арттырып үтәргә кирәк. Бу мәсьәләдә мин аларга нык булыштым. Нишлим соң, миндә ирлек ягы көчлерәк. Тавышым, мыегым, физик көчем — ирләрнекечә. Телим икән, күп кенә ирләрне бер селтәнүдә сугып ега алам. Тракторда эшлим, кирәксә, аның алгы күчәрен күтәреп күрсәтә алам. Телисезме, исбатлыйм...

— Ничек инде сез моңа кадәр шулай яшеренеп йөри алдыгыз, ир кеше икәнегезне ничек сизмәделәр?

— Бик гади бу, гражданин тикшерүче! Җәмәгать мунчаларына йөрмәдем, үз мунчам сауналардан бер дә ким түгел иде. Бер бидон сыра күтәреп керәм дә, ике сәгать чамасы рәхәт кичәм, берниндн шайтанның да комачауламый. Больницада беркайчан булганым юк, даруларның ни икәнен белмим... Миңа мужикларның бәйләнгәне бар. Яратмыйм шуларны, чөнки үзем мужик токымы. Шулай берчакны порт тирәсендә бер исерек бәйләнде миңа. Юләр димә инде, хәтта ресторанга чакырган була. Мин аңа шундый итеп чәпәдем, «скорый» белән алып киттеләр үзен. Ә постовой милиционер мактады мине. «Әгәр барлык хатын-кызлар да синең кебек каты куллы булса, әллә кайчан тәртипкә дә, коммунизмга да ирешкән булыр идек», — дип, ачык авызлар каршында кулымны кысты. Ахмак ул, теге милиционерны әйтәм! Әгәр барлык хатын-кызлар да минем сыман булса, кешелек дигәнең инде әллә кайчан яшәүдән туктар иде. Бөтен хатын-кызлар минем кебек булса, ирләр нишләр иде икән?.. Дөресен әйтеп сөйләшкәнгә ачуланмагыз, кеше башлы этләр, сарыклар, ике аяклы һәм ике имчәкле сыерлар дөньяга хуҗа булыр иде, мөгаен. Ул чагында илнең ит һәм сөт планы, ай-һай, үтәлер иде микән?

— Туктатыгыз бу әшәке фәлсәфәне! Җитте кыланырга! — дип, шушы урында кырт кисте аны тикшерүче, кисәтүе артыннан ук урындыгын-

нан торып.— Эшнең асылы турында сөйләгез. Айныткычка сез ничек шулай махсус төстә эләгә белдегез?

— Бик гади ул, гражданин тикшерүче! Теләгән кадәрле аракы эчкәннән соң мин, гадәттә, милиция күбрәк булган урынга барырга тырышам. Сумка почмагыннан бер шешәне тартып чыгарам да, тегене йота башлыйм — ә эченә су тутырылган була аның. Милиция егетләре, билгеле инде, елгыр машинасына утырта да мине кирәкле җиргә алып китә. Күп шәһәрләрдә булганым бар, күп кенә мильтоннарны исеме белән беләм. Алар мине Маша буларак беләләр һәм хатын-кызлар айныткычына ябалар. Анда инде мин, иптәш тикшерүче, нәрсә эшләргә кирәген беләм...

— Кисәтеп куям, мин сезгә иптәш түгел!

— Гаеплемен, гражданин следователь... Ә ничек анда, төрмәдә, мин гомуми мунчага йөриячәкменме?..

— Солдатлар сыман, саф белән тезелеп, уртак мунчага йөриячәксез. Анда аерым мунча юк.

— Ә мине кайсыларына кушарлар икән — ирләргәме, хатын-кызлargaмы? Хатыннар белән дөресрәк инде...

— Хатын-кызларны көчләгәнсең, үтергәнсез икән, димәк, сезне ирләр камерасына билгеләячәкләр.

— Ой, никадәрле хәтәр бу! Иң курыкканым шул иде. Алар бит мине көчлиячәкләр! Ирләр булып йөрүем үземә ошаса да, мин бит әле шул ук вакытта хатын-кыз да! Дөресрәге, кы-ы-ыз! — дип шартлап елап җибәрде гермафродит. Гәүдәгә курач кына тикшерүче каршында бала башыдай йодрыгы белән эре-эре күз яшьләрен сөртеп маташуы гаҗәп иде аның. Аның кул астына эләккән, аның табигать көче тарафыннан бирелгән көченнән рәнҗетелгән корбаннар ничек күз яше түксә, хәзер ул үзе дә нәкъ шулайрак итеп елый һәм тыпырчына иде.

— Танышыгыз һәм беркетмәгә кул куегыз.

— Мин ни укый, ни яза белмим...

— Алайса тамгагызны салыгыз!

— Гражданин тикшерүче! Үтенеп сорыйм сездән, мине атарга хөкем итсеннәр иде, ә... Үтенәм сездән, мәрхәмәт күрсәтегезче...

— Берни дә барып чыкмый! Сез аны аңлы рәвештә үтермәгәнсез. Сезгә «вышка» түгел, ун ел биреләчәк.

— Беркетмәне яңадан язып булмасмы, гражданин тикшерүче, мин бит аны аңлы рәвештә үтердем, сезгә ялганладым гына...

— Юк, ярамый! Хәзер сезне КПЗга алып китәчәкләр...

Шушы төндә гермафродит, тәрәзә рәшәткәсен һәм үз киемнәреннән оешкан баудан файдаланып, ялгызаклар камерасында асылынып үлде...

## Эпилог

Мира Сергеевна айныткычтан «чиста» гына чыгып киткәннән соң бер атна узды. Тормыш һәм эшләр элеккечә бара иде шикелле: инвалид, айныткыч һәм андагы хәлләр хакында берәү дә берни белмичә калды бугай.

Ләкин көннәрнең берсендә тугызынчы класс укучысы Мира Сергеевнаны берникди сәбәпсез мәсхәрәләп ташлады. Үзенең укучыларыннан әле беркайчан да мыскыл күргәне юк иде аның. Эш укучының әтиәнисен мәктәпкә чакыру һәм ахыр чиктә гауга белән тәмамланды. Хикмәт шунда ки, Мира Сергеевнаны мыскыллаган укучының әнисе — теге көнне инвалид карт подъездында очраган хатын булып чыкты...

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, инвалид карт инде кабер эченә кереп яткан һәм «Эше» туктатылган булса да, прокуратура сугыш ветераны-

ның үлемен янадан тикшерергә карар итте. Стакандагы, шешәдәге һәм презерватив пакетындагы бармак эзләре Мира Сергеевнаныкы белән туры килгәнлектән, аны кулга алдылар. Тол хатын ялгызак инвалидны бозыклыкка этәрүдә, аны аракы һәм политура белән агулауда гаепләнә иде. Шушылар расланган очракта, аны төрмә көтәчәк. Ләкин Мира Сергеевна ябык суд утырышының кызып килгән мәлендә «Сугышта гондон нигә кирәк?» дигән сорау биреп ташлады прокурорга һәм экспертлар, артык көч түкмичә генә, аны акылыннан авышкан дип бәяләделәр дә өлкәнең атаклы психбольницасына озаттылар.

«Нигә кирәк соң ул? — дип һаман баш ватты Мира Сергеевна. Өстендәге буй-буй халаты белән ул концлагерь әсиренә охшап калган иде.— Сугышта нигә кирәк ул? Бу сорауга нигә соң берәү дә җавап бирә алмый? Әлеге сорауда мин бернинди ахмаклык күрмим, ә менә шуның өчен тоттылар да юләрләр йортына ябып куйдылар. Мин үземне һич тә юләргә санамыйм! Төрмәгә тыккан булсалар, хөкемне кире кагар идем. Ә бирәдә, ни генә язма яисә сөйләмә, барыбер юләргә саныйлар. Бәлки, боларның һәммәсе дә бирегә кайчандыр нормаль кеше булып килеп кергәннәрдер?» — дип шикләнә башлады ул, тирә-юнендә кайнашкан авыруларга карап. Әнә бит, кайсыдыр берәү һавада нидер тотарга азаплана, кемдер караватт астыннан нәрсәдер эзли, кайсыдыр бик озаклап түшәмгә текәлеп тора, кемдер кычкыра, кулын селки-селки кемдер дирижерлык кыла. «Смело, товарищи, в ногу» дигәнне җырлаучылар бар, кайберләре «Советлар Союзы Гимны» һәм «Интернационал»ны көйләп күрсәтә. Тик боларның берсе белән дә кешечә, юньләп кенә сөйләшеп булмый иде, менә шуңа да Мира Сергеевна ялгызак дөньясына барып эләкте. Кайчакны ул шифаханә хезмәткәрләре белән ихлас гәп корырга тырышып карады, әмма алар да «акылыннан язган» хатын белән әңгәмә куертуны кирәк санамадылар.

Әнә шулай итеп, юләрләр йортында ун ел яши торгач, Мира Сергеевна, чыннан да, үзе дә тәмам авышып бетте бугай. Ләкин теге һәлакәтле сорауны кайчак һаман исенә төшергәли иде. Бу сорауның җавабы еллар узган саен көчәя, фәнни яктан үткенәя бара иде. «Бүгенге термоядер сугышта гондонның нигә кирәге бар?» — дигән сорауны биргән саен әзмәвердәй санитарлар аны кыйнап ташлыйлар яисә тимер караватка бәйләп куялар иде. Хакимиятне үз кулында нык тотучы врачлар, горур психиаторлар исә аңа голопиридол дигән даруны һаман саен ешрак кадау сәбәпле, ул инде чынлап та акыл ягыннан зәгыйфьләнгән иде.

Соңгы елларын Мира Сергеевна иректә үткәрде, дини бер карчык аны — илле яшьлек, чирле, торыр урыны булмаган бәхетсез хатынны — сеңлеседәй күреп, үзенең куышына сыендырды. Хезмәт стажы җитмәгәнлектән, Мирага сукыр бер тиен дә пенсия акчасы түләнми иде. Кабарына ризык эзләп, шуңа да ул көннәр буе диярлек шәһәрне гизде, ашханәдәге калдык-постык белән тамак туендырды. Ак чәчле, бөкрәйгән, ябык, иске киемнәргә уранган бу карчыкны бөтен шәһәр диярлек азмы-күпме чамалый, «юләр» дип йөртә иде, тик аның чын исемен, чыгышын, яшен белүче генә булмады. Кайчакны ул шәһәрнең үзәк телеграфына керә дә, казнаның бушлай ручкасыннан файдаланып, бөгәрләнгән кәгазь битенә теге иншаның эчтәлеген яза башлый. Укучысы Лена Соловьева кайчандыр иҗат иткән язма бөтен сүзләре, хәрефләре, грамматик хаталары белән һаман да исендә һәм ул боларны үзгәртүсез диярлек кәгазьгә төшерә... Калтыранган куллары исә кәкре-бөкре хәрефләрне шулкадәр «биетеп» яза, аның кайчандыр рус теле һәм әдәбияты укытучысы икәнлеген әйтсәң, моңа берәү дә ышанмас иде, мөгаен.

Урамнан барган чакта ул, шифаханәдә егерме ел буе кристаллашкан уй-фикерләрен кабатлый-кабатлый, үзалдына сөйләнергә ярата иде: «Берәүләр күпләр өчен, күпләр берәү өчен» дигән төрмәчел принцип бердәм коммунистик җәмгыятьтә куәт ала барган заманда, бер үк полюстагы кисәкчәләр бер-берсеннән этәрелгән шикелле, гражданнар да бер-берсен-

нән акырынлап читләшәчәкләр. Философиядә бу күренеш психологик ярашмаучанлык дип атала. Ясалма җәмгыятьтәге шушы хәл актив массалар югарылыгына кадәр күтәрелә икән, чылбырлы реакция башланачак һәм шпионаж, диверсия, агитация, коткыдан тыш та бу агым коммунизм идеологиясенең рәхимсез таркалуына китерәчәк. Булачак коммунизм илләрендә психологик сыешмаганлыкның зурлыгы егерме процент чамасы тәшкил итә. Инде шулары да үзен нык сиздерә килә: төрле-төрле чирләрдән рак, аллергия, акканлылык, инфаркт, психоз, караклык, көчләү, алкоголизм, үтереш һәм хәтта үз-үзенә кул салулар — болар һәммәсе шушы факторга бәйле. Оешып җиткән коммунистик җәмгыятьтә, психология киртәләрен уза алмыйча, бик күпләр һәлакәткә дучар ителәчәк. Йөрәгеңне кешеләргә бирәсе урында аны юкка чыгару, юк итү кыйммәтрәк булачак».

Шулай үзалдына сөйләнә килгән илле яшьлек «карчык», куркынып-мы, кайчак тирә-ягына карангалап та ала. Ләкин бер дә юкка: аның болай сөйләшүләре хәзер инде җәмгыять өчен тамчы да куркынычлы түгел, кешеләр исә моны акылыннан язган исәр бер бәндәнең саташуы дип кенә кабул итәләр иде.

1976.

## ӘДӘБИ МИРАС

**Әдәби мирасны — халкыбызның рухи байлыгын, күңел җәүһәрләрен өйрәнү, үзләштерү — кечкенәдән үк, хәтта ки бишек җырларыннан, мәктәптә укыган сабак китапларыннан ук башлана дип беләбез. Бу җәһәттән, чыннан да, уку-укыту мәсьәләләрендә үзгәрешләр күзәтелеп, мәктәпләребездә туган тел, әдәбият һәм халкыбыз тарихын яңача укытуны бурыч итеп куйган дәреслек-китаплар басыла башлады. Әдәбият тарихын өйрәнгәндә уртак төрки ядкярләрне һәм классиканы ныклап өйрәнү күздә тотыла. Җөмләдән, «Мәгариф» нәшрияты шундый характердагы китаплар чыгара башлады да инде. Мәсәлән, мәктәп һәм лицейларның 9 нчы сыйныфлары, педагогия училищелары, колледж укучылары өчен бай эчтәлекле, кызыклы әдәбият хрестоматиясе басылачак. Аны төзүчеләр — танылган галимнәребез Хатыйп Миңнегулов һәм Шәйхи Садретдиновлар. Җыентыкның Х. Миңнегулов әзерләгән аерым сәхифәләрен без бу санда журнал укучыларыбызга тәкъдим итәбез — туган тел, әдәбият һәм рухи мирасыбызны тирәнтен үзләштерү юлында җан аткан укытучыларыбызга, һәр милли кардәшебезгә бу — матур ярдәм һәм кызыклы бер гыйбрәт-дәрес сәгате булыр дип ышанабыз. Ә мираска — рухи хәзинәбезгә без һаман да еш рак әйләнеп кайтачакбыз, бу — шиксез. Хәерле юлга!**

# БОРЫНГЫ ҺӘМ УРТА ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫ

### БОРЫНГЫ ТӨРКИ РУН ЯЗМАЛАРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

(VI—VII ГАСЫРЛАР)[1]

* * *

...Йөз йәшәйен! Тәңрем-очук безкә. Идел-йәремә — бәңгү бал!

Тәрҗемәсе:

...Йөз яшә (йөзгә кадәр яшим)! Тәңрем-безгә таяныч (учак, йорт, «очаг», саклаучы). Идел-җиремә мәңгелек һәйкәл (балбал)!

* * *

Энем йите, урым өч, кызым өч әрти. Әбләдем углымын. Кызымын калыңсыз биртем...

Тәрҗемәсе:

Энем җиде, улларым өч, кызым өч иде. Улларымны өйләндердем. Кызларымны калымсыз бирдем...

---

[1] Малов С. Е. Енисейская письменность тюрков: Тексты и переводы.-М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1952.-С. 66, 84—85.

* * *

Сеземә, йөз кадашыма, алты будуныма, сеземә адрылтым.

Тәрҗемәсе:

Сездән, йөз дустымнан, алты ыруымнан (халкымнан), сездән аерылдым.

## КҮЛТӘГИН ЯЗМАСЫ (732—735 еллар)

*(өзекләр)*[1]

...Ерак әрсәр йаблак агы бирүр.
Йагык әрсәр әдгү агы бирүр.

Тәрҗемәсе:

...Ерактагыңа начар бүләк бирер(ләр),
Якындагыңа затлы бүләк бирер(ләр).

* * *

Чыгаң будуныг бай кылтым,
Аз будуныг үкеш кылтым.

Тәрҗемәсе:

Ярлы халыкны бай кылдым,
Аз халыкны күп кылдым.

* * *

...Иллег будун әртем,—
Илем амти каны?..
Каганлыг будун әртем,—
Каганым каны?..

Тәрҗемәсе:

...Дәүләтле (илле) халык идем,—
Илем инде кайда?..
Каганлы халык идем,—
Каганым кайда?

* * *

...Каңым каган сүсе бүре әрмеш,
Йагысы коң тәг әрмеш.

Тәрҗемәсе:

...Атам каган гаскәре бүре (кебек) иде,
Дошманнары куй кебек иде.

* * *

...Кыркыз, курыкан, утыз татар, кыдан, татабы — күп йагы әрмеш.

Тәрҗемәсе:

Кыргыз, курыкан, утыз татар, кыдан, татабы — бары да дошман иде.

* * *

...Каның субча йөгертте,
Сөңүкең тагча йатды,
Бәгелег ари углың кол булты,
Сөлек кыз оглы коң булты...

[1] Стеблева И. В. Поэтика древнетюркской литературы... — М.: Наука, 1976.— С. 175—197.

Тәрҗемәсе:

...Каның суча (су кебек) акты,
Сөягең таудай ятты (өелде),
Бәктәй саф (затлы) ул(лар)ың кол булды,
Сөлектәй кыз балаларың кәнизәк булды...

* * *

...Күрер күзем күрмәз тәг,
Белер белегем белмәз тәг булды.

Тәрҗемәсе:

...Күрер күзем күрмәс,
Белер белегем белмәс булды.

### ЮРАУ КИТАБЫ (IX гасыр)

*(өзекләр)*

Әр бушушлуг, тәңре болытлыг булды. Ара көн тугмыш. Буша(н)нч ара мәңи кәлмештер. Анча беленләр: әдгү ол!

Тәрҗемәсе:

Кеше кайгылы, күк болытлы иде. Арада (алар арасында) кояш чыкты. Кайгы арасына шатлык килде. Шуны белегез: яхшыга (игелеккә) ул!

* * *

Су тамыры корыйсәр,—
Яшь явышгу корыйыр.
Кеше көче корыйсәр,—
Ят кешегә басытыр.

Тәрҗемәсе:

Су юллары корыса,
Яшь яфрак та корыйдыр.
Кеше көче корыса,—
Ят кешедән басылыр.

# Мәхмүд Кашгарый

*(XI йөз)*

## ДИВАНЕ ЛӨГАТЕТ-ТӨРК (1072—1074)

*Мәкальләр һәм әйтемнәр*[1]

Атасы ачыг алымла йийсә, углының теше камар. [Атасы ачы алма ашаса, улының теше камашыр.]

Ач ни йиймәс, тук ни тимәс. [Ач ни ашамас, тук ни димәс.]

Бер карга берлә кыш килмәс.

Бер төлкү тиресен икилә суймас. [Бер төлке тиресен ике мәртәбә тунамыйлар.]

Боздан сув тамар.

Йыгач озын кис, тимүр кыcга кис. [Агачны озын кис, тимерне кыска кис.]

Йыгач очына йил тигер, күрклек кешегә сүз килер. [Агач очына җил тияр, матур кешегә сүз килер.]

---

[1] Махмутов Х. Тугыз гасыр кичкән мәкальләр // Мирас.— 1992.— № 5.— 91—99 б.

Канигъ кан белә йумас. [Канны кан беләп юмыйлар.]
Куш кылыч кынга сыгмас. [Куш кылыч кынга сыймас.]
Кыш конукы — ут. [Кыш кунагы — ут.]
Күздән йыраса, күнелдән йемә йырар. [Күздән ерагайса, күнелдән дә ерагаер.]
Көнгә бакса, күз камар. [Көнгә (кояшка) бакса, күз камашыр.]
Тегермәндә тугмыш сычган күк күкрәгеңә курыкмас. [Тегермәндә туган тычкан күк күкрәгәннән курыкмас.]
Олыгны олыгласа, кот (бәхетле.— Х. М.) булыр.

## *ШИГЫРЬЛӘР*[1]

### Каты юллар йомшара

Йалвын аның күзе,
Йалкын аның үзе,
Тулун айын йөзе,
Йарды мәнең йөрәк.

Әйдем аңар: «Сәвүк,
Безни таба нәлүк,
Кичтең йазы кәрик,
Кырлар әзиз бәзүк?»

Әйде: «Сәнең узу —
Әмгәк тәлим ызу,
Йомшар катыйг узу,—
Күңлем сәңа йөгрек».

Тәрҗемәсе:

Сихерле аның күзе,
Ялкынлы аның үзе,
Тулган айдай йөзе —
Телгәләде йөрәгемне.

Әйттем аңар: «Сөеклем,
Безгә таба ничек
Кичтең киң дала(лар)ны,
Кырларны, биек тауларны?»

Әйтте: «Сиңа килү юлы (узу) —
Күп газаплы үзе,
(Әмма) йомшый каты юл да,
(Чөнки) күңлем сиңа ашкына».

* * *

Йәй күркенә инанма,
Сувлар үзә таянма,
Әсизлигиг анунма,
Телдә чыкар әдгү сүз.

Тәрҗемәсе:

Җәй (яз) күркенә ышанма,
Су өстенә таянма,

[1] Стеблева И. В. Развитие тюркских поэтических форм в XI веке.— М.: Наука, 1971.

Явызлыкка алынма,
Телеңнән яхшы сүз (генә) чыгар.

* * *

Бирмеш тавар — сәнең, бел,
Йалыңук табар карынка.
Калмыш тавар — ажунның,
Керсә кара урынга.

Тәрҗемәсе:

Биргән мал — синеке,
Кеше карынга табына.
Калган товар — дөньяныкы (башкаларныкы),
(Әгәр дә) керсә (кеше) кабергә.

# Йосыф Баласагунлы

*(XI йөз)*

## КОТАДГУ БЕЛЕК[1] (1069)

### Тел турында

...Укушка, белегкә бу телмәчи тел,
Йаруттачы ирне йорук телен, бел.
[Укуга, белемгә тылмач ул бу тел,
Кешене нурлаган нәрсә тел ул — бел.]

Кешег тел агырлар, булыр кот кеше,
Кешег тел очызлар, йарыр ир башы.
[Кешене тел хөрмәтле, бәхетле итәр,
Кешене тел очсызлар, башын ярыр.]

Тел арслан торыр, күр, ишекдә йатар,
Әйа эвлүг арсык — башыңны йийәр.
[Тел ишектә (читлектә) яткан арслан кебек ул,
Аның белән бераз гына саксызлык — башыңны ашар.]

Телен имгәмеш ир никү тәр, ишит,
Бу сүз эшкә тоттыл, үзеңә иш ит:
[Начар телле ир ни дип әйтә, ишет,
Бу сүзне гамәл кыл, үзеңә иш ит:]

«Мәне имгәтер тел иди үк тәлим,
Башым кисмәсене кисәен телем».
[«Мине тел күп бәлаләргә сала,
Башым киселгәнче, (мин) телемне кисәм».]

Сүзеңне күдәзгел, башың бармасын,
Телеңне күдәзгел, тешең сынмасын.
[Сүзеңне күзәт, башың китмәсен,
Телеңне тый, тешең сынмасын.]

Будун теле йаулак — сине сүзләгәй,
Кеше кылкы киртүч — итеңне йийгәй.

[1] Юсуф Хос Хожиб. Кутадгу билиг.— Тошкент: Фан., 1971.— 84—88, 656—659, 666—667, 934—939 б.

[Халыкның теле яман — сине сүзләгәй (гайбәтеңне),
Кешенең холкы киртле (начар) — итенне ашар...]

Исәнлек теләсә синең бу үзең,
Телеңдә чыкарма йарагсыз сүзең.
[Син үзеңә исәнлек теләсәң,
Телеңнән яраксыз сүз чыгарма.]

Белеб сүзләсә, сүз белегкә саныр,
Белегсез сүзе үз башыны йийыр.
[Белеп сүзләсә, сүз акыллыга (белемлегә) саналыр,
Наданның сүзе үз башына җитәр.]

Үкеш сүздә артык асигъ күрмәдем,
Йәнә сүзләмешендә асигъ булмадым.
[Күп сүздә артык файда күрмәдем,
Янә (күп) сөйләшүдән файда алмадым.]

Үкеш сүзләмә сүз, берәр сүзлә аз,
Төмән сүз төгенен бу бер сүздә йаз.
[Күп сөйләмә сүз, бераз (гына) сөйлә,
Ун мең сүз төенен бер сүз белән яз (чиш).]

Кеше сүз белә купты, булды мәлик,
Үкеш сүз башыг йиргә кылды күлик.
[Кеше сүз белән күтәрелде, хөкемдар булды,
Күп сүз башны җиргә идерде (башны җирнең күләгәсе итте).]

Үкеш сүзләсә, «йаңшады,— тир,— теле»,
Йәнә сүзләмәсә, «агын»,— тир кеше.
[Күп сөйләсә, әйтерләр: «теле йомшарды (бушка әйләнде)»,
Янә сөйләмәсә, «телсез»,— дип әйтерләр.]

Кали мондаг ирсә, йорык утру ор,
Йорык утру орса, кешег йөкөтер.
[Әгәр алай икән, урталыкны тот,
Урталыкны тотса, кеше күтәрелер.]

Телег кәд күдәзгел, күдәзелде баш,
Сүзеңне кысыргыл, озай(й)тылды йәш.
[Телеңне кыска тот, баш(ың) сакланыр,
Сүзеңне аз сөйләсәң, гомерең озынаер.]

...Нәчә мондаг ирсә, белеб сүзлә сүз,
Сүзең булсы(н) күрсү карагыка күз.
[Әгәр шулай икән, сүзеңне белеп сөйлә,
Сүзең күзсезгә күз кебек булсын.]

Белегсез карагы торыр, билгелүг,
Йөре, әй белегсез, белег ал өлүг.
[Белемсез сукыр торыр, һичшиксез,
Кил, әй надан, белемнән өлеш ал.]

Тугуглы үлер, күр, калыр билгесез,
Сүзең идгү сүзлә, үзең үлгесез.
[Туган (кеше) үләр, күр, калыр билгесез,
Изге сүз сөйләсәң, үлмәссең үзең.]

Ике нәң белә ир карымаз үзе,
Бер — идгү кылынычы, бер — идгү сүзе.
[Ике нәрсә белән кеше үзе картаймас,
Бере — күркәм холкы, бере — изге сүз.]

Кеше тугды, үлде, сүзе калды, күр,
Үзе барды йаңлук, аты калды, күр.

[Кеше туды, үлде, сүз калды, күр,
Үзе киткәч тә (яхшы) исеме калды, күр.]

Тереглег теләсә үзен үлмәгү,
Кылынчын, сүзен идгү тот, әй бәгү...
[Үзеңә бетми торган тереклек теләсәң,
Холкыңны, сүзеңне изге тот, әй акыл иясе...]

## Белем турында

...Белег бирде йаңлук бәдүде бу көн,
Укуш бирде өтрү йазылды төген.
[Белем бирде, (шуның белән кеше) бу көн бөеклеккә ирешге,
Уку аркасында күп төеннәр чишелде...]

...Белегне бәдүг бел, укушны олуг,
Бу икке бәдүтер өдүрмеш колуг.
[Белемне бөек, укуны олуг бел,
Бу икегә коллык кылган бөек булыр...]

...Белек мәгънәсе, бел, никү тир белег:
Белек белсә өтрү йырар ирдә иг.
[Белем мәгънәсен бел, ни дип әйтер белем:
Белем белгән кешедән бәла-казалар ераклаша.]

Белексез кеше барча иглиг булыр,
Игиг имләмәсә, кеше тәрк үлер.
[Надан кешеләрнең барчасы авыру була,
Чирен дәваламаса, кеше бик тиз үлә.]

Йөре, әй белексез, игенне ута,
Белексез онытсән, и билгә кота.
[Кил, әй надан, авыруыңны дәвала,
Белемсез (икәнсең) — түбән син, белемле (икән) — бәхетле.]

Укуш ул борындык, аны йитсә ир,
Теләккә тигәр ул төмән арзу йир.
[Белем ул (гүя) тезген (йөгән; ияр), әгәр дә кеше аны эләктерсә,
Теләгенә ирешеп, күп максатларын гамәлгә ашырыр.]

Укуш булса иргә, күр, асгы үкеш,
Белек белсә, өтрү булыр ир көшеш.
[Белем булса кешедә, күр, (ул) күп файдалыдыр,
Белем белсә, кеше кадерле буладыр.]

Укуш берлә эшләр камуг эш көдүг,
Белек берлә бикләр бу булмыш өдүг.
[Белем белән барлык эшләр гамәлгә ашар,
Гыйлем белән бикләр максатларына ирешә.]

## Шагыйрьләр белән аралашу турында

...Баса килде шагыйрь — бу сүз тергүче,
Кешег үггүчеләр йәмә йәргүче.
[Янә килде шагыйрь — ул сүз тезүче,
Кешене мактаучы һәм дә сүгүче.]

Кылычта йэтигрәк боларның теле,
Йәнә кылда йинчкә бу хатыйр йулы.
[Кылычтан үткенрәк боларның теле,
Янә кылдан нечкәрәк хәтер юллары.]

Татыг, йинчкә сүзләр укайын тисә,
Болардин ишет сүз, укылгай баса.

[Татлы, үткен сүзләр белим дисәң,
Боларны тыңла, аларның сүзләре жиңел төшенелә.]

Тиңизгә керер күрсә күңлен төгәл,
Гүһәр, йенжү, йакут чыкарыр мәсәл.
[Күрсәң: алар күңел диңгезенә тәмам керерләр,
(Аннан) гәүһәр, энже, якутларны чыгарырлар.]

Улар үксәләр, үкде илкә барыр,
Калы сүксәләр, аты артыб калыр.
[Алар мактасалар, мактаулары илгә таралыр,
Әгәр сүксәләр, (кешенең) яманаты калыр.]

Уса, идгү тоттыл боларны, кадаш,
Боларның теленгә эленмә, адаш.
[Уйла, яхшы тот боларны, кардәш,
Боларның теленә эләкмә, адаш.]

Калы идгү үгде теләсә үзен,
Боларны сэвендер, киселде сүзен.
[Әгәр яхшы мактау сүзләре теләсәң үзең,
Боларны сөендер, бетте-китте сүзем.]

Никү кылса, биргел боларка төгәл,
Боларның телендин үзең сатгын ал.
[Ни сорасалар, бир аларга төгәл,
Боларның теленнән үзеңне коткарып кал.]

**Һөнәрчеләр белән мөгамәлә кылу турында**

...Тәкый бер котысы бу узлар торыр,
Терелгү теләб үзгә узлук кылыр.
[Янә бер төркеме бу һөнәр ияләре торыр,
Яшәр өчен (алар) осталык кылыр.]

Кирәклек кешеләр йәмә бу сиңа,
Йакын тот боларыг, тосулгай тоңа.
[Болар сиңа шулай ук кирәкле кешеләр,
Аларны якын тот, (алар сиңа) файда китерерләр.]

Тимерче, итекче йәнә кырмачы,
Йә сырчы, бидезче, йә укчы, йачы.
[Тимерче, итекче һәм дә кыручы (столяр),
Йә буяучы, бизәүче, яисә ук-җәя ясау остасы.]

Бу дөнья йитеге болардин торыр,
Ажунда таң эшләр болардин торыр.
[Бу дөнья байлыгы алардан торыр,
Галәмдә таң (калырдай) эшләр болардан булыр.]

Боларның белә ма катыл һәм карыл,
Сэвендер уларыг сэвенечен терел.
[Болар белән катыш һәм аралаш,
Аларны сөендер — (үзең дә) сөенеч белән яшәрсең.]

Эшең кылсалар, тәрк тирен тигрү бир,
Йийдыргыл, эчергел ашың киңрү бир.
[Эшеңне башкарсалар, бик тиз тиешле хакын бир,
Ашат, эчерт, ашларын мул итеп бир.]

Әйеңләмәсенләр сине халык ара,
Атың артмасын моны кәд күрә.
[Сөйләмәсеннәр синең хакта (гайбәт) халык,
Яманатың чыкмасын, моны яхшы бел.]

Йәмә йакшы әймеш белеклек сүзег,
Будунга багырсак, ни күнле төзек:
[Ничек яхшы әйткән белек иясе сүзне,
Халыкны яратучы вә күңеле төзек кеше:]

«Тереклек теләмә, ат әдгү телә,
Ат әдгү кирәк бу терекле белә.
[«Тереклек түгел, ә изге ат (исем) телә,
Бу тереклеккә изге ат кирәк.]

Үзең үлгү, ахыр бу атың калыр,
Атың әдгү булса, тереглек татыр.
[Үзең үләрсең, ахырда изге исемең калыр,
Атың изге булса, тереклек татлыдыр.]

Кемең аты әсиз булыб артаса,
Аңар йегрәке ул терек тормаса.
[Кемнең аты яман булып калганчы,
Аның өчен тере тормавы яхшырактыр.]

Мүн — ул тереклек, телә әдгү ат,
Эсиз кылма, әдгү кылын мәңү ат».
[Бу тереклек — бозыклык, телә изге ат,
Үзеңне пычратма, изгелек кыл, (шунда сиңа) — яхшы исем!»]

## Яшьлекне сагыну һәм картлык турында

Йөрегле болыт тик, йегетлекне идтем,
Төби йил кичәр тик, тереклек төгәттем.
[Аккан болыт кебек, яшьлекне үткәрдем,
Искән җил-давыл кебек, гомерне уздырдым.]

Эсизем йегетлек, эсизем йегетлек,—
Тота белмәдем мин сине, тәрк качыттым.
[Яшьлегем үкенечле, яшьлегем үкенечле,—
Тота белмәдем мин сине,— тиз качырдым.]

Йәнә килгел имди, йегетлек, мәңа син,
Айада тотайын, агы, җөз түшәттем.
[Янә кайт инде, яшьлегем, миңа син,
Кадерләп тотармын, ефәк-парчаларга гына салып.]

Эсиз бу йегетлек каны, канча барды?—
Теләб булмадым мән ничә ма теләттем.
[Бу яшьлек эзсез генә (сиздермичә) кая, кайчан китте?—
Эзләп таба алмадым,— никадәр теләсәм дә.]

Тереклеккә татгы сөчек, җан сәвенче,
Йегетлек тик әдгү йук ирмеш әйеттем.
[Яшәешкә татлы эчемлек, җан сөенече
Яшьлектән башка нәрсә юк икәнен белдем инде.]

Кечеклек татыгы, йегетлек эрәже
Йитердем мән имди тотарда күрәттем...
[Сабыйлык татысын, яшьлекнең рәхәтен
Мин инде югалттым, тотар мәлдә качырдым...]

...Әсиргәб ачырмән сәңа, әй йегетлек,
Камуг күркеме сән йыраттың, йыраттым.
[Үкенәм, ачынам сиңа, әй яшьлегем,
Һәммә күркемне син үзләштереп качтың, (ә мин) югалттым.]

Тәмам аргуван тик кызыл миңзем ирде,
Бу көн зәгъфәран оргын индә тарыттым.

[Тәмам алсу төстә иде минем йөзем,
Бу көн аңа инде сары төсне сиптем.]

Йыпарсыг кара башка кафур эшедем,
Тулун тик талу йөз кайука иләттем?
[Җәфардай кара башыма (ак) кафур бөркедем,
Тулган айдай матур йөземне кайда калдырдым?]

Йарук йаз тик ирдем төмән тү чәчәклек,
Хәзанмы түшәттем,— камугны корыттым.
[Күп чәчәкле нурлы яз кебек идем,
Көз җилеме исте,— барысын корытты.]

Каен тик будым, ук тик көни, төз,
Йә тик игри булды, игелдем, төңеттем.
[Каендай буем ук тик туры төз (иде),
(Хәзер ул) җәя кебек бөкрәйде — иелдем, хәлсезләндем...]

...Кечеклек кичердем, йегетлек йитердем,
Көнем чалпаладым, үземне чөкеттем.
[Балачакны уздырдым, яшьлекне калдырдым,
Көннәремне (бушка) үткәрдем, үземне чүктердем.]

Йимәк, эчмәк ирсә — йийдем, эчтем уд тик,
Теләк сөрмәк ирсә, төмән туг тузыттым.
[Ашарга, эчәргә булса, сыер кебек ашадым, эчтем,
Теләкне үтәү өчен, күп вакыт уздырдым (тузан туздырдым)...]

...Теләк арзу берлә йөгердем ничә мән,
Котырмыш бүре тик ажунны улыттым.
[Теләгемне үтәү өчен күпме йөгердем мин,
Котырган бүре кебек дөньяны шаулаттым.]

Кешег тоттым, алдым көчен йармакын мән,
Кемег сөрдем ирдем, кеме ма ачыттым...
[Кешеләрне тоткын кылдым, көч белән акчасын алдым,
Берәүләрне сөрдем, икенчеләрен газап кылдым...]

Никү асгы? Ахыр йәнеш йиргә булды,
Тору калды, дөнья ике бәз эләттем.
[Ни файда? Ахырда җиргә кайтасы булгач,
Дөнья торып калды, (мин) ике бәз (кәфенлек) алып китәчәкмен.]

Йалың килдем ирде, йалың кирү йиргә,
Нилүг дөньяка үзне монча исетдем.
[Ялангач килдем инде, җиргә дә (кабат) ялангач керермен,—
Ни өчен дөньяга исем китте!]

Кичәр дөнья кичте түби йил кичәр тик,
Кичәр дөньяка үз осалын басыттым.
[Кичәр дөнья искән җил-давыл кебек китте,
Фани дөньяга үземне бастырдым...]

...Никү иктем ирсә, аны ургу ахыр,
Никү урдым ирсә, аның үз сөчеттем.
[Ни чәчкән булсам, аны (хәзер) урам,
Ни урган булсам, аның (белән) үземне (хәзер) юатам...]

# Әхмәд Ясәви

*(?—1166)*

## ШИГЫРЬЛӘР[1]

### Гарибләр

Гариблегъдә гариб булган гарибләр,
Гарибләр хәлене белгән гарибләр,
Сәбәб берлә ерак йиргә барибән[2],
Карендәш кадрене белгән гарибләр.

Сусаганда суга мохтаж булган,
Терекдә[3] зар улыб улган гарибләр,
Кеше белмәс гарибләр хале нидер,
Мәгәр белгәй гариб булган гарибләр.

Гариблегъ катыйг ишдер, и газизем,
Кем ул би кадер — улар мескин гарибләр[4],
Кил имди Әхмәдә[5], үзеңә бакгыл,
Гариб син, син гариб, мескин гарибләр.

### «...Гафу кылгыл гөнаһымны»

Күңлем кошы очар даим канат тукыб[6],
Ике күзем нәдамәтдә[7] канлар түкеб,
Тән үлтереб, риазәтдә[8] тезен чүкеб,—
    Йа иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

Наданлыкда кылган эшем барча хата,
Тәүбә, тәкъсыйр[9] әйләмәдем йакам тота,
Гәрдәнемгә тоук йаңлигъ салыб фута[10],—
    Йа иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

Дөнья сөеб, дин сәүдәсен үткәреб мин[11],
Йазык йөген, әйа дустлар, бөткәреб[12] мин,
Дәргяһына[13] мәгъсыятьләр[14] килтереб мин,—
    Йа иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

Шом[15] дөньяга күңел баглаб кәһел булдым[16],
Гыйшрәт белән, ва(й) дәрига, җаһил булдым[17].

---

[1] Хужа Әхмәд бине Ибраһим бине Мәхмүд Ясәви. Диване хикмәт хәзрәте солтан...— Казан: Университет тәбыгханәсе, 1893.— 104, 253—254 б.
[2] Барибән — барып, барган.
[3] Терекдә — исән чакта.
[4] «Кем кадерсез — алар мескен гарибләр».
[5] Әхмәд — шагыйрьнең исеме.
[6] Тукыб — кагып.
[7] Нәдамәт — үкенеч.
[8] Риазәт — теләкләрне (нәфесне) тыеп тору.
[9] Тәкъсыйр — дин әһелләрен олылау.
[10] «Муеныма (гәүдәмә) сөлге (чүпрәк) урап чылбыр кебек».
[11] «Дөнья сөеп, дин шөгылен (эшен) калдырып мин».
[12] Бөткәреб — үстереп, күтәреп.
[13] Дәргяһына — бусагасына, катына.
[14] Мәгъсыять — гөнаһ, йазык эш.
[15] Шом — *шомлы, ышанычсыз* мәгънәсендә.
[16] Кәһел булдым — ир уртасы булдым, гомер уздырдым.
[17] «Күңел ачып, ай үкенеч, надан булдым».

Бу дөньяны(н) үтәрене имди белдем,—
Йа иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны...

Кол Хуҗа Әхмәд гөнаһига каил[1], ирер,
Һәркем алла дисә аңа йари[2] бирер,
Ирәнләрне сөхбәтегә маил ирер[3],—
Йа иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

# Сөләйман Бакырганый

*(?—1186)*

## *ШИГЫРЬЛӘР*[4]

### «Мән еглармын, һәммә галәм көләдер»

Мәнем җаным сәнең гыйшкың беләⁿ(н)дер,
Тәнем гаҗиз, вәли җаным уладыр[5].

Бу гыйшк гәр булмаса, мән ниткәй ирдем[6],
Камуг[7] аһым мәнем гыйшкым кыладыр.

Зиһи халь[8], зиһи халь, зиһи халь! —
Мән еглармын, һәммә галәм көләдер.

Гашыйкдин сорманыз[9] дөнья вә гокба[10],—
Гашыйк мәгъшукы өчен һәр дәм уладыр[11].

Гашыйкны көйдерер гыйшык уты,
Гашыйклар гыйшык утига мөбтәлядер[12].

Мәнең сән бакмагыл бу сурәтемгә,
Йөрәгем кан булыб, бәгърем суладыр.

Аерды гыйшык мәне хәйл-хишемдин[13],
Күзем яше акыб, мәнзем[14] суладыр.

Күрең: ни хәлгә төшде Кол Сөләйман[15],
Камуг гыйшкым мәнең рәнҗем беләндер[16].

---

[1] Каил — әйтүче, җиткерүче.
[2] Йари — дуслык; куәт.
[3] «Кешеләрне әңгәмәгә (үзе белән аралашуга) һәвәс итәр».
[4] Бакырган китабы.— Казан: Кокобин тәбыгханәсе, 1878.— 10—11, 19, 25 б.
[5] «Тәнем көчсез, әмма җаным бардыр (яшидер)».
[6] Ниткәй ирдем — нишләр идем.
[7] Камуг — һәммә, барлык.
[8] Зиһи халь (зәһи хәл) — гаҗәеп хәл.
[9] Сорманыз — сорамагыз.
[10] Дөнья вә гокба — дөньяны һәм теге дөньяны; бу һәм теге дөньяны.
[11] «Гашыйк (кеше) һәр сулышында (мизгелдә) үз сөйгәне өчендер».
[12] «Гашыйклар гыйшык утына дучардыр».
[13] Хәйл-хишемдин — туган-тумачамнан, дус-ишләрдән.
[14] Мәнзем — йөзем.
[15] Кол Сөләйман — Сөләйман Бакырганыйның әдәби кушаматы.
[16] «Барлык гыйшкым минем газабымдадыр» (ягъни, газапларда күренәдер).

### «Сиңа кол булганым — солтаннан артык»

Сәнең дәрдең бәңа дәрмандин артык,
Сәңа кол булгам — солтандин артык.

Сәнең ядыңны әйсәм[1] чүл эчендә,
Булыр ул чүл мәңа бостандин[2] артык.

Сәнең ядың әгәр китсә телемдин,
Вөҗүдем корыйур (корыр.—Х. М.) вәйрандин артык[3].

Мәнең хар[4] булмышым үз гафләтемдин[5],
Мәгәр кыйлсаң нәзар — ихсандин артык[6].

Газиз хар кыйлгучы солтан сынуксән,
Сәнең лотфың каму әлвандин артык[7].

Нә хуш бу дөньяда иман вә «Коръән»!
Ни булгай дөньяда имандин артык!

Мәнем дәрдеме һич кемсә белмәс,
Әгәр белсә хәким Локмандин[8] артык.

Бу йаңлигъ гасый иркән[9] Кол Сөләйман,
Гыйнаять уманыр барандин артык[10].

### «Кичә-көндез хәзер торың — килер әҗәл»

Белең, дуслар, ничә кичде[11], ничә калды,—
Нә булгусын, нә килгүсен белгән бармы[12]?!

Монда кыйлган эшләр анда соралгучы,
Соралмаен котылубән калган бармы[13]?!

Соралмагай, әгәр булса изге гамәл,
Кылмыш гамәл җөмләмезгә хирыс әмәл[14].

Кичә-көндез хазыйр торың, килер әҗәл,
Әҗәл килер тибиян, йараг[15] кылган бармы?!

Коллыксыз бирелмәсдер икән дидар[16],
Имгәксез[17] ир морадыга качан йитәр?!

Гаувас кереб гомманга гәүһәр табар[18],
Рәнҗсез, гәнеҗ эстәйүбән табкан бармы?![19]

---

[1] Сәнең ядыңны әйсәм — сине исемә төшерсәм.
[2] Бостан — бакча, гөлбакча.
[3] «Яшәешем корыр хәрабәләрдән дә артык».
[4] Хар — түбән, гөнаһлы.
[5] Гафләтемдин — ваемсызлыгымнан, пошмаучанлыгымнан.
[6] «Мәгәр күз ташласаң (карасаң) — ярдәмнән (игелектән) артык».
[7] «Синең мәрхәмәтең барлык (төстәге) чәчәкләрдән (нигъмәтләрдән) артык».
[8] Хәким Локман — Шәрык дөньясының легендар акыл иясе.
[9] «Мондый гөнаһлы икән».
[10] «Ярдәм көтәр яңгырдан артык» (ягъни: аннан яңгырдан да артык мул шәфкать, мәрхәмәт көтәр).
[11] Кичде — монда: үлде, теге дөньяга күчте.
[12] «Ни буласын, ни киләсен белгән (кеше) бармы?!»
[13] «Соралмыйча котылып калганнар бармы?!»
[14] «Кылган гамәл — барчабызның комсызлыктыр».
[15] Тибиян (тыйбиян), йараг — игелек, ярак (кирәкле азык); хәстәр.
[16] Дидар — очрашу, кавышу; йөзен күрү.
[17] Имгәксез — мәшәкатьсез, хезмәт кылмыйча.
[18] «Водолаз кереп диңгезгә (Гарәбстан ярымутравындагы Оман култыгы да күздә тотыла) җәүһәр табар».
[19] «Мәшәкатьсез, (кемнең) хәзинә эзләп (теләп) тапканы бар?»

Коткаргу[1] үзене монда коллык берлән,
Кермәгү тәмуг эчрә мәнлек берлән[2].

Коллык кыйлгы мәүлясенә ирлек берлән[3],
Коллыксыз үзене утдин йолган (йолып калган.— Х. М.) бармы?!

Йарак кыйлгу хәмд-ү сәна шәһадәтне[4],
Гадәт кыйлгу коллыгда кыяфәтне.

Бер көн менгү (менү.— Х. М.) ул җеназа атлыйг атны,
Ушал атка һич менмәйен калган бармы?![5]

Белер булсаң: гәнеҗ, торыр йир вәйран торыр[6],
Хозыр берлә Муса кәлим(е) йаран торыр[7].

Кал әһеле[8] сүз эчендә хәйран торыр,
Хальне күреб кал әһеле салган бармы?!

Кол Сөләйман, халь берлә, хикмәт төзәр[9],
Халь берлә тагать нәфсене өзәр[10].

Заһир хәраб, батыйн мәгъмур булыб гизәр[11],
Гыйшык базарын бүлеп, рәх(ә)тен алган бармы?!

## «КОРЪӘН»НӘН ТӘФСИРЛӘР[12]

### «Җир тетрәү» («Зилзилә»)

*(99 нчы сүрә, 8 аять)*

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кайчан җир үзенең тетрәү вакытында тетрәтелмеш булса (2), Җир үзенең авыр йөкләрен чыгара (3), шул вакытта адәм әйтер: «Ни булды бу җиргә?» — дип (4). Шул көндә ул халыкка үзенең тетрәвен һәм дә йөкләрен чыгарып ташлавын бәян итәр (5). Моны бәян итүгә җирнең Раббесе — Аллаһы Тәгалә аңа вәхи[13] белән белдергән булыр. Шул вәхи сәбәпле бәян итәдер (6). Ул көндә адәмнәр таралышып, хисап мәйданына төшәләр, үзләренең гамәлләренең җәзаларын күрсәтмәкләре өчен (7). Инде берәү дөньяда вакытында тузан кадәр изгелек эшләсә, шуны да күрер (8). Һәм тузан кадәр явыз гамәл кылган булса, аны да күрер, ягъни тузан кадәр генә изгелекләре булмаган кешеләр дә шул гамәлләренең җәзаларын күрерләр.

---

[1] Коткаргу — коткар.
[2] «Кермә тәмуг эченә минлек белән (үз-үзеңне югары куеп)».
[3] «Аллага коллык кыл син ирлек белән» мәгънәсендә.
[4] «Ярак (теге дөньяга әзерлек) кылуның дәлиле — Аллага мактау-дан уку».
[5] «Шул атка (ягъни җеназа атына) һич менмичә калган (кеше) бармы?»
[6] «Белсәң: хәзинә, торган җир (һәммәсе) вакытлыдыр».
[7] «Хозыр белән Муса (пәйгамбәрләр) — якын дуслар (фикердәшләр) торыр».
[8] Кал әһеле — сүз сөйләүче; буйсынып гыйбадәт кылучы.
[9] Хикмәт төзәр — хикмәт (шигырь) язар.
[10] «(Аллага гыйшык) хәле белән буйсыну нәфесне өзәр».
[11] «Тышың харап, эчең төзек булып гизәр».
[12] Әнвәр Хәйри тәрҗемәсендә // Казан утлары.— 1991.— № 11.— 178, 179—180, 185 б.
Җәя эчендәге саннар аятьләрнең тәртибен күрсәтә.
[13] Вәхи — иңдерү; җибәрү.

## «Кыямәт көне» («Әл-Каригаһ»)

*(101 нче сүрә, 11 аять)*

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кыямәт көне (2). Нәрсә ул Кыямәт көне (3)? Һәм син Кыямәт көне нинди булуы турында нәрсә беләсең (4)? Кыямәт көне — һәр нәрсәне куркытучы һәм һәр нәрсәне урыныннан кубаручы, куркынычлы көн. Ул Кыямәт көнендә адәмнәр — таралган чикерткәләр (5), таулар тетелгән йоннар кебек булырлар (6). Инде ул көнне берәүнең гамәл үлчәүләре авыр булса (7), ул кеше үзенең күңеленә ошаган кәеф-сафада булыр (8). Әмма берәүнең гамәл үлчәве җиңел булса (9), ул кешенең урыны — һавийәһ булыр (10) һәм син һәвийәһнең нинди булуы турында нәрсә беләсең (11)? Ул — кызулыкта чиктән чыгып янып торучы ут.

## «Байлык белән мактану» («Тәкәсүр»)

*(102 нче сүрә, 8 аять)*

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Байлык белән мактану — сезне Аллаһыдан аера (2). Каберләргә барып күмелгәнче сезне байлык белән мактану шөгыльләндерде (3). Каберлеккә күмелүне онытып, байлык белән мактанышу — яраклы эш түгел, андый эшнең яраксызлыгын киләчәктә белерсез, ягъни үлгәннән һәм дә үлеп кубарылганда белерсез дә үкенерсез (4). Әгәр дә сез киләчәк куркынычлы кыямәтне үзегез күреп белгән кебек белсәгез иде (5), маллар белән мактанышуны сөймәс идегез (6). Әмма эш сез уйлаганча түгел, ант итәмен, кыямәттә җәхим, ягъни җәһәннәм тәмугысын алдыгызда күрерсез (7). Шул вакытта Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзегезгә бирелгән нигъмәтләреннән соралырсыз, ягъни, «Мактанышкан малыгызны кая куйдыгыз, фәкыйрьләргә бирдегезме?» дип соралырсыз да, җәһәннәм тәмугысына кертелерсез (8)! Шулай булгач, каберлеккә барганчы алдыгызны һәм артыгызны карагыз!

## «Заман» («Гасыр»)

*(103 нче сүрә, 3 аять)*

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Заман белән ант итәмен (2), дөреслектә адәм һаман хәсрәттә (3), мәгәр иман китереп, изге гамәл кылып, хаклык белән һәм дә сабырлык белән васыять итешкән кешеләр генә хәсрәттә түгелләр. Ягъни, дөнья-ахирәт(тә) сәгадәтле (бәхетле.— Х. М.) булачак кешеләр шундый кешеләрдер: алар Аллаһыга һәм башка ышануы тиешле булган нәрсәләргә иман китерерләр, өсләренә тиешле булган изге гамәлләрнең кулларыннан килгәннәрен кылырлар. Шуннан соң берберсенә хак юлда булып, яманлыктан тыелу белән үгет бирешерләр.

## «Кешеләр» («Ән-нас»)

*(114 нче (соңгы) сүрә, 6 аять)*

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй, Мөхәммәд! Әйт син: «Мин адәмнәрнең Раббесе (2), адәмнәрнең Алласы булган Раббемә сыенам (3). Вәсвәсә кылып, ягъни күңел аздырып, изге гамәлләрне кичектерүче заттан, ягъни шайтаннан (4), җеннәрдән һәм адәмнәрдән дә булып (5), адәмнәрнең күңелләрендә вәсвәсә кылучы заттан сакланам» (6).

# ДРАМАТУРГИЯ



**Рөстәм Мингалим**

**Ризван Хәмид**

# ИДЕГӘЙ

(НӘФИС ФИЛЬМ ӨЧЕН ДРАМА)

## Беренче фильм

### I бүлек

**1. Пайтәхет Сарай Бәркәдә Хан Сарае. Иртән.**

**Ханнар бистәсенең тышкы капкасы янына юлаучы җайдак килеп туктый һәм чыбыркы сабы белән капкага берничә мәртәбә кага.**

**Тоткавыл кечкенә капканы ача.**

Тоткавыл. Кем?

Юлаучы. Мәвәрә-эн-нәһр хакиме бөек әмир Шаһ Тимер илчесе! Жучи Улусы хакиме Туктамыш ханга фәрман!

Тоткавыл. Күрсәт.

**Юлаучы куенына тыгыла һәм сафиян күн тышлы, асылма тамгалы кәгазь төргәге күрсәтә. Кырыс йөзле капучы тамганы игътибар белән тикшерә. Юлаучы дөрес әйтә: Шаһ Тимернең өч боҗралы кул тамгасы.**

Тоткавыл. Калдыр. Тапшырылыр. Кәрван-сарайга төш һәм Туктамыш ханның әмерен көт!

Юлаучы *(ачулы)*. Мин бөек әмиремнең ярлыгын Туктамыш ханга үз кулым белән тапшырырга тиеш! Илчегә юл!

Тоткавыл *(сөлгесенең очы белән илченең атына төртә)*. Әйтелде. *(Ярлыкны бирүен сорап кулын суза.)*

Юлаучы *(ачуланып чыбыркысы белән аның кулына сыдыра)*. Шаһ Тимер илчесе белән ничек сөйләшәсең, ахмак?!

Тоткавыл *(сөңгесе белән селтәнә)*. Аксак Тимерең үзе килсен, килмешәк! Чонтык аягын тагын да ныграк кыскартып җибәрербез! *(Мыскыллап көлә.)*

Юлаучы *(мондый мәсхәрәне көтмәгән, күзләре киртәсеннән чыга)*. Нәрсә?!

Ясавыл *(тавышка кече капкадан чыга)*. Ни бар? Нинди тавыш монда?

Тоткавыл *(йөзенә гадәти кырыслык төсе ала)*. Сәмәркандтан килгән чапкын. «Алтын Таш»ка бәреп кермәкче иде.

Ясавыл *(аңа йодрык күрсәтә һәм юлаучыга таба борыла)*. Ни йомыш?

Юлаучы *(ясавылның исе китмәвенә тагын да ныграк гаҗәпләнеп)*. Өнемме бу, төшемме?! Бөек Шаһ Тимернең илчесен ничек каршылыйсыз? Туктамыш хан үз тирәсенә җыен әшәке эт аламасын җыйган диләр иде, дөрес, ахры!

Ясавыл *(янаулы тавыш белән, әмма үз дәрәҗәсен түбәнсетмичә)*. Кунак булсаң, тыйнак бул, юлаучы. Ни йомыш?

Юлаучы. Миндә — Туктамыш ханга бөек Мәвәрә-эн-нәһр солтаны Шаһ Тимер фәрманы! Миңа аны ханның үзенә тапшырырга боерылды. Мине Туктамыш хан янына алып барыгыз!

**Тоткавыл, тагын берәр нәрсә таләп итмисеңме, дигәндәй, мыскыллап көлеп җибәрә.**

Ясавыл *(күз карашы белән аны тыя)*. Бөек ханиябез ауда. Икс көнсез кайтмый.

Ю л а у ч ы *(түземсезләнеп)*. Кайда? Мин үзем барам анда: фәрман кичектерелмичә хан кулына тапшырылырга тиеш! Миңа юл күрсәтүче бирегез!

Я с а в ы л *(уйланып)*. Яхшы. Шушында көт!

**Капка сакчысы белән ясавыл эчкә кереп китәләр һәм кече капка, шапылдап ябылып, эчтән бикләнә.**

**2. Куе әрәмәлек белән капланган калкулык. Көн.**

**Әрәмәлек арасында ике чапкынчы — Алтын Урда ханы Туктамышның тән сакчылары — постырмада, юлдан күренмәслек булып, ат өстендә әкрен генә сөйләшеп тора. Аннан каршыдагы дала уч төбендә кебек ап-ачык күренә: анда-санда зур орышлардан калган кеше гәүдәләре, ат үләксәләре таралып ята. Ара-тирә нидер чокчынган чүл шакалларына, соры бүреләргә караганда, соңгы орыш күптән түгелрәк булып үткән.**

1 - н ч е  ч а п к ы н. Ырыс хан Күк Урдасыннан Сарай өстенә өр-яңа җайдаклар җыеп килгән иде — хәзер аларны шакаллар җиеп йөри! Ярый — үз сөякләрен алып качарга өлгерде! *(Көлә.)*

2 - н ч е  ч а п к ы н *(кырыс)*. Ялгышасың, Тимер Мәлик ханның сугышчылары болар. Ат эзе белән эт эзе буталды — аңсы дөрес.

1 - н ч е  ч а п к ы н. Миңа димәгәе! Икесе дә бер калыптан сөрелгән нәмәрсәләр... Безгә — кем боера, шул солтан! Туктамыш хан юкка әллә кайларга еракка киек эзләп китте. Төкле Аяк атлы лачынны монда да сынарга мөмкин булган! Кайда яңа үләксә бар — шунда ерткыч киек!

2 - н ч е  ч а п к ы н. Сиңа — үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын! Орышларның ике ягында да үзебезнең татар асыллары икәнлеге башыңа да керми... Йә Хода! Тагын берсе иренең гәүдәсен эзләп йөри...

**Гаҗәпләнеп тынып калалар: каршыдагы далада, ерткычларга әз генә дә игътибар итмичә, чәчләре тузган бер хатын үлекләр арасында кемнедер эзли. Җирдә аунап яткан мәетләрнең һәрберсе янында туктап, йөзенә карый һәм ары үтә. Ул якыная башлагач, ерткычлар кинәт сискәнеп читкәрәк китәләр һәм, гаҗәпләнгәндәй, аның артыннан карап калалар.**

1 - н ч е  ч а п к ы н. Бүреләрдән ничек курыкмый икән ул хатын?!

2 - н ч е  ч а п к ы н. Акылдан язганнарга бүре түгел, эт тә тими.

1 - н ч е  ч а п к ы н. Тегендә кара!

**Даланың икенче ягыннан балалар килеп чыга: алар, әтиләрен һәм абыйларын эзләгән арада, бүреләр ашап киткән урыннарда туктап, ат үләксәләрен кимерәләр һәм ит чәйнинәйни туганнарын эзлиләр. Бүреләр һәм шакаллар башта, сәер күренеш күзәткәндәй, аларны тирәләп тезелешеп басып торалар һәм, ниндидер команда ишеткәндәй, берьюлы төрле якка качалар.**

**Малайлар һәм кызлар кыр аша үтеп китәләр. Далада үләксәләр генә кала.**

2 - н ч е  ч а п к ы н. Үзең бәхиллә, тәңрем!

1 - н ч е  ч а п к ы н. Нәрсә булды бу?! *(Гамьсез булса да, бу күренеш аны да тетрәндергән.)*

**1-нче чапкын аркадашына сәерсенеп карый, ләкин шулвакыт аларның игътибарын әрәмәлек авызыннан үткән юлдан килүче ике җайдак җәлеп итә. Тынып калалар.**

1 - н ч е  ч а п к ы н. Берсен беләм: хан шыгавылы. Аңгысын батыр... Кемгәдер ханиябез ашыгыч кирәк булган, ахрысы...

2 - н ч е  ч а п к ы н. Миндә дә күз бар, тынып тор.

**Җайдаклар килеп җитүгә кисәк каршыларына чыгалар һәм 2-нче чапкын кул күтәреп, туктарга ишарә ясый.**

2 - н ч е  ч а п к ы н. Ары юл юк, шартлы билге!

А н г ы с ы н *(юлдашына сиздермичә, уң кулының баш бармагы белән имән бармагыннан боҗра ясап, өч бармагын югары тырпайта)*. Сәмәрканд хакиме Шаһ Тимернең илчесе бу — ханиябез катына ашыга.

2 - н ч е  ч а п к ы н. Яхшы, синең үзеңә кире китәргә мөмкин, ары юлны ул үзе табар.

**Аңгысын берсүзсез атын кире бора һәм чаптырып китеп бара.**

2 - н ч е  ч а п к ы н *(юлаучыга)*. Коралларыңны калдыр.

**Юлаучы җәя белән уклар салынган садагын, кылычын һәм матур кынлы хәнҗәрен чишеп бирә: 1-нче чапкын аларны үзенә тага һәм җитез хәрәкәтләр белән юлаучыны куллары белән капшап чыга, аның куеныннан кәгазь төргәге алып, 2-нче чапкынга бирә.**

2 - н ч е  ч а п к ы н *(асылма тамганы җентекләп тикшерә һәм аркадашына кайтара: аңсы кәгазьне илчегә тапшыра)*. Үтәргә рөхсәт. Юлдан читкә чыкмаска — башың киселәчәк. Хәерле юл сиңа, Шаһ Тимер илчесе! Исән-имин борылып кайтырга язсын. Коралларыңны шушында алырсың.

Ю л а у ч ы. Юл еракмы әле?

2 - н ч е  ч а п к ы н. Юл үзе әйтер.

**Шаһ Тимер илчесе ул күрсәткән юлдан ары ялгызы китә.**

1 - н ч е  ч а п к ы н *(юлаучы күздән югалгач)*. Бара-бара күзең күгәрер әле! Син аңа хәерле юл теләп калдың, ә ул, хәерсез, рәхмәт тә әйтә белмәде! Артык йомшак күңелле икәнсең син, кан дошман илчесе бит ул... Андый кеше икәнлегеңне белми идем!

2 - н ч е  ч а п к ы н. Юкны лыгырдама! Нинди кан дошман? Туктамышка хан тәхетенә менәргә шул Шаһ Тимер ярдәм итте ич!

1 - н ч е  ч а п к ы н. Үткән эшкә салават!

**2-нче чапкын, аңа җавап биреп тормыйча, куеныннан кечкенә быргы алып, 3 тапкыр кычкырта һәм, илче киткән яктан ерактан 1 мәртәбә кычкырткан быргы тавышы ишетелгәч, атын постырмага таба бора: аркадашы аңа иярә.**

### 3. Шәрә калкулык. Көн.

**Калкулыкта вәзирләре, иярченнәре һәм тән сакчылары белән Алтын Урда ханы Туктамыш лачынны чөяргә әзерләнә: Төкле Аяк әлегә лачынчы Балтычак әмир Котлыкыя би кулында. Бер читтәрәк чит дәүләтләрдән килгән илчеләр үзара бедер-бедер сөйләшеп торалар: аларның киемнәре бүтәнчәрәк. Барысы да ат өстендә. Туктамышның аты ап-ак. Менә алар каршындагы киң далада үләксәләр арасында бер соры бүре күренә.**

Туктамыш *(лачынчы ягына карамыйча гына бармакларын шартлатып ала)*. Котлыкыя!

**Котлыкыя башы бөркәүле лачынны ханга бирә: Туктамыш лачынның башлыгын салдырып җиргә ташлый һәм туграчта утырган кошны югары чөя, туграчын да шулай ук җиргә ташлый. Лачын кинәт югары күтәрелә һәм, даладагы бүрене күреп, шул якка таба томырыла. Калкулыктагылар тын да алмыйча лачынны күзәтәләр. Арадагы җайдаклардан яшьрәге җирдә аунап яткан лачын дирбиясен иярдә утырган килеш иелеп алмакчы була, ләкин ханның ризасызлык белән кулын кинәт селкетеп куйганын күргәч, шып тынып кала. Ук кебек томырылып очкан лачын берни сизми үләксә өзгәләгән бүре турына җитәрәк яшен утыдай түбән кадала һәм бер аягының үткен тырнакларын аның сыртына, икенче аягының тырнакларын алга сузып күзләренә батыра. Калкулыктагылар дәррәү: «Кһа-а!» дип кычкырып җибәрәләр. Салкын канлылык белән берninди хәрәкәтсез торган Туктамыш тагын бер кат бармакларын шартлатып ала: ике яшь җайдак шундук лачын тырнакларыннан ычкынырга маташкан бүре янына чаптырып китәләр.**

### 4. Елга буенда тугайлык. Көн.

**Бер яктан сөзәк таулар, икенче яктан елга белән чикләнгән иркен яшел тугайлыкта дүрт почмаклы ефәк хан чатыры тирәсенә тагын берничә кечерәк түгәрәк чатырлар корылган. Хан чатырына керә торган ишекнең ике ягында зур савытларда ут көйри, айбалталы ике тоткавыл баскан. Гөмбәзле түбәнең нәкъ уртасына кара төстәге хан байрагы кадалган. Читтәрәк өчаякларга зур казаннар асылган: ит пешә, төрле-төрле ашамлыклар әзерләнә. Ә тагын да арырак түшкәсе-ние белән ат ите кыздырыла. Пешекчеләр, күзәтүчеләр мәш киләләр. Хан чатырында мәҗлеснең дуены: Туктамыш хан үзе дә кәефләнеп өлгергән — ул иң түрдә биеклеккә утырган, уң ягында — өлкән хатыны Йәникә, ә башкалар, дәрәҗәләренә карап, аңа каршы ярымай ясап урнашканнар. Ханның сул ягында, кул буе чамасы читтәрәк, алтын читлек белән Төкле Аякны элеп куйганнар: Туктамыш әледән-әле аңа тәмле чи ит калҗалары каптыра. Лачынчы Котлыкыя да шунда утыра. Талгын моң астында гүзәл кызлар бии, дүрт церемониалмейстер тәртип саклый. Бавырчылар кабул ителгән ритуал буенча алтын-көмеш савытлар белән ашамлыклар ташый, эчемлек өләшүчеләр түрә янына тезләнгән килеш көмеш чокырларга шәраб сала.**

Туктамыш *(ярым исерек тавыш белән)*. Җантимер би!

**Арадан мәһабәт гәүдәле бер ир сикереп тора һәм, ике кулын күкрәгенә кушырып, баш ия.**

Җантимер. Боер, ханиям.

Туктамыш. Без сине, күп бала атасы булуыңны истә тотып һәм зирәклегеңне белеп, тәхет варисларына аталык итеп билгеләдек. Сынап карыйк: зирәклегең расмы икән. Лачынчыбыз Котлыкыя би, Урдабызданы Төкле Аяк тиздән ана булырга җыена, ди. Ул үзе бүген бөтен җиһанга таралган данын тагын бер мәртәбә раслады, нәселе нинди булыр синеңчә?

**Сыйланучылар тыйнак кына көлешәләр.**

Җантимер. Ходай сиңа — тәхетебезнең алтын баганасына — озын гомер бирсен, ханиям: аталык итеп бик олыладың мине һәм мин кулымнан килгән кадәр ышанычыңны аклармын. Тик, зинһар, кичер, ханиям: Төкле Аякның киләчәк нәселе турындагы сүзне җан дустым Котлыкыя бинең үзенә яисә бүтән кешегә тапшырсаң иде.

Туктамыш *(тирән гаҗәпләнеп)*. Ник?! Бозау чаклы ата бүрене алганын син үз күзләрең белән күрдең ич!

Җантимер. Күрдем. Һәм соклануымны яшермим, ханиям: Төкле Аяк, чынлап та, арыслан йөрәкле һәм батыр ирләргә тиң гайрәтле ау лачыны! Шуңа күрә аның варислары да үзенә охшар шәт дигән зур өмет бар. Әмма минс хәзер бүтән варисларның киләчәк язмышы ныграк борчый: аларның да үз аталары кебек үк арыслан йөрәкле һәм аналары кебек зирәк акыллы булып үсүләрен телим, ә шуларның беренчесе бүгенге көндә анасының бөере өстендә тыпырдап бии башлаганга охшый инде. *(Елмая.)*

Туктамыш *(башта берни аңламыйча аптырап карап тора, ирексездән, тыйнаклык белән күз карашын түбән төбәгән хатынына борылып карый һәм аның сизелерлек бүлтәя башлаган корсагын күреп, кычкырып көлеп җибәрә)*. Ха-ха-ха! Сынауны шәп үттең, Җантимер би!

**Чатырдагылар барысы да аңа кушылып көләләр. Тик, толмачны ауга алып чыгарга онытканнар, ахры, чит илчеләр генә берни аңламый җилкәләрен җыералар. Җантимер урынына утыра.**

Туктамыш *(илчеләрнең аптырашып җилкә җыеруларын күреп)*. Нәрсә анда, ерактан килгән илчеләр бүген толмачсыз калганнармыни? Нишләп ауга килмәскә батырчылык иткән ул?!

**Чатырда кинәт тынлык урнаша.**

*(Кул селти.)* Ә! Зыян юк. Анасының бөерен тынгысызлый башлаган варис, үсеп житкәч, үзе аңлатыр әле яхшылап. Юлында шушылар кебек телсез башлар очраса! *(Йодрыгын селтәп күрсәтә.)* Татарга толмач кирәкми бит!

**Чатырда кабат дәррәү көлешү куба.**

Туктамыш *(көлешү тынгач)*. Йә, кем Төкле Аякның киләчәк варислары турында күрәзәлек итәргә база?

Кәмал *(торып, кулларын күкрәгенә кушыра)*. Мин фәкыйрегезгә рөхсәт ит, бөек ханиям?

Туктамыш. Ә, Кәмал би... Баш вәзирем нишләп күземә чалынмый дисәм, монда икәнсең. Йә, әйтеп кара: тыңлыйбыз сине.

Кәмал. Бөек хакимебез! Син утырган алтын тәхеттән уң ягыңа күз ташласаң, дәүләтеңнең читенә чыкканчы — алты айлык юл, сул ягыңа карасаң — жиде айлык юл. Аллага шөкер, синең тиңдәшсез гайрәтең Нугай илен таралмаслык итеп кабат алтын кыршау белән кыршаулады. Һәм хәзер синең биек тәхетеңнән бөтен жиһан уч төбендә кебек күренә. Иле күпнең ире күп: акыл бәйгесендә дан тотарлык зирәк ирләребез житәрлек. Әмма син биргән сорауга борынгы ата-бабаларыбыз әйтеп калдырган бер хикмәтле сүздән дә төгәлрәк итеп беребез дә жавап бирә алмабыздыр: алма агачыннан ерак төшми!

**Чатырда аны хуплау, жанлану башлана.**

Син итәген тотырып бала асраган һәм зирәк исле Жантимер бине тәхетеңнең варисларын тәрбияләчәк аталык итеп билгеләдең: чөнки, барыбызга да билгеле, Жантимер би һичшиксез өметеңне аклаячак, ә инде ул кайбер нәрсәләрне күреп бетермәсә, тәхет варислары янында һәрвакыт арыслан йөрәкле гаярь аталары белән аксакаллардан да үткенрәк зиһенле аналары булачак бит. Ә Төкле Аякның нәселен кем тәрбияләчәк? Бер ялгызы Колыкыя би. Яңа туган кошчыклар бары тик Котлыкыя би карамагында гына булачак. Төкле Аякның үзеннән балаларыңны үзең булдырганнарның барысына да өйрәт, дип таләп итеп булмый бит инде!

**Көлешәләр.**

Туктамыш *(елмая)*. Димәк?

Кәмал. Димәк, бөек ханиям, синең соравыңа мин менә болай гына жавап бирер идем: даны йөз дәүләткә таралган лачыныбыз Төкле Аякның туачак балаларының язмышы — тулысынча Котлыкыя би кулында! Сүзем бетте, ханиям. *(Кулларын күкрәгенә кушырып, баш ия.)*

Туктамыш. Йә, ни әйтерсең, лачыным?

Котлыкыя *(әкрен генә)*. Төкле Аякның йомыркаларын күрмәдек бит әле, ханиям.

Туктамыш. Моның белән ни әйтмәкчесең?

Котлыкыя. Кош йомыркаларының ике сарылы була торган сәер гадәтләре бар.

**Чатырда авыр тынлык урнаша.**

Туктамыш *(ачулы)*. Нәрсә, алдан ук жаваплылыкны жилкәңнән төшерәсең киләме? Табынның түмен бозарга чамалыйсың, ахры, син! Төкле Аяк ике сарылы йомырка салмас! Иртәгә ауны Ку күлендә дәвам итәбез, фикерең үзгәрер, бәлки, шуннан соң! *(Мәҗлесне каш асты белән сөзеп чыга.)*

**Шулвакыт ерактан сөрән салып кычкырган тавыш ишетелә: «Бөек ханга — Шаһ Тимер илчесе килде!»**

Туктамыш *(үзен бүлдергәнгә ризасызлык белән)*. Нәрсә бар анда?!

**Тәртип саклаучыларның өлкәне тышка юнәлә.**

**5. Хан чатыры алды. Көн.**

**Чатыр ишеге алдында, ритуал буенча, кулларын күкрәгендә чалыштырып, Шаһ Тимер юлаучысы басып тора: ул монда жәяү китерелгән. Аның як-ягында Туктамыш ханның атлы ике тән сакчысы басып тора.**

Ясавыл. Йомышыңны әйт!

Юлаучы. Туктамыш ханга — Шаһ Тимер ярлыгы! Үз кулым белән тапшырырга тиеш!

Ясавыл. Яхшы. Көт. *(Чатырга керә.)*

**6. Хан чатыры. Көн.**

**Ясавыл чатырга керә һәм хан алдында баш ия.**

Туктамыш. Йә?

Ясавыл. Шаһ Тимер илчесе кабул итүеңне үтенә, ханиям. Ярлык китергән.

Туктамыш *(ризасызлык белән тирәягына карана, хатыны Йәникә кулы белән иләп кенә аның кулына кагылып куя)*. Керсен!

**Шундук тәртип саклаучыларның икесе тышка юнәлә һәм Шаһ Тимер илчесен, ике ут арасыннан үткәреп, чатырга култыклап алып керә: алар, чатыр эченә кергәч, илчене хан алдында бер аягына тезләндереп, беренче мәртәбә йөгендерәләр, аннан соң, ике-өч метр алгарак атлатып, тагын шулай ук йөгендерәләр һәм, хан янына житәрәк биш метр чамасы калгач, ике аягына да тезләндерәләр. Илче ике кулын күкрәгенә кушырып баш ия һәм, куеныннан кәгазь төргәге алып, аны ике уч өстендә алга таба суза. Тәхетнең уң ягында утырган ирләрнең берсе, тиз генә торып, Шаһ Тимер ярлыгын Туктамышка илтеп бирә. Ул арада тәртип саклаучылар илчене ике ягыннан култыклап артка чигендерәләр: кергәндәге кебек үк, өч тапкыр йөгендерәләр һәм аны тышта көтеп торган тән сакчылары карамагына тапшыралар. Илче, чатырга керер алдыннан торгандагы кебек, кулларын күкрәге өстендә чалыштырып, ишеккә карап баса.**

Т у к т а м ы ш *(тøргәкне сутә һәм бераз карап торганнан соң).* Битекче! Кычкырып укы! *(Йәникәсенең ризасызлык белән нидер ымлавын күрә.)* Укысын!

Б и т е к ч е *(ул, хан тәхетенең сул ягында бер читтәрәк утырган җиреннән сикереп торып, ярлыкны ала һәм, арткарак чигенеп, кычкырып укый).* «Бисмиллаһи-ирахман-иррахим...»

Т у к т а м ы ш. Туры төп сүзгә күч!

Б и т е к ч е *(баш иеп ала).* «Мәвәрә-әннәһр хакиме Шаһ Тимер сүзе. Ак Урда ханы Туктамышка. Ошбу сүзем белән мин синең исеңә төшерәм: син, үз атаң, Маңгышлак хакиме Түли-хуҗа, Күк Урдада хакимлек итүче Ырыс хан тарафыннан үтерелгәч, миңа килеп сыендың һәм ашарыңа ризык таптың. Табынымда кымызымның курысын эчтең, мин сине үз канатым астына алдым, атаңныкыннан күп мәртәбәләр биегрәк тәхеткә утырттым: сине — Алтын Урданың бөек ханы иттем. Мин сиңа — ата, син миңа — угыл булып, мәңге минем сүздән чыкмаска вәгъдә бирдең. Сүзеңне кылган эшең белән беркетергә вакыт җитте. Синдә даны еракларга таралган ау лачыны бар, шуны миңа тапшыр! Язылды Сәмәрканд каласында...»

Т у к т а м ы ш *(ачуыннан шартлардай булган).* Җитте! *(Сикереп тора һәм илчеләрнең үзара чыш-пыш кызу-кызу сөйләшүләрен күрә.)* Толмач кая?!

Я с а в ы л *(барысы да аякөсте басалар).* Белә алмадык, бөек ханиям.

Т у к т а м ы ш. Борынына чылбыр тагып, кала урамнарында йөртергә һәм, башын чабып, Иделгә ташларга! *(Тирә-ягына карана.)* Ә аягы чонтык Шаһ Тимергә җавап шул булыр: илчесен, табан астын телгәләп, кыл сибеп...

Й ә н и к ә *(ханның җиңеннән тарта һәм ишетелер-ишетелмәс пышылдый).* Илчегә үлем юк, бөек ханиям... Җавапны Сарайга кайткач яздырырбыз.

Т у к т а м ы ш. Мәҗлес тәмам! Сарайга кайтабыз.

### 7. Хан сарае «Алтын Таш». Иртән.

**Хан бистәсендә гадәти вакыйгаларның берсе: чит илчеләрдән бер адым да калмый кайда да ияреп йөрергә билгеләнгән т о л м а ч н ы, хан оештырган лачын авына бармый калганы өчен, борынын тишеп, чылбыр тагалар һәм аны ике сакчы белән бер барабанчы кала күчәләре (урамнары) буйлап йөртергә алып чыгып китәләр.**

Б а р а б а н ч ы *(ул хан фәрманын җиткерүче сөрәнче дә).* Хан фәрманын тыңлагыз! Котлытимер толмачның, хан боерыгын тиешенчә үтәмәгәне өчен, бүген башы чабылып, гәүдәсе Иделгә ташлана!

**Барабан кагу тавышы ерагая һәм капка бикләнә.**

### 8. Кәрван-сарай. Иртән.

**Ыгы-зыгылы зур утарның бер кырыенда Туктамыш хан лачынчысы Сәмәрканд әмире Шаһ Тимернең илчесе белән очраша.**

К о т л ы к ы я. Туктамыш хан Шаһ Тимергә җавап ярлыгы әзерли. Җавабы нинди булачактыр — миңа караңгы. Мин шуны гына яхшы беләм, илче: хан ярлыгын Шаһ Тимергә синең аша җибәрәчәкләр.

И л ч е *(гаҗәпләнеп).* Туктамыш ханның үз илчесе минем белән Сәмәркандка бармаячак, димәк?

К о т л ы к ы я *(шикләнеп тирә-ягына карана).* Дөрес аңладың, илче. Әмма артык борчылма: юлда сине тоткарлаучы табылмас — синең кулда Туктамыш хан ярлыгы булачак, ә ул — һәр йозакка ярый торган ачкыч. Шуңа күрә мин, Туктамыш ханның лачынчысы Котлыкыя би, Шаһ Тимергә күчтәнәчне синең белән җибәрергә булдым. Күз карасы кебек сакла боларны! *(Кечкенә сафиян янчык белән нидер бирә.)*

И л ч е. Ни бу?

К о т л ы к ы я. Төкле Аяк астыннан алган ике йомырка! Юлың озын һәм бик авыр: исән-имин кайтарып җиткереп, Шаһ Тимергә тапшыра алырсыңмы?

И л ч е. Тапшырырмын, шикләнмә, Котлыкыя би! Туктамыш хан сизенсә, ни дип җавап тотарсың?

К о т л ы к ы я. Сизенмәс. Мин аларны тупыйк томшыклы гади бидаяк йомыркалары белән алыштырдым. Аермаларын күрер өчен Туктамыш күзе генә җитми монда! Шаһ Тимергә телдән тапшыр: Алтын Урда Сараенда ике кардәш дәүләтнең тату яшәвен теләүче лачыннар да бар. *(Кәрван-сарай капкасына юнәлә.)*

### 9. Кәрван-сарай капкасы алды. Иртән.

**Котлыкыя би капкадан чыгуга Җантимер аталык белән маңгайга-маңгай очраша. Берберсенә сүз катып өлгермиләр, барабан каккан тавыш артыннан борылмадан толмачны чылбыр белән йөртүчеләр килеп чыга.**

Б а р а б а н ч ы *(кагудан туктаган арада).* Ишетмәгәннәр ишетсен, күрмәгәннәр күреп калсын! Котлытимер толмач, Туктамыш ханның боерыгын тиешенчә үтәмәгәне өчен, бүген җәзалап үтерелә һәм аның гәүдәсе Иделгә ташлана!

**Кәрван-сарай турыннан үтеп киткәләр: капка төбендә торучылар Котлытимер белән күз карашы белән хушлашып калалар.**

К о т л ы к ы я. Ханнарның бөеклеге гаепләне ярлыкауда беленә!.. Котлытимер толмачны Туктамыш хан хәтта синең хакка да ярлыкамады! Толмачның сиңа якын туган тиешле кеше икәнлеген бик яхшы белә бит! Туктамыштан рәхим-шәфкать сорау — үгез саву белән бер. Нишләп ауга бармый калган соң ул? Чакырулы булгандыр ич?

Җ а н т и м е р *(Котлыкыяны сынагандай күзләренә туп-туры карый).* Дөрес әйтәсең, чакырулы иде... Ырыс ханның аркадашлары белән очрашырга тиеш иде ул бүген, шуңа Туктамыш хан тантанасын күрә алмады.

К о т л ы к ы я. Ничек?! Котлытимер дә Ырыс хан кешесе идемени?

Җ а н т и м е р. Ачыктан-ачык сөйләшик, Котлыкыя. Таркалган мәмләкәтебезне

Ырыс хан үз кулы астында берләштерергә йөргәндә син «әмирләр әмире» булган кеше... Аның уң кулы!

Котлыкыя. Хәзер — кайчандыр Ырыс ханның тырнагыннан көчкә качып котылган Туктамышның лачынчысы! Син дә, Җантимер дус, кайчандыр Ырыс ханның сул кулы идең, ә хәзер — аның кан дошманы Түли-хуҗаның оныкларын — Туктамыш хан варисларын тәрбияләргә җыенасың! Ырыс хан — дала бөркете иде, ә бүгенге көндә Алтын Урда тәхетендә күгәрчен дә тибә алмаган тупыйк томшыклы бидаяк утыра! Сиңа Алладыр ул, бүтәнгә — карга!

Җантимер. Чү, әкренрәк... *(Котлыкыяны кәрван-сарайның таш коймасы янынnan читкәрәк алып китә.)* Даланың да колагы була, ә монда — биек таш койма. Килешәм: хан тәхетенә Ырыс хан утырса, татар каны бу кадәр коелмаган булыр иде шәт. Ләкин ул — гүр иясе инде, Ырыс ханны аннан кайтарып булмый, Котлыкыя.

Котлыкыя. Аның каравы, Ырыс ханның улы Тимер Мәлик исән! Тимер Мәлик тегермәнгә су сорый! Туктамыш хан барыбер, Ак Урданы үз утарына әйләндергән Мәмәй Әмирне кумыйча, кан коюдан туктамаячак. Бер казанга ике тәкә башы сыймый, Җантимер!

Җантимер. Сарай тәхетендә кем утырса да, безгә барыбер түгелме? Илнең бер кулга төйнәлеп, балаларымның тыныч гомер кичерүен генә телим мин. Шуны истә тотып кына, Туктамышның варисларын тәрбияләргә ризалыгымны бирдем: Туктамышның үзенә буй житмәсә, аларны, шәхси дан-шөһрәт артыннан куып, адәм канын коюдан туктатып булмасмы, ичмасам!

Котлыкыя. И, Җантимер дус! Буш хыял белән янасың икән! Туктамышның баш вәзире Кәмал бинең сүзләрен ишеттең ич: алма агачыннан ерак төшми. Юк, Ырыс хан нәселе — боларның бөтенләй киресе! Әгәр дә Тимер Мәлик, Туктамыш хан белән Мәмәй әмирнең икесен дә себерке белән себереп чыгарып, зур тәхеткә хуҗа була алса, иң беренче эше итеп, күршеләргә дуслык тәкъдиме ясап, илчеләр җибәрәчәк. Ә Туктамышны, ул бөтен Урдага хаким булып калганда да, төрле олыслардан җыелган яран әмирләре яу артыннан яу чабарга котыртып ятачаклар, чөнки сакалында карабодай чәчәк атса да, башында җил уйнаганын күреп торалар. Сукыр дәүләт бу!

Җантимер *(серле итеп)*. Менә хәзер аңлашыла...

Котлыкыя *(кискен)*. Нәрсә аңлашыла сиңа?!

Җантимер. Тәкле Аякның йомыркаларын, оясыннан алып, нинди максат белән Шаһ Тимер илчесенә монда китереп бирүең аңлашыла!

Котлыкыя *(югалып кала)*. Ни сөйлисең син!

Җантимер. Шикләнмә, әлегә мин үзем генә беләм бу серне, Котлыкыя дус. Үзең ычкындырмасаң — шулай калыр да. Мин әйтмәдем, син ишетмәдең. Туктамыш, Шаһ Тимердән гаскәр алып килеп, тәхет өчен канлы орыш башлагач, авыр хәлдә мине үлемнән син йолып калдың, Котлыкыя! Аш белән атканга таш белән җавап бирә белмим мин. Без синең белән ул чакта, каннарыбызны тамызып, мәңге бер-беребезгә хыянәт итмәскә ант сөте эчтек! Ләкин сак бул: Туктамыш ханның колаклары күп, күзләре үткен, куллары озын!

Котлыкыя *(дустына ышанып бетми)*. Мин әлегә Туктамышның үткен күзләрен синең маңгаеңда күрәм, Җантимер би!

Җантимер *(тирән рәнҗеп)*. Күрәм: җан дуслар идек, хәзер ике эт кебек ырлашырга әзербез!

Котлыкыя. Чөнки этләр хуҗаларына охшый!

**10. Хан сарае «Алтын Таш». Иртән.**

**Сарайның кечерәк пулатларының берсендә Туктамыш хан ханәше Йәникә белән Шаһ Тимергә нинди җавап бирү хакында киңәшә.**

Туктамыш *(Тимернең ярлыгын идәнгә ташлый)*. Минемчә, лачынымны соравы — Аксак Тимернең мине сынап каравы гына! Ничек җавап бирермен!? Тәкле Аякны аңа бүләк итсәм — аның миңа кылган яхшылыкларын онытмаганмын булып чыга. Баш тартсам — мин яхшылыкның кадерен белмәүче мәнсез кеше. Ашаган табагына төкергән! У-у, анда «кунак булып» яткан чорда бик нык күзәттем мин ул хәйләкәрне. Кайда да мәкерле шымчылары бар аның: төрле күрше илләрне аркылыга-буйга айкап йөриләр һәм кимендә атнага бер аңа бөтен нәрсәләрне хәбәр итеп торалар. Идел аръягында утырган Мәмәй әмир белән кайчандыр якага-яка киләчәгебезне бик әйбәт белә ул! Миннән ярдәм сорап киләсең бар, чамала, Туктамыш, ди ул миңа!

Йәникә *(ханның сүзләренә артык игътибар итми)*. Идел буе олысларының әмирләре белән төн буе киңәш тоттың — алар ни диләр?

Туктамыш *(кул селти)*. Атка таянма, Иделгә ышанма! Ни дисеннәр алар? Минем, берәр зур ызгышка кереп, муенымны сындырганны көтәләр!

Йәникә. Шулай да? Барысы да бер сүздәмени?

Туктамыш. Күбесе — Шаһ Тимер белән араны өзүне хуп күрә. Ногай иле хәзер — кичәге эт өере талашыннан арынды, синең кул астында шактый ныгыды, борынгы Чыңгыз бабаң чорындагы көч-куәтен кайтарды, нинди дә нәселсез заттан чыккан Аксак Тимергә баш орып яту килешмәс, имеш. Аларга нәрсә? Туктамыш, Тимер өстенә яу чабып, максатына ирешсә — баеп калачаклар, баштүбән мөтәлсә — үзбашка аерылып, миңа буйсынудан котылачаклар. Тегеләй дә лафа, болай да лафа! Чакмагыш би белән Дөрмән би генә нишләптер, авызларына су капкандай, теге якка да, бу якка да бер сүз кушмадылар. Күптән сизенеп киләм: миңа каршы нидер әзерли ул ике астыртын! Дөрмән би генә: ояга утырган бөркет күрше-тирәсендә киек типми, дип әйтеп куйды. Ни әйтергә теләгәндер — төшенмәдем.

Йәникә *(иелеп Шаһ Тимер ярлыгын ала һәм җентекләп карый)*. Аның ни әйтергә теләгәнен аңладым, бугай, ханиям: миңа ишарә итүе, минемчә.

Туктамыш. Синең ни катнашың бар бу эшкә?

Йәникә *(елмая)*. Ояга утырган бөркет — мин булам ич инде! *(Җитдиләнеп.)* Дөрмән би сиңа: Шаһ Тимер белән ара бозарга ашыкма, Туктамыш хан, Йәникә ханәшең ул табып, үстереп бирсен — үзенә ышанычлы терәк булыр, шуннан соң куәтле күршеләрең белән аяк терәп сөйләшә башларсың, ә варисың тумас борын ызгыш башлап, үзең белән ул-бу була калса, нәселең киселәчәк, диюе! Анасының бер имчәген имгәндә икенчесен кулы белән җибәрми торган бала иде диләр аны. Ләкин син аның хәйләкәр сүзләрен тыңла да, үзеңчә эшлә: чынлап та, астыртын мәкер әзерләп, вакытны үз файдасына сузарга теләмиме икән?

Туктамыш. Һе — үзеңчә эшлә, имеш... Әйтүе ансат!

Йәникә *(елмая)*. Мин сине бик тәвәккәл кешегә санап йөри идем, ялгышканмын, ахры, бөек ханиям! Башыңны югалтып, алдың-артың ныклап уйламыйча, утка ташлан димим мин сиңа. Шаһ Тимернең хатын игътибар белән укыдыңмы?

Туктамыш. Кырык тапкыр укысаң да — мәгънәсе бер: Төкле Аякны таләп итә! Иң авыры шунда — мин аңа тәхетем белән бурычлы!

Йәникә. Җентекләп укыганга охшамыйсың шул, ханиям. Менә кара: Шаһ Тимер үз исемен алтын хәрефләр белән яздырган. Ә синең исемең? Гап-гади кара белән! Бу ни дигән сүз? Артык масайма, Туктамыш хан, мин — бөек мәмләкәт тәзегән хаким, ә син, Чыңгыз нәселеннән чыксаң да, минем алда бер мескен генә, янәсе! Бу — булды бер. Икенче: нишләп әле ул кинәт кенә әллә кайчан аңа барып сыенганыңны һәм аның ризыгын ашаганыңны исеңә төшерергә булган? Илсез-йортсыз калган бер хәерче идең син, дип сине мыскыл итүе. Өченче: «мәңге минем сүздән чыкмаска вәгъдә бирдең. Сүзеңне кылган эшең белән беркетергә вакыт җитте», — дип лачыныңны сорый. Юк, ханиям! Лачын монда бер сылтау гына... Синең көннән-көн көчәя баруыңны күреп тора ул, үзенә буйсынудан чыгып ычкынмагае, дип курка! Турыдан-туры шулай ачык әйтеп салыр иде — үз куәтенә ышанып битми, димәк. Икенчедән, бүген аның кайгысы син түгел — үз дәүләтен ныгытасы бар, кайда да аңа каршы баш күтәреп яталар.

Туктамыш *(ханәшенең акыллы фикер йөртүенә шаккатып)*. Ә бит чыннан да шулай бу, Йәникә?

Йәникә *(елмая)*. Димәк?

Туктамыш. Димәк, Аксак Тимернең ярлыгын ертып атып, илчесен артына тибеп кайтарып җибәрергә була — баш ватасы да калмый!

Йәникә. Һәм озакламый башыңны тагын да ныграк ватарга туры килер иде! Юк инде, ханиям: Аксак Тимер үзе башын ватсын. Җавабың шундый булсын — көч-куәтең барлыгы әллә кайдан аңкып торсын! Син Чыңгыз оныгы ич! Ә ул кем? Сәнәктән көрәк булган, заты билгесез бер әмир! Ачуы чыкса да йотып җибәрер: үз утарын ныгытасы бар. Тик онытма, ханиям: ул койма ныгыта икән — син дә ныгыт! Аксак-туксак каравыклар керерлек булмасын! Ә инде Чакмагыш белән Дөрмән биләргә килгәндә... *(Елмая)*. Кичер, бөек ханиям: дәүләт эшләренә тыгылмаска сүз биргәнемне истән чыгара язганмын! *(Башын иеп, елмаюын яшерә.)*

### 11. «Алтын Таш» хан сарае. Көн.

**Кече пулат. Тамгалык дип аталган кечкенә тәбәнәк өстәл артында хан катибы аякларын чалыштырып утыра.**

Туктамыш *(ул пулат буйлап әрле-бирле йөри.)* Шаһ Тимергә җавап хаты әзерлә. Эчтәлеге болай булсын: ул, чонтык аяк Әмир Бырлас Шаһ Тимер, Сыр-Дәрья артында Сәмәркәндтә утырса, мин — аргы атам Чыңгыз хан, бирге атам Түли-хуҗадан туган Туктамыш хан — Күк Түбәдә Ак Сарайда утырам! Ил булганга — ил булам, яу булганга — яу булам. Тугыз йортыма дан булган кара лачын Төкле Аяк мәңге сиңа булмас, Шаһ Тимер! Аннан кайтыш Бүз Тойгыным бар, ул да сиңа булмас, Шаһ Тимер! Сычкан типкән бидаяк очадыр илең күгендә — шуны ау лачыны ит, Шаһ Тимер!

### 12. Котлыкыя би йорты. Иртән.

**Котлыкыя бинең йортында ыгы-зыгы: аның хатыны бүген бала табарга тиеш. Котлыкыя үзе алгы якта тынгысызланып йөри: әледән-әле эчке як ишегенә колак салып тыңлый, ләкин кендек әбиләре аны, аяк астында чуалма дигәндәй, абруена игътибар итмичә, төртеп кенә җибәрәләр. Менә, ниһаять, эчке якта яңа туган бала елавы ишетелә һәм Котлыкыя шатлыгыннан елмаеп җибәрә.**

Кендек әбисе *(ефәккә төргән бала күтәреп чыга)*. Улың бар, Котлыкыя би! Әгүзе билләхи миннә шәйтан ирраҗим... *(Баланы әтисенә тоттыра.)* Тәңребез бәхетле итсен ятимеңне.

Котлыкыя *(баласын кулыннан төшереп җибәрә яза)*. Ничек — ятимемне?!

Кендек әбисе. Бар нәрсә дә хак тәгалә кулында, Котлыкыя би... Анасы мәңгегә күзен йомды, бахыр!

**Тышта ат тояклары тавышы ишетелә.**

Чапкын *(тыштан кычкыра)*. Котлыкыя би! Хан чакырта сине!

### 13. «Алтын Таш» хан бистәсе. Көн.

**Иркен хан утарында тәбәнәк казыкка озын җеп белән кыр куяны бәйләп куелган. Туктамыш хан вәзирләре белән бергә шул тирәдә басып тора. Котлыкыя да шунда.**

Туктамыш. Улың туган дип ишеттек, котлыйм, Котлыкыя би!

Котлыкыя. Рәхмәт, ханиям. Туды, ләкин анасын тәтенсез йортка җибәреп дөньяга килде...

Туктамыш. Алай икән... Йә, артык бетеренмә: улың яшәсен, ә хатын табылыр! Без калга улыбызга Кадыйрбирде куштык, синең улыңның аты ничек булды инде?

Котлыкыя. Кушарга өлгермәдем, ханиям.

Туктамыш. Зыян юк, Котлыкыя! Булган атка ат кушу кыен түгел. Малай — атаның аты ул, шулай бит? *(Каламбурыннан үзе канәгать булып рәхәтләнеп көлә, яраннары аңа кыткылдап кушылалар.)* Нугай татары бишектәге бала кырыкка төрләнә, ди, син аны безгә тугрылыклы итеп үстер!

Котлыкыя *(җитди)*. Чакыртказсың икән, боер, ханиям.

Туктамыш. Төкле Аякның токымын сынар көн җитте, Котлыкыя. Икесен дә китер. Әлегә — шушы киекне тибеп күрсәтсеннәр. *(Казыкка бәйләнгән кыр куянына ымлый.)*

Котлыкыя. Яхшы, ханиям. *(Караллылар ягына карап, кемгәдер кул изи.)*

Кәмал. Төкле Аяк — тугыз йортның даны, ханиябез. Димәк, кошчыклары да үзе кебек гайрәтле ау лачыннары булырлар. Котлыкыя би — тәҗрибәле лачынчы. Сынагансынаган, кырга чыгып, төлке типтереп карарга иде! Бүрегә — иртәрәктер.

Туктамыш. Җитешербез, Кәмал би.

**Ул арада Котлыкыяга ике лачын китереп бирәләр.**

Котлыкыя *(кошларның берсен туграчка бастырып, хан алдында иелә)*. Рәхим ит, ханиям!

Туктамыш *(туграч белән кошны ала һәм башлыгын салдырып, һавага чөя, әмма кош канатларын җилпи дә, туграчыннан аерылырга теләмичә, тынып кала)*. Нәрсә бирдең син миңа, лачынчы?! Томшыгы тома бидаяк баласы ич бу! *(Ачудан кошны туграчы-ние белән җиргә ора.)* Икенчесен бир!

Котлыкыя *(шулай ук аның алдында иелеп, икенчесен ханга тоттыра)*. Икенчесен рәхим ит, ханиям!

Туктамыш *(кулына алуга башлыгын салдырып ташлый һәм кычкырып җибәрә)*. Бусы да — сычкан тибүче бидаяк баласы! *(Җиргә ора.)* Кая иттең Төкле Аякның балаларын?!

Котлыкыя. Ялгышасың, ханиям! Мин сиңа Төкле Аякның үз балаларын бирдем. Без картайганда, Төкле Аяк та яшь көенә тормас. Шуңа күрә нәселе аннан күпкә кайтыш.

Туктамыш. Лыгырдама юкны, лачынчы! Сәмәрканд әмире Шаһ Тимер Төкле Аякны сораткан иде, син, миңа хыянәт итеп, дан тоткан лачынымның йомыркаларын аңа җибәргәнсең! Лачынымның токымын кан дошманыма бүләк итеп, оясына бидаяк йомыркалары салгансың!

**Котлыкыя бер читтә торган Җантимер белән күз алыша: саттыңмы, янәсе.**

Котлыкыя *(горур)*. Дөрес әйтәсең, Туктамыш хан! Нәкъ шулай эшләдем! Салкын исәп белән эшләдем.

Туктамыш. Ни өчен? Башың икеме әллә?

Котлыкыя. Әйе, Шаһ Тимер — синең кан дошманың, Туктамыш хан. Бер башымны ике итеп, Шаһ Тимергә сатылганмын икән — синнән дәүләт, бездән ырыс киткән дигән сүз ул.

Туктамыш. Миннән дәүләт киткәнме?! Алыгыз үзен!

**Котлыкыяны ике яктан ике сакчы тотып ала.**

Котлыкыя. Башымны кистерәсеңне беләм, Туктамыш хан, ләкин әйтеп бетерергә рөхсәтеңне бир!

Туктамыш *(алып китми торыгыз, дип ымлый)*. Әйтәсең булса, әйтеп кал! Әмма шуны да белеп кит: ашаган табагына тычкан ахмак син! Исән чакта дәүләт Туктамыш кулыннан китмәс. Онытгыңмыни, Котлыкыя? Мин килгәнче Алтын Урда нинди хәлдә иде? Егерме ел эчендә егерме биш түрә алмашкан ил иде бу! Ә мин аны менә шушы учыма тупладым. Кем дәвере хәзер? Туктамыш дәвере! Кем заманы хәзер? Туктамыш заманы! Данлыклы бабам Чыңгыз ни кылса, мин шуны кылдым! Шулай булгач, мин үзем дә Чыңгыз түгелме? Миннән дәүләт киткән дигән сүзеңнең мәгънәсен аңлат, каның котсыз, Котлыкыя!

Котлыкыя. Мин аңлатырмын — син аңларсыңмы икән, белмим. Син тәхеткә менгәнче байлыгы мәңге бетмәс ил иде бу — кая булды ул маллар? Аласыңнан бирәсең күп! Сарайның дүрт капкасы бар: элек җиһанның дүрт кыйбласыннан дүрт кәрван килеп, шул дүрт капкага сыймый иде — бүген кая булды ул иртә таңнан кичкә кадәр калага керер өлгерә алмаган озын кәрваннар? Синнән дәүләт тайганы шушы түгелме, Туктамыш хан? Элек Идел тулы кала иде — бүген кая булдылар алар? Син, тәхет өчен сугышып, ул калаларны җимертеп, урыннарын үлән үсмәс тозлы чүлгә әйләндердең! Кулыңнан дәүләт китүе шушы түгелме, Туктамыш хан?! Мин ике ханга берьюлы баш орсам — Йортыңның абруе китүе ул, ханиям. Чаптыртасың килсә — башым җилкәмдә, чаптырт, Туктамыш хан! *(Хан алдында иелә.)*

Туктамыш *(яраннарына каранып)*. Дөрмән би!

Дөрмән *(хан алдына иелә)*. Боер, ханиям.

Туктамыш. Башын чаптырт мөртәтнең! Чакмагыш би!

Чакмагыш *(хан алдында иелә)*. Тыңлыйм, ханиям.

Туктамыш. Йортына бар: бишегендә яңа туган улы ятадыр — токымын корыт хыянәтченең! Йортын яндырып, оясының көлен күккә очыр!

Җантимер *(хан алдында иелә)*. Сүз әйтергә рөхсәт ит, ханиям!

Туктамыш. Сузма, әйт сүзеңне, Җантимер! Тик кара аны: сез бу сатлыкҗан белән җан дуслар — яклыйсы булсаң, үзеңә үпкәлә!

Җантимер. Синең алда Котлыкыяның гаебе зур, ханиям: якын дустым булса да, яклап сүз кушарга базмыйм! Ләкин аның бишектә яткан сабыеның синең алда нинди гаебе бар? Дөрес, Котлыкыяның хатасы зур: ата-бабалары буыннан буынга Чыңгыз нәселенә ышанычлы терәк булдылар, ул — шушы изге юлдан тайпылды! Ләкин аның атасы Баба Төкләс Хуҗа Әхмәт

әүлияләр пире иде, ил терәге булган азамат ирнең оныгының синең алда нинди хатасы бар? Котлыкыяны кичермәсәң, аталыгым хакына бишектә яткан сабыеның бер кашык канын кичер, ханиям! Буында типкән каны калсын, токымын корытма, зинһар, ханиям!

Туктамыш. Хан сүзе бер булыр, күземнән югал, Җантимер! Гомеремне үтәгез!

**Котлыкыяны, колларын каерып, алып китәләр.**

Котлыкыя *(башын артка каерып кычкыра)*. Кичер мине, җан дустым Җантимер!

**14. Җантимернең йорты. Көн.**

**Өйдә тәрбияче хатын, әкрен генә көйләп, бишектәге баланы тирбәтеп утыра.**
**Җантимер ашыгып кайтып керә һәм бишектән баласын ала.**

Сөт анасы. Чү! Йоклап кына китте! Кая алып китәсең Кобогылыңны?

Җантимер. Шым бул, сөт анасы, бикәнә белгертә күрмә! Хәзер кире кайтарып куям.

**15. Котлыкыяның йорты. Көн.**

**Котлыкыяның сабые йоклап яткан бишек янында беркем дә юк.**
**Баласын күтәргән Җантимер килеп керә һәм иплән кенә Котлыкыяның баласын бишегеннән алып, аның урынына үз баласын сала. Ул арада тышта ат тояклары тавышы ишетелә. Җантимер кулына тоткан сабыйны кая яшерергә дә белми аптырый һәм киң итегенең куныычына тыгып куя. Ул арада Чакмагыш би белән берничә кораллы кеше килеп керә.**

Чакмагыш *(Җантимердән шикләнеп)*. Син нишләп монда, Җантимер би?

Җантимер *(бишеккә ымлый)*. Котлыкыяның сабыен күреп каласым килде, Чакмагыш би! Кара эшегезне баланы уятмыйча башкарыгыз, ичмасам! *(Чыгып китә.)*

Чакмагыш *(бишек бөркәвен күтәреп карый һәм баланың урынында икәнлеген күрә)*. Алыгыз!

**16. Урам. Көн.**

**Җантимер, куа килмиләрме икән дигәндәй, артына борылып карый-карый урам буйлап атлый: Котлыкыя дустының йорты өстеннән куе кара төтен күтәрелә башлый.**

Җантимер *(күз яшьләрен сөртә)*. Әтиеңне кичер, гөнаһсыз сабыем Кобогыл! *(Итек куныычыннан икенче сабыйның елый башлавын ишетеп, иелеп куныычны рәтләгән булып кылана һәм кулы белән иплән кенә сыккалый.)* Чү-чү, балакай!.. Кара көн килде. Сабыр гына кайт. Атаң, мескен, сиңа ат кушарга өлгермәгән икән... Итегем куныычы эчендә исән-имин кайтарып, бишеккә сала алсам, атың... Идегәй булыр! Сөт абыйлары белән бергә Кобогыл урынына үсәрсең...

**17. «Алтын Таш» хан сарае. Көн.**

**Туктамыш хан янына баш вәзир Кәмал би керә.**

Кәмал *(йөзе качкан)*. Эшләр харап, ханиям! Кәрван-сарайда үләт чире! Мәскәүдән килгән ике сәүдәгәр үлгән!

Туктамыш *(куркып кала)*. Тагын?! Биш ел элек ярты халык кырылган иде бит инде! Чарасын күрдеңме?

Кәмал. Кәрван-сарайны бикләттем, ханиям. Хакимлеккә синнән ярлык сорап килгән Елец кенәзе анда чак иде, нишлибез? Чыгарыгыз, дип ялвара.

Туктамыш. Ник чыгармадың?

Кәмал. Куркам, ханиям! Смоленскида егерме биш мең кешедән биш кенә кеше исән калган, имеш: кенәзләр дә, боярлар да кырылып беткән! Шул биш кеше кырга чыгып, кала капкасын тышкы яктан бикләп киткәннәр, ди. Мәскәүнең үзендә дә үләт кузгалган икән. Бөек кенәз Дмитрий гаиләсе белән Ярыслауга качкан. Елец кенәзен ничек тәвәккәлләп чыгарыйм?

Туктамыш. Ары нишләргә уйлыйсың?

Кәмал. Белмим, ханиям! Нишләргә дә аптыраш. Башым катты.

Туктамыш *(ачулы)*. Баш вәзирем ич син! Кәрван-сарайны ут төртеп яндырт.

Кәмал. Елец кенәзе белән бергәме?! Анда тагын өч йөзләп кеше бар!

Туктамыш. Ә Сарайда — җитмеш биш мең кеше яши!

**18. Җантимер йорты. Көн.**

**Җантимер йортында көчле ыгы-зыгы: ашыгыч рәвештә балаларны җәйге киез йортка күчерергә әзерлиләр. Урамда төтен, атлылар чаба.**

Җантимер *(имезүче хатынга)*. Калада кыргын үләт чире! Дөнья хәлен белеп булмый, балаларның язмышын синең ихтыярга куям, сөт анасы! Бигрәк тә төпчек улым Кобогылны күз караң кебек сакла! *(Пышылдауга күчеп.)* Үзең өчен генә әйтәм, ишетсен колагың, бикәң дә белмәсен: үз төпчегебез Кобогыл түгел ул — башы чабылган Котлыкыя дустымның улы Идегәй! Минем белән ул-бу хәл булса... Кашың җыерылмасын — мин калада калам. Үләт чире дан-шөһрәткә дә, байлыкка да карамый — бөтенесен рәттән кыра! Шуңа күрә генә сиңа ачам бу серемне: мин, Котлыкыяның нәсел чылбыры өзелмәсен өчен, аның баласы урынына үземнең төпчегемне җәллад балтасы астына салдым! Тик, кара аны, бала, үсеп җитеп, бәлигъ булганчы, чын исемен беркемгә дә ачасы булма! Киез йортны Аккош күле буендагы җәйләүгә корырлар: шуннан беркем дә кузгалмагыз! Азык-төлек, кирәк-яраклар берничә еллык әзерләнде. Аңынчы кыргын чире калабызны ташлап китәр шәт, аллаһе боерса...

**19. «Алтын Таш» бистәсе капка төбе. Көн.**

**Капка төбенә чабып килгән Җантимер атын туктата һәм чыбыркы сабы белән кече капкага суга. Капка бик аз гына ачыла.**

Тоткавыл. Кем?
Җантимер. Туктамыш хан аталыгы Җантимер би.
Тоткавыл *(кырыс)*. Хан бистәсенә беркемгә дә керергә рөхсәт юк! *(Капканы ябa башлый.)*
Җантимер. Син ишеттеңме: мин — Туктамыш ханның варисларын тәрбияләүче Җантимер би!
Тоткавыл. Ишеттем! *(Капканы шапылдатып ябып куя һәм бикли.)*

## 20. «Алтын Таш» хан сарае. Көн.

**Йәникә бүлмәсендә Туктамыш хан ханәше белән ятакта иркәләнеп ята.**

Йәникә. «Алтын Таш»ны бикләттеңме, ханиям?.. Ач тормабыз — ашау-эчү кирәкләре ун елга җитәрлек.
Туктамыш. «Алтын Таш»ка беркем керми һәм моннан беркем чыкмый! Үләт чире ун елга сузылмас, Йәникәм!
Йәникә. Аксак Тимернең сәүдәгәрләре кәрван-сарайда калып яндымы?
Туктамыш. Янсыннар...
Йәникә. Кызганыч...
Туктамыш. Нәрсә, Аксак Тимернең сәүдәгәрләрен кызганып ятасыңмы әллә?
Йәникә. Үзең уйлап кара, ханиям: ул сәүдәгәрләр янгач, Күк Урдада үләт чире туй иткәнен кем Аксак Тимергә кайтып сөйләр?
Туктамыш. Сөйләмәсә? Моның ни хаҗәте бар?
Йәникә. Шуны да төшенмисеңме, ханиям? Кәрван-сарайда үләт чыккан, дигән хәбәр таралгач нишләп соң аның тирәсеннән бар кеше качып бетте?
Туктамыш. Һе! Кемнең күрәләтә җәһәннәмгә олагасы килсен!
Йәникә. Ә Аксак Тимернең башы икеме? Күк Урда — аның өчен шул үләт чирле кәрван-сарай кебек бит инде!
Туктамыш *(сикереп тора)*. Ә бит бик дөрес бу, ханәшем! Ә мин һаман шул аксактан сагаеп яшим! Яу булып өстемә килмәгәе, дип шикләнеп йөрим! Күк Урдада үләт чире таралганны ничек тә аңа җиткерергә кирәк, Йәникә... Бүгеннән илче юллатам, болай булгач!
Йәникә. Шуннан?
Туктамыш. Шуннанмы? Шуннан тынычланып китәбез, зиһен иясе Йәникәм! *(Хатынын кочаклый.)*
Йәникә *(ирен иплән кенә читкә этәрә)*. Аңламадың син мине! Масая башлаган Болгарны акылга утыртырга җай эзләп йөрисең ич? Бүгенге көндә синең өчен иң куркыныч дошман — Аксак Тимер. Бездә үләт чире кузгалганын ишетсә, ул синең якка борылып та карамаячак. Арканы сөнге кадаучы булмагач, Болгарга «кунак»ка барырга сиңа кем комачаулый? Җай килгәндә сугып калыйк!

## 21. Аккош күле буенда җәйләү. Көн.

**Кояшлы көн. Күл буенда яшь малайлар ук атышлы уйныйлар: кем ераграк һәм төзрәк ата? Менә малайлар арасында бер өлкәнрәге, бүтәннәргә сиздермәскә тырышып, юан имәнгә кадалган угын тиз генә тартып алып, акбур белән билгеләнгән түгәрәкнең үзәгенәрәк күчереп кадый.**

Малай. Минеке — тач уртада!
Төпчек *(ул абыйсының хәрәмдәләшүен күрә)*. Хәрәмдәләшмә! *(Ачуыннан угын абыйсына төзәп атып җибәрә: тегесе чыт-чыт кенә иелеп кала.)*
Сөт анасы *(куркып)*. Кобогыл!

## 22. Урман буенда киң дала. Иртә.

**Кырда яшь сугышчыларны сынау һәм күнектерү уеннары оештырылган: унбашлар, йөзбашлар һәм меңбашлар егетләрне, төрле төркемнәргә бүлеп, ат чабып барган унайга сикереп менеп атлану, бер аттан янәшә барган икенче атка кызу чапканда сикереп күчү, чапкан килеш алга, ян-якларга һәм артка таба борылып ук ату, тыгыз төркем булып чапканда киңәт тирә-якка сибелешү һәм билгеләнгән бер урында кабат берьюлы төркемләнү, һау-һаулап һөҗүмгә ташлану, сөңге белән эш итү, кылыч белән тигәнәк очын кыркып узу һәм шулар кебек төрле-төрле хәрби хәрәкәтләргә өйрәтәләр. Абыйлары белән бергә Кобогыл да шунда: ул осталыгы белән күпләрдән аерылып тора һәм түрәләр аны әледән-әле «Егет икәнсең, Кобогыл!» — дип мактап куялар.**
**Менә, ниһаять, уеннарны туктатырга дигән быргы кычкырту яңгырый: командирлар яшь сугышчыларны сафларга тезәләр.**

Меңбашы *(аты белән сафлар алдына чыгып, кычкырып сөйли)*. Оланнар! Бүген сез тәүге сынаулар үттегез: мин канәгать сездән! Лепкә киптергән арада хөрәсән ялкаулары кебек кул кушырып ятмагансыз. Әмма болар — буынга сикермәгән үсмерләр өчен генә. Кан чирканычы алмаган сары томшыклы кошчыклар өчен. Хәзер монда тас коллар китерерләр. Сезнең дошманнарыгыз алар. Сез барыгыз да хан баласы буласы оланнар: дошман белән маңгайга-маңгай күп очрашачаксыз! Анда икенең бере: йә дошман сине үтерә, йә — син аны! Олы юлга чыгуыгыз шушында башланачак. Беренче күнекмә: атта чапкан унайга тас колны укка алу! Әзерләнегез!

**Яшьләр арасында җанлану башлана: кайсы агарынган, кайсы, киресенчә, шатлану хисләре кичерә. Хәрби уеннар мәйданына, парлап-парлап, муеннарына бау тагылган әсирләрне китерәләр: алар арасында төрле халыклар бар, әмма күбесе — Кавказлыларга охшаган. Әсирләрне бер читкә илтеп туктаталар һәм арадан бер парны аерып, яшь сугышчылар алдына бастыралар, муеннарыннан элмәкне чишәләр. Әсирләрнең берсе шактый өлкән яшьтә, икенчесе яшь ир. Яшь сугышчылар, кайсы кызганып, кайсы кызыксынып, әсирләргә текәлә. Менә хәрби казаклардан берәү әсирләргә нидер әйтә һәм алар кыр буйлап йөгерә башлыйлар. Яшь сугышчылар арасында көлешү, сызгыру башлана.**

Меңбашы. Йә, кайсыгыз тәвәккәлләп башлый?

**Көлешү шундук тына.**

Әллә барыгыз да куян йөрәклләрме?! Кызганмагыз! Монда китерелгән тас колларның барысы да, кемнеңдер якын туганын яисә атасын-анасын мәкер белән үтереп, качарга маташкан кансыз мөртәтләр! Караклар һәм көчләүчеләр! Үзегез яхшы беләсез — әсир төшкән дошманны бездә үтерү гадәте юк! Болар — үз язмышларын үзләре хәл иткән имгәкләр!

Кобогыл *(уң кулын югары күтәрә).* Миңа рөхсәт ит, меңбашы!

Меңбашы *(елмая).* Ә, Җантимер мәрхүмнең төпчек улы Кобогыл! Рәхим ит — рөхсәтемне бирәм! Кул артың җиңел булсын! *(Шактый ерак китеп өлгергән тас колларга таба кулын изи: әсирләр икесе ике якка йөгерә.)*

**Кобогыл сафтан атылып килеп чыга һәм ике качкынны ян-якларында калдырып, уртадан чабып китә, әмма аларга якынайганны көтмичә, садагыннан ук алып, өлкәнрәгенә төзәп атып җибәрә: ук тас колның аркасына барып кадала һәм ул йөзтүбән җиргә капланa. Яшь сугышчылар дәррәү «Kha!» дип кычкырып җибәрәләр. Кобогыл шул ук секундта әсирләрнең икенчесен куа китә һәм кылычы белән аның башын кыеп төшерә. Саф дәррәү «Ah!» итә. Меңбашының сүзен көтәләр. Читтә торган тас колларның кайберләре, җиргә тезләнеп, догаларын укына башлыйлар. Кобогыл ул арада борылып кайтып житә.**

Кемдер. Таштан яралгандыр бу Кобогыл!

Меңбашы *(кырыс).* Хуп! Егет солтаны икәнсең! Ләкин күнекмәне төгәл үтәмәдең, Кобогыл! Унбашы!

**Кобогыл беркетелгән унлыкның түрәсе, сафтан чыгып, меңбашы янына килә.**

Унбашы. Боер, түрәм!

Меңбашы. Тәвәккәллек күрсәткәне өчен Җантимер углы Кобогылга иярле ат бүләк ит һәм тәртипне бозган өчен, күнекмәләр беткәч, ун таяк суктыр!

**Кобогыл елмаеп урынына баса. Сафлар каршына тагын бер пар тас колны китереп бастыралар: колларны бүлеп торучы казак, муеннарыннан элмәкне чишеп, качарга куша. Тас колларның берсе шундук йөгерә башлый, ә икенчесе, урыныннан кымшанмыйча, горур рәвештә кулларын күкрәгенә чалыштырып басып кала. Тәртип саклаучы казак аңа йөгерергә ишарә ясый, әмма таза гәүдәле тас кол аңа мыскыллы караш кына ташлый. Яшь сугышчылар арасында җанлы сөйләшү башлана: кемнәрдер гаҗәпләнә, кемнәрдер тас колга сокланып карыйлар.**

Меңбашы *(янында торган унбашына).* Боер!

Унбашы *(үзенең унлыгына карап).* Кәмал би углы Җанбай! Синең чират!

**Бераз югалып калган Җанбай бер мизгелгә нишләргә белми тора һәм, атын алга сикертеп, йөгереп качкан тас кол артыннан ташлана: Кобогылдан калышмаска теләпме, садагыннан ук алып, ерактан ук атып җибәрә, әмма тидерә алмый. Тас кол да хәйләкәррәк булып чыга: ул, төзәргә комачаулар өчен, төрле якка ташланып йөгерә. Сафлар арасында көлеш башлана, сызгыралар. Җанбай тагын ата, әмма бу юлы да тидерә алмый. Ниһаять, өченче ук тас колны аяктан ега, тик үтерә алмый, ул укны тартып алып ыргытырга маташа. Җанбай, йоланы онытып һәм гарьләгеннән, тагын бер мәртәбә атмакчы була.**

Унбашы. Җанбай! Ул — каны белән үзен аклады!

**Җанбай, исенә килеп, угын садагына сала һәм кылычын кынысыннан алып, сафлар каршында горур басып торган яшь тас кол янына ташлана: унбашы да, меңбашы да аны туктатып өлгермиләр, ул ат өстендә кызу чабып килгән уңайга кылычын, баш өстендә айкап, тораташ кебек кымшанмый басып торган тас колның муен тирәсенә селти. Шулвакыт могҗиза булган кебек, тас кол кинәт җиргә чүгә һәм исән-имин кабат торып баса. Бу хәл шулкадәр күз ияртмәслек тиз була ки, хәтта яшь сугышчылар үз күзләренә ышанмый торалар. Ачуы кызган Җанбай ул арада атын кабат борып, тас колга ташлана һәм тагын кылычы белән селтәнә: бу юлы тас кол чүгеп маташмый, бер якка кинәт янтаеп кына кала. Сафтагылар ирексездән тас колны хуплап, «Kha-a!» — дип кычкырып җибәрәләр. Җанбай өченче мәртәбә атын кол ягына бора. Кобогыл колны хуплап көлеп җибәрә.**

Кобогыл *(кычкырып).* Сүзем бар, меңбашы!

Меңбашы. Шым бул, Кәмал углы!

**Җанбай атын шып туктата.**

Меңбашы *(Кобогылга).* Сүзеңне әйт, Җантимер углы Кобогыл!

Кобогыл *(алга чыга).* Ата-бабаларыбыз йоласы буенча, маңгайга-маңгай очрашкан дошман батырлык күрсәтсә, сугышчы аны ярлыкалый ала. Мин хаклымы, меңбашы?

Меңбашы. Сүзем юк, син хаклы, Кобогыл!

Кобогыл. Рәхмәт, меңбашы! Тагын бер соравым бар: әгәр дә сугышчы дошманын шул чакта ярлыкарга теләмәсә, аның хатасын иптәше төзәтергә тиеш, шулаймы, меңбашы?

Меңбашы. Бусы да дөрес, Кобогыл!

Кобогыл. Ишеттегезме барыгыз да? *(Иптәшләренә карап чыга.)* Меңбашы үзе минем сүзләрне дөресләде! Димәк, шушы горур тас колны ярлыкарга минем дә хакым бар! Олуг акыл меңбашы! Кәмал углы Киң Җанбай ярлыкарга теләмәгән тас колны минем карамакка тапшыргыл! Сүзем бетте!

**Мәйданда тынлык урнаша.**

Җанбай *(гарьләнеп.)* Ә мин аны ярлыкарга теләмим!

Кобогыл *(елмаеп)*. Син бар түшәмеңне күрсәттең инде, Кин Җанбай дустым!

Меңбашы *(кулын күтәреп, тын кайырга куша)*. Син ярлыкаган тас кол кабат җинаятьтә тотылса, синең үз башың киселәчәген беләсеңме, Җантимер углы тәвәккәл Кобогыл?

Кобогыл. Беләм, меңбашы!

Меңбашы. Ризалыгымны алдың, Кобогыл!

Кобогыл *(шатланып)*. Миңа дигән бүләк атны шушы тас колга бирче, унбашы!

Унбашы. Ә сиңа — ун таяк, киң Җанбай!

**23. Сарай каласы артында болын. Көн.**

**Киң болынлыкта Сабантуй: кайда да ераклардан килгән түрәләрнең ефәк чатырлары, учаклар. Хан чатыры нәкъ уртада биегрәк урында корылган. Сабантуй агалары төрле урыннарда ярышлар, көрәшләр, ат чабышлары уздыралар. Яшь кыз-кыркыннар егетләрдән аерым җирдә көянтә-чиләк белән йөгерешәләр, кашыкка йомырка салып узышалар. Кайбер кыюрак кызлар һәм егет-җилкенчәкләр, өлкәннәрнең сабантуй мәзәкләре белән мавыгып игътибар итмәүләреннән файдаланып, тиз-тиз очрашып алалар, вәгъдәләр бирешәләр.**

Җанбай. Айтулы! Күпме чибәрләнергә була — җитәр, дөнья гүзәллеген бер үзеңә җыйдың, тукта инде!

Айтулы. Бер-ике елдан күрерсез әле! Нәмә кирәк, Киң Җанбай? *(Көлә.)*

Җанбай. Егерме тотам толымыңа кул салучылар бар, имеш, яклаучы кирәк булса, миңа дәш, сылу!

Айтулы *(көлә)*. Мин дә синең киң җилкәңә авыр кулларын куючылар табылган, дип ишеттем, Киң Җанбай! Үзеңә ярдәм кирәккәндә кемгә таянырсың?

Тас кол *(алар янына килә)*. Лачын юкта ябалак мәйдан тотамы, асыл кыз Айтулы?

Айтулы *(куркып Җанбайга елыша)*. Бу нинди кап-кара гарәп?!

Җанбай. Менә — минем ярдәмгә мохтаҗ чагың да табылды, сылуым! *(Кочмакчы була.)* Курыкма: бу — Кобогыл үлемнән коткарып калган тас кол гына! Күз алдыбыздан югал, гарәп!

Тас кол *(елмая)*. Тел бер, колак — ике, Җанбай би! Әйдә, тагын бер мәртәбә кырга чыгып, син кылычлы, мин коры кул килеш алышабыз?

Айтулы *(Җанбай яныннан читкә тайпыла)*. Кобогылның җан сакчысы икәнсең, егет! Әйтче, үткен егет: карадан кара ни кара?

Тас кол. Сабыйлар табышмагы, Айтулы атлы сылу! Карадан кара ни икәнен күрәсең килсә — яныңа борылып кара!

Айтулы *(Җанбай ягына борылып карый һәм кычкырып көлә)*. Йомышчысының акыл савытын чамаладым, хуҗасының чүлмәге тулымы икән?

Тас кол. Тулы гына түгел — чүлмәге астында ут дөрли, сылу!

Айтулы *(Җанбайга карап ала)*. Дөрләсен, гарәп егете! Мин дә утын өстәрмен! Учакка салкын су сибәргә теләүчеләр бар — шуларны онытмасын!

Тас кол *(көлә)*. Җавабың көмеш, үзең — алтын, Айтулы атлы сылу! Бүген кич Тимер Казыкка берәүнең атын бәйләгәнен күрсәң — курыкма: дөрләп янган учак сүнмәгән икән диярсең! Калганы — үз ихтыярыңда. *(Айтулыга күз кыса һәм чүрәкәй булып кычкырып китә.)*

Җанбай. Тимер Казыкның әлегә хуҗасы юк — һәркемгә уртак йолдыз! Димәк — аңа буе җиткән һәркем атын бәйләп куя ала, гарәп! *(Китә.)*

**24. Сабантуйның бер чите. Көн.**

**Яшь кыз-кыркыннар әбәкле уйныйлар, көлешәләр, тулганалар. Алар янына Айтулы килә. Кызлар аны сырып алалар: «Кем ул — синең янга килгән кара гарәп?!» «Ничек курыкмадың шул күмер кебек кара адәмнән?» һ. б.**

Айтулы *(көлә)*. Күпне белмәгез әле — тиз картаерсыз!

Бер кыз. Ә майлы күз Киң Җанбай нишләп синең яннан ачы капкандай йөзен чытып китте, Айтулы?

Айтулы. Татлы хөрмә дип, тешләп алмакчы иде, җимеш дигәне кара гарәп булып чыкты — шуңа йөзе чытылгандыр, кызлар!

**Көлешәләр.**

Икенче кыз. Өр-яңа җыр чыгаргансың, диләр, Айтулы апа, шуны җырлап күрсәтче?

Айтулы *(тирә-ягына карана)*. Серемне читләргә тишмәсәгез генә, кызлар! Синең кебек бер юләр кызый турында ул җыр, аппагым! *(Уртага утырып җырлый.)*

**Җыр булачак.**

Бер кыз. Киң Җанбайның нинди ачы йотканын аңладым хәзер! Җан дусты каптырган икән! Карагыз, кызлар: Айтулының ике бит алмасы ут яна! *(Көлешәләр.)*

**25. Сабантуй кырының икенче ягы. Көн.**

**Яшь егетләрне Кобогыл нидер сөйләп көлдерә. Киң Җанбай килә.**

Җанбай. Кобогыл дусның мәзәкләре бетмәс, егетләр: форсаттан файдаланып калыйк!

Егетләр. Нәрсә бар? Нинди форсат?

Җанбай. Кобогылның үзеннән сорагыз!

Кобогыл. Җанбай дуска һәрвакыттагыча мәйдан җитми, егетләр! Даучан кеше! *(Елмая.)* Бил алышасың килсә — әнә көрәш мәйданы, тел алышасың килсә — әнә чичән мәйданы!

Җанбай. Боргаланма, Кобогыл дус! Сүз минем хакта бармый — бу юлы үзәктә син үзең! Күрәм: егетләр әлегә берни дә белми икән. Сез — Туксан башлы Урданың туксан углы. Күпләрегез — сабантуйга бик алыстан килгән. Шуңа күрә — Кобогылны

бик белеп тә бетермисездер. Дустым миңа күзләрен алартмасын — үзе каршында үзен мактыйм: ятимнәргә — яр, аты юкка — ат, сусаганга — су, адашканга — юл, ялгызга — ясак, җәяүгә — таяк ул.

Е г е т л ә р. Беләбез! Күрдек!

Ж а н б а й. Боларын белсәгез, калганын да белеп китегез — ул сезгә көтүче булырга чамалый!

Е г е т л ә р. Аңлашылмады, Жанбай! Без — сарык түгел, безгә көтүче кирәкми!

Ж а н б а й. Аңлатам: туксан башлы Урдага кем хуҗа? Туктамыш хан хуҗа! Безнең аталарыбыз — гаяр атлар кебек булса, без аларның тайлары гына ич? Тайларга да көтүче кирәктер? Барып җиттеме, егетләр?

Е г е т л ә р. Хак сүзме бу, Кобогыл?

К о б о г ы л *(елмая)*. Киң Җанбайның һәр сүзендә ике төрле тәм булыр: берсе ачы, берсе — төче! Әмма төп сүзе — хак. Барыгыз да беләсез, борынгыдан килгән бер матур гореф бар: кем алышта бөтенесен җиңеп чыга — шул аларга түрә була! Ризамы сез шуңа?

Е г е т л ә р. Дөрес, бар андый гадәт! Уең буш түгел! Тик ант итештән булсын!

**Ярым шаярып, ант итәләр.**

К о б о г ы л. Көрәшеп барың мин ексам, мин — барыңа баш! Сүзеңдә тормасаң — барың җир упсын!

Е г е т л ә р. Көрәшеп беребез сине екса, ул — сиңа баш! Сүзеңдә тормасаң — сине җир упсын, Кобогыл!

К о б о г ы л. Килештек! Озын таяк табыгыз! *(Кемдер озын колга китерә. Кобогыл кушагын (билбавын) чишеп, ту (байрак) итеп, колга очына күтәрә һәм җиргә кадап куя)*. Бисмилла әйтеп, башладыкмы, егетләр? Кем казый була?

Ж а н б а й. Минем синең белән бил алышасым юк, Кобогыл, егетләр кире какмаса — мин казый булам.

Е г е т л ә р. Киң Җанбайны яхшы беләбез! Без — риза!

Ж а н б а й *(ту янына баса)*. Хәрәмләшү — язык! *(Каранып.)* Дөрмән би углы Урман би!

**Егетләр арасыннан чандыр гәүдәле бер яшүсмер чыга: Кобогыл аны бер селтәүдә сыртына сала.**

Е г е т л ә р. Kha!

К о б о г ы л. Сал туныңны, Урман би — минем тәхет нигезенең беренче ташы булыр! *(Егетләр көлешәләр: Урман би ос киемен салып бирә. Кобогыл аны ту колгасы янына ташлый.)*

Ж а н б а й. Бу — гадел эш! Чакмагыш би углы Хөрмәт би!

**Егетләр арасыннан икенче яшүсмер чыга һәм көрәш башлый.**

**26. Шунда ук. Көн кичкә авышкан.**

**Ту колгасы янында биек итеп кием өелгән: Кобогыл егетләрнең барысын да җиңеп чыккан, димәк.**

К о б о г ы л *(кием өеме өстенә менеп утыра)*. Туктамыш хан тәхетенә мендем! Бу — гадел эшме, Киң Җанбай казый? Җавабың ошаса — баш вәзирем итәчәкмен үзеңне!

Ж а н б а й. Гаделме, түгелме — Туктамыш хан үзе әйтер, Кобогыл! Әнә — үзе килеп ята монда.

**Яшүсмерләр көрәшкән җиргә яраннары, хан сакчылары белән уратып алынган Туктамыш хан якынлаша: аны «таныш булмаган ту» кызыксындырган.**

К о б о г ы л *(вассалларына)*. Икс якка тезелеп, каршыма утырыгыз! Туктамыш хан булса да, алдында баш имәгез. Алдан үзе безгә сәлам бирмәсә, башлап сәлам бирмәгез! Мин әйттем!

**Туктамыш хан болар янына килеп җитә һәм берәү дә каршында иелгенеп сәлам бирмәгәч, аптырап туктый.**

Т у к т а м ы ш. Бу ни хәл?! Ханыгызны танымыйсызмы әллә? Кайсы ыру үсмешләре сез? Нишләп утырасыз монда?!

К о б о г ы л. Таныйбыз, Туктамыш хан! Башта — син өлкән, аякта чыгарбыз без өлкән! Шөгылебез — әлегә саескан бутәкәсе санап утыру!

Т у к т а м ы ш. Итагатьсезлегеңне аңлат, калтак бала!

К о б о г ы л. Итагатьсезлек кемдә — күрербез, ханиям. Синең каршыда туксан башлы Урданың туксан түрәсенең углы утыра. Шушы туксан үсмешнең яшен санап чыксам, бездән дә өлкән кеше табылмас монда. Шулай булгач, өлкәнне өлкән итә белмәгән кем була, ханиям? Син буласың түгелме?

**Хан яраннары яшереп кенә елмаешалар.**

Т у к т а м ы ш *(тирә-ягына карана һәм елмаешуларны күреп, Кобогылның сүзләрен уенга ала)*. Яхшы, синеңчә булсын, жор егет... Атың кем һәм үзең кем?

К о б о г ы л. Атым — синең утарыңнан бүләк ителгән айгыр иде: миңа аны сугыш уеннарында меңбашы, тәвәккәллек эшләгәнем өчен, ганимәт итеп бирде. Мин аны ике аяклы ганимәтемә тапшырдым. Үзем — Җантимер углы Кобогыл, утырган урыным — үзем төзегән тәхетем: син килер алдыннан гына мине, туксан башлы Урданың туксан түрә углы, гадел көрәштә барын җиңгән өчен, үзләренең ханы итеп күтәрделәр! Артымда — кушагымнан ясалган ту булыр!

Т у к т а м ы ш *(ачуланырга да, кичерергә дә белми аптырабрак тора һәм кычкырып көлеп җибәрә: бутәннәр аңа кушылалар)*. Ниндидер бер хикмәт бар бу балада!.. *(Кобогылга.)* Тәвәккәллегең турында ишеттек, Кобогыл! Авызыңнан алты хат очырганыңны да беләбез. Яугир орышта сынала: берике елдан сөйләшербез!

К о б о г ы л. Хак әйттең, ханиям: җилкәңдәге туныңа яурыным таман түгел әлегә! *(Күкрәгенә кулын куеп, ханга баш иеп кала.)*

**Туктамыш хан яраннары белән көлә-көлә китеп бара.**

Кобогыл *(хан белән тел көрәштерүеннән бик канәгать).* Беренче фәрманымны тыңла, туксан угыл: иртәгә Айдалага сугыш уеннарына китәбез! Әзерлекләр: иярле ат, көбә күлмәк белән турка, утызар уклы садак белән җәя, кылыч һәм калкан! Ә хәзер... *(Колганы сындырып, кушагын ала.)* Үз туннарыгызны сайлап алыгыз!

**27. Сабантуй мәйданының бер кырые. Кич.**

**Кечерәк чатыр янына ике җайдак килеп туктый: Кобогыл белән аның тас колы. Гарәп чүрәкәй булып кычкыра. Чатыр артында түгәрәк ай эленеп тора.**

Кобогыл *(чатыр кырындагы казыкка бәйләнгән атны күрә).* Тын бул, гарәп! Кемдер, бездән алда килеп, Тимер Казыкка аргамагын бәйләп өлгергән!

Тас кол *(ат янына якынлашып).* Киң Җанбай дустыңның аты!

Айтулы *(чатырдан чыга; кулында кечкенә хәнҗәр).* Кем бар?

Кобогыл. Чатырыңда кемне кунак итәсең, ике сарылы Айтулы?!

Айтулы *(Кобогылны таный).* Мин кемне кунак итмәм, Кобогыл! Канатларым бәйләнмәгән, күңелем — ирекле кош! Ә син нәрсә эзләп килдең? Әллә — адашып йөрисеңме? Юл тапмасаң, хәзер шәм алып чыгып бирәм! *(Әкрен генә көлә.)*

Кобогыл. Шәмең кирәкми миңа, сылу кыз! Үлән арасына төшеп югалган угымны, болытлар арасына кереп качкан лачынымны һәм далада адашкан чәчәкне эзлим мин!

Айтулы. Угыңны — үләннән, лачыныңны — болыттан, дала чәчәген — даладан сора, батыр егет! Мондагы чәчкәләр бөредә генә әле, иртәрәк килгәнсең!

Кобогыл. Җавабыңа караганда — бер чәчәк бөредән узганга охшый, Айтулы! Берәрсе, өзеп, түшенә кадамаган булса инде — аты казыкка бәйләнгән!

Айтулы *(җитдиләнеп).* Нинди ат?! *(Тас колны күрә.)* Чүл гарәбең ич, Кобогыл, — йөзен кара төннән аерып булмый!

Кобогыл. Арырак күз сал, сылу кыз!

Айтулы *(казыкка бәйләнгән атка якынрак бара).* Кем аты бу?

Тас кол. Киң Җанбай аты ич, шомырт күзле гүзәл кыз. Телең ике япле, ахрысы!

Айтулы *(кинәт хәнҗәрен чыгарып гарәп өстенә бара).* Авызыңны үлчәп ач, чүл гарәбе! Мин — хуҗаң түгел, кызганып тормам!

Тас кол *(көлеп куя һәм күз ачып йомган арада Җанбай атын, тезгенен өзеп, куып җибәрә).* Киң Җанбай дустыңның хәйләсе икән бу, Кобогыл! Чатырны тикшермәсәң дә була: мондый сылуның теле ике япьле булмый! *(Казыкта өзелеп калган тезгеннең бер өлешен кисеп, кесәсенә тыга.)*

Кобогыл. Ышандырдың, гарәп дустым! *(Кинәт Айтулыны, бер кулы белән биленнән кочып, ияренә күтәреп ала һәм иреннәреннән үбә.)*

**Айтулы югалып калмый: хәнҗәр очы белән Кобогылның бармагын яралый.**

Кобогыл *(көлеп, канлы бармагын Айтулының иренәнә терәп ала һәм, артыннан ук авызына кабып, канын суыра).* Рәхмәт, сылу кыз: мин эшлисене син үтәдең — барыбер вәгъдә анты эчәсе идек! Үз бармагыңа да чәнчеп, иренемә куй!

Айтулы *(Кобогылның кулыннан ычкынып, җиргә сикереп төшә).* Гарәбеңә рәхмәт әйт, Кобогыл! Аның белән телләшү аркасында гына яныма якын килә алдың! Яңадан рөхсәтсез чатырым тирәсендә күренсәң — үзеңә үпкәлә! *(Чатырга юнәлә.)*

Кобогыл. Кереп китми тор, дала чибәре: димәк, аңлавымча, кайчан да булса рөхсәт итәчәксең? Озак көтәсеме?

Айтулы. Кырык тотамлы толымым белән киңәшеп карармын, ул ни әйтер бит!

Кобогыл. Кырык тотамлы? Егерме тотамлы, диләр ич синең чәч толымың!

Айтулы *(көлә).* Кырык тотамга житкәнен көтәргә туры килер, димәк.

Кобогыл. Көтәргә күп калмаган икән инде, алайса!

Айтулы *(керфекләрен җиргә чәнчеп).* Юкка өметләнәсең, батыр: егерме тотамын унөч яз үстердем! Калган егерме тотамы да шулай озак үссә, нишләрсең? *(Күзләрен күтәрә).*

Кобогыл. Бер-ике елдан да озаккарак сузылмаячак ул, сылу кыз! Минем кулга тизрәк керер өчен, син аны үзең тартып үстерәчәксең! Тик толымың өзеп чыгара күрмә! *(Көлеп, атын чаптырып китеп бара; тас кол аңа ияря.)*

**Айтулы алар күздән югалганчы карап тора һәм чатырына кереп китә. Бераздан чатыр тирәсенә, тирә-ягына карана-карана, Киң Җанбай килеп чыга: ачуына буылырга житешеп, казыкта киселгәннән калган тезген очын сүтеп ала һәм куенына яшерә.**

Җанбай *(Кобогыллар киткән якка карап, теш арасыннан).* Күрербез: кемнең өлеше өскә чыгар икән, Кобогыл! *(Караңгылыкка кереп югала.)*

**28. Айдала. Иртә.**

**Такыр далада Кобогылның оланнары чын сугыштагыча күнекмәләр ясыйлар: кылычлар белән сугышалар. Калканын кылыч астына куеп өлгермәгәннәрнең тәнен тимердән эшләнгән көбә күлмәкләр, терсәктез япмалары саклый. Шулай да ара-тирә вак-төяк җәрәхәт алып, кычкырып җибәргәлиләр.**
**Менә Дөрмән бинең улы Урман би һәм Кәмал би улы Җанбай би, пар туры килеп, сугышырга әзерләнәләр.**

Җанбай *(Урман би якынаюга аның астында үзенең атын танып ала).* Туктагыз! *(Уң кулын югары күтәрә.)* Гаделлек таләп итәм! Кобогыл, син безнең башчы: Дөрмән би улы Урман бинең түрәсен бир — аның астында минем югалган ат! Аның үз атының кабырга араларына карга оялар лык иде!

**Бәхәсләшүчеләрне уратып алалар.**

Урман *(агарынып).* Ялган бу!

Җанбай. Тезгененне күрсәт, Урман би!

Урман. Минем тезгендә синең ни эшең бар, Киң Җанбай?!

Кобогыл *(кырыс)*. Атының йөгәнен салдырып, Җанбайга күрсәтегез.

**Егетләрнең берсе шундук Урман бинең атыннан йөгәнен салдыра һәм Җанбайга ыргыта, ә үзе Урман бинең атына аркылы баса.**

Кобогыл. Йә, ни әйтерсең, Җанбай.

Җанбай. Ни әйтәмме? Менә күрәсезме: йөгән каешының эчке ягында — минем тамга? Бу гына бетмәде әле! Йөгән искереп, карала башлаган, ә тезгене яңа. Чөнки... Чөнки тезгене — минем кесәмдә! *(Куеныннан тезген очын алып күрсәтә.)* Күрдегезме, оланнар?

Кобогыл *(елмаеп)*. Кайда бәйләгән идең соң атыңны, Җанбай? Минем кесәгә түгелдер бит? *(Кесәсеннән тезгеннең тас колы кисеп алган өлешен алып, Җанбайга ыргыта.)* Киселгән җирдән ялгап карачы: туры килмиме?

Җанбай *(ирексездән очны очка куеп карый: туры килә)*. Берни аңламыйм мин, Кобогыл дус?

Кобогыл *(кырыс)*. Аңларга вакыт, Җанбай! *(Кинәт бүтәннәргә таба борыла.)* Атны урлаган карак — бер языклы булса, урлаткан — ике языклы! Бүтән чак булса, Урман бидән атны хуҗасына кайтарып бирдерер идек тә, ике араны гадел хәл итәргә Җанбайның үзенә калдырыр идек — теләсә, милкенә кул сузган каракны бергә-бер орышка чакырсын! Ләкин бу юлы — бөтенләй башка төрле очрак! Дөрмән би углы Урман бинең кырын эше — белүемчә, беренче генә түгел! Әйтегез: кайсыгызга нинди кырын эше билгеле?

Берәү. Сабантуй көнне син бездән җыйган киемнәр арасыннан Урман би минем яңа тунымны киеп китмәкче булган иде — караклыкмы бу, Кобогыл башчы?

Кобогыл. Караклык. Әмма без аны ул чакта гафу иттек, чөнки ыгы-зыгы арасында аның чынлап ялгышуы мөмкин иде. Тагын кемнең сүзе бар?

Икенче олан. Айдалада сугыш уеннарының берсендә Урман би минем садагымнан унике өр-яңа ук алып, үзенең иске укларын салып киткән иде! Караклыкмы бу, башчы Кобогыл?

Кобогыл. Караклык. Әмма без аны икенче юлы да кичердек: чөнки йола икенче мәртәбә дә кичерергә куша. Тагын нинди кырын эшен беләбез?

Өченче олан. Моннан ике тапкыр өч көн элек Дөрмән би углы Урман би минем җиз аеллы яңа йөгәнемне үзенең тузып чуклана башлаган иске йөгәненә алыштырмакчы иде, кулына сугып туктаттым. Караклыкмы бу, башчы Кобогыл?

Кобогыл. Караклык! Әмма без Урман бине өченче тапкырында да кичтек: чөнки йолабыз өч мәртәбә кичерергә куша. Инде Дөрмән би углы Урман би дүртенче мәртәбә караклыкта тотылды! Миннән нәрсә таләп итәсез?

Оланнар. Түрәсен бир, Кобогыл! Туксан авыз сүзнең төене шушы!

Кобогыл. Яхшы. Атыннан алып, кулларына җеп салыгыз!

Урман *(эшнең җитди якка китүен күреп, аты белән качмакчы була)*. Якын килмәгез! Миңа хан үзе генә түрәсен бирә ала!

**Әмма аңа качарга ирек бирмиләр: аттан сөйрәп төшереп, кулларын Җанбайның тезгене белән бәйлиләр. Җанбай аты табылуга шатланырга да, көенергә дә белми аптырый.**

Җанбай. Болай ярамый ич, Кобогыл!

Кобогыл *(салкын)*. Теләсә кем чатыры каршына илтеп бәйләмиләр атны, азагын алдан күрмәгәч! *(Урман бине тотып торучыларга.)* Әнә — түмгәк, шунда илтегез каракны! Чакмагыш би углы Әкмал би! Урман бине, түмгәккә салып, башын ора чап!

**Урман бине акырта-акырта җәза бирергә алып китәләр.**

**Җанбай, атына атланып, кала ягына чаба.**

**29. «Алтын Таш» хан сарае. Көн.**

**Туктамыш ханның зар кабул итү пулаты. Айбалта тоткан Дөрмән би хан янына Чакмагыш би углы Әкмал бине кертә.**

Дөрмән *(Әкмалне хан алдында төртеп ега һәм үзе бер тезенә төшеп, йөгенә)*. Гаделлек сорыйм, бөек ханиям!

Туктамыш. Сора, Дөрмән би.

Дөрмән. Шушы бәбчи йонлы бала, җәллад булып, минем углым Урман бинең башын ора чапкан! Канын кайтием мөртәтнең, ханиям?!

Туктамыш. Кем баласы син, кансыз?

Әкмал *(тора)*. Чакмагыш би углы Әкмал би, ханиям!

Туктамыш *(шаккатып)*. Чакмагыш би углы?! Ни өчен Дөрмән бинең углы Урман бинең башын ора чаптың, явыз бала?

Әкмал. Без, туксан түрә угыллары, башчыбыз Кобогылны тыңлыйбыз, ханиям. Дөрмән би углы Урман бинең түрәсен Кобогыл бирде. Калганын ул үзе әйтер! Ул — каршыңа килер өчен алгы якта әмеренне көтә.

Туктамыш. Керсен!

**Әкмал тиз генә алгы якка чыгып, Кобогылны ияртеп керә.**

Кобогыл *(бер тезенә төшеп, йөгенә)*. Боерың, бөек ханиям.

Туктамыш. Җантимер би углы Кобогыл! Атаң яхшы кеше иде! Ул — варислар тәрбияләүче аталык булды, ә син — агачыннан еракка тәгәрәгән кансыз бала булып үстеңме?! Әнә кара: азамат ир Дөрмән би, кайгысына тыела алмыйча, канлы күз яшьләре түгә! Аның углын ник чаптың?

Кобогыл *(торып баса)*. Синең хөкемеңә таянып, ханиям!

Туктамыш. Сөйләп бир!

Кобогыл. Идел белән Җаекта, Болгар белән Сарайда синең гадел хөкемең хакимлек итә, ханиям: карак дигән кара җан өч тапкыр урлашып, котылса, дүртенчесендә тотылса — аның башы чабыла. Дөрмән би-

нең углы Урман би өч тапкыр тотылды — гаебен кичтек, ханиям. Дүртенчесендә баш вәзирең Кәмал би углы Җанбай белән аргамагын урлап тотылды. Алла аны дөньяның бер җиренә буш калмасын дип кенә яраткан булган, күрәсең. Шуңа күрә без, синең гадел хөкемеңә таянып, аның башын ора чаптык! Кылуыбыз рас кылумы, ханиям?

Туктамыш *(Дөрмән бигә)*. Белеп сукалый бу. Моннан артык гаделлек эшли алмыйм сиңа, Дөрмән би... Хан сүзе — бер була! Китәргә мөмкин. Ә син, тәвәккәл баш Кобогыл, кал. *(Ишектән чыгып баручы Дөрмән бигә.)* Бер генә киңәш, Дөрмән би!

**Дөрмән би ишек төбендә туктый.**

Чакмагыш би углы Әкмал бигә рәнҗешең зурдыр: ике араны хәл итәр өчен аны бергәбер орышырга чакыра аласың! Тик бу чакта коралны ул сайлый — шуны онытма.

Дөрмән *(хан алдында йөгенә)*. Киңәшең өчен рәхмәт, ханиям: тик мин аннан файдалана алмам, ахры — картайдым. Минем өчен — бу да кара хөкем. Ә картаймыш көнемдә яклар кешем Урман би углым гына иде... *(Хан алдында баш иеп чыгып китә.)*

Туктамыш. Гаебең чиксез зур, Кобогыл! Хан хөкемен хан җәллады гына үти ала! Әмма атаң мәрхүм Җантимер би хакына бер юлга ярлыкалыйм сине.

**Кобогыл, күкрәгенә кулын куеп, рәхмәтен белдерә.**

Бик күптән күзәтәм мин сине, Җантимер углы... Бәлигъ булып, уеннан уймакка күчтең. Туксан яшьтәшең алдында, бәйге тотып, дан алдың. Орыш уеннарында, тәвәккәллек күрсәттең. Чын ирләр эшенә тотынырга вакыт сиңа: йөзбашы итәм үзеңне, Сараемда каласыңмы?

Кобогыл. Рәхмәт, ханиям. Йөзбашы ит, ләкин Сараеңа алырга ашыкма, зинһар. Башта җитди орышта сыныйсым килә үземне! Болгар җирен урыс ушкуйниклары талый: шулар белән алышырга рөхсәтеңне бир миңа, ханиям!

Туктамыш *(уйланып)*. Яхшы, Җантимер углы Кобогыл.

**30. Җантимер би йорты. Таң вакыты.**

**Кобогыл ерак юлга әзерләнә: кәбә күлмәген кия, коралланә. Тас колы аңа ярдәм итә. Сөт анасы керә һәм Кобогылга серле ишарәләр ясый.**

Кобогыл. Сиңа нәрсә, сөт анасы?

Сөт анасы. Гарәбең чыгып торсын — сүзем синең колагың өчен генә.

Кобогыл *(колга)*. Аннан шикләнмә, сөт анасы... Безнең колаклар уртак! Яхшы, синеңчә булсын. Ишеттеңме, гарәп дус?

**Гарәп егете берсүзсез чыгып китә.**

Сөт анасы *(пышылдауга күчә)*. Хәвефле юлга әзерләнәсең, Кобогыл! Арты нинди булыр — бер Хак Тәгалә белә.

Кобогыл. Күк күкрәмәс борын, ләхәүләңне укымачы, сөт анасы!

Сөт анасы. Ә син бүлдермичә генә тыңла! Җантимер бинең васыять әмерен җиткерәм мин сиңа. Кыргын чир башлангач, сезне алып җәйләүгә качар алдыннан үземә генә әйтеп калдырды: балаларымны күз карац кебек сакла, сөт анасы, диде, бигрәк тә — төпчек улым Кобогылны сакла! Мин әйтәсе серне бикәнә дә белдермә, үсеп җитеп, бәлигъ булган көнне Кобогылның үзенә генә әйтерсең: ул бала безнең хәләл төпчегебез түгел, ә Туктамыш хан Дөрмән биеннән башын чаптырган Котлыкыя бинең бердән-бер углы! Хан әмере белән ул баланың да башы чабылырга тиеш иде, мин аның бишегенә төпчегем Кобогылны салып, үзен итек куңычыма яшереп алып калдым. Шуңа күрә аңа Идегәй дигән ат куштым, чөнки үз атасы баласына ат кушарга өлгермәгән иде, диде... Чү-чү! Ни булды сиңа, балам?! *(Кинәт чайкалган Идегәйне тота.)*

Идегәй. Сүзләреңне нәрсә белән раслый аласың, сөт анасы?

Сөт анасы. Сезне имезгән сөтем белән, Идегәй! Котлыкыя би белән Җантимер би, мәңгелек җан дуслар булсалар да, җир белән күк аерылган кебек, икесе ике холыклылар иде. Җантимер йомшак күңелле, саф йөрәкле кеше иде — син бертуган абыйларым, дип йөргән сөт туганнарың да, ике тамчы су кебек, аңа охшап үстеләр, ә син — суйган да каплаган Котлыкыя би!

Идегәй. Яхшы, сөт анам! Беркемгә дә тишмә бу сереңне: вакыты җиткәч, үзем ачармын... *(Чыга.)*

**31. Кәмал би йорты. Таң вакыты.**

**Киң Җанбай Кобогыл белән юлга китәргә әзерләнә: хезмәтчесе ярдәм итә.**

Кәмал *(улы янына килеп керә.)* Орышка әзерләнеп беттеңме, углым Җанбай?

Җанбай. Әзерләнеп беттем, атам, хәвефле юлга чыгам — фатихаңны бир!

Кәмал *(улының колына чыгып китәргә ишарәли)*. Әзерләнеп беткән булсаң, фатихам шул: көбәңне сал, коралларыңны кире урыннарына элеп куй.

Җанбай. Бу ни дигән сүз, атам?

Кәмал. Бу — ошбу таңнан җан дустың Кобогыл белән юлларыгыз ике якка аерыла дигән сүз! Ул — сугыш чукмары, аның язмыш учагы — орыш кырлары. Син — тел остасы, сине язмышың — хан тәхете тирәсенә чакыра. Сәлам күшәп, кибәк төчкергән җыен әтрәк-әләмнәргә ияру сиңа төс түгел. Безнең нәсел буыннан-буынга ханнарның асыл киңәшчеләре булды. Минем картаймыш көннәрем якынлашты: ата-бабаңнар һөнәрен сиңа тапшырырга вакыт. Безне Туктамыш хан көтә!

Җанбай *(орышка бармый калу аны шатландыра, ләкин әтисе әйткән һөнәргә күче җитәрчәгенә дә ышанмый)*. Кеше көлдермәче, әти! Мин — Туктамыш ханның баш вәзире?! *(Көлә.)*

Кәмал. Беркайчан да көләргә ашыкма! Менә сиңа һөнәрең өчен иң беренче киңәшем. Беркем дә һәрнәрсәне белеп тумый! Чарланырсың. Атаң исән ич әле. Кем сиңа бүгеннән вәзирлек вазыйфасы тәкъдим итә? Мин сине, Туктамыш хан рөхсәте белән,

үземә кинәшче итеп алам. Ә чынында мин үзем сиңа киңәшләремне биреп торачакмын. Һәр эшнең үз җае була. Түрә булуның да үз сере бар. Ачкыч таба белергә генә кирәк. Берничәсен хәзер үк колагыңа киртеп куйи: үзеңнән югарыларны беркайчан да ачыктан-ачык җиңәргә тырышма. Авар якка терәү сал — беркем сизмәсен. Көтмәгән адым ясау — уңышның ачкычы! Синең хаҗәтең кешегә төшмәсен, бүтәннәрнең хаҗәте синдә булсын: шуңа күрә беркайчан да гозер белән яныңа килгәннәрнең теләген тулысынча канәгатьләндермә, юкса суы сыгылып беткән җимешкә охшап калырсың. Эчеңдәге — тышыңда булмасын: чын көчеңне белмәүләре яхшы — яратмасалар да хөрмәт итәрләр. Беркемгә дә көндәш булма: дошманың шундук кимчелекләреңне эзләп табачак. Һәр теләк тормышка ашмый — җаваплылыкны башкалар җилкәсенә күчертергә өйрән: үз җилкәң исән калыр. Һәр адымыңны алдан уйла һәм күңелеңдә мая сакла — әйтелеп бетмәгән фикер бөтенләй ачып салган фикердән көчлерәк! Сорамаган чакта акланма. Ярым-йорты эшеңне беркемгә дә күрсәтмә!

Җ а н б а й. Җитте-җитте, зат шәрифләре, башым әйләнә башлады!

К ә м а л. Әлегә — соңгысы: яңа кеше булуыңнан файдаланып кал! Баштарак кояшны айга бәйләп чабарга туры килер...

**32. «Алтын Таш» капкасы. Иртән.**

**Капка янына Туктамыш ханның баш вәзире Кәмал би яугир киемен сарай кешесе киеменә алмашкан углы Җанбай белән килеп туктый. Кәмал би Кече капканы кагарга үреләм дигәндә генә, эчке яктан барабан каккан, сорнай-быргы кычкырткан тавышлар яңгырый һәм Олы капка шар ачылып китә. Хан бистәсеннән баштанаяк коралланган җайдаклар йөзлеге чыга. Киң Җанбай, йөзбашы Идегәйнең күз карашы белән очрашкач, күзләрен түбән төшерә. Идегәйнең иреннәрендә аны кимсетүле елмаю чагыла. Кырыс чырайлы җайдаклар капка төбендә торучыларны тузанга күмеп үтеп китәләр.**

# 2 бүлек

**33. Идел буе тугайлыгы. Кичке як.**

**Идегәйнең җайдаклары чатырлар корып ял итәргә туктаган: учаклар өстендә ашлар пешә, атлар үлән утлап йөри.**
**Идегәй Идел дулкыннарына карап тирән уйга баткан.**

Т а с к о л *(хуҗасы янына килә)*. Беренче тапкыр җитди эшкә алынуы — куанычы култыгына сыймыйдыр түрәмнең, дисәм... Хуҗама нинди авыр уйлар тынгылык бирми? Нишләп мыегың чуалган? Әллә Сарайда калган егерме тотамлы толым, тышау булып аягыңа уралып, ерак сәфәреңә кузгалып китәргә ирек бирми торамы? Ике көн инде шушы тугайны саклыйбыз, ә урыс ушкуйниклары үзләре, Болгар җирләрен талап туйганнар, ахры, монда төшеп киләләр!

И д е г ә й *(кинәт башын күтәрә)*. Кем хәбәре, гарәп?!

Т а с к о л. Гарәп егете түгел мин, Кобогыл би! Мин — Кырым татары. Бу якларда якташларым күп минем. Шулар әйтте. Ушкуйниклар иртәгә кичкә монда булачаклар. Ике меңнән артык юлбасар.

И д е г ә й *(аңа сынап карый)*. Димәк, син бүген миннән качып китә ала идең, Кырым татары?

Т а с к о л *(көлә)*. Син мине үлемнән коткарган көнне үк качып китә ала идем, киң күңелле йөзбашы!

И д е г ә й. Нишләп качмадың?

Т а с к о л. Кырымга качып нишлим мин?!

И д е г ә й. Ә минем белән калып нишлисең?

Т а с к о л. Син Сарайга хуҗа булгач, мине ун кулың итәрсен, дип өметләнәм, Кобогыл би! *(Елмая.)*

И д е г ә й *(ирексездән тирә-ягына карап куя)*. Авызыңнан җил алсын, Кырым татары! Май кап, тимер йот! Каян килде башыңа андый... тузга язмаган уйлар?! Мин — гап-гади йөзбашы!

Т а с к о л. Ачуланма, Кобогыл би: мин синең чынында кем икәнлегеңне беләм. Син — Туктамыш хан җәзалап үтерткән Котлыкыя бинең углы Идегәй!

И д е г ә й *(аның авызын кулы белән каплый)*. Шым бул! Кемнән белдең?!

Т а с к о л. Сөт анаң белән сөйләшкәнегезне очраклы ишетеп калдым... Курыкма, Идегәй: шымчы да, җинаятьче дә түгел мин. Ишеткәннәрем, колагыма керүгә, синең үзеңнән башка беркемгә дә җитмәслек булып төпкә сеңделәр. *(Кызу-кызу сөйли.)* Без икебез дә Туктамыш ханга бурыч кайтарасы кешеләр! Ул синең атаңны да ора чаптырган, үзең дә тәкъдирең белән генә исән калгансың. Минем нәселем дә затлы ыру иде — Туктамыш хан аның тамырына балта чапты. Чөнки без Мамай ягында идек. Үземне кол иттеләр. Качмакчы идем — тотып алдылар. Шунда кемнедер яраладым — мена минем бөтен гаебем! Үч сәгате сукты! Хан сараенда Туктамышның җан сакчылары арасында минем бер-ике ышанычлы якташым бар: алар минем өчен утка-суга керергә әзерләр. Мине үлемнән алып калганыңны яхшы беләләр. Синең бер сүзең җитә миңа, Идегәй. Туктамыш ханның куян җаны бүген үк җәһәннәмгә олагачак!

И д е г ә й. Атың кем, Кырым егете?

Т а с к о л. Атым — Бәхтияр, атамның исеме — Нургадел би!

И д е г ә й. Әгәр дә мин сине Туктамышка тотып бирсәм, Нургадел би углы Бәхтияр?

Б ә х т и я р *(кырыс)*. Тотып бирмисен, Идегәй! Тотып бирсәң, минем башым чабылган сәгатьтә синең башың да җиргә тәгәрәячәк!

И д е г ә й. Чын йөземне Туктамышка ачасыңмы?

Б ә х т и я р *(ярсып)*. Мин — сатлыкҗан түгел, Идегәй! Якташларым минем өчен үч алачак!

И д е г ә й *(уйланып)*. Яхшы, Бәхтияр. Мин кешене ике кат сынамыйм: бер күрүдә үк ышандым мин сиңа. Ләкин Туктамыштан үч алуны әлегә онытып тор!

Б ә х т и я р. Бүтән унайлы чак булмавы бар, Идегәй!

И д е г ә й. Мин — хан канын коючы гади башкисәр түгел, Бәхтияр! Туктамышны бүген үтертсәк — без гап-гади җинаятьче булып калачакбыз! Һәм иң түбән җанлы әтрәк-әләмнәр дә безнең йөзебезгә төкерәчәк! Юк, Бәхтияр. Туктамыш ханны орыш кырында гына җиңәргә мөмкин.

Б ә х т и я р. Ничек итеп? Аның гаскәрендә хезмәт итепме?!

И д е г ә й. Тиз кулга эшлисе нәрсә түгел ул, Бәхтияр: мин әлегә — йөзбашы гына. Ләкин мин үземә ышанам: мәңгегә йөзбашы булып калмаячакмын мин. Гомеребез булса, күрерсең — берничә елдан Туктамыш хан мине уң кулы итәр! Туктамыш хан әлегә — илне бер учка туплarga тырышучы азамат ир һәм мин аңа бу изге эштә бөтен көчем белән ярдәмләшәчәкмен. Әмирләрне әйбәт беләм мин: бүген алар Туктамышка ышыкланалар, чөнки Мамайдан өркәләр. Мамайны җиңеп, илне үз кулына туплап бетерүгә, Туктамыш хан әмирләр белән сanашмый башлаячак. Табигате шундый! Менә кайчан мин әмирләрне үз ягыма аударачакмын.

Б ә х т и я р *(көлә)*. Әйтәм ич, син кайчан да булса Сарайга хуҗа булып керәсе кеше! Мине онытмассыңмы ул чакта, Идегәй?

И д е г ә й *(җитди)*. Башларыбыз сау булса, онытмам, гарәп егете. Сизгәнсеңдер, мин синең чын йөзеңне вакытлыча оныттым, син дә минем Идегәй икәнлегемне онытып тор! Ә хәзер җайдакларга әмеремне тапшыр: чатырым янына җыелсыннар. Урыс ушкуйниклары килеп җиткәндә бу тугайда гап-гади балыкчылардан башка беркем дә булмаска тиеш. Балык шулпасы белән буза эчереп, әйбәтләп сыйлыйк әле үзләрен!

Б ә х т и я р. Аңламадым, хуҗам?

И д е г ә й *(елмая)*. Ике меңнән артык дисең ич алар? Ә без — йөз җайдак кына. Кайчагында кораллы йөз җайдактан йөз балыкчы көчлерәк була!

**34. Сарай каласы урамы. Көн.**

**Киң урамга, Идегәйнең кораллы җайдаклары сагы астында, иксез-чиксез колонна булып, әсир ушкуйниклар килеп керә: алар барысы да бер-берсенә бау белән бәйләнгәннәр. Идегәй бер төркем атлы гаскәре белән алдан килә: янында җан сакчысы Бәхтияр. Әсирләр колоннасы артыннан ияргән йөзәрләгән атлы олауга ушкуйникларның Идел буе халыкларын талап җыйган байлыклары һәм кораллары төялгән. Колонна хан бистәсе ягына таба юнәлә. Урамга чыккан халык «Ура!» кычкыра, арада «Кобогылга дан!» — дип яр салган тавышлар да ишетелгәли. Айтулы да халык арасында. Идегәй аны күреп елмая.**

**35. Хан сарае. Иртән.**

**Киң Җанбай сарай алдында әтисе Кәмал би белән әкрен генә сөйләшеп йөри.**

К ә м а л. Кобогыл дустың, чынлап та, бик елгыр егет булып чыкты: китеп күләгәсе күмелеп өлгермәде — дан-шөһрәткә чумып кайтып та төште! Сиңа да хан күзе бизмәненә бирер нәрсә салырга вакыт. Хан иртәнге ашны тәмамлауга Диван утырышы башлана. Менә шунда үзеңне күрсәтеп калырга форсат табылыр, улым!

Җ а н б а й. Куй, әти! Утырышта нәрсә караласын да белмим мин!

К ә м а л *(башын чайкый)*. Шулай килеп чыгар, дип көткән идем мин! Диван утырышы булачагын кичә үк белдең ич! Нишләп нәрсәләр караласын сорашмадың?! Бүтәннәргә тел ачкычы табалмасаң, янында мин бар! Ике колагыңны да киереп тыңла: Кобогыл әсир иткән урыс ушкуйникларының язмышын хәл итәчәкбез бүген. Хан Диван киңәшчеләренә мөрәҗәгать итәр: кемдә нинди тәкъдим бар, диер? Менә шунда синең тәкъдимең үтәчәгенә шикләнмим.

Җ а н б а й. Минем тәкъдимем?! Ә мин ни әйтергә дә белмим, әти!

К ә м а л. Кем сиңа беләсең диде? Тәкъдим итәргә синең хакың да юк әлегә. Синең исемнән мин сөйләячәкмен. Ә син колагың белән карап, авызың белән тыңлап утырма! Игътибар ит: кемнәр ни сөйли, ничек сөйли, үзен ничегрәк тота!

Җ а н б а й. Ә син минем исемнән нәрсә тәкъдим итәргә уйлыйсың? Хан углың үзе сөйләсен дисә, нишләрмен? Шуңа соравым.

К ә м а л. Ниһаять, башына җитте! Мәскәүдә бүгенге көндә бөек кенәз Дмитрий утыра, ул тәхет ярлыгын Туктамыш хан кулыннан алмаган кеше. Солтан Морат биргән иде аңа ярлыкны. Шуңа күрә Дмитрий Туктамыш алдында борынын чөяргә маташа. Әсир төшкән ушкуйниклар — аның баскагын танырга теләмәгән Новгородтан чыккан башкисәрләр. Дмитрий инде ничә тапкыр ушкуйникларны тыйдым, минем гаебем юк, дип ялганлап ята. Туктамыш хан өчен җайлы форсат бу: ике мең башкисәре аның кулында. Синең исемнән Дмитрийга чакыру хаты язарга киңәш итәчәкмен: шулай итеп без ике куянның койрыгын берьюлы тотабыз — Туктамышка Дмитрийны үзенә чакыртып алырга яхшы сәбәп тә була, син дә аның алдында абруй казанып каласың! *(Сарайга кереп китәләр.)*

**36. Туктамыш ханның кабул итү пулаты. Иртән.**

**Пулатка Идегәйне кертәләр: ул хан алдында бер тезенә чүгеп йөгенә.**

Т у к т а м ы ш *(ачык йөз белән)*. Түр, түр, батыр! Без синнән бик канәгать! Сора, тартынма: батырлыгың өчен бездән ни үтенер иден?

И д е г ә й *(тыйнаклык белән)*. Кечкенә хезмәтемне шушылай олылау — үзе зур бүләк миңа, ханиям! Әмма шулай да бер үтенечем бар: миңа Айтулы атлы бер кызны туйлап хатынлыкка алырга рөхсәтеңне бир.

Т у к т а м ы ш *(мондый гади үтенечне көтмәгән: көлеп җибәрә)*. Кыз чибәрме соң? Нишләп без белмибез андый кызны?

И д е г ә й. Тома ятимә ул, ханиям. Багавыл кулында яши.

Т у к т а м ы ш. Яхшы, теләгеңә каршы килмим... меңбашы Кобогыл!

Идегәй. Ялгыш ишетелдеме колагыма, ханиям? Мин — синең гади йөзбашың.

Туктамыш. Колагың ялгыш ишетмәде, Кобогыл. Без сине шушы минутта меңбашы итеп билгеләдек! Һәм калабызның иң матур йортларыннан берсен бүләк итәбез. Туйга әзерлән: чыгымнарыңны хан казнасы каплар. Китәргә мөмкин, ары тотмыйм: Диван киңәше көтә мине. *(Тәхетеннән кузгала һәм, алдында түбәнчелек белән баш игән Идегәйгә карап тормыйча, ян ишектән чыгып китә.)*

**37. Идегәй йорты. Көн.**

**Идегәйнең Туктамыш хан бүләк иткән йортында зур учак яна: тышта кыш. Хуҗа орышка китәргә әзерләнә — җылы тунын киясе генә калган. Зур туйлап алган хатыны Айтулы борчулы.**

Айтулы. Туебыз узганга өч көн дә юк — мине ташлап орышка китәсең! Һәр ягын да ныклап уйладыңмы, Кобогыл? Йортыңны кем саклар син әйләнеп кайтканчы? Суык тешләсә, яшь бичәңне кем җылытыр?

Идегәй. Мин — хан ихтыяры кешесе, йөрәк маем Айтулы. Карлуклар, Шаһ Тимергә ант итәргә теләп, ханга каршы баш күтәргән — шуларны бастырырга мине җибәрә. Мин әйләнеп кайтканчы йортыбызны кем саклармы? *(Елмая.)* Киләсе булмаса да, ишегебез кыршаулы: йокларга ятканда кыршавыннан кырык тотамлы толымың белән бәйләп куярсың, күз нурым! Сине кем җылытырмы? Учагың сүнсә — толымыңны горур күтәреп йөрткән акыл чүлмәгең бар — шул җылытыр, фәрештәм! Болары — мин әйтәсенең чәчәге генә. Мин урап кайтканчы баһадирдай ул табып куй син миңа, сылуым! Менә монсы — җимешем була. Әгәр дә ерактa башым салсам...

Айтулы. Әйтмә андый сүзне! *(Кобогылны иреннәреннән үбә.)* Менге атың арысландай таза — мин җинел сөякле, ал мине үзең белән!

Идегәй *(хатынын йомшак кына читкә этәрә)*. Аякларыма тышау булма, Айтулы! Син җиңел сөякле дә — мең җайдагымның сүзе авыр! Шуны белеп кал: ул тапсаң, әйләнеп кайтсам-кайтмасам да — аты Нурадын булыр! *(Җылы тунын кия.)*

**38. Кәмал би йорты. Иртә.**

**Кәмал белән Җанбай хан сараена барырга җыеналар.**

Кәмал. Кобогыл эзеннән җибәргән дәрвишебез бик вакытында кайтып җитте: хан безне киңәшкә чакыра. Дәрвиш алып кайткан яңалыкны хан үзе дә, якыннары да белми әлегә: меңбашы Кобогыл, карлукларны буйсындырып, күрше олысларны да безгә тугрылыклы булырга кабат ант иттергән. Ә бу хәбәрне хан күптән дүрт күз белән көтә! Киңәш барганда мине игътибар белән тыңла! Кирәк чакта файдаланырсың. Кара аны: яңалыкны белүеңне ханга сиздертмә! Әз генә каушасаң да зыян итмәс: ханны олылау булып кына күренә ул. Әмма үз сүзеңдә нык тор!

Җанбай. Кичер, атам, минем башта болар түгел! Кобогыл исән! Кобогыл өенә әйләнеп кайта! Карлуклар арасында башын җуяр, дип өметләнгән идем мин! Ә ул — җиңеп, дан-шөһрәткә күмелеп кайта! Миңа Айтулы кирәк, атам!

Кәмал. Ахмак! Син хан тәхете янында урын яула! Айтулы турында кытыгы качканчы уйларга иде! Туктамышның уенда — Мамай әмир. Алдан күрә бел: Кобогылны ул, кайтып керүгә, Мамайга каршы җибәрәчәк! Чөнки мин көн саен шуны тукыйм! Һе! Кобогыл исән! Бүген аның башы исән булса, иртәгә мәтәлер! Бәйрәмеңне көтеп ала бел!

**39. «Алтын Таш» хан сарае. Иртә.**

**Туктамыш хан тәхет палатасында вәзирләре белән киңәш кора.**

Туктамыш. Кара дошманыбыз Мамай, бөтен гаскәрен җыеп, Мәскәүгә каршы яу чыккан. Литвалы Җаһайлу да аңа кушылмакчы, имеш. Мәскәү кенәзе Дмитрий, сүздә безне таныса да, чынында Мамай белән генә эш итә: аннан курка, аңа ясак түли. Күрәсең — Мамайның нәфсесе Мәскәү кенәзенең юмартлыгыннан артыграк. Юкса яу чапмас иде. Ышанычлы кешеләребез хәбәр иткәнчә, Дмитрий гадәтенчә Ярыслауга качар, дип көткәнебез расланмады — Мамайны каршы алырга унбиш төмән гаскәр туплаган, имеш! Колак ишетмәгән, күз күрмәгән хәл! Мәскәү айлап-еллап түгел, көнләп-сәгатьләп куәтләнә бара. Мамайны куып, Идел-Йортыбызны бер кулга туплыйк, дидек, олыс түрәләрен күндереп булмады! Шуңа күрә бүген сандал белән чүкеч арасында калып барабыз! Мамайга арттан китереп орсак, Дмитрий тегермәненә су коябыз булып чыга. Ике йөзле Дмитрийга янасак — Мамай да ота, безнең өскә ташланырга ындыр артыбызда җай гына көтеп яткан Шаһ Тимергә дә форсат ачыла! Кем акыллы киңәш бирер? Мин әйттем!

**Палатада тынлык урнаша.**

Туктамыш. Баш вәзирем Кәмал би! Синең сүз.

Кәмал *(күкрәгенә кул кушырып, баш ия)*. Баш өсте, ханиям! Минем, әлбәттә, баш вәзир буларак, үз тәкъдимем әзер: без, ханиям, бүген орышка кушылсак, нәтиҗәсе бик томанлы. Беренчедән, меңбашы Кобогылның исе-коны юк: тун киеп киткән иде, инде җәй үтеп, кылычын сөйрәп икенче кыш килә — яңа тун әзерләргә вакыт, ә без һаман да ачык кына белмибез: Сыр-Дәрья буе олыслары ханыбызның ярлыгын таныйлармы, юкмы? Димәк, көчле гаскәр җыя алмыйбыз әлегә. Икенчедән, орышка кушылган очракта — кем ягын тотарга? Мин — орыштан читтә торырга кирәк, дим.

Туктамыш. Сүзең беттеме?

Кәмал *(елмая)*. Бетмәде, ханиям: үзең беләсең, минем хәзер бер акыллы киңәшчем бар. Углым Җанбай би минем фикергә кушыла, ләкин ул миңа чиннарның бер хикмәтле мәкален китерде: арыслан белән юлбарыс, үгез итен бүлешә алмыйча, көч алы-

шканда маймыл тау башыннан карап тора, имеш. Һәм ике ерткыч бер-берсен үтергәч, түшкәне үзенә ала! Үзебезне маймыл белән чагыштырып кимсеткәнгә киңәшчемнең авызына сугарга туры килде, әлбәттә! *(Көлешәләр.)* Шулай да... нидер бар бит монда, ханиям. Маймыл кебек хәйлә белән эш итсәк, Мамай белән Дмитрий бер-берсен кара канга батырганын көтеп торырга да, икесенең дә якаларыннан алырга! Углымның киңәшен мин үзем шулай аңладым, ханиям.

Туктамыш *(елмая)*. Углың үзеңнән гакыллырак, ахры, Кәмал би! Үзең урынына баш вәзирем ясап куюым бар! *(Көлешәләр.)* Ләкин аның киңәшендә сүз ике ерткыч хакында гына бара, ә өченчесе белән нишлибез? Шаһ Тимер белән? Киңәшчең монламы, Кәмал би? Безгә күренсен?

Җанбай *(торып баса һәм кулларын кушырып, баш ия: ул дулкынлануыннан тирләп чыккан — беренче тапкыр үз авызыннан сүз әйтүе)*. Монда, ханиям...

Туктамыш. Йә: Шаһ Тимерне нишләтергә киңәш итәсең, Җанбай би? Тыңлыйбыз сине.

Җанбай *(бераз тотлыгып)*. Шаһ Тимернең бездә кайгысы юктыр, дип уйлыйм мин, ханиям.

Туктамыш. Менә ничек? Дәлилләрең?

Җанбай. Меңбашы Кобогыл — аның күршесендә генә: әгәр дә Сәмәрканд әмире безгә каршы астыртын нидер әзерләп ятса, Кобогыл шундук сиңа атчабарын җибәргән булыр иде, ханиям. Сыр-Дәрья олыслары да сиңа тугрылык саклыйлардыр, дип уйлыйм: Кобогыл бу турыда да дәшми калмас иде.

Туктамыш *(кырыс)*. Ялгышсаң?

Җанбай. Ялгышсам: — җилкәмдәге башымның язмышын синең кулыңа тапшырам, ханиям!

Туктамыш *(аңа яшь киңәшченең җавабы ошый)*. Яхшы. Без синең киңәшеңә колак салдык!

Тоткавыл *(ишектә күренә)*. Меңбашы Кобогыл!

**Палатада җанлану башлана.**

Туктамыш. Керсен!

Идегәй *(кызу хәрәкәтләр белән килеп керә һәм, бер тезенә төшеп, иегенә)*. Киңәшеңне бүлдерергә базганга ачуланма, ханиям: ике яхшы хәбәрем бар!

Туктамыш. Тыңлыйм сине, меңбашы!

Идегәй *(торып баса)*. Беренче: карлуклар һәм Сыр-Дәрья буендагы башка олыслар, Шаһ Тимер янына качкан ике-өч әмирдән башкалар, сиңа тугрылыклы калуларын белдереп, кабат ант итteләр. Һәрберсе сиңа берәр төмән гаскәрен бирергә әзер! Икенче: ышанычлы кулдан хәбәр алдым — Мәскәү кенәзе Дмитрий Мамайны тар-мар иткән һәм ул калдык гаскәре белән Калка елгасы буена качкан!

Туктамыш. Ә Дмитрий?

Идегәй. Орыш канлы булган: Дмитрийның да унбиш төмәненнән бер-ике төмәне генә исән калган, шуңа күрә, анысы Мамайны эзәрлекләүдән баш тартып, яраларын яларга Мәскәвенә кайтып киткән!

Туктамыш *(шатлыгын эченә сыйдыра алмый)*. Хак сүзме бу, Кобогыл?

Идегәй. Башым белән җавап бирәм, ханиям!

Туктамыш *(тора, елмаеп)*. Димәк, маймылга таудан төшәргә чират җитте!

**Барысы да торып басалар һәм көлешәләр.**

Төмәнбашы Кобогыл әмир! *(Елмая.)* Колагың ялгыш ишетмәде, Кобогыл: әмеремне тыңла! Бүген үк төмәнең белән Калка елгасы буена юнәләсең һәм кара дошманыбыз Мамайның башын минем алга китереп саласың! Ә без, Аллага тапшырып, аның тәхетен кабул кылырга китәбез! Көтеп алган көнебез килде!

## 40. Идегәй йорты. Көн.

**Айтулы учакка ут дөрләтеп маташа.**

Идегәй *(атылып кайтып керә)*. Фәрештәм! Норадыны күрсәт!

Айтулы *(сикереп тора һәм иренең муенына сарыла)*. Кобогылым! Кайттың! Син исән! *(Көлә.)* Озак йөрдең, язмышым! Син югында кайберәүләр мине кысыр калган язгы басуга тиңләмәкчеләр иде! Дусларыныңкулларында хәнҗәр эзе күрсәң — үч алма берүк! Үзем бирә килдем мин аларга җәзасын! *(Оялып, күзләрен түбән төби.)* Үпкәләмә, җаным: Норадынымны кулларыңа тоттыра алмыйм әлегә... Тегe чакта «басу»да, игенче дә чәчүгә әзер булмагандыр, бәлки?

Идегәй *(көлә-көлә хатынын үбә)*. Ә хәзер? Йә, Алла! Син, чынлап та, тагын да ныграк чибәрләнә төшкәнсең, фәрештәм! Вакытым бик чамалы минем! Нишләтим сине?! Вәгъдәңдә тормаган өчен үтеримме, кашыкка салып суырып йотыйммы?!

Айтулы *(оялчанлыгын җиңеп)*. Икесен дә бергә эшлә, язмышым! Тик башта суырып үп! Безгә Норадын кирәк ич!

**Идегәй кычкырып көлә һәм Айтулыны ятак бүлмәсенә күтәреп алып кереп китә.**

## 41. Азов диңгезе буенда Идегәйнең сугыш чатыры. Кичке як.

**Бертөркем атлы йөзбашлары һәм меңбашлары белән бергә Идегәй үз чатырына кайта.**

Идегәй *(бик шат, әмма аны нидер борчый)*. Мамайны җиңдек, әмирләр! Ул хәзер Урдабызга мәңге аяк баса алмаячак. Караңгы төшүгә чатырыма рәхим итегез! Табынымның түрендә утырырга барыгызның да тулы хакы бар, баһадирларым!

Бер әмир. Рәхмәт, төмәнбашы Кобогыл әмир! Тик без синең йөзеңдә шатлык белән бергә нииндидер кара күләгә дә күрәбез.

Идегәй. Син хаклы, Исәнтәй углы Ходайбирде әмир... Мин ханыбызга Мамайның башын алдыңа китереп салырмын, дип вәгъдә иттем — ә ул берничә нөгәре белән качып котылды! Вәгъдәмдә тора алмадым.

Икенчедән, берничә мәртәбә мине үлемнән саклап калган гарәбемне күрмим. Ә ул — сирәк очрый торган асыл егет иде... Орыш кырында югалды.

Икенче йөзбашы. Мин күрдем аны түрәм: ул берничә егет белән Мамайның байрагы тирәсендә сугыша иде. Ары ниләр булгандыр — язмышын белмим... Башын җуйган булса, ару үлем — ак кәфен бирсен!

Бәхтияр *(чатырдан елмаеп килеп чыга: кулына яссы савытка салып өстен япкан нидер тоткан).* Аның каравы, мин яхшы беләм гарәбеңнең язмышын, түбәнбашы Кобогыл әмир!

**Барысы да кинәт аңа таба борылып карыйлар.**

Икенче йөзбашы. Менә ич ул!

Идегәй. Син... ничек монда?

Бәхтияр *(бераз кыланып, уң кулын күкрәгенә куеп баш ия).* Түрәм минем өчен борчыладыр, дип тизрәк монда ашыктым. Кабул итеп алчы, түрәм! *(Кулындагы савытын Идегәйгә таба күтәрә.)*

Идегәй. Нәрсә ул?

Бәхтияр *(кинәт япмасын ачып ташлый).* Ханиябез дүрт күз белән көткән бүләк.

Ходайбирде *(гаҗәпләнеп кычкырып җибәрә).* Мамай башы!

Бәхтияр. Хаталык эшләгән булсам, кичер, түрәм!

Идегәй *(атыннан сикереп төшеп, Бәхтиярне кочаклый).* Шушы яхшы атымны бүләк итәм сиңа, гарәбем! *(Башкаларга.)* Менә хәзер — йөземдә күләгә әсәре күрмәссез, дусларым! Чөнки, ниһаять, Алтын Урдабыз бөтенләе белән бер учка тупланды.

Бәхтияр *(серле итеп).* Аны куй да, моны әйт, батыр түрәм: димәк, сиңа да чын асыл ат алырга вакыт!

**Идегәй башта аңа гаҗәпләнеп карый һәм аңлап көлә башлый: бүтән әмирләр дә, сүзнең төп мәгънәсен аңламасалар да, аңа кушылалар.**

Идегәй. Вакыт, гарәп дустым, бик вакыт! Тик шуны онытма: асыл ат алу — уен эш түгел... Ашыккан ашка пешкән! *(Гаскәр башлыкларына.)* Мәҗлескә соңга калмый рәхим итегез, ил өстендә иләмән батырларым.

**Әмирләр үз чатырларына таралалар: Идегәй белән Бәхтияр ялгыз кала.**

Идегәй *(Мамайның башын савыты белән кулына алып, уйланып тора).* Сөйлә, ничек булды?

Бәхтияр. Анда ир-ат өчен эш калмаган иде инде. Байрагы авып төшкәнен күрүгә, Мамай, үзе тирәсендәге унбишләп нөгәре белән, камышлыкка кереп качты. Артларыннан ташландык. Казнасын гел үзе белән йөртә икән дигән сүз таралган иде бит — буш хәбәр булып чыкты, табалмадык. Диңгезгә ташлап өлгергәннәрдер, бәлки... Киләчәккә зур сәрмая булачак иде, кызганыч... Менә шул гына!

Идегәй *(башны җиргә куя, уйчан).* Ә бит, беләсеңме, заманында Җиһанны тетрәткән Нугай әмирдән дә куәтлерәк баһадир иде бу кеше... Күпме ханны курчак кебек уч төбендә биетте! Арысландай көчле Ырыс хан ничә тапкыр аңа ыргылып карады — үз борынын гына канатып китте... Мәскәү кенәзе Дмитрийга Донской дигән данлы кушамат биргәннәр, имеш. Киресенчә дә килеп чыгасы булган! Мәскәү кенәзен данлыйсы урынга, бүген шушы Мамайны Дон батыры, дип мактарлар иде! Үз көченә артык масаеп, алдан вәгъдәләшкән аркадашы литвалы Җагайлуның орыш кырына килеп җитүен көтәргә теләмәгән... Һәм гапгади тас кол кулыннан китте! Күпләр өчен сабак бу, тас кол дустым!

Бәхтияр. Коллыкка төшкән һәр халыкның богауны ватарга хакы бар, түрәм.

Идегәй. Сүзеңнең төбенә төшеп җитмәдем?

Бәхтияр. Мәскәү кенәзе Дмитрий бүген җиңмәсә, иртәгә башка берәрсе аны тармар итәр иде!

Идегәй *(нөгәренә гаҗәпләнеп карап тора).* Мин сине чиксез кыю егет бу, дип йөри идем, чүлмәгең дә шактый шәп кайный, ахры, синең...

Бәхтияр. Кичер, түрәм: башымны бер уй бораулый... Кайчандыр Ырыс хан, үзе тәхеткә менәр өчен, Урданы таркаткан, ләкин таркаткан илен, кабат җыеп бетерә алмыйча, дөнья куйган. Аның артыннан шушы Мамай Урданы тарката башлаган: ул да үзе җимергәнне кире төзәтә алмады — башы аягыбыз астында ауный. Боларның икесен дә, үзенә тәхет яуларга теләп, Туктамыш хан синең кул белән юк итте. Бусы, ичмасам, Урданы кабат бер учка туплап бетереп килә, бугай... Инде хәзер син, Кобогыл түрәм, яңабаштан алар юлыннан китәргә чамалыйсың! Мәгънә күрмим. Халык каны коелганын гына күрәм. Сукырайган булсам, күзләремне каплаган кара пәрдәне алып ташла, сәргаскәр!

Идегәй *(нөгәренең сүзләре аны бераз аптырашта калдырган).* Саташма, гарәп! Мин әлегә — түбәнбашы гына!

Бәхтияр *(Мамай башын күрсәтә).* Ошбу бүләктән соң, Туктамышның сине бөтен гаскәренә баш итеп куюына шикләнмим мин.

Идегәй. Ә мин — шикләнәм! Тик эш анда түгел, гарәп... Син мине Ырыслар, Туктамышлар, Мамайлар шикелле, зур түрә булырга ярата торган кеше, дип уйлыйсыңдыр. Бөтенләй үк кире какмыйм. Син үзең дә горур җан ич! Ләкин син аерманы белмисең. Минем төп максат икенче. Күргәнсеңдер: Мамайны куып йөргәндә Туктамыш баскаклары безнең арттан әсир җыеп, Сарайга кайтара тордылар. Хатын-кызларны алар, карт-корыларны, бала-чагаларны — кол сатучылар өчен барыбер! Орыш кырында әсиргә алуны аңлыйм мин. Ә гади кара халыкның сугышка ни катнашы бар?! Менә нәрсәне бетерергә телим мин! Гаделлек урнаштырырга. Әйт әле: син кайчандыр шушы башның тугрылыклы нөгәре идең, ә бүген ник аны җилкәсеннән кисеп төшердең?

Бәхтияр *(ярсып).* Ул безне сугыш кырында дошман кулына ташлап качты!

Идегәй. Менә-менә! Чөнки син аның ниятен үтәүче корал гына идең! Ә мин — сиңа дус булырга телим!

Бәхтияр. Кол түрәгә дус була алмый, Идегәй... Нәтиҗә күрмим! Һаман, сумалага утырган кебек, кузгалганыбыз юк...

Идегәй *(ул да саклыкны оныта)*. Мине ташлап китәсең, димәк, Бәхтияр?

Бәхтияр. Юк! Дошманыма үч кайтармыйча — китмим!

Идегәй. Ә аннан соң? Ник дәшмисең?

Бәхтияр. Авызга сүз төшми тора...

Идегәй. Һәр колның богавын ватарга хакы бар, дип әйтәсең киләме?

**42. Идегәйнең йорты. Көн.**

Айтулы *(Идегәйгә бала тоттыра)*. Бисмилланы әйтеп ал Норадыныбызны, күз нурым! Улыбызны беренче мәртәбә кулыңа аласың...

Идегәй *(елмая)*. Бисмилласын әйтү генә түгел, әгүзебилләхи-миннә-шәйтаниражим, бисмиллаһир-и-рахманир-рахим, дип авыз тутырып әйтә алабыз инде без улыбызны... Әйе бит, йөрәк маем бергенәм?

Айтулы. Йәникә ханәш белән бер көнне таптык без балаларыбызны, атасы... Туктамыш ханның ике игезәк кызы бар. Йәникәсе бөтен җиһанга шаулатып бәби туе ясамакчы, имеш.

Идегәй. Бәби туе? Без дә ясыйбыз аны, җанашым! Шулай бит, улыкаем? Туктамышның кызлары алтын бишектә ятсалар, безнең Норадыныбыз да көмеш бишектә ятмас! Ул ту бияләр суйдырса, без дә кәҗә чалдырмабыз! Ул игезәкләрен тәрбияләргә абруйлы аналыклар алдырса, без дә әтрәк-әләм аталык тотмабыз! Аның игезәкләрен котларга ханнар җыелса, безнең улыкаебызга ак бәхетләр теләргә барлык дусларыбыз җыелыр, Аллаһы боерса! Атаң туры сукалыйммы, Норадын?

Айтулы *(улы булып кыланып)*. Сукаң буразнаны бик дөрес сала да бит, кадерле әтием, Туктамыш ханның ханәше Йәникә апа үтә көнчел хатын, диләр...

**43. Хан сарае. Иртән.**

**Тәхет залы алды. Залга килеп ятучы Идегәйгә шагыйрь Сәйф Сараи очрый.**

Сараи *(Идегәйне танып)*. Мамайны җиңгән данлыклы баһадирга сәлам.

Идегәй. Ә, мөхтәрәм Сарай шагыйре Сәйф Сараи! Вәгаләйкемәссәлам!

Сараи. Хан бистәсе «Алтын Таш» шагыйре, дип әйтүеңме бу, Кобогыл баһадир? Хәер, сиңа әйтергә ярый: син — җиһан батыры!

Идегәй. Аллам сакласын, бөек чичән! Киресенчә, син бөтен Җир шарын бер карашың белән айкый аласың! Гыйшык тоткан кызларның сөйгән егетләре янында чуалуын Җир шарының кояш тирәсендә әйләнүенә тиңли алган чичән хансарайда куштанланып бәтерелмәдә. Мин үзем, мисалга, Җирнең шар икәнен дә белми идем!

Сараи *(җитди)*. Ә кайбер батырларыбыз, кызганычка каршы, Сөһәйлне күреп гашыйк булган Гөлдерсен күк, әтрәк-әләм ханнар тирәсендә әйләнә... Хуш, янадан күрешергә язмаган булса, туры юлыңны табуыңны телим, Кобогыл батыр: ерак сәфәргә китүем.

Идегәй. Ничек, хөрмәтле чичән? Идел-Йортыбызга тыныч көннәр килгәчме? Сараебызда болай да чичәннәр калмады — барысы да чит мәмләкәтләргә... китеп беттеләр!

Сараи *(елмайгандай итә)*. Мине аярга тырышма, батыр, качып беттеләр, дип туптуры ярып сал! Мин дә — алар артыннан... Идел-Йортыбызның һавасы тынчу... *(Идегәйгә ихтирам белән кулын күкрәгенә куеп, башын ия һәм китә.)*

**44. Тәхет залы. Иртән.**

**Залга Идегәй килеп керә һәм, үз дәрәҗәсен саклап, Туктамыш хан алдында иелә. Залдагылар, аның үзен хөрмәтләп, аяк-өсте басып каршы алалар. Туктамыш хан үзе дә ирексездән тәхетеннән күтәрелә төшә һәм, күрмәделәрме икән дигәндәй, тиз генә тирәягына карап ала. Тәхетнең сул ягында утырган ханәше Йәникә, иренең йомшаклыгын күреп, авызын кыйшайтып куя.**

Туктамыш *(үз-үзен кулга ала)*. Уң ягыма рәхим ит, меңбашы Кобогыл әмир. *(Идегәй ул әйткән урынга урнашкач.)* Ярлыгыбызны игълан ит, Диван битекче.

Битекче *(торып хан алдында иелә)*. Баш өсте, ханиям. *(Укый.)* «Туктамыш каган сүзе. Кара дошманыбыз һәм тәхет карагы Мамай әмирне тар-мар итеп, каһарман Чыңгыз бабаларыбыздан безгә мәңгегә мирас булып калган җирләребезне кайтарып алуда кылган эшләренә карап, әмирләрем: Исәнтәй углы Ходайбирдене... *(Үз исеме аталган әмирләр аякөсте басып, ханга иелеп, нәләр һәм урыннарына утыралар.)* Акбалтыр углы Уакны, Монҗыр углы Чуакны, Аргын би Кара Куҗаны, Туктар углы Тугачаны, Мөйтән углы Кыпчакны, мәмләкәтебезгә кайтарылган олысларга түрә итеп билгеләдем. Мин әйттем». *(Ханга иелеп, утыра.)*

**Идегәй бераз сәерсенеп хан ярлыгын тыңлый: исемнәре аталганнар барысы да — үз кулы астында сугышкан әмирләр, ә аның үзе хакында ярлыкта бер сүз дә юк!**

Туктамыш *(Идегәйне күзәтеп торган икән, елмаеп)*. Хәзер тагын бер сүземне тыңлагыз. Меңбашым Кобогыл әмир! *(Идегәй торып баш ия.)* Син кара дошманымны җиңүдә аеруча зур батырлыклар һәм зирәклек күрсәттең. Шуны истә тотып, без сине уң кулыбыз итеп билгеләдек.

**Әмирләр арасында чыш-пыш китә: «Кобогылның кояшы байый башлады! — Меңбашыннан да түбәнрәк урын ич ул! Иярәннән ауды, Кобогыл!»**

Идегәй *(күңеле кителүен күрсәтми)*. Боер, бөек каган. *(Утыра.)*

Туктамыш. Кәмал би улы Җанбай! *(Киң Җанбай аякөсте басып, түбәнчелек белән иелә.)* Вакытсыз вафат киткән атаң Кәмал би кебек син дә безгә киңәшләрең белән яхшы хезмәт күрсәттең. Шуны истә тотып, без сине сул кулыбыз итеп билгеләдек. *(Ханәше Йәникә янындагы буш урынга күрсәтә.)*

Җанбай *(авызы ерылуын чак-чак тыеп).* Боерың, бөек каганым! *(Шулай ук түбәнчелек белән иелеп, күрсәткән урынга барып утыра.)*

Туктамыш. Монда исемнәре аталган әмирләремнең барысы да каган җилкәсеннән асыл туннар белән бүләкләнә. Мин әйттем. *(Тәхетеннән тора һәм ишеккә юнәлә. Ханәше аңа ияра.)*

**Залдагылар аякөсте торып басалар һәм, кулларын күкрәкләренә кушырып, баш иеп калалар. Хан чыгып киткәч, Киң Җанбай Идегәй янына авызын ерып килә.**

Җанбай. Хан тәхетенә тагын бер адым якынаюың белән котлыйм, җан дустым Кобогыл би!

Идегәй *(мыскыллы көлемсерәп).* Монда керер алдыннан гына бөек чичән Сәйф Сараи бер тапкыр котлады инде мине! *(Аның учында җәрәхәт эзе күрә.)* Уч төбеңдә хәнҗәрдән калган яра җөе күрәм: тәхет тирәсендә урын яулау синә да җиңел булмаган, күрәсең?

**45. Сарай каласында коллар базары. Иртә.**

**Кораллы сакчылар карамагында коллыкка сатылачак кешеләрне тактадан эшләнгән күперчеккә берәм-берәм мендереп бастыралар. Базар маклеры сатылачак һәр кешенең кайдан, кем, ничә яшьтә булуын һәм нинди һөнәрләр белүен игълан итеп тора. Сатып алучыларга бәяне әйтә, ә алар үз бәяләрен мәйданнан кычкыралар. Бер читтә сатылачак коллар төркеме: арада ир-атлар, хатын-кызлар, бала-чагалар күренә.**

Маклер *(күперчеккә менеп баскан ир-атны таныштыра).* Җәмәгать! Сезнең алдыгызда — Арыслан атлы Мамай батыры! Шәп тимерче. Кулыннан килмәгән эше юк. Ат дагасын сыңар кулы белән бөгә! Егерме ике яшьтә. Өйләнмәгән. Бәһасе — ун алтын!

Сатып алучылар. Биш алтын! Җиде алтын! Үзенә булсын!

Маклер. Җәмәгать! Аршиндай киң җилкәләренә карагыз сез аның! Ишетмәгән булсагыз, ишетегез: бервакыт ул, бәхәсләшеп, ястык сыртлы зур атны җилкәсенә күтәреп, базарга сатарга алып барган! Булдыклы кеше!

Хатын *(йөзенә пәрәнҗә япкан).* Унбиш алтын!

**Халык хатын ягына борыла һәм көчле көлеш башлана.**

Маклер. Унбиш алтын! Менә бу — чын бәя ичмасам! Кем арттыра? Юкмы? Сатылды! Игелеген күр, яшь бикәч! Картайганчы файдаланырга язсын!

**Халык дәррәү көлә. Колны, муенына бау салып, аяк-кулын богаулап, алып китәләр. Күперчеккә җиде-сигез яшьлек кыз баланы бастыралар: ул елый-елый шешенеп беткән. Иреннәре әллә дерелди, әллә «Әнием!» дип кычкырырга телиләр.**

Маклер *(кызчыкка йодрык яный).* Затлы нәсел баласы! Буй-сынына, йөзенә игътибар итегез, җәмәгать! Сөлек кебек зифа гәүдә, бөреләнеп килгән алсу чәчәк! Баг алма кебек кыз! Иртәгә үк бер кашык суга салып йотарлык булачак!

**Мәйданга ике җайдак керә: Идегәй белән Бәхтияр әкрен генә сөйләшеп киләләр.**

Идегәй. Дөрес сукалыйсың, гарәп... Икебез дә ялгышканбыз: син Туктамыш мине югары күтәрәчәк, дигән идең, мин — шикләнәм, дидем, ә ул — мине, күкләргә чөеп мактап, түбән төшереп куйды!

**Күперчек янына житәр-житмәс туктыйлар.**

Бәхтияр. Нәрсә, түрәм: син дә кол сатып алырга булдыңмы?

Идегәй. Юк, гарәп! Синең үзеңне китердем.

Бәхтияр *(кинәт куркып кала).* Мине сатарга телисең?!

Идегәй. Ахмак булма! Хәтереңне яңартырга уйлыйм! Карап тор! Һәм мыегыңа чорна. Әнә — нинди дер сабыйны саталар. Ә тегендә — бер хатын кулларын чытырдатып изүенә ябышкан. Анасы, димәк!

Бәхтияр *(башын түбән төшерә).* Зинһар, китик моннан, түрәм! Бу коллар базарын мин ләхет тактам так иткәндә дә онытмаячакмын... Маклер да яхшы таныш миңа!

Идегәй *(атын читкә бора).* Яхшы. Китик. *(Бераз дәшми-тынмый баралар.)* Зур үтенечем чыкты сиңа, нөгәрем. *(Ул, берни булмагандай, дустанә сөйләшә башлый.)* Күк Урданың элекке ханы Тимер Мәлик Туктамышка каршы фетнә башларга тора, имеш. Аның әмирләре арасында минем якын әшнәләрем күп. Шуларга җиткерәсе сүзем бар. Идегәй исеменнән. Аңлыйсыңдыр, теләсә кем аша юллый алмыйм. Сиңа гына ышанам. Ризамы?

Бәхтияр *(уйланып).* Кайчан юлга чыгыйм?

Идегәй *(йөзе ачылып).* Менә бу — мин белгән Бәхтияр сүзе! Ике көннән — бәби туе. Шуннан соң. *(Атына камчысы белән сугып, кыра тартып чаптырып китә.)*

**46. Хансарай. Көн.**

**Туктамыш ханның аш бүлмәсе. Хан ханәше белән бергә ашап утыра: җарияләр ритуал буенча аш-су китерәләр, кәнизәкләр талгын музыкага биилэр.**

Йәникә. Сәнәктән көрәк булган Кобогылыңны уң кулың ясап ашыктың, ханиям. Төмәнбашы гына булуы бик җиткән иде әлегә!

Туктамыш *(көлә).* Күтәрелде, дип уйлыйсыңмыни?

Йәникә. Тәхетең кырына утырттың ич?!

Туктамыш. Хатын-кыз хатын-кыз инде! Уң кул, имеш. Түмәнбашы чагында аның кулында ун меңлек гаскәре бар иде, ә хәзер — бер тас колы белән ялгызы торып калды. Әмирләрен уч төбендә тота белергә тиеш дәүләт башлыгы: бүген татлы бал каптырам мин аларның авызына, иртәгә — әрем суы бирүем дә мөмкин! Кичә Кобогылны күтәргән булсам, бүген — аның кулы астындагы әмирләрне үзеннән зуррак дәрәҗәле иттем. Олыс хуҗалары булдылар. Урыннары Кобогылныкына караганда төшемлерәк тә, иркенрәк тә. Ә Кобогыл — минем тәхет кырында күзле бүкән булып утырып калды. Телим икән — майлы ботка ашатам, телим икән — суган суы чөмертәм! *(Көлә.)* Шушы — аны күтәрүме?

Йәникә *(ханның сүзләренә исе китми)*. Әйтәм аны, улларының бәби туен безнең игезәкләребезнекеннән дәрәҗәлерәк итеп уздыра алмады! Ике туй да синең казнаңда булганына карап бертигез узды. Игезәкләребез Ханәкә белән Көнәкә ни ашаса, малайлары Норадын да шуны гына ашый!

Туктамыш *(елмая)*. Куйчы, Йәникә... Колыңнан көнләшеп утырасың! Ни ашатса да — ул үзе дә, бишектә яткан баласы да — минем белән синең коллар!

Йәникә. Һе! Моңа кадәр каганнарның үз колларын аякөсте торып басып каршы алганын белми идем.

Туктамыш *(гаҗәпләнеп)*. Тузга язмаганны сөйләнә башладың, ханәшем. Кәефең начар булса — җарияләрең белән, күл буена чыгып, күңел ачып кайт.

Йәникә *(сүзне читкә бора)*. Синнән башка нишлим мин анда ялгызым?

**47. «Алтын Таш» бистәсе капкасының эчке ягы. Көн.**

**Капка кырында откавылына нидер аңлатып торган ясавыл янына Йәникә килә.**

Откавыл *(урәката)*. Ханбикә килә!

Ясавыл *(Йәникәгә каршы ашыга һәм түбәнчелек белән аның алдында йөгенә)*. Боер, олуг ханбикә.

Йәникә. Бүген монда хан киңәшенә олуг ханның уң кулы Кобогал әмир килер. Син аны, берәр сәбәп табып сөйләндереп, беразга тоткарла. Әмирләрне киңәшкә чакырган чаң тавышы яңгырагач кына, хансарайга керсен. *(Ясавыл кулына нидер суна.)*

Ясавыл *(башын ия)*. Үтәлер, олуг ханбикә! *(Йәникә киткәч, аптырап җилкәсен җыера.)*

**48. Хансарай. Көн.**

Җанбай *(хан алдында тугызга бөгелеп)*. Бөек каган! Диван киңәше алдыннан бер сүз әйтергә рөхсәт ит.

Туктамыш. Әйт.

Җанбай. Күзәтчеләрем хәбәр итә: Күк Урданың элекке ханы Ырыс хан улы Тимер-Мәлик, үз тирәсенә әмирләр җыеп, сиңа каршы баш күтәрергә котырта башлаган!

Туктамыш. Ышанычлы хәбәрме бу?

Җанбай. Ышанычлы, бөек каган. Ниндидер Идегәй атлы бер кеше коткысы белән кузгалган фетнә, диләр.

Туктамыш. Киңәшең?

Җанбай. Уң кулың Кобогыл әмир соңгы вакытта үзенә шөгыль табалмыйча интегә: я сәүдә эшләренә тыкшына, я — кала биләренә тәртип сакламыйсыз, дип бәйләнә икән. Мин яхшы аңлыйм аны: ул — орыш өчен туган кеше. Без аның белән — балачактан аерылгысыз якын дуслар.

Туктамыш. Яхшы. Диван битекчесенә җиткер.

**49. Тәхет залы. Көн.**

**Әмирләр һәм вәзирләр җыелып беткән. Туктамыш хан тәхетендә утыра. Аның сул ягына ханәше Йәникә белән баш киңәшчесе Кин Җанбай урнашкан. Ханның уң кулы Кобогыл әмирнең генә урыны буш.**

Туктамыш *(түземсезләнеп)*. Битекче! Уң кул нишләп юк һаман?! Хәбәр иттеңме?

**Диван битекчесе торып баса, әмма җавап биреп өлгерми — Идегәй килеп керә. Әмирләр барысы да аңа хөрмәт йөзеннән торып басалар. Туктамыш хан да, ирексездән, аягына күтәрелә башлый һәм кинәт артка тартылып туктап кала: ханәше аның кием чабуын энә белән тәхетенә беркетеп куйган.**

Туктамыш *(ханәшенең хәйләсен аңлый, ачуы килә)*. Кхм... Кхм! Каганының көттерәсең, уң кулым Кобогыл әмир!

Идегәй *(йөгенә)*. Кичер, бөек каган! Чаң тавышын ике генә тапкыр яңгырады әлегә. *(Урынына утә.)*

Туктамыш. Тугрылыклы әмирләрем! Ышанычлы кешеләребездән яман хәбәр алдык: тәхетеннән колак каккач, кырда йөргән киек кебек йортсыз-җирсез кангыраган Тимер-Мәлик безгә каршы мәкер оештырмакчы, имеш. Битекче! Каган ярлыгын әмирләребезгә җиткер!

Битекче *(торып каган алдында йөгенә һәм укый)*. «Туктамыш каган сүзе. Ошбу ярлыгым белән мин уң кулым Кобогыл әмирне түмәнбашы итеп билгелим һәм аңа Тимер-Мәликне тотып, әгәр дә аңа кушылучы әмирләр табылса, аларны да минем каршыма китерүне тапшырам. Мин әйттем.»

Идегәй *(торып баса һәм йөгенә)*. Әмерең тиешенчә үтәлер, бөек каган. *(Залда утыручы әмирләргә карап чыга: йөзләреннән берни аңлап булмый, бары тик Кин Җанбайның иреннәрендә генә елмаюга охшаш нәрсә чагылып уза.)*

**50. Җаек буенда Идегәй чатыры. Кич.**

**Идегәй әле генә таныш әмирләре белән яшерен киңәшмә үткәргән: борчулы йөзле әмирләр таралышырга җыена.**

Идегәй. Коткыга бирелмик, ил агалары! Мин сезгә ышанам!

Әмирләр *(барысы да аның күтәренке рухына кушылмый)*. Шулай, Кобогыл

әмир... Уйлашырга кирәк... Тимер-Мәлик ханның сүзенә дә колак салмый булмый. *(Таралышалар.)*

Бәхтияр *(әмирләр таралып беткәч, чатырга керә)*. Егетләр җилле, чикмәннәре генә тар! Йә, син ни әйтерсең, Идегәй?

Идегәй. Ишетеп тордың ич... *(Дулкынланып әрле-бирле йөренә.)* Күбесенең кендеге искегә береккән!.. Тимер-Мәликкә нәрсә аңа... Ул үзенә Нугай иленнән бер кисәк җир сындырып алырга гына тели! Үтелгән дәвер инде ул! Алтын Урда ничә мәртәбә, вак өлешләргә бүленеп, үзара сугышып ятты... Юк, Тимер-Мәлик безгә юлдаш түгел! Ә уллары — акыллыга охшаган... Аталары артыннан ялгыш юлга кереп адашмасалар...

**Тышта ат тояклары тавышы ишетелә. Бәхтияр тиз генә тышка юнәлә һәм атчабарны ияртеп керә.**

Атчабар *(хөрмәт йөзеннән баш ия)*. Туктамыш каганның уң кулы Кобогыл әмир! Тимер-Мәлик, гаскәр туплап, Сыгънак каласын камап алган!

Идегәй. Син кем?

Атчабар. Туктамыш каганның сул кулы Җанбай бинең ышанычлы кешесе.

Идегәй. Хәбәрең өчен рәхмәт. Хәзер үк Сарайга юнәл һәм түрәңә җиткер!

Атчабар *(икеләнеп)*. Үз түрәм мина...

Бәхтияр. Каганның уң кулы кушкан әмерне үтә, атчабар!

Атчабар *(куркып)*. Баш өсте, Кобогыл әмир! *(Югала.)*

Идегәй *(ат тояклары тавышы ерагайганнан соң)*. Киң Җанбайның шымчысы, димәк! Әмирләр белән сөйләшү алып барганыңны күрдеме ул?

Бәхтияр *(уйланып)*. Хәтерләмим, Идегәй...

Идегәй *(кискен)*. Хәтерләргә тырыш! Кылыч йөзе өстендә йөрибез! Ә хәзер — Тимер-Мәликкә каршы яу чабабыз, меңбашларны җый.

Бәхтияр *(гаҗәпләнеп)*. Тимер-Мәликкә каршы?! Туктамыш ханның дошманы ич ул!

Идегәй. Дошманыңның дошманы — сиңа дус, дигән сүз түгел. Миңа аның әмирләре кирәк!

### 51. Сарай каласы. Көн.

**Аулак җирдә Киң Җанбай үзенең шымчысы атчабар белән очраша.**

Җанбай. Идегәй дигән кешене күрдеңме?

Атчабар. Уйдырма түгелме икән ул, Җанбай би? Кобогылның гарәбенең берничә тапкыр Күк Урда әмирләре белән чыш-пыш килгәнен күрдем. Ни сөйләшкәннәрдер — белә алмадым.

Җанбай *(кырыс)*. Бик начар! Белергә кирәк иде! Кобогыл үзе кайда?

Атчабар. Син кушканча, Тимер-Мәликнең Сыгънакны камавын ишетүгә, бу хәбәрне Кобогыл әмиргә җиткердем.

Җанбай *(түземсез)*. Йә-йә, ничек кабул итте хәбәреңне?

Атчабар. Бик текә холыклы! Шундук сиңа җиткерергә боерды!

Җанбай *(ризасызлык белән)*. Йөзен тел астына яшергән, димәк! Сине җибәреп, ялгышмадыммы икән мин! Йөреп-йөреп, бер эш чыгара алмагансың! Яңалыкларың шул гынамы?

Атчабар *(хәйләкәр елмая)*. Кичер, хуҗам: мин аның боерыгын шундук үти алмадым: башта Кобогыл үзе нинди чара күрәсен беләсем килде.

Җанбай *(җанланып)*. Сузма, белә алдыңмы соң?

Атчабар. Кобогыл... Тимер-Мәликкә кушылырга китте!

Җанбай. Ялгышмыйсыңмы, шымчы?! Башың белән җавап бирәсең — кара аны!

Атчабар. Кобогылның түмәнендә минем якын кешеләрем бар!

### 52. Хансарай. Көн.

**Киң Җанбай Туктамыш хан янына атылып килеп керә: бөек каган ау кошлары кетәгендә яраткан лачынын ашатып тора.**

Җанбай. Кичер, бөек каган: бүлдерәм сине! *(Йөгенә.)*

Туктамыш *(кырыс)*. Сүзеңне әйт, киңәшче.

Җанбай. Имеш хәбәрләр йөри: Кобогыл түмәне белән хыянәтче Тимер-Мәликкә кушылган!

Туктамыш *(дертләп китә)*. Бәдбәхет икән, йөзе кара! Киңәшең әзерме?

Җанбай *(җаваплылыкны үз өстеннән төшерү нияте белән)*. Ләкин мин бу имешмимешкә ышанырга ашыкмас идем, бөек каган. Йомыркадан сап эзләмиләрме икән?

Туктамыш. Аңлат?

Җанбай. Кобогылның көче зур түгел. Тимер-Мәликнең гаскәре дә санаулы гына. Шуны күрә торып, сиңа хыянәт итү — ахмаклык. Кобогылның башы ике түгел ич! Шулай да мин кайбер чараларны күреп куйдым, бөек каган: әмирләргә түмәннәрен әзер тотарга кушылды. Кобогылның ниятен ачыклау өчен шымчылар җибәрелде.

Туктамыш *(тынычлана төшә.)* Яхшы. Хуп. *(Лачынын ашатуын дәвам итә.)*

**Киң Җанбай хан алдында йөгенә һәм, арты белән чигенеп кетәклектән чыгып китә.**

### 53. Хансарай. Кичке як.

**Туктамыш хан битекчесенә ярлык әзерләтә.**

Туктамыш *(әйтеп яздыра)*. Мәскәү кенәзе Дмитрийга ярлык әзерлә! Без аңа Мамайның башын чаптыруыбыз хакында хәбәр итеп, уртак дошманыбызның юк ителүе белән котлау хаты юлладык — ул хатыбызны җавапсыз калдырды! Үзен берничә тапкыр каршыбызга чакырдык — кунагыбыз буласы килмәде! Ясак түләми! Соңгы тапкыр кисәтәбез: әгәр дә бу хатыбызны да җавапсыз калдырырга батырчылык итсә, үзенә үпкәләсен! Иле бүлемсез түгел! Тамга җыючыларымны юллыйм. Мин әйттем!

**Ишектә Тоткавыл күренә.**

*(Кискен).* Нәрсә бар?

Т о т к а в ы л. Кичер, бөек каган: түмәнбашы Кобогыл әмирдән чапкын.

Т у к т а м ы ш. Керсен!

Б ә х т и я р *(түбәнчелек белән йөгенә).* Бөек каган! Түмәнбашы Кобогыл әмир Тимер-Мәликне тар-мар итте һәм аның ягына чыккан әмирләре белән бергә әсир кылды. Ике көннән монда синең каршыңда булачаклар.

Т у к т а м ы ш *(битекчегә).* Баш вәзирем Җанбайны чакыртырга!

**54. Сарай каласы каршында дала. Иртә.**

**Киң Җанбай, берничә кораллы ялчылары белән бергә, ш ы м ч ы с ы н а т койрыгына тактыра.**

А т ч а б а р *(аның алдында тезләнә).* Кичер, зинһар, хуҗам! Ике балам хакына кичерә күр! *(Елый.)*

Җ а н б а й *(ачулы).* Бәйләгез, ни карап каттыгыз!

**Бер жайдакның атының койрыгына шымчыны ике кулыннан тагалар.**

Җ а н б а й *(атка чыбыркысы белән сыдыра).* Сөякләре таралып бетсен бәдбәхетнең!

**Җайдак атын чаптырып китә.**

**55. «Алтын Таш» хан бистәсе утары. Иртә.**

**Туктамыш хан яраннары белән бергә ауга китәргә әзерләнә: аңа хансарай хезмәтчеләре иярле ат китерәләр, бүтәннәр ханны олылау йөзеннән, түземлелек күрсәтеп, атларына менми торалар. Олуг капкадан түмәнбашы Идегәй килеп керә: Туктамыш хан, аны күргәч, янына килеп җиткәнен көтә. Идегәй аның алдында йөгенә.**

Т у к т а м ы ш *(хуш күңеллелек күрсәтеп).* Без синнән канәгать, меңбашы! Сүзебезне мин аудан кайткач дәвам итәрбез. Сине сәргаскәребез итәргә чамабыз бар: ныклап уйла — күтәрә алырсыңмы? Кабул итмим дисәң, гаепләмәбез — һәркемнең үз түшәме. Кузгалдык! *(Ат китергән хезмәтчеләрнең берсе, тиз генә чүгәләп, хан аягы астына аркасын куя: ул, аңа басып, авыр гәүдәсен иярә ташлый.)*

**56. Хансарайда Йәникә тирмәсе. Кич.**

Й ә н и к ә. Дөресме ул, ханиям: Кобогылны, бөтен гаскәреңне биреп, сәргаскәрең итмәкче икәнсең?

Т у к т а м ы ш. Ирләр эше ул, Йәникә.

Й ә н и к ә. Хак сүз әйттең, ханиям! Ирләр эше! Үз-үзенә нык ышанган, корыч ихтыярлы хаким гаскәрен колына тапшыра. Чөнки андый хан колга үзенең кол икәнлеген бер мизгелгә дә онытырга мөмкинлек бирми! Ә синдә мин андый көчле ихтыяр күрмәдем, ханиям. Минә ни өчен бу ниятеңне башсызлык, дип атыйм!

Т у к т а м ы ш. Син үзең онытылма, Йәникә! Мин — Чыңгызлар оныгы!

Й ә н и к ә. Ырыс ханнар да, Тимер-Мәликләр дә — Чыңгыз нәселеннән иде. Нугай морза, Мамай заманнарында да Урда тәхетләрендә гел Чыңгыз нәселеннән ханнар утырмаган идемени?! Чыңгыз каны аларны заты билгесез әмирләрнең кулгаләреннән өркеп яшәүдән коткара алмаган! Әгәр дә инде Аксак Тимердән дер калтырап, тәхетләрендә утырган ерак туганнарың шикелле, син дә Кобогыл кулгәсендә яшәргә риза булсаң, бер сүзем юк. Ул, чынлап та — булдыклы яугир. Гаскәреңне үз кулында нык тотар!

Т у к т а м ы ш. Йөрәкне яндырма, Йәникә... Яхшы атадан туган бала ул. Җантимер мине җандай күргән бер ир иде. Алма агачыннан ерак төшми. Кобогылның миңа кырын кылыгын белмим мин! Миңа тугрылыклы хезмәт итеп килә!

Й ә н и к ә. Ә аның уенда ниләр бар — шуны беләсеңме соң? Ә минем күңел аңа ышанмый! Кобогылның кулы астында синә тугрылыклы әмирләр күп. Белешү зыян итмәс, ханиям: берсе әйтмәсә, берсе әйтер. Кеше турында кешедән сорашу — борынгыдан килгән саклык йоласы ла ул!

Т у к т а м ы ш. Яхшы! Соңгы тапкыр синең сүзенә колак салуым! Монсы да — үз күңелем дә тыныч булмаганга гына... Миңа кадәр Идел-Йортыбыз ханнары тәхет өчен генә талашканнар. Шуңа күрә дәүләтебез эттән таланган тун кебек теткәләнеп беткән иде — мин кабат җөйләдем аны! Менә нәрсә кадерле миңа! Шуңа сак кылану кирәк дигәнеңә кушылам. Ләкин, ишетсен колагың, соңгы мәртәбә кушылуым булыр! *(Чыга.)*

**Йәникә аның артыннан елмаеп кала.**

Җ а н б а й *(посып торган җиреннән чыга).* Күндердең, рәхмәт, бөек ханбикә!

**57. Кече тәхет залы. Иртә.**

**Туктамыш хан яшерен киңәшкә Идегәйнең әмирләре Ходайбирде, Уак, Чуак, Кара Куҗа, Тугача һәм Кыпчак биләрне җыйган. Ханның баш вәзире Киң Җанбай да шунда.**

Т у к т а м ы ш. Тугрылыклы әмирләрем! Ишеткәнсездер: без түмәнбашы Кобогылны сәргаскәребез итеп куймакчы булабыз. Ләкин... хак тәгаләбез сакланганны саклармын, дигән. Ялгыш адым булмасмы бу? Зур дәрәҗәне булдыксыз иргә тапшырмыйбызмы икән? Сез барыгыз да Кобогыл кулы астында йөргән әмирләр идегез. Утны-суны бергә кичкәнсез. Фикерләрегезне белергә телим!

**Залда тынлык урнаша. Әмирләр бер-берсенә карашалар.**

Т у к т а м ы ш. Исәнтәй углы Ходайбирде би!

Х о д а й б и р д е. Ниятең яхшы, бөек каган. Ялгышмассың.

**Ходайбирдегә бүтәннәр дә кушыла: «Дөрес әйттең, Ходайбирде би! Кобогыл — моңа лаек! Гадел булыр!» һ. б.**

Туктамыш *(әмирләрдән бүтән төрле җавап ала алмаячагын аңлый: бик сак кыланалар, андый эшләрдә авызлары күп пешкән)*. Безнең ният яхшыдыр... Ә менә Кобогылның үз нияте нинди? *(Узалдына уйга кала.)* Асылы кем? Нугай йортында киңәш тотышырдай кеше дә калмадымы әллә?!

**Шулчак Кыпчак би кузгалмакчы була. Киң Җанбай аны җиңеннән тартып кире утырта.**

Туктамыш. Киңәшчем Җанбай! Кыпчак бигә ник аркылы төштең: әйт!

Җанбай *(тора)*. Кобогылның асылын монда беребез дә белмәстер, бөек каган. Синең илеңдә Субра атлы бер юраучы бар: гадел сүзне әйтсә, бердәнбер шул гына әйтеп бирә алыр: ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән, җитмеш җиде ил гизгән кеше ул.

Туктамыш. Хәзер үк атчабар җибәреп, чакырт шул картны!

Җанбай. Атчабар җибәртеп кенә китертеп булмастыр аны, бөек каган: дөрес булса, йөз яшәгән ап-ак сакаллы карт ул — ат менеп юл йөри алмастыр. Борынгы бабаларыбыз андый аккамнарны алтынлы көймәле так арбага алты ат җиктереп, астына мамык ястыклар салдырып барып ала торган булганнар.

Туктамыш *(Җанбайга бармагы белән төртеп күрсәтә)*. Үзең барасың!

### 58. Идегәй йорты. Көн.

**Идегәй иркен болдырда ял итеп утыра, хатыны Айтулы белән улы Норадын ишегалдында «әбәкле уйнап» күңел ачалар. Норадынга ун яшьләр чамасы.**

Норадын *(әнисенә суккандай итә һәм читкә йөгерә)*. Әбәк! *(Ялгыш биек койма янындагы таш баганага бәрелә һәм ачуланып аңа тибә.)* Менә сиңа! Менә сиңа!

Айтулы *(улының кинәт усалланып кызып китүенә гаҗәпләнеп)*. Чү-чү, Норадын улым! Рәнҗетмә аны! Таш багананың да җаны бар. *(Улын читкә тарта.)*

Норадын. Ялганлыйсың син! Ташның җаны юк!

Айтулы. Җаны булмагач, ник тибәсең соң анарга? Җаны бар аның... Менә тыңлап карале! *(Нииндидер тимер кисәге табып, баганага суга.)* Колагыңны куеп тыңла...

**Икәүләп баганага колакларын куеп тыңлыйлар.**

Ишетәсеңме?.. Зеңләп тора... Ә хәзер колагыңны ал... Бер тавыш та килмиме?.. Хәзер кабат колагыңны куеп тыңла... Һаман зеңли! Эчендә җаны булмаса, зеңләр идеме? Их, син! Ә типсәң, ачуланып бер генә кычкырачак та шундук тынып калачак... Кара аны: каты типмә...

**Улы ышаныр-ышанмас баганага тибеп куя.**

Колагыңны куй... Ышандыңмы инде?

**Аларны күзәтеп утырган Идегәй кычкырып көлеп җибәрә.**

Норадын. Чын, әти!

Айтулы. Кил, атасы, син дә тикшереп кара! *(Күл изи.)* Кил инде: юкса багана йокыга китәчәк... *(Улына сиздерми генә күз кыса.)*

Идегәй *(елмаеп, гаиләсе янына килә)*. Йә-йә...

**Хатыны баганага сукмакчы була да тимерне улына тоттыра.**

Айтулы. Син сугып кара, улым... Бик каты сукма, ямме?

Норадын. Сугыйммы, әти?

Айтулы. Кара син бу баланы: әтисе кайтып кергәнгә атна-ун көн узмаган — аның сүзеннән башка берни эшләргә теләми! *(Көлә.)*

Идегәй. Биләүсәдән бик соң төшергәнсең, ахры, син аны. Сук, улым, сук...

Айтулы *(киная белән)*. Атабыз безне киләчәктә дә мендәр почмагын тешләтеп яшәтергә уйласа, тагын ныграк иркә булып үсәчәкбез әле без!

**Идегәй хатынына гаҗәпләнеп карап куя. Норадын шикләнеп кенә баганага суга һәм алар өчәүләп колакларын куеп тыңлыйлар. Капкадан Бәхтияр белән Туктамыш ханның шыгавылы килеп керә: хуҗаларның кыланышларына гаҗәпләнеп карап торалар.**

Идегәй *(кунакларны күрә)*. Ник капка төбендә катып калдыгыз? Түргә үтегез, рәхим итегез. *(Улы белән хатынына.)* Ышандырдыгыз мине — җаны бар икән шул!

Бәхтияр. Нәрсәнең җаны бар, зат шәрифләрегез түрәм?

Идегәй *(елмая)*. Бер сере бар аның... *(Хатынына.)* Кунакларга сусын чыгарт, Айтулы!

Айтулы *(улын кулыннан җитәкли)*. Әйдә, улым!

**Өйгә кереп китәләр.**

Бәхтияр *(алар күздән югалгач)*. Туктамыш синнән кыйбла алыштыргандыр дип шикләнә, түрәм. Бу — минем якташым Ангысын. Ханның шыгавылы. Теге чакта сиңа әйткән идем бит? Тыңгысын атлысы хансарайда калды. Икесе бер кашыктан ашыйлар. Сөйлә, Аңгысын!

Аңгысын. Мин кичә кич ишектә сакта тора идем, Кобогыл би. Ханәш тирмәсе ишегендә. Башта Җанбай би, ханәш янына кереп, синнән шикләнүен әйтте. Шуннан соң, хан килеп кергәч, ханбикә иренә сөйләде: сәргаскәр итеп куяр алдыннан Кобогыл бине яхшылап сына, диде. Дошманың булып чыкмагае, ди.

Бәхтияр *(түземсезләнеп)*. Кыскасы, Җанбай киңәше белән Субра атлы бер аккамны чакыртып, сине анардан сынатмакчы булганнар.

Идегәй. Субра? Ишетеп беләм мин аны! Гомергә Чыңгызлар җырын җырлаган юраучы. Ничегрәк итеп мине сынатмакчылар инде?

Бәхтияр. Ачыгын белмим, әмма Җанбайның нидер маташтыруына шигем юк! Ак яктан кусаң, кара яктан керә, кәбих! Синс

хыянәттә гаепләгәч, бер авызы пешеп, абруе кирләгән иде — тагын хан алдында абруй тота. Картны ул чакыра китте: юрауны үз файдасына хәл итеп кайтачак. Битлеге ачылды! Сине сынауда катнашачак әмирләргә корал яшереп килергә кушкан, имеш! Иртәгә, ауга чыккан булып, сиңа тозак кормакчылар икән. Бәладән баш-аяк, тозаклары ябылганчы таярга кирәк сиңа, Идегәй! Дус бар, дошман бар, дигәндәй.

Идегәй. Качарга өлгерербез... Ике үлмәм, бер калмам! Кызганыч, болгарлардан хәбәр килеп җитмәде! Кисәтүегез өчен рәхмәт, дусларым! Бәхтияр, син иртәгә, кеше аягы басыла төшкәч, Җантимер би улларын — сөт абыйларымны әйтәм — Җаек арьягына алып чык. Мин сезне шунда кояш сөңге буе күтәрелгәндә куып җитәрмен. Очрашкач, калганын аңлашырбыз. Син дә — безнең белән китәсеңме?

Аңгысын. Миннән әлегә шикләнмиләр, Идегәй батыр... Без иртәгә Тыңгысын белән икәү хан чатырын сакларга тиеш: сиңа кирәгебез чыгуы мөмкин.

Идегәй. Яхшы. Мин сиңа ышанам, егет.

**Айтулы белән хезмәтче кызлар тустаганнар белән сусын чыгаралар.**

**59. Тугайлык. Төн.**

**Тугайлыкка хан чатыры корылган. Аңгысын белән Тыңгысын чатыр ишегенең ике ягында айбалталар тотып сакта торалар. Зур чүлмәкләрдә күмер көйри. Читтәрәк — атлар утары. Атлар барысы да иярле.**

**Чатыр эчендә — хан мәҗлесе: Туктамыш үзе, ханәше белән бергә, түргә урнашкан. Аларның уң ягында бик тә бетәшкән кыяфәтле бер карт утыра: ияге, салынып төшмәсен өчен, ефәк яулык белән бәйләнгән. Туктамышның сул ягында — Киң Җанбай. Әмирләр, биләр, дәрәҗәләренә карап, Туктамышка каршы урнашканнар. Идегәй чатыр ишеге тирәсендәрәк. Хезмәтчеләр төрле ашамлыклар, эчемлекләр кертәләр.**

Туктамыш. Уң кулым Кобогыл әмир! Син нишләп үз урыныңда түгел?

Идегәй *(уң кулын күкрәгенә куя)*. Бүген синең яныңда — бөек хан кунагы бар, каган. Мин үземне аның алдында сабый бала кебек кенә тоям. Шуңа күрә урынымны аңа бирдем. Дөрес эшләдемме?

Туктамыш *(килешергә мәҗбүр)*. Син — һәрвакыттагыча зирәклек күрсәтәсең, Кобогыл би! Ул чагында... без сине аякчыбыз итеп билгелибез.

Идегәй. Боер, бөек каган! *(Баш кагып ала һәм хезмәтчеләр кертеп куйган чапчактан эчемлек коя башлый: бер касәгә әче бал агыза һәм, тәхет янына якынайгач, сул учына берничә тамчы тамызып, үзе йотып куя, аннан соң гына алтын касәне ханга тәкъдим итә.)* Рәхим ит, бөек каган. Көрәгәгә бәрәкәт!

Барысы да. Көрәгәгә бәрәкәт!

Туктамыш *(касәне ала һәм, бик әз генә эчеп, саркытын Субрага бирә)*. Субра атлы бөек чичән! Беренче саркытым сиңа — иң кадерле кунагым!

Барысы да. Тау сиңа!

**Карт тавыш-тынсыз эчемлекне эчә. Ул арада Идегәй икенче касәгә бал агыза, сул учына әз генә коеп үзе йота да ханга бирә.**

Туктамыш *(касәне алып, бераз йотып куя һәм беренчесе кебек үк, кунагына бирә)*. Субра атлы бөек чичән! Икенче саркытым да сиңа — иң кадерле кунагым!

Барысы да. Тау сиңа!

**Карт шулай ук тавыш-тынсыз эчемлекне кабул итә. Бу ритуал тагын бер тапкыр кабатлана.**

Туктамыш *(карт өченче касәне бушаткач)*. Субра атлы бөек чичән! Бушаган касәләрне үзеңә калдыр: без аларны сиңа бүләк кылдык. *(Борылып карамыйча гына уң кулын җилкәсе аша артка сузып, бармак шартлата: картның җилкәсенә искиткеч зиннәтле тун китереп салалар.)* Кадерле кунагым! Хәзер кичләр салкыная төште: каган җилкәсен җылыткан шушы тун сине ачы җилләрдән сакласын! Кадерен күр — өстеңдә тузсын!

Барысы да. Өстеңдә тузсын!

Субра *(ул канәгать)*. Кадерләдең-сыйладың мине, олуг каган! Озак яшә! Ләкин... *(Такмаклап китә.)*

Йөздән артык яшәгән,
Җаны-сөяге какшаган,
Азауларын тездереп,
Ак ефәк белән бәйләгән
Бер алҗыган картыңмын!

Табыныңның ямен җибәрүче булмаммы? Билдә ыштан, телдә сүз тормый хәзер минем.

**Көлешәләр.**

Туктамыш. Булмассың, чичән! Син — даның еракларга җиткән юраучы. Теләсә кемнең төп асылын әйтеп бирүче. Ике ягымда ике кулым: сул кулым — баш вәзирем Кәмал би углы Җанбай булса, уң кулым — каршыңда торган аякчым Җантимер углы Кобогыл! Безгә икәвенең дә төп асылын әйтеп бирче!

Субра. Алайса... Икесен дә сынап багыйк, каган! *(Киң Җанбайга.)* Дүрт колак белән тыңлагыз! Бездән борын заманда кырык илгә баш булып Тунику атлы хан торган. Шуның Колатай атлы вәзире даладан ятим бала табып үстергән. Теге бала, үсеп җитеп яугир булгач, Туникуны тәхетеннән кудырып, тәрбиячесе Колатайны хан иткән. Ханга ирешкәч, Колатай, яугиренең башын чаптырып, Туникуны тәхетенә кире кайтарган. Кайсы дөрес эшләгән?

Җанбай. Телдән тел узып, яңа сүз әйтә алмам, йорт агасы Субратай! Минемчә, вәзир Колатай — азамат ир: яман юлга басарга теләмичә, гаделлек эшләгән — тәхетне хуҗасына кире кайтарып биргән!

Субра. Тел төбенә сары май, Җанбай угыл! *(Идегәйгә таба борыла.)* Яшең утыз җитмәсен тугыз йортка дан булдың, азамат ир Кобогыл! Синең сүзне көтәм.

Идегәй. Уйга бай йорт агасы! Колатай вәзир үстергән ятимнең аты Тимертау иде — син, күпне күргән Субра чичән, нигә атын әйтмәдең? Гөнаһын кая куярсың? Өнәндәге сигез хан, эресе-вагы, Туникуга баш булган! Нигә моны әйтмәдең? Гөнаһын кая куярсың? Тунику, Кытайны басып, күккә ашкач, үзен хан итеп үстергән йортка кыңгыр карый башлаган. Көчле көчсезне зар иткән! Тимертау моны аңлаган һәм шуңа күрә гамьсез ханны иленнән куалаган — нигә моны әйтмәдең? Гөнаһын кая куярсың? Мылҗырап йөргән вәзир Колатай асрама улы Тимертауның башын чаптырып бик ялгышкан — минем белгәнем шул, чичән!

**Чатырда тынлык урнаша.**

Субра *(уйланып)*.

Яшь җелектә май була,
Акылы уйга бай була!

*(Туктамышка.)* Касәм коры — чылаттырчы, бөек каган!

**Туктамыш бармак шартлатуга картка бал тулы касә бирәләр.**

*(Идегәй белән Җанбайның икесенә дә карап.)* Икегезгә — бер касә, кайсыгыз эчәргә базыр?

**Җанбай икеләнеп торган арада Идегәй, картның кулыннан касәне алып, эчеп куя.**

Тау сиңа! Афарин, куш йөрәкле батыр икәнсең, Кобогыл! Кулыңнан да, телеңнән дә килә. Ханга дуслыкны ничек аңлыйсың?

Идегәй. Ханга дус булганда — казна өстенә казна арттырып, дәүләт иминлеген күз карасы кебек саклау, дип!

Субра. Ханга дошманлыкны ничек аңлыйсың?

Идегәй. Тәвәккәлләп ат менеп, аның өстенә карчыга булып куну, дип! Казнасын алып — илгә, тәхетен — лаек иргә бирү, дип!

Субра *(Туктамышка)*. Сына да, сына дисең, бөек каган... Әйтмәгә авызым бармыйдыр, бармаса да әйтием! *(Кулына думбра ала һәм, талгын гына чиртеп, көйли.)*

Кара лачын, Бүз тойгын —
Икесе ике ояның кошы икән, әй!
Мин картыңмын, картыңмын,
Күпне күргән картыңмын.
Ни күрмәгән картыңмын?
Башлык та башлык Башлык хан —
Аны күргән картыңмын.
Аннан соңгы — Чыңгыз хан —
Аны күргән картыңмын,
Бәянду хан, Саен хан —
Аны күргән картыңмын.
Билгә булат бәйләгән
Бура солтан Бәрки хан —
Аннан калган картыңмын.
Өзәңгесе өзмә алтын,
Бер өзмәсе мең алтын,
Үзбәк дигән хан үткән —
Аны күргән картыңмын.
Бирдебәк тә хан булган,
Биреме синнән күп булган —
Аны күргән картыңмын,
Олы ханнан тугыз хан,
Кече ханнан утыз хан
Ыгына кергән картыңмын!
Карт бабагыз Туктага,
Аның улы Туйгужа —
Аны күргән картыңмын.
Әй, Туктамыш, Туктамыш:
Яланаяк, яланбаш
Йөреп торган бала идең,
Бүген син дә хан булдың —
Сине дә күрә торамын.
Күп батырны мин күрдем,
Күп батырны мин белдем.
Утыз тешем беткәндә,
Утыз ханны үткәндә
Кобогылдай ирне мин
Бер күрмәгән картыңмын!
Алтыннан суккан Ак Урдаң,
Көмештән суккан ак ишек:
Төшсә тимер чукмары —
Ишегеңне ачар ул.
Кисмә-кисмә сары алтын —
Кисеп илгә сибәр ул.
Кашыклап җыйган малыңны
Чүмечләп чәчеп бетәр ул!
Бар урдаңны алыр ул,
Тәхетеңә бау салыр ул!
Камчы тияр муеныңа,
Кан соргылыр куеныңа,
Такыя олы башыңны
Кисәр булгай шул угыл.
Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул — Кобогыл *(Тына.)*

**Табында шаулашу башлана. Туктамыш хан югалып калган.**

Җанбай. Кобогыл дип йөргәнебез шундый азамат ир Идегәй булгач, күтәрик аны дәрәҗәгә! Бөек каган! Бер аяк бал бирикче үзенә!

Йәникә *(Җанбайны бер сүздән аңлый, иренә пышылдый)*. Агулап бир — башы моннан чыкмасын!

**Йәникәнең сүзен тыңлап торган Аңгысын Тыңгысына күз кыса: ансы шундук караңгыда югала.**

**60. Тугайлыкта атлар утары. Төн.**

**Тыңгысын атлар янында посып торган бер шәүлә күрә.**

Тыңгысын *(шомланып)*. Кем бу?!

Бәхтияр. Бу мин — якташың Бәхтияр! Тыңгысын, синме? Идегәйнең атын үзем әзерләдем. Калган атларның ияр каешларын кисеп чыктым. Йөгәннәре дә яраксыз. Син бар: Идегәйне кисәт!

**61. Хан чатыры. Төн.**

**Әмирләр барысы да сикерешеп торганнар: җиң эчләрендә пычаклары күренә. Идегәй, әмирләрнең кайсы үзенә дошманлык күрсәткәнен хәтердә калдырырга тырышып, ишеккә таба чигенә.**

Җанбай. Тукта, җан дустым! Йоланы бозма: бөек каган сиңа үз саркытын бирә! *(Идегәй янына касә тотып килә.)*

Аңгысын *(ул Идегәйнең артында гына ишек катында пышылдый)*. Эчмә, Идегәй! Ачы салынган!

Җанбай *(шыгавылга Идегәйнең юлына аркылы бас, дип ишарәли һәм Идегәйгә касә суна)*. Мә, жан дустым... Эчеп җибәр! Аннан — җавап сүзеңне әйтерсең... Картның ялгышын төзәт! *(Идегәй касәне алмагач, үз кулы белән эчермәкче булып, аны авызына якын китерә.)*

**Ул арада Туктамыш әмирләргә Идегәйне уратып алырга ымлый; әмирләр аңа якынаялар.**

Идегәй *(юри кыланып)*. Аһ! Иренемә төртеп канаттың, Җанбай! *(Авызын тотып, тышка ташлана.)*

Туктамыш. Беркая чыгармаска!

**Әмирләр Идегәй артыннан ташланалар, Аңгысын белән Тыңгысын да аларга ярдәм иткән булып кыланалар.**

**62. Атлар утары. Төн.**

**Атка атланган Бәхтияр, Идегәйнең атын житәкләп, аның каршына чыга.**

Бәхтияр. Идегәй! Мин монда!

Идегәй *(күз ачып йомган арада атына сикереп менә)*. Очтык, Бәхтияр дустым!

Бәхтияр. Юк, бу якка, Идегәй!

**Караңгылыкка томырылалар.**

Туктамыш. Атларыгызга менегез, йоклаган сарыклар! Җанбай! Кулымнан агу биргәндә син юри аның борынына сугып канаттың! Качарга мөмкинлек бирдең! Бастырып тотмасаң — башың чабылыр!

Җанбай. Минем арттан!

**Җанбай әмирләр белән атлар янына ташлана: ләкин сикереп атланабыз дигәндә генә барысы да иярләре-ниләре белән җиргә егылып төшәләр.**

**63. Хан чатыры. Төн.**

**Туктамыш, чыгырыннан чыгып, аягы туры килгән урындыкларны тибеп очыра. Талгын моң астында биюче җарияләр куркудан катып калганнар. Ханның үзләренә таба килүен күреп, чырулашып чыгып качалар.**

Җанбай *(төсе китеп, урап керә)*. Кичер, бөек каган! Ияр баулары киселеп беткән — куа чыга алмадык! *(Хан алдында тезләнә.)* Башымны чаптыр!

Туктамыш. Бик кирәк иде миңа синең ахмак башың! Идегәй башын китереп сал син минем алга!

Субра. Ялгызы ерак китә алмас ул, каган. Артыннан берничә гаярь егетләреңне чаптыр. Исән-имин китеп котылып, Шаһ Тимергә барып сыенмагае! Шаһ Тимер Сарайны җимерергә форсат кына көтеп ята, булса кирәк. Мин — күп яшәгән, күп ишеткән карт: ел ел артыннан Идел-Йортыбызның талануын күреп сыкрандым мин, каган! Инде, ниһаять, син илебезгә тынычлык китерерлек азамат ир. Идегәй исән калса — иленә дә, үзенә дә аннан аяу көтмә!

Туктамыш *(Җанбайга тибә)*. Бар күземнән югал: таң атканда артыннан бастырып төшкән булыгыз! Көч белән кулыңа төшерә алмасаң, атаңнан калган хәйләңне җик! Тик чабылган башы минем алда булсын!

**64. Җаек елгасы яры. Иртә.**

**Яр буенда учак яна: казан асылган. Берничә ир-ат ит пешерә. Идегәйнең сөт агалары — Җантимер бинең өлкән уллары алар. Бәхтияр дә шунда. Иярләнгән атлары читтәрәк утлап йөри. Идегәй елга бусагасында агач астында уйланып ята. Аның күз карашы елганың аргы ягына — артта калган туган иле ягына төбәлгән. Идегәй сикереп тора: елганың аръягында җайдаклар күренә. Ул җайдаклар арасында Киң Җанбайны таный. Аларга мыскыллы караш ташлап, кире урынына утыра. Идегәйнең тынычланганын күреп, юлдашлары да гамьсез рәвештә аш пешерүне дәвам итәләр.**

Җанбай *(алгарак үтеп, елга аша кычкыра)*. Һай! Идегәй! Каганың сине хансарайга чакыра! Хыянәтче Тимертау кебек хурлыкка төшмә, оятыңа кайт! Игелекле көннән башыңа имгәк табып йөрмә!

Идегәй. Кара елан, Киң Җанбай! Акылың чонтык, тинтәк би! Туннку утыз йортка дан иде — Тимертау аның даның юк итте!

Җанбай. Туктамыштай олы ханга кем каршы тора ала?! Көчленеке замана! Явың булса — чык бире! Тугызга да тулмыйсың әле син! Яудан качкан — ир түгел!

Идегәй. Тугызга тулмасам, күләгәмне кушып сана! Ир булсаң — суны үтеп мине тот!

Җанбай. Атынны кире бор, Идегәй, жан дустым! Туктамыш хан сиңа игезәк кызларын бирә — кияве бул! Яу түбәгә башчы итә — кайтып түрә бул! Җил житмәс иң шәп атын бирә — кайтып кабул ит! Алтын якалы тунын бирә — кайтып җилкәңә сал! Биленнән чишеп булат кылычын бирә — кайтып биленә бәйлә! Мең алтын көбә киемен бирә — кайтып яугир бул! Туктамыш хан сиңа үпкә тотмый — сүзләрен үз колагың белән ишет! Әйдә безнең белән кайт!

Идегәй. Ерактан өреп, якыннан койрык кыскан Кәмал углы эт Җанбай! Ары китеп сөйлә, бире килеп тыңла! Атаң мал биргәннең колы булды, син дә — акча исе чыкса койрык болгый башлыйсың! Анаң — аш биргәннең олтаны иде — син дә Алла бозавы! Юха телеңне сузма бу якка! Пычратмаган куагың юк! Мине ханга саттың — акчаңны тешләп үләрсең!

Җанбай. Кат-кат уйлан, Идегәй! Илеңдә яшь улың белән зифа буйлы хатының ятим калды! Улыңны кем өйрәтер! Хатыныңны кем юатыр?

Идегәй. Биек очсаң да сай йөзәсең, эт Җанбай! Улым — синнән зирәгрәк, тиздән синең үзеңне акылга утыртыр! Хатыным синнән кыюрак: уч төбеңә кара, астыртын эт Җанбай! Бу киткәннән яу кайтып, кырык түбәле Идел-Йортымны алмасам, атым Котлыкыя углы Идегәй булмас!

Җаекның аръягындагы җайдаклар аларга ук аталар, ләкин уклары елгы уртасын да үтә алмый. Бу яктагылар аларга таба борылып та карамыйлар. Идегәй кәгазьгә нидер яза, аны угының сабына урап, бәйли һәм җәясен ала.

И д е г ә й *(җирдә утырган килеш)*. Калканыңны күтәр, эт Җанбай! *(Төзәп тә тормыйча атып җибәрә.)*

### 65. Җаекның алгы ягы. Иртә.

**Киң Җанбай ирексездән калканы белән каплана: Идегәйнең угы, сызгырып килеп, калканын тишеп чыга. Йөзе агарынган Киң Җанбай көчкә читкә янтаеп өлгерә. Иптәшләре аны сырып алалар һәм укка бәйләнгән язуны сүтеп карыйлар. Анда эре хәрефләр белән болай дип язылган: «Әгәр дә минем йортым тирәсендә синең үзеңнең яисә бүтән берәрсенең бөтерелгәнен ишетсәм, кайткач, ир горурлыгыңны печеп, авызыңа каптырачакмын, Киң Җанбай! «Җан дустың» Идегәй.» Җанбай кәгазьне йомарлый һәм иптәшләренә күтәрелеп карамыйча, калага кайтыр якка чабып китә.**

### 66. Җаекның аргы ягы. Иртә.

**Ат пешерүчеләр кычкырып көлеп җибәрәләр. Җитди йөзле Идегәй дошманнары качкан якка уйланып карап тора.**

И д е г ә й *(әкрен генә җырлый)*.

Ап-ак кына тирмәм түбәсендә
Дога гөрли микән күгәрчен?
Ак догасы миңа ирешми шул,
Ишетмәсләр булдым, күрәсең?! —
　Ишетмәсләр булдым, күрәсең, ай,
　Ишетмәсләр булдым, күрәсең...
Якыннарым янда шикелле дә,
Кулым сузсам тапмыйм үзләрен.
Әллә күрмәс кенә булдымы соң
Бөркетләрдән мирас күзләрем?! —
　Бөркетләрдән мирас күзләрем, ай,
　Бөркетләрдән мирас күзләрем...
Алтын бакча, Алтын Урдам шаулый,
Бу кайларда тынар җил икән?
Тәкъдир җиле куган алтын яфрак —
Мин микән ул, әллә ил микән? —
　Мин микән ул, әллә ил микән, ай,
　Мин микән ул, әллә ил микән...

Б ә х т и я р. Аш пеште, Идегәй батыр!

И д е г ә й *(бер карарга килеп, сикереп тора)*. Тамак сипләп алыйк та — Шаһ Тимергә киттек, егетләр! Ризыгыбыз читкә язган булмаса, исән-имин урап кайтырбыз! Сәхрә малайлары ла без! Яңабаштан башлыйбыз!

Беренче фильм тәмам.

*Дәвамы бар.*

# ШИГЫРЬ КЕМГӘ КИРӘК?

Нәрсә ул поэзия? Кем ул шигырь язучы? Бүгенге болгавыр заманда әдәбият кемгә кирәк? Аны бүген үз теләге, эчке ихтыяҗы белән укучы бармы?

Килешәм, сорауларда яңалык юк, борын-борыннан куела килгән бу сорауларга җавапны Буало, Аристотель, Әбугалисина, Мәхмүд Кашгари кебек акыл ияләре, Хафиз, Хәйям, Кол Гали, Сәиф Сараидай — шигырьләрендә сандугач сайраткан шагыйрьләр үзләре эзләгән. Мәгәр хәзергәчә инсанны канәгатьләндерерлек җавапның табылганы юк. Бәлки, аның кирәге дә юктыр. Чөнки һәр чор әлеге борчуларга үз эчтәлеген сала, үзенчә кабул итә, аңлата.

Шигъри сүзгә ихтыяҗ халыкның, җәмгыятьнең үзаңына, тормыш кимәленә бәйле рәвештә, дәверенә карап үзгәчә булса да, чал тарих күрсәткәнчә, сәнгатьнең җаны — шигъриятне яшәүдән туктатырлык көч дөньяда юк икән. Ул — мәңгелек. Һәрхәлдә, җир йөзендә бер генә акыллы зат калганда да, сурәтле фикерләүнең ярсу йөрәге тибүдән туктамас. «Безнең җырлар — үрсәләнгән җаннарга терәк әле» дип язуы белән Лена Шагыйрьҗан хаклы.

Гаяз Исхакый гасыр башында иҗат ителгән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле хисси-мавҗаралы әсәрендә татар милләтенең бетүен, җир йөзендә яшәгән соңгы вәкилләрен тасвирлый. Әдипне төшенкелектә, куркынычны күпертүдә гаепләүчеләр дә табылды. Хезмәт сөючән, язгы үренте төсле яктыга, кояшка тартылып торган халыкның мәңгелегенә ышанган хәлдә дә, Исхакый үз милләттәшләрен уяулыкка чакыра, битарафлык, наданлык, мескенлек, томаналык сазлыгына батудан кисәтә. Бу кисәтүнең ничаклы урынлы һәм вакытлы булуын төссез, җансыз, аңсыз «совет кешеләре»нә әверелүдән чак кына котылып калган буын яхшы күзаллый булыр. Гамьсезлек — заманында ут чәчеп, буран уйнаткан төрки халыкларны шундый аяныч хәлгә төшергән сәбәпләрнең берсе булды.

Ташка уеп куелган борынгы Орхон-Енисәй язмаларында ук «Түрк будун... бик токсар ачсык өзәмсән» («Төрк халкы... Бер туйгач, ачлыкны уйламыйсын»), дип ачынып яза бабабыз.

Бер караганда, шигырь сугыш вә үлем, нәсел калдыру, иген игү, тамак ялгау кебек кеше өчен иң ихтыяҗ нәрсә түгел кебек. Адәм баласы анардан башка да яши ала төсле. Әмма бу — ялгыш караш. Теләсә нинди халыкның телен, моңын, холкын, фигылен шигъри сүз саклый, үстерә, күтәрә.

Үз дәүләтчелегеннән мәхрүм ителгән, яшәешенең нигезенә үз кануннарын сала алмаган халыклар өчен әдәбият ул чакма ташыннан чыккан өмет уты, яшәү чыганагы.

Озак еллар дәвамында шигъриятне реалистик һәм романтик, иҗтимагый һәм лирик-шәхси төрләргә бүлеп өйрәнә килдек. Әдәбият дәресләкләре өчен бәлки анысы да кирәктер. Әмма олы исәптән килеп бәяләгәндә, поэзия ике төрле генә була ала. Үз халкының мәнфәгатьләре, шатлыгы-кайгысы, сөенече-көенече белән яшәгән шигърият һәм тыштан ялтыравык, заманчалыгы мөгез төсле алга чыгып торган, агымдагы сәясәтне, хакимиятне шашынып мактаган, чынында исә битараф, ваемсыз тезмәләр бәйләме. Берсенең эчке януы халык җанына барып тоташса, икенчесенең тышкы ярсуын сүндерү өчен бер чиләк ачы тәнкыйть суы да җитә. Соңгысы халыклар дуслыгы, Ленин турындагы мифлар фаш ителү, КПСС бетү белән үк, комнан ишелгән бау шикелле, юкка чыга, тарихи чор истәлеге булып кына кала.

Гадел шигърият исә илһамны туган халкына мәхәббәттән ала. Бу хисне гадиләштерергә ярамый. Туып-үскән иленне, милләтеңне ярату — аның өчен арабыздан вакытсыз киткән Рәшит Әхмәтҗан кебек җаның, тәнеңне кызганмыйча көрәшә белү дигән сүз. «Бер елмайдым, биш моңайдым, сизмәдем дә таңнар

атты», — дип язган иде шагыйрь. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланнардан соң бу татар поэзиясенең чираттагы олы югалтуы.

Әдәбиятның бүтән төрләреннән аермалы буларак, поэзия һәрвакытта илаһи матурлыкка тартыла. Агымдагы татар поэзиясендә мондый максатлы омтылышның яңа чоры тоталитар җәмгыять диварлары ватыла башлаган сиксәненче еллар ахырына туры килә. СССРны таркатуга алып чыккан хөррият җилләре, иман рухы кайту шагыйрьләрнең аңын, мүкләнә башлаган җанын уятып җибәрде. Гамил Афзал белән бергә бу юлга Рәшит Әхмәтҗан, К. Сибгатуллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Зәйдулла, Г. Морат h. б. шагыйрьләр чыкты. Сынгансындырылган милли рух ныгыды, мәсләк яңарды, үзгәртеп коруга омтылышны, гөнаһлы җәмгыятькә иңгән нурны эзләгән шигырьләр күбәйде.

Гамәл һәм сүз бердәмлегенә ашкынуның икенче чоры — туксанынчы елларда, мөстәкыйльлек игълан ителгәннән соң башланды. Татар халкының сәяси уянуга омтылуы, олы вакыйгалар агышына кушылып китүе, ярты-йорты булса да, бәйсезлек билгеләренең кабул ителүе шагыйрьләрнең күнел күзәнәкләренә тәэсир итте, иҗатка уятты. Тарихи фикерләү алга бәреп чыкты.

Берәүләрне татар халкының Болгар дәүләте, Казан ханлыгы чоры, гасырлар дәвамында кан саркып торган азатлык өчен көрәше белән бәйле олы тарихы рухландырды. Г. Афзал «Сарматлар», «Тарих мең дә...», «Болгар бәете», «Болгарлар» кебек тарихи рухлы шигырьләрендә ерак үткәннең чал сәхифәләрен бүгенге көн, халыкның үзаңын уяту рухыннан килеп сурәтли.

Коммунистик режимның илне талауга, халыкны изүгә, сытуга корылган залимлеген дүрт юлга сыйдырган шагыйрь:

Большевиклар искелекне җиңде,
Яңа юлга чыгып шат булдык.
Яңа юлдан барган идек инде,
Колымага килеп тап булдык.
*(«Яңа юл»)*

Шагыйрьләр татар халкының тарихи шәхесләрен күтәрү, аларның тормышын, көрәшен үрнәк-өлге итеп күрсәтү юнәлешендә дә киеренке эзләнүләр алып бардылар. Татар әдәбиятын кырмавык кебек басып киткән большевик образларын Кол Гали, Колшәриф, Сөембикә, Батырша, Тукай, Сәйдәш, Туфан кебек олы һәм фаҗигале шәхесләрнең сыннары кысрыклый.

Г. Афзалның «Кол Гали», «Сөембикә сылу», Ә. Рәшитовның «Колшәриф», «Сөембикә», Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» әсәрләре олугларның исемнәрен мәңгеләштерү юлында мәгълүм казаныш булдылар. Хәсән Туфанга багышланган ике поэма — К. Сибгатуллинның «Туфан белән сөйләшү», Р. Зәйдуллинның «Койрыклы йолдыз» — шагыйрь образын мәңгеләштерүдә яңа адым саналырга лаек әсәрләр.

Алга бару өчен артка борылып карый белү дә кирәк икән шул. Фаяз Фәиз «Кондыс кыйссасы» поэмасында Польша, Литва һәм Беларусьтагы татарларның ачылмаган тарихын, яңа теманы калкыта.

Ничәмә гасырлар дәвамында каберендә тыныч ята алмаган Чыңгыз хан турында шул исемдәге шигырендә Н. Әхмәдиев нинди яңа сүз әйтә алыр икән, дип укый башлаган идем, әсәр без яшәгән каһәрле чор, шагыйрьнең үз шәхси хисе, рәнҗүе турында булып чыкты («Мескен икәнеңне аңлаулары хәнҗәр булып җанга кадала»).

Хыянәтне, үчлек, явызлыкны
Бармы тагын шулай җыйган җир.
Бүгенгеләр белән чагыштырсаң,
Син фәрештә генә, Җиһангир.

Тарих — кешелек хәтере. Әмма хатирә диңгезендә мәңге йөзеп булмый. Халык бәгыре, халык җаны, матурлык һәм илаһилык җимеше поэзиянең үзегендә бүгенге көн борчулары ятарга тиеш.

Гасыр күкесе С. Баттал «Кеше иҗат миссиясен Үтәр өчен туа. Аның ничек үтәлүен Вакыт карап тора», — дип бик урынлы һәм вакытлы кисәтә.

Каршылыкларны Галәмнән, Вакыттан эзләү бер хәл. Ә бит һәр кешенең үз эчендә катлаулы төерләр, үкенечле сагышлар, авыр таплар утыра. «Багышлау», «Аңлашуга өмет», «Син ышанма, Аллам, аларга» шигырьләрендә Лена Шагыйрьҗан шул хакта уйлана: «Синең исем белән тырыша алар Адым саен сине алдарга».

«Гаделлеккә сусап алжыган Кеше җаны өчен көрәш бара»,— дию белән К. Булатова хаклы («Соң булса да...»).

Х. Әюп «Авыл җаны», «Көй эзләү», «Су хәтере», «Көзге» кебек кечкенә күләмле, тыгыз эчтәлекле поэмаларында, күңел байлыгын, фикер иркенлеген эченә алган шигырьләрендә рухи дөньяга игътибарлы, тормыш киеренкелеген фәлсәфи уйларга төреп, тәгәл һәм ягымлы итеп ачып салырга омтыла.

...Үз-үземә урын табалмыймын—
Кая куйыйм сине, авыл җаны?!
*(«Авыл җаны»)*

Сина шатлык каян килсен, Казан,
Сатлыклардан булган бәхетең!
*(«Су хәтере»).*

Йөрәктә бөреләнгән шигырь икейөзле була алмый, ул — сер саклый белми, эчендәгесе тышында — фикер сөрешендә, сурәтлелек чараларында. Кайберәүләр поэзияне замана өчен файдалы, отышлы фикер-ниятләрне һәм кешенең рухи дөньясын хисси телгә салып биргән аралашу чарасы дип кенә кабул итәләр. Бу да — хата караш. Шигырьдә иҗатчының тынгысыз җаны, гаҗиз йөрәге ачылырга тиеш. Менә ике мисал.

Р. Фәйзуллин алтмышынчы елларда фәлсәфи публицистик поэманың югары үрнәкләрен бирде: «Көрәшчеләр кирәк», «Гадиләргә гимн». Үз чоры өчен ачыш булган бу әсәрләр шагыйрьнең яшьлек романтикасын үзәккә алды. Әмма хәзерге җәмгыятькә гадиләр дә, ул чорда кабул ителгән мәгънәдәге көрәшчеләр дә кирәк түгел икән.

Шагыйрьнең «Нюанслар иле», «Минем әти», «Менә без дә үсеп життек, әни» шигырьләре, мәхәббәт лирикасы яшь. Беренчеләре шагыйрьнең зирәк акылында туган, икенчеләрендә шагыйрьнең шәхси тормышы, үз кичерешләре шигъри сынын тапкан.

Шактый вакыт эндәшми торгач, табигый булган үкенү-эзләнү чорын кичергәч, үткән елның азагында «Заман кемнең заманы?» исемле шигырьләр көлтәсен бастырды Р. Фәйзуллин. Кыска парчалары да тиешле дәрәҗәдә эшләнгән. Берничә шигырьне эченә алган, тәгәл исеме табылган «Көзге күкрәү» көлтәсе ихласлылыгы белән күңелдә кала. Үзәктә җитлеккән, ир уртасы яшен үткән шәхеснең мәхәббәте, үзе һәм тормыш турында уйлануы ята. («Батыр калыр көч тоеп та, көрәшмәгән хәлемдә»). Шагыйрьнең әле ачылмаган тормыш тәҗрибәсе, хисси йөрәге — таянычы бар икән. Аның уйланулары ышандыра.

Язмыш иҗат кешесен туктаусыз сыный, җиз иләк аша уздыра. Ренат Харис һәрвакыт житәкче эшләрдә, хакимият дилбегәсен кулларында тотучылар кырында булды. Ул — хәзер дә иярле ат өстендә. Бу хәле шагыйрьлегенә зарар китермәде, үзенчәлекле, ачык сурәтле, кыю метафоралы, тормышның башкалар күрмәгән, сизмәгән кыйтгаларын, кыйблаларын ачып бирүдә киртә була алмады. Шагыйрьнең Дәрдмәнд, Җәлил, Фатих Кәрим кебек поэзиябезнең алтын баганаларына багышланган бәйләмнәре, «Рәссам», «Ат иярләү» поэмалары әдәбият тарихында урын алган әсәрләр.

Шул ук вакытта Р. Харис, башка шагыйрьләребез төсле үк, большевиклар кылган гамәлләргә, Ленин турындагы әкиятләргә дә ышанды, аларны поэзиясе түренә кертте. Ә бит Шайтанга хезмәт итү — эзсез кала алмый.

Шигъри йөрәк бәргәләнде, эзләнде, алтын читлекне ватып чыгу юлларын эзләде. Соңгы ике елда Р. Харис татар поэзиясенә Көнчыгыш шигърияте рухын, Кандалыйлар мәхәббәтен алып кайтты. «Өч үбешү», «Мәхәббәт шигырьләре» шуның ачык үрнәге. Кемдер аның эротик поэмасын, мәхәббәтнең җаннан бигрәк тәнне, тышкы матурлыкны, женси ләззәтне күтәргән өлешен кабул итмәс. Мәгәр шагыйрьнең порнографик түбәнлеккә төшмичә, хатын-кыз матурлыгын үзенчә күрә һәм сурәтли алуын инкяр итеп булмый. Бу төр шигърият укучыны кулда тоту, югалтмау өчен дә кирәк әле. Р. Фәйзуллин шикелле үк, шагыйрь иҗатының үзгә бер чорына кереп бара дип фараз кылырга нигез бар.

З. Мансуров та Ленинда пәйгамбәр һәм изге җан эзләвенә үкенеп, тәмам тәүбәгә килеп, «Хозыр галәйһиссәләмне эзләү» поэмасын иҗат итте. Бу әсәрдә кешелек тарихында һәм һәркемнең күңелендә явызлык белән имансызлык, вәхшилек белән миһербанлык арасындагы көрәш ята дигән фикер үзәккә алына:

Изгелекле Ата эзләренә
өммәтсезлек көн дә көл сибә...

Пакьләндергеч Хозыр
пәйгамбәрнең
ясинчысы
яши
кешедә.

Өлкәнрәк буыннан И. Юзеев, Ә. Баянов, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Гаташларның соңгы басмаларында тәүбә, үкенеч һәм милли рух көчәя баруы сизелә.

Әдәбият һәрвакыт аңлауга, яклауга, ярдәмгә мохтаҗ. Шул ук вакытта шагыйрьләр арасында туктаусыз ярыш, бәйге рухы яшәргә тиеш. Сибгат Хәким әйтмешли, бер-беребезгә төрткәләп тору лазем.

«Бәйге» исемле сатирик балладасында Ә. Фәйзи халык мөнбәрендә урынга дәгъва иткән бик кызыклы шигъри типларны дөнья яктысына тартып чыгарган иде.

Дулкынлана диңгез шикелле,
Шау-гөр килеп, дала,
Сайлый халык монда үз шагыйрен.
Бик зур бәйге бара.

Публицистика һәм проза өлкәсендә хәзер еш кына ярышлар уздырыла. Асылында чичәнлек, ягъни үзара сүз әйтешү, такмак, фикер көрәштерү яткан шигырь өлкәсендә әлегә диңгез дулкынланмый, дала тын килеш кала килә...

Ә менә халык елмаеп сөйләү, аның язучысы исә кычкырып көлү сәләтен югалтып бара икән. Сатирик поэзия Сәнди Мәндиев, тәвәккәл әби, Әсмабикә җаным-ахирәт, Шәрифулла күрше турындагы әсәрләрдә ирешкән үрендә калды. Бүген мескен хәлгә төшерелгән әби-бабайлардан мыскыл итеп көлеп кенә ерак китеп булмас. Хәзер башка дәрәҗәдәге юмор кирәк. Ә сәяси сатира сәхнәдән үк төшеп китте.

Чын байлык — Син... Урлый алмыйм — куркам мин
«Мәкәрҗәдән» ирең кайтып төшәр, дип, —

язуы белән Р. Гаташ хаклы. Әлегә куркыбрак, шикләнебрәк, як-якка карабрак иҗат итәбез. Беребезгә рәсәй «Дружба народов» орденын биреп, Е. Евтушенко кебек, хөкүмәт алып барган сәясәт белән килешмичә, аны алудан рәсми баш тартырга кыюлыгы җитәр идеме икән берәр татар шагыйренең?! Кистереп әйтүе кыен.

Поэзия тәнкыйтен сүтү — Дон Кихотның җил тегермәне белән сугышуы кебегрәк гамәл булыр иде. Ул — юк. Яшьләр тәнкыйтькә килми. Аның абруе бетте. Үз иҗатына ераккарак китеп карау сәләтен югалткан исемле шагыйрьгә сүз әйтү дә куркыныч. Кемгә кирәк бу заманда шәхси дошман?! Мәгәр шигърият турында сөйләшү юлына чыкканбыз икән, димәк, аның бүгенге торышы, хәле шатландырмый — анда барысы да ал да гөл түгел. Яңачалык, кыюлык житешмәү, фикерләүдәге торгынлык, элек ачылган юлдан атлау укучыны югалтуга алып килә.

Үткәннәр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, гасыр ахырында шигъриятгә үсеш күбрәк эчке уйлану, моңлану, сызлану рәвешендә бара. Эзләнүләр күбрәк шигырьнең тышкы киемен яңарту, сүз-тел бизәкләре, тел чарлау өлкәсенә күчә. Инде шәүләсе күренгән яңа гасыр башында ясалачак «шартлау»га әзерлек алып барыла.

XXI йөздә Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиев кебек олы йолдызлар кабынсын иде татар поэзиясе гөмбәзендә!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН.**

# ШИГЪРИ ПУБЛИЦИСТИКА

Сиксәненче еллар ахырында шигъри публицистика шактый җанланып киткән иде. Иҗтимагый-сәяси сүз әдәби-нәфис сүзне бераз кысрыклап, алгы планга чыкты. Шагыйрьләр дә, лирик булудан бигрәк, сәясәтчегә әйләнә башлады.

Соңгы бер-ике елда бу шигъри дулкын, иң югары ноктасын үтеп, кимүгә таба бара. Публицистика публицистика булып, шигърият исә шигърият булып калды. Публицистикада турыдан-туры «маңгайга бәреп» әйтү, үгет-нәсихәт тә урын алырга хаклы. Шигъриятнең исә законнары башкача.

Менә, әйтик, Сафуан Мулла Гали читкә сибелгән татарларны Татарстан жиренә кайтырга үгетли: «Моңаясың, татар, саргаясың, чит жирләрдә илне сагынгач... Канлы яшең ташны тишә синең, Тама-тама — тамып кич-иртә. Өмет әзмә, татар, ничек тә, Кайт Иленә — юлга кичекмә!»

Әлбәттә, мондый шигырьләр дә яшәргә хаклы. Ләкин аларда публицистика алымнары поэзияне кысрыклап чыгара, шигырь рифмалаштырылган мәкаләгә әйләнә яза. «Саф» публицистика исә бу максатны яхшырак башкара ала. Публицист — фактлар, дәлилләр китерә, укучыны хис-эмоция белән генә түгел, фикер көче белән ышандыра.

Соңгы еллардагы шигъри публицистиканың иң югары ноктасы турында сүз йөрткәндә, мин Рәшит Әхмәтжанның «Ачлык мәйданы» китабын күздә тотам. Монда публицистика белән шигърият, йөрәк ялкыны белән фикер көче, эчке инану белән сүз көченә ышану бик тыгыз, аерылгысыз үрелгән. Шагыйрь Ирек мәйданында ачлык игълан итүчеләрне читтән күзәтеп кенә йөрмәгән, үзе алар арасында булган, үзе ачлыктан интеккән. Шигырьләрдәге геройларның исемнәре дә чын, документаль. Хисләре, кичерешләре дә чын, алдаусыз. 1993 елда чыккан бу китап шигъри публицистиканың асыл үрнәге булып санала ала. Рәшит Әхмәтжан үз йөрәген Данко йөрәге сыман дөрләтеп яндырган, шуңа да аның шигъри юллары жаннарны көйдереп-өтеп ала.

Бу темага күпләр язды. Менә, Шамил Маннапның «Ирек мәйданы. 1991 елның мае» исемле шигыре («К. У.», 1994, 9 сан). Шигырь профессиональ осталык белән язылган. Образлары да матур, күңелгә ятышлы: «Бу мәйданда ачыгучыларны Санау өчен бармак житәдер. Ләкин сусау... Азатлыкка сусау Интектерә инде күпләрне». Шулай да бу юлларда Рәшиткә хас ялкын, чын күңелдән инану житенкерәми. Әйе, шигъри публицистиканы, шигъриятнең башка жанрлары кебек махсус язып булмый. Ул үзе языла, үзе шигъриятка бәреп керә.

Менә, әйтик, Гамил Афзал. Гомер-бакый ижтимагый проблемалар турында уйланып, милләт язмышы турында кайгыртып яшәде һәм ижат итте. Аның лирикасында сатирик төсмерләр әледән-әле чагылып китә. Сатирик шигырьләренә дә лирик жылылык хас. Рөстәм Мингалимнең дә ижтимагый-сәяси темалардан читләшкәне юк. Бу өлкәгә Зиннур Мансуров, Әхсән Баянов, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла да житди, төпле шигырьләре белән сизелерлек өлеш керттеләр.

Болар барысы да — көтелгән, табигый дип кабул ителә торган уңышлар. Әмма көтелмәгәннәре дә бар. Шундыйлардан мин Илдус Гыйлажевнең «Казан утлары»ның жиденче санында басылган (1994 ел) шигырь бәйләмен күрсәтеп үтәр идем. Шагыйрьнең колачы киң, фикере үткен, күтәргән проблемалары житди. Иң мөһиме исә — аның шигырьләрендәге публицистика тирән хис белән үрелеп бара. Шуңа да Илдус шигырьләре ышандыра, күңелгә тәэсир итә.

Без хәзер социализмнан капитализмга күчү чорын кичерәбез. Ләкин цивилизацияле илләрдәге күркәм йөзле капитализмга түгел, ә кыргый, комсыз, вәхши капитализмга күчәбез кебек. Торгынлык чорындагы партия функционерларының, эш урыннарын алыштырса да властьны үзләрендә саклап калды. Алар бүген дә хакимияттә. Алар тирәсендәгеләр, властька таянып, дәүләт милкен үзләштереп калырга ашыгалар, ил байлыгына кул сузалар, халыкны кычкыртып талыйлар. Яшәү рәвеше үткән елларга караганда күп түбән. Анысы бер хәл, монысына гына түзәр идек әле, — тигезсезлек артты. Яңа байлар барлыкка килде, мафиозлар, рэкетерлар — кендекләре шулар белән үк береккән эшкуарлар. Бер яктан, ике-өч катлы коттеджлар төзелә, Канар утрауларына ялга йөрүчеләр арта, икенче яктан, күпләр хәерчелектә интегә.

Бу күренешләр бүгенге шагыйрьләрне борчымыймы? Борчый, һичшиксез борчый. Көндәлек мәсьәләләр Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гаташ, Харрас Әюп, Ренат Харис һәм башкаларның ижатларында теге яки бу рәвештә чагылыш таба. Ничек атарга мондый шигырьләрне? Шигъри публицистика дипме, әллә гади шигырь дипме? Монысы мөһим түгел. Иң мөһиме — шигырьнең укучы күңеленә ясаган тәэсир көчендә.

Безнең заман — сораулар заманы. Прозаик Аяз Гыйләжев «Балта кем кулында?» дип баш ватса, шагыйрь Равил Фәйзуллин «Заман — кемнең заманы?» дип уйлана.

Кѳтмәдекме безне баскан
басымның басылуын?
Җанга, рухка, хәр фикергә
юлларның ачылуын?

Кѳттек, кѳттек. Ниһаять,
күзләр шәрран ачылды.
Күз алмасына шәп-шәрә
чынбарлык кереп тулды.

Менә бу «шәп-шәрә чынбарлык» шагыйрьне борчулы уйларга сабыштыра. Ул империя коллыгыннан котылу юлларын эзли, демократиянең тышкы тѳсләренә дә алданмый, чѳнки аның җисеменнән иске, юылмаган сасы ис килә. Шагыйрь конкрет кешеләрне гаепләү белән чикләнми. Тарихи Хатаның тирән сәбәпләрен барыбызның да күңел тѳпләреннән эзли. Фәйзуллин публицистикасына фәлсәфи яңгыраш хас. Ул барысын да әйтеп бетерми, укучыга уйланырга, үзенчә нәтиҗә ясарга урын калдыра. Укучы аның ѳчен элеккечә иптәш кенә түгел, ул — галәмдәш тә, замандаш та, илдәш тә, милләттәш тә, кардәш тә, җандаш та...

Равил Фәйзуллин замандашларына ышанып караса, Лена Шагыйрьҗан исә күп вакытта аларга ачынып-кѳенеп карый, хәтта нәфрәтен дә яшерми. Аның ѳчен алар арасында тѳрле-тѳрле типлар бар:

Атасызлар, Анасызлар,
Ватансызлар, Алласызлар,...
Алма бакчаларын корытып,
Мәхрүм калган алмасызлар...

Корабсызлар, җилкәнсезләр...
Мәчетсезләр, имамсызлар...
Мәгънәсезләр вә тозсызлар,
Шәригатьсез, имансызлар...

Бер караганда, шагыйрә кешеләрне кимсетә кебек. Әмма тѳплерәк уйласаң, бу кимсетүдә кешеләргә ышану да, аларның Кеше булып калуларына ѳмет тә чагыла. Дѳрес, шагыйрә күбрәк мәхәббәт лирикасын яза, «җитми калды сѳю ялкыннары», — дип уфтана. Әмма публицистик аһәңнәр дә аның лирикасында бик ачык яңгырый.

Илдар Юзеев үзенең «Казан утлары»нда (1994 ел, 9 сан) басылган шигырь бәйләмен «Моңсу шигырьләр» дип атаган. Чыннан да, алар шагыйрьнең элеккеге шигырьләре белән чагыштырганда шактый моңсу яңгырыйлар: «Кесәләр буш... Күңелем хуш... Акчасыз-нисез җырлыйм. Гармун уйнап, бүрек тотып Урамда гына тормыйм». Менә ул — шәп-шәрә яңа чынбарлык! Бүген ул безнең барыбызга да кагыла. Аңардан күз йомып кына котылып булмый. Ул теләмәсәң дә, шигырьгә үзе бәреп керә.

Ләкин заманның күзгә чалынган һәрбер күренешен чын публицистика дип әйтеп булмый әле. Бу турыда Нәҗип Мәдьяров бик матур итеп әйткән:

Зурдан кубып, яңа җырлар эзләп
Чыгып йѳрим иген кырларына.
Ияреп кайта чалбар балагына
Кайчагында фәкать сырлан гына...

Әйе, күргән бер нәрсә шигырьгә фәкать сырлан булып кына да кереп тула ала. Әлеге күренеш йѳрәк аша узып, аның җылысын алса гына чын шигырьгә әйләнә...

Әйтик, бүгенге кѳн күренешләре Әзһәр Габидинең «Казан утлары»нда 1994 ел, 12 сан) басылган шигырьләрендә шактый мул сибелгән. Шагыйрь бүгенге кѳн турында, үткәнебез, киләчәгебез турында уйлана. Ләкин шигырьләре никтер күңелгә үтеп керми, укылу белән шундук онытыла. Ни ѳчен? Моның сәбәбен, минемчә, шагыйрь үзе түбәндәге юлларда ачып бирә: «Канәгать булып яшим мин Туган ил бирнәсенә...», — ди ул. Чыннан да, шагыйрь канәгать, артык канәгать булып яши. Аның ѳчен барысы да ал да гѳл, барысы да яхшы. Моны шагыйрь: «Елмаеп кына барырмын Дусларым каршысына. Чәчәкләр генә бирермен Мин аларның барсына» — дип ярып сала. Әйе, һәркемгә чәчәкләр генә ѳләшеп яшәү бик рәхәт булыр иде дә бит, алай яшәп булмый шул. Чын шигърият тирә-як мохиттән канәгать булмаудан башлана...

Бармы соң бүгенге поэзиядә әнә шундый чын шигырьләр? Аллага шөкер, бар. Шундый шагыйрьләрнең берсе — Рөстәм Сүлти. Аның публицистика лирикасыннан аерылгысыз. Лирикада булсынмы, публицистикада булсынмы, ул кеше күңелен аңларга, кешенең рухын иңләргә тырыша. Аның каләме астында күптән таныш, күнегелгән образлар бөтенләй яңача яңгыраш таба. Әйтик, шул ук күптән таныш, күнегелгән Шүрәле образы:

«Былтыр кысканга ник быел
Кычкырасың соң?» — димә.—
Ул кысуның авыртуы
Үткәнгә бәгыремә...
Шүрәлесең,— тик көлмә!

Җанымны кысты ул чөнки,
Телемне, ил-көнемне,
Кысты, кысты газизләрдән
Газиз булган денемне...
*(«Казан утлары», 199', 12 сан.)*

Шулай итеп, шагыйрьнең фикере үсә, ул зур гомумиләштерүләргә ирешә... Туган халкының язмышын үз язмышы итеп кабул итә: «Миңа тигән өлеш — каргыш, каргыш янә каргыш...» Алай гына да түгел, ул барлык төрки халыкларның язмышын да үзенеке кебек кабул итә, Идел-Урал, Төркестан, Кырым, Төрек дәүләтләре язмышлары турында уйлана...

Публицистик рухтагы шигырьләрнең төп темасы — милли азатлык, бәйсезлек темасы. Шигъриятебез халыкның үзаңын үстерүгә шактый зур өлеш кертә.

Сез кайларда, татар угланнары?!
Калдырасыз мирас кемнәргә?!
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
Җыр җырлыйсыз нинди телләрдә?
«Әнкәй!» — дисез нинди телләрдә? —

дип сорый Марис Нәзиров («Казан утлары» 1994, 11 сан) хәер, милли тема социаль тема белән бик тыгыз үрелеп бара:

Җан кибә тулай торакта,
Кысынкы ул, караңгы.
Үрелгәч, калҗа сузалар,
Тик ак дисәң караны...—

дип яза үзенең яшәү мохиты турында шул ук Нәзиров.

Әлбәттә, бер шагыйрь дә бүгенге җәмгыятьнең тулы картинасын тудыра алмый. Һәр шагыйрьдән аны таләп итеп тә булмый. Әмма барлык татар поэзиясен алсак, шактый тулы картина күз алдына килеп баса. Әйтик, Нур Әхмәдиев, үз халкының үткәне һәм бүгенгесе турында уйланып, болай ди: «Сарык булулары, ай, туйдырды, Кеше булуларга зарыктык...» Милләт язмышы аның иҗатында зур Ватан язмышы белән килеп тоташа:

Этләр өрә, бүре йөри тора,
Зәңгәр күктә йолдыз атыла...
Өрә-өрә этләр ни саклыйдыр,—
Бездән урлап Ватан сатыла.

Бу юлларны укыгач, Союз таркалуы турында да уйланасың, Рәсәй язмышы да күз алдына килеп баса, Татарстанның киләчәге дә пошындыра...

Газинур Морат Татарстан язучыларының XII съездында сөйләгән докладында: «Поэзия — намус, әхлак кебек үк, беркайчан да үсеш-үзгәреш кичерми торган статик категория»,— дип әйткән иде. Мондый караш белән берничек тә килешеп булмый. Поэзия алдында куела торган таләпләр дә, шигърият үзе дә беркайчан да статик хәлдә булмый, булганы да юк. Ул тормыш кебек үк туктаусыз үзгәрештә. Дөрес, ул һәрвакыт үсештә дип әйтә алмыйм. Кайчакта шигърият артка да чигенә, бер урында да таптана. Әмма барыбер үзгәрешсез тормый.

Соңгы елларда шигъриятебезнең элекке штамплардан шактый уңышлы арына баруын күрәбез. Әйтик, күп еллар буе аерым кешегә социаль яисә производство берәмлеге итеп карау яшьи иде. Кеше, шәхес булудан бигрәк, йә алдынгы терлекче, йә нефтьче, мехчы, ташчы, кыскасы берәр тармак эшчесе буларак кына

сурәтләнә иде. Таштан коелган кебек нык ихтыярлы большевикларны да, кансыз акгвардиячеләрне дә, комсыз кулакларны да күп күрдек. Хәзер исә поэзиябездә кеше беренче нәүбәттә кызыклы, тулы канлы шәхес буларак күз алдына килеп баса.

Күп еллар буе без яңа кеше тәрбияләү турында хыялландык. Әдәбиятны да шуңа юнәлдердек. Баксаң, яңа кеше дигәнебез буш куык кына булып чыкты. Мәңгелек кеше исә,— Кол Галиләрдән килә торган кеше — һаман яши, яңадан-яңа яклары белән ачыла.

Соңгы берничә ел эчендә хатын-кызлар шигърияте көтмәгәндә үсеп, ачылып китте. Китапханәләрдә үткәрелгән тикшерену буенча, иң укыла торган шигъри китаплар арасында Эльмира Шәрифуллина китаплары бар. Очраклы фактмы бу? Юк, әлбәттә. Әмма бездә аңа әллә ни игътибар бирүче булмады.

Нурия Измайлова иҗаты шигъриятттә үзенә аерым бер урын биләп тора. Аңа да игътибар итеп җиткермибез.

Үткән елны шагыйрә Салисә Гәрәева һәм Флера Гыйззәтуллина матур-матур шигырь бәйләмнәрен бастырдылар.

Ә яшьрәк буынны алып карагыз: Халисә Мөдәррисова, Илсөяр Иксанова, Рифә Рахман, Фәйрүзә Исмәгыйлева һ. б. Әдәбиятка яңа аяк басучылардан Ләйсән шигырьләре дә өмет уята.

Хатын-кызлар шигърияте поэзиябезгә яңа төсмерләр дә алып килә: эчкерсезлек, ихласлык, хискә бирелү. Дөрес, алар күбрәк мәхәббәт, сагыну, тугрылык турында язалар. Әмма бүгенге мохитне дә читләтеп узмыйлар: милли, иҗтимагый мәсьәләләр турында да шул ук ихласлык, эчкерсезлек белән язалар. Минемчә, хатын-кызлар шигърияте аерым бер сөйләшүне таләп итә торган зур, җитди тема.

Әйе, поэзиябез заман үтү белән үзгәрә тора. Әмма шулай да сүз иреге ачылу белән без поэзиядән күбрәкне көтәргә дә хаклы идек. Элек, цензура басымы булганда, шагыйрьләр әйтергә теләгән фикерләрен ничектер киная белән генә, яшертен-астыртын гына әйтә алалар иде. Шигъри әсәрне дә без күбрәк нәфис булганы өчен түгел, кыю әйткәне өчен мактый идек.

Хәзер инде кыюлык белән беркемне дә шаккатыра алмыйсың. Бүген барыбыз да кыю, барыбыз да усал телле. Димәк ки, алгы планга шигъри әсәрнең эшләнеше, поэтик яңгырашы килеп баса. Ә бу инде таланттан тора. Моны шагыйрьләр үзләре дә аңлый. Гамил Афзал, мәсәлән, «Эзоп теле белән сөйләшкәндә, мәгънәлерәк иде сүзебез», дип юкка гына әйтмәгән. Әйе, мәгънәлерәк тә, сәнгатьчә эшләнеше дә югарырак иде шигырьләрнең. Монда таләпчәнлекнең кимүен дә күрсәтеп китәргә кирәктер. Элек, һәр сүз җиде иләк аша чыкканда, туры сүзне генә түгел, зәгыйфь сүзне дә матбугат битләренә чыгармаска тырышалар иде. Хәзер исә җыен чүп-чар җиңелрәк дөньяга чыга.

Шагыйрьләребез яңа тормыш, яңа күренешләр алдында бераз каушабрак калдылар сыман. Бу каушау озакка бармас, тиздән үтәр дип ышанасы килә...

**Рафаэль МОСТАФИН.**

# ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР КАЯ КАЧКАН?

Белгәнебезчә, соңгы елларда татар милләтенең матбугат мәйданы нык кына киңәйде. Дөрес, дөньяның алга киткән бүтән халыклары белән чагыштырып караганда, безнең матбугат әле һаман да мескен хәлдә. Мисалга Балтыйк буе халыкларын китерү дә җитә — аларда басмалар саны бик күпкә артык. Нәтиҗәдә, милли аң да нык югары. Шулай да, артта калган торгынлык елларын искә төшереп, без татарлар бүгенге хәлгә дә сөенәбез.

Ләкин безне бүген шунысы нык уйландыра: ни өчен әдәби тәнкыйть үсми? Милли матбугат белән бер адымнан ул да үсәргә тиеш иде бит. Ә безнең әдәби тәнкыйть исә соңгы елларда, киресенчә, бик тә сүлпәнәйде. Аны хәтта «үлде» диярге дә була кебек.

Әдәби тәнкыйтьнең шулай сүлпәнәюен тарихи закончалыклы күренеш, дөрес күренеш итеп күрсәтергә тырышучылар да юк түгел. Мисал өчен, безнең бер каләмдәшебез язучылар алдында элегрәк ясаган чыгышында әдәби тәнкыйтьне «торгынлык чоры җимеше» дип аңлатырга тырышкан иде. Әдәби процессны кулда тоту өчен партия тарафыннан уйлап чыгарылган «дилбегә» сыманрак итеп күрә икән ул әдәби тәнкыйтьне.

Мондый фикернең бик тә тар караш икәнлеген раслау өчен үзебезгә бер-ике генә сорау биреп карыйк. Тукайлар, Әмирханнар, Исхакыйлар чорында — ә урыс тормышын алсак, Белинскийлар, Добролюбовлар чорында «дилбегә» кирәк булганмы соң? Ул чорда бит әдәби тәнкыйть гөрләп чәчәк аткан!

Хәзерге чорның иреклерәк яшәүче, алга киткән бүтән милләтләрен алсак та, аларга «дилбегә» нигә кирәк икән соң? Аларда да бит әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть бүген актив хәрәкәттә: анда әдәби тәнкыйть буенча махсус журналлар басыла, том-том китаплар чыга, әдәбиятның актуаль проблемалары буенча галимнәр, белгечләр еш кына җыйналып сөйләшәләр.

Әйе, бераз тирәнгәрәк һәм алгарак карый алсак — үзебездә әнә шундый интеллектуаль көч таба алсак — без әдәби тәнкыйтьнең бүген татар халкына бик тә кирәк икәнлеген күрербез. Чөнки әдәбият турында, яңа гына басылып чыккан әдәби әсәрләр турында уйлана-уйлана (ә әдәби тәнкыйть ул — нәкъ әнә шул процесс дигән сүз) милләтнең зиһене үсә, фәлсәфи фикер офыклары киңәя, дөньяны тоюы нечкәрә, эстетик зәвыгы яңа баскычка күтәрелә. Яңа әсәрләр турында матбугат аша сөйләшә-сөйләшә милләтнең тагын да гүзәлрәк әдәби әсәрләр иҗат итә алу потенциалы да арта! Чөнки рухи, фәлсәфи яктан эшкәртелгән, ашланган «туфракта» яңа үсентеләр яхшырак үсә. Ә кыргый, ташландык җирдә чүп үләннәре генә тантана итә.

Үткән 1994 ел дәвамында вакытлы матбугатта басылган әдәби тәнкыйть әсәрләребез үзләре үк моны раслап тора. Мисал өчен, Айдар Хәлим бер үзе генә дә «Ватаным Татарстан» битләрендә өч зур мәкалә бастырды. 28 январь санында Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында, 15 июньдә Ямаш Игәнәй иҗаты һәм Кырым татарлары фаҗигасе турында, ә 4 ноябрь санында каһарман әдибебез Фәнис Яруллин иҗатыннан һәм тормышыннан берничә сәхифә бирде ул.

Бу язмаларның өчесендә дә күренекле шагыйрьләребезнең язганнары милләтнең сәяси һәм әхлакый тормышыннан чыгып карала. Олы Иҗат һәм Чын Гражданлык турында фикер йөртелә аларда. Әйе, милләтебез әле һаман да диярлек коллык хәлендә яшәп ятканда, безгә Иҗатчының Олы Гражданин булуы бик тә кирәк. Айдар Хәлим соңгы елларда үзенең бөтен иҗаты һәм эшчәнлеге белән безне әнә шуңа чакыра.

Күрше Киров өлкәсендә яшәп иҗат итүче каләмдәшебез Рафаил Сибат үткән ел шулай ук әдәби тәнкыйтьтә дә актив катнашты. Аның шагыйрь Харрас Әюп иҗатына багышланган «Гомерлек Аргамак» исемле язмасы («Ватаным Татарстан», 29 июль саны) үзенчәлеге һәм шагыйрь иҗатын нечкә, тулы тоюы белән истә кала.

Өлкән каләмдәшебез Гариф ага Ахунов, гадәттәгечә, үткән ел да төрле жанрларда бик актив эшләде. Аның «Ватаным Татарстан»да (18 февраль саны) басылган «Колшәрифкә килү юлы» исемле мәкаләсе — бу язма шагыйрь Әхмәт Рәшит иҗатына багышланган иде — миңа бигрәк тә ошады. Биредә тирәнлек тә, киңлек тә һәм шагыйрьнең иҗаты, тормышы турында җитди фикер йөртү дә бар.

Тәлгат Галиуллинның Равил Фәйзуллин иҗаты турындагы «Боз өстендә учак» дигән мәкаләсе, Газинур Моратның Ркаил Зәйдулла китабы турындагы язмасы да «җитди язма» дигән фикер калдыралар.

Әдәбият галимнәреннән Нил Юзиевнең Тукай иҗатындагы бәхәсле мәсьәләләр турындагы, Фәрит Бәшировның «Бул яхшы, рәнҗетмә...» исемле язмалары да, бу жанрда каләм уйнаткан башка авторларга үрнәк булыр дәрәҗәдә — тирән акылны һәм кайнар хисне эшкә җигеп иҗат ителгәннәр.

Күренекле шагыйрьләребездән Шәүкәт Галиевнең, Гөлшат Зәйнашеваның, Рәдиф Гаташның, Рахмай Хисмәтуллинның кызыклы мәкаләләре булды. Галим һәм педагог Мәхмүт Әхмәтҗанов узган ел вакытлы матбугатта бик актив эшләде. Ул «Казан утлары»нда «Шигърият аша тәрбия» дигән, «Татарстан» журналында Рәдиф Гаташ турында, шулай ук башка басмаларда күпләгән хезмәтләр бастырды.

Хәмзә Зариповның мәрхүм шагыйрьләребез Фатих Кәрим белән Әхмәт Фәйзинең шигырьләрен табып, дөньяга чыгаруы да, галимә Розалина Нуруллинаның Сәйфи Кудаш турындагы хикәя сыман кызык язмасы да һәм башка мәкаләләр безнең рухи тормышыбызны баеттылар.

Әйе, боларның һәммәсе дә уку өчен кызыклы язмалар иде.

Ләкин, шулай да, тулаем алганда, безнең милләтнең поэзия тәнкыйте һич кенә дә канәгатьләнерлек хәлдә түгел! Матбугат битләрендә бик сирәк авторлар хакында гына сүз әйтелә. Ул сүз бары тик мактау рухында гына була. Хәтта дифирамбыга да якынлаша! Ә ел дәвамында басылып чыккан байтак кына шигырь китаплары, журналларда һәм газеталарда дөнья күргән шигырь бәйләмнәре турында инде әйткән дә юк — алар тиешле реакция тудырмыйча, теге яктан да, бу яктан да фикер ишетмичә калалар. Ә бит игътибар белән карасаң — нинди генә кызыклы шигъри әсәрләр чыкмый бездә! Чөнки, күз генә тимәсен, поэзиябез соңгы елларда бик матур җимешләр бирә башлады. Дөньялар болганган, авырайган чакта хис-кичерешләр өлкәсе булган шигърият, чыннан да, көчәеп китүчән була инде ул.

Ләкин без бит әнә шул үсешне күрергә һәм ул хакта язарга, уй-фикерләребезне әйтеп чыгарга тиеш идек! Тик, кызганыч, әдәби тәнкыйтьчеләребез әллә кая китеп бетте безнең. Тәмам югалды алар!

Соңгы елларда «Казан утлары» журналы битләрендә шактый гына бәхәсләр, фикер алышулар үткәрдек. Хәтта, аерым бер әсәрне генә алып, шул нигездә генә дә шактый мәгънәле итеп сөйләшә алдык. Әмма тәнкыйтьчеләребез анда да актив булды дия алмыйм. Кат-кат мөрәҗәгать итүгә дә карамастан, аларның күбесе дәшми калуын артык күрде. Әнә шул сәбәпле үткән ел дәвамында хәтта китапларга рецензия бастыру да бик нык кимеде.

Газета редакцияләрендә дә шундыйрак хәл. Шигырь турында фикер әйтергә ни өчендер атлыгып тормый башладык. Әйбәтме, бу начармы? Юк — минемчә, бу бик тә начар күренеш! Бу — рухи тәрбия җитмәү, мәдәният җитмәү билгесе!

Ә шулай да конкрет сәбәпләр нәрсәдә икән соң?

Минемчә, иң төп, иң нигез сәбәп шул: бездә, безнең мохиттә, талантлы шәхесне һәм талантлы әсәрне иң беренче урынга куеп уйлау, әнә шул принциптан чыгып эш йөртү һәм язу юк! Безнең күбебез, кол милләтләргә хас булганча, иң башта һәм иң беренче эш итеп көчле кешегә баш иярга, матбугат аша аңа җылы мөнәсәбәтен белгерергә ашыга.

Ләкин андый язмалар укучыны да һәм тулаем әдәбиятны да, поэзияне дә ялгыш юлга таба тарталар. Талантлы авторлар иҗатыннан игътибарны читкә юнәлтәләр. Мисал өчен, соңгы елларда нишләп әле Гамил Афзалның «Казан утлары» журналында һәм «Ватаным Татарстан» битләрендә басылган менә дигән шигырь бәйләмнәре безнең тәнкыйтьчеләрдә бер фикер дә тудырмады? Матбугатта аларның сүзе булмады. Зөлфәт иҗаты да соңгы елларда күтәрелеш кичерә. Без моны да күрмибез кебек. Талантлы хатын-кыз каләмдәшләребез турында да матбугатта сүз әйтелгәне юк.

Әйе, алар җитәкче урыннар биләми. Бәлки дуслары да күп түгелдер... Ләкин безнең иҗади мохитебездә талант беренче урында торырга тиеш бит. Бары тик талант һәм талантлы әсәр генә безне каләмгә тотындырырга тиеш.

Матбугатта әдәби тәнкыйтьне җанландыру буенча берничә тәкъдим дә белдерәсе килә.

Газеталарда шигърият турында фикер алышулар оештырырга кирәк. Элегрәк алар була иде. Бу — яхшы традиция.

Шулай ук басмаларда һәр елның иң яхшы әсәрләрен билгеләп барасы иде. Бу авторларда мораль стимул тудырачак.

Радиода «Бер шигырь» дигән тапшырулар циклын башлап җибәрүче табылмасмы икән? Бу тапшырулар — шигъри тәрбия һәм шигырьне аңларга, тоярга өйрәнү мәктәбе булыр иде.

Кыскасы, якын елларда үзебезнең поэзия тәнкыйтен актив итеп күрәсе килә. Милли мәдәниятнең бүтән яклары үсеп барган бер вакытта тәнкыйтьнең сүлпән яшәве белән һич кенә дә килешеп булмый.

**Мансур ВӘЛИ.**

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КӨРӘШЧЕ ГАЛИМЕ

ӘБРАР КӘРИМУЛЛИНГА 70 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН



*Әбрар Кәримуллин эш бүлмәсендә.*

Ходайдан бирелгән иң зур бүләкләрнең берсе — безне шушы якты жир йөзенә яратуыдыр, мөгаен. Бу жылы, ягымлы кояш астында Җир кешесе булып яшәүгә, үзенә бирелгән Гомернең тәмен, ләззәтен, кадерен белеп тормыш кичерүгә ни житә! Әлеге олы сөенечне мәңгегә саклап калу омтылышы безнең аңыбызда гына түгел, ә бәлки инстинкт тойгылар рәвешендә бөтен нерв күзәнәкләребезгә салынган. Шуңа күрә, үз тереклегебез һәм барча табигатьнең яшәеше безгә чиксез бәхет китергән кебек, һәрбер жан иясенең якты дөнья белән хушлашуын күрү — бездә шулкадәр үк авыр хис уята. Кызганыч, әмма безнең цивилизацияле заманыбызда мондый югалтулар киму генә түгел, киресенчә, арта бара. «Кызыл китап» төшенчәсенең аңыбызга ныклап торып кереп урнашуы да, планетабызның экологик һәлакәт зонасына килеп керүе дә, тулы бер халык-милләтләр язмышының жир йөзеннән бөтенләй сызып ташлану куркынычы астына куелуы да, шыксыз Чернобыль, канлы Әфганстан, кайнар Чеченстан вакыйгаларының шаһиты булу да безнең яшәү чорына туры килде. Хәер, үз милләтебезнең кара язмышы да алай бик ЯКТЫРА барганга охшамаган. Классик язучыбыз Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дип белдергән мәгълүм сүзләрендә күрсәтелгән вакытның кыл уртасына житеп киләбез.

Замандаш галимебез Әбрар Кәримуллинның бүген әчтән сызланып: «Кая китә бу татар?» — дип, Кешелеккә сорау белән мөрәҗәгать итүе дә тикмәгә түгелдер... Милләтебезнең юкка чыга баруы — безнең өчен абстракт төшенчә генә түгел шул. Менә бишенче гасыр дәвамында инде без аны һәрдаим күреп һәм бөтен күзәнәкләребез белән тоеп-кичереп яшибез. Шунысы гажәп, күпләребез инде бу процесска бөтенләй игътибар итмәскә дә, игътибар иткәндә исә, шахмат уенында йөрешләрне алдан санап чыгарган кебек, инкыйразның нинди баскычларны үтеп килгәнлеген ачып салган «фәнни механизмы» турында фәлсәфә-гәп корырга да өйрәндек: халыкның мәдәнияте, гореф-гадәтләре юкка чыга бару, дине, иманы какшау, теле онытылу — болар милләтнең бетүгә йөз тоткан иң ачык симптомнары, әлбәттә, әмма,— дип юатабыз без үзүзебезне,— бу әле аның үлеме түгел. Милләтнең чын үлеме — аның үзаңы юкка чыккач кына килә. Ник дисәң, тел, мәдәният — күбрәк жисми чынбарлык булып материальләшкән, ә үзаң исә башлыча — жанда һәм ул хәтернең чишмә башы, аның йөрәге... Бу фаразда дөреслек бардыр, мөгаен. «Манкорт» сүзе юкка гына XX гасыр азагында «спид», «геноцид» сүзләре белән янәшәдә чорыбызның иң дәһшәтле һәм куркыныч бер символик төшенчәсенә әверелмәгәндер!

Бөек мәгърифәтчеләребез халкыбызның үзаңын уятуны һәм саклауны, бабаларыбызның кем булуын, үткәненнән без нинди мирас кабул итеп киләчәккә ни нәрсә илтергә тиешлегебезне аңлатып, күрсәтеп бирүне үзләренең төп бурычлары итеп санаганнар. Бу уңайдан К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинев һ. б.ның башкарган эшләрен искә төшереп узыйк.

Замандашыбыз академик Әбрар Кәримуллинга да, күрәсең, Ходай Тәгалә әнә шундый — татар халкының үзаңын саклап калу, димәк, аны үлемнән йолып калу кебек зур изге миссия йөкләгәндер?!

Бу фикер күңелдә очраклы гына тумый, әлбәттә. Белүебезчә, татар халкы талантларга ярлы халык түгел. Кешелекнең фән һәм сәнгать өлкәсендәге үсешенә дә ул үзенең лаеклы өлешен кертеп килә. Хезмәтләре дөнья фәненең бүгенге үсеш дәрәҗәсен билгеләгән мәшһүр академикларыбыз, исемнәре бар кешелекне таң калдырган даһи талант көченә ия сәнгать әһелләребез, дөнья күләмендә даншөһрәт казанган беренче дәрәҗәле спорт йолдызларыбыз да шактый. Әмма аларның ничәсе генә бүген язмышын үзен тудырып үстергән халкы язмышы белән бәйләп карый һәм аның әрнү-борчуларын күңеленә якын итеп яши икән?! Үзенең газиз халкын саклап калуга гомерен багышлаганнары ничәү икән?! Кызганыч, әмма аларның кардәшлеккә битарафлыгы милли тәрәккыятькә берни дә кертмәү генә түгел, милләт өчен алар үзләре дә юкка чыга... Ә бит шәхеснең зурлыгы, ахыр чиктә, шушы милли аңның дөрес куелышын да үз эченә ала түгелме соң? Бүген безгә әлеге «уңайсыз» — «интим» темага да ачыктан-ачык сөйләшер чак җиткәндер, шәт!.. Һәрхәлдә, минем моңа иманым камил, милли мәсьәләне әнә шулай үзәккә куеп, фәлсәфи ноктадан чыгып фикер йөрткәндә генә без шәхесләрнең асыл йөзен, «кемнең кем булуын» ялгышмыйча, төгәл итеп билгели алачакбыз. Әбрар Кәримуллинның татар халкы һәм кешелек җәмгыяте алдында башкарган эшләренең асыл мәгънәсен, аларның үзкыйммәтен дә, һичшиксез, бары тик шушы күзлектән чыгып кына дөрес аңлап һәм бәяләп була.

Әбрар Кәримуллин исеме киң катлам мәдәни җәмәгатьчелектә татар матбагачылыгының һәм татар китабының тарихын җентекләп өйрәнгән зур галим буларак билгеле. Бу, һичшиксез, шулай. Әмма галимнең хезмәтләрен басма сүз, матбугат, китап тарихы белән генә бәйләп күз алдына китерү, миңа калса, аның тоткан максатларын нык тарайту, эшчәнлегенең асыл мәгънәсен һәм кыйммәтен дөрес бәяләмәү, фидакярлеген бөтенләй күрми калдыру булыр иде. Сүз бирелә бу эшчәнлекнең күпкырлырак, киңрәк һәм күпкә тирәнрәк булуы турында гына бармый. Сүз эчтәге ялкын, Ходайдан аңа үз халкына карата бирелгән көчле мәхәббәт тойгысы хакында бара. Минемчә, Ә. Кәримуллин татар матбагачылыгы белгече — библиограф һәм китап белеме галиме генә түгел; әлеге гаять мөһим фән тармакларын аякка бастырып ул, барыннан да бигрәк, «безнең бабайлар надан булган» дип йөргән татарга аның чынлыкта кем икәнлеген инкяр итеп булмас саллы дәлилләр белән раслап, күрсәтеп бирүгә ирешә. Һәм мин моны татар халкының чын тарихын яңадан торгызу итеп кенә дә аңламыйм... Бу — татар халкының язмышын өйрәнү фәненә нигез салу! Дөрес, бирелә «фән, галим» сүзләре янына «шигърият, шагыйрь» дип тә өстәү кирәктер. Чөнки халык язмышы стихиясендә бәргәләнүче иҗат кешесе ул — һичшиксез, Шагыйрь! Әбрар Кәримуллинны да, бер генә юл шигырь язмауга да карамастан, үз халкының тугры шагыйре дип атыйсы килә. Шунысы кызык, аның иҗади эзләнү — эш методларында да, язган хезмәтләрендә дә, эшчәнлегендә дә, көндәлек яшәешаралашуларында да «академизм» стилен күрмисең. Салынган эз-буразнадан бару — аның табигате өчен ят нәрсә. Аның иҗаты — язын ташыган елга кебек, үз агар юлы-үзәне булса да, бөтен кыр-басуларны тутырып иңләп ага.

Ул хәрәкәтчән, актив, сайлаган һөнәре — эш юнәлеше белән китапханәдән яисә мәгарәдән чыкмыйча казынып гомер үткәрергә тиеш кеше булса да, табигате белән анда акыл җыеп утыручы галим-суфыйлардан ерак тора. Ул — сүзне турыдан яручы, ихлас, самими, гади, беркатлы... Шул ук вакытта гаять эмоциональ, кызу канлы, романтик рухлы. Нинди дәрәҗәле рәсми форумнар рамкасы аңа кысан. Әмма милләтнең язмышына кагылган берәр четерекле мәсьәлә килеп туганда, ул гыйльми аудиторияләр мөнбәрендә, зур җыеннарның үзәгендә, меңләгән милләттәшләребез кайнап торган ташкын митинглар мәйданының трибунасында! Аңарда эчке хәрәкәт бар, ут бар, ялкын бар, яну бар. Үзе мөкиббән китеп яраткан халкының ул чын-чынлап галим-шагыйре. Көрәшче галим-шагыйре! Чөнки ул тумыштан: табигате белән, язмышы белән көрәшче. Һәм, әйтергә кирәк, талантының тулысынча ачылуы өчен мөһим булган «объектив шартлар»дан да ул шактый «уңды»: «Бөек Октябрь революциясенә кадәр татарлар грамотасыз булган» дигән кара, ялган ярлыкны милләт өстеннән

алып ташлар өчен генә дә аңа дистә еллар кирәк булды. Бу уңайдан, Ә. Кәримуллинның тагын бер алыштыргысыз сыйфатын ассызыклап үтәсе килә: ул сүз кылычын кыю болгаган «аксөяк» көрәшче түгел, ә бәлки халыкның бүгенге ихтыяҗын исәпкә алып, аңа һәртөрле «кара эш»тән тайчанмыйча хезмәт күрсәтеп килгән турылыклы милләт хадиме дә. Халык язмышына караган һәр мәсьәләдә мондый сизгерлек һәм фидакярлек күрсәтү теләсә кемгә бирелми. Халыкка хезмәт күрсәтү өчен аның ихтыяҗларын нечкә тоемлап, авыруларына дөрес диагноз куеп эш итә белү кирәк. Мин бу сыйфатны табигать бүләге яисә тупланган белем хәзинәсе дип кенә карамыйм, әлеге үзлеккә ия булу өчен үз язмышының халык язмышы белән күпмедер аваздашлыгы, ягъни тормыш әчетөчесен билгеле бер дәрәҗәдә татыган булуың да сораладыр... Бу «алшартлар» исә Ә. Кәримуллин биографиясенең буеннан-буена сузылган. Ул яшәп үткән гомер һәм иҗат эшчәнлеге авыр да, кызыклы да, каршылыклы да, гыйбрәтле дә. Язмыш аңа һәртөрле каршылыкларны һәм сынауларны аз җибәрмәгән...

Әнә ул, бәләкәй Әбрар, башка бик күп чордашлары кебек үк гамьсез сабый, туган авылы Чәбия-Чүрчидә беренче сыйныфка укырга килгән... Монысы бик күпләребезнең башлангыч тормыш юлына охшаш. Инде менә моннан соң аның биографиясе елдан елга катлаулана бара, дөнья нужасын, тормыш каршылыкларын язмыш аның гомер юлында берсе артына икенчесен куя тора. Икенче сыйныфка инде ул үз авылларыннан 4 чакрым ераклыктагы күрше авыл мәктәбенә йөреп укый башлый. Бишенче сыйныфны Әбрар туган авылыннан 9 чакрым читтә булган Татар Икшермәсе мәктәбендә укырга керешә. Көн саен 9 чакрым барып, 9 чакрым кайтып мәктәп юлын таптавы нәни балага бик ансат булмагандыр... 7 класстан соң Әбрар Мамадыш педагогия училищесына укырга керә, тик матди кыенлыклар аңа укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирми... Урта белемне ул үзләреннән 22 чакрымдагы Саба урта мәктәбендә алып чыга. Монда укыган чакта да Әбрар тулай торакта яшәп, һәр шимбәдә дәресләрен калдырып, азык-төлеккә һәм яңа чабата алырга үз авылларына кайтып йөри. Татар академикларының үсеш юлын киләчәктә кемгә дә булса өйрәнергә туры килсә, бәлки бу тәрҗемәи хәлләр дә гыйбрәтле тоелыр?..



*Әбрар Кәримуллин хәрби хезмәттә. Кытай, Порт Артур, 1946 ел.*

Инде моннан соң Ә. Кәримуллинның хезмәт биографиясе тезелеп китә: колхозчы, хисапчы, укытучы, солдат... Болары гадәти михнәтләр. Әмма тормыш юлында зуррак сынаулар да көтеп тора икән бит әле. Әбрар мәктәпкә кергәнче үк, биш яшендә үзенең иң якын кешесен — әнисен югалта (күмәкләштерү елларында авыл укытучысы булган Сафия Мөхәммәттата кызының гомерен 26 яшендә кулаклар өзә). Уны бетереп, зур хыял-өметләр белән олы тормышка аяк баскан 16 яшьлек Әбрарны 1941 елның дәһшәтле сугышы каршы ала. Әтисе Гыйбадулла абзый фронтка — сугыш кырына чыгып китә. 1943 елда инде Әбрар үзе дә армия сафларына алына.

Үсмер егетне, гади бер авыл малаен, инде сугыш чын-чынлап сынарга керешә. Ул солдат-автоматчы, разведчик, 82 ммлы миномет наводчигы сыйфатында фронт буйлап сугышчан юл уза: Курск дугасындагы сугышларда, Украинаны, Румынияне, Венгрияне, Чехословакияне азат итүдә, Ерак Көнчыгышта япон милитаристларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Монголия, Кытайдагы Үлем далаларын, Хинган тауларын кичә. Ничә ел дәвамында янәшәсендә генә аны үлем сагалый. Үзенең 18 яшен, 19 яшен, 20 яшен ул яралану һәм контузияләр белән үткәреп җибәрә. Шәхси батырлыгы өчен Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, ике тапкыр «Батырлык өчен» медале һ. б. медальләр белән бүләкләнә. 1947 елда

яраларына бәйле төстә Әбрар демобилизацияләнеп туган авылына, тыныч тормышка кайта. Сөенечен кабат болыт каплый — сугышта алган яраларыннан әтисе дөнья куя.

1948 елда, ягъни җиде елга сузылган тәнәфестән соң, Ә. Кәримуллин белемен күтәрү теләге белән Казан университетының татар бүлегенә укырга керә. Зур, тетрәткеч сугыш вакыйгалары гадәти-көндәлек тыныч тормыш михнәте белән алышына: бер якта — сагынылган уку, белемгә сусау, киеренке акыл хезмәте, икенче якта — матди кысанлык, буш вакытларда товар вагоннары бушату, елга портындагы төрле эшләр, урам җыештыру, утын кисү, җәй айларында урман әзерләү, төзелештә эшләү.

Укып бетереп, Казан университетының фәнни китапханәсендә өлкән китапханәче, фән буенча директор урынбасары, сектор мөдире булып ун елдан артык эшләү дәверендә дә каршылыклар кимеми генә түгел, киресенчә, артып, берсе артыннан икенчесе алышынып кына тора.

Ә. Кәримуллин биредә, бер яктан, профессиональ белеменең җитмәвен тойса (һәм ул библиотекарь, библиограф профессиясен үзләштерү өчен Ленинград дәүләт культура институтына читтән торып укырга керә), икенче яктан, аның тагын да бер мәсьәләдә «күзе ачыла»: үзе укып чыккан университетта бу елларда татар халкының тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын, матбагасын, сәяси фикерен, аның урыс һәм дөнья тарихында тоткан урынын аңлатуда шактый тенденциоз, берьяклы эш алып баруын, биредә ялган белән ярымхакыйкатьнең бик оста бергә үреп алып барылуын ачык төшенә.

Татар язуында ике тапкыр хәреф алышыну гарәп язулы материалның күпләп юкка чыгуына китергән. Әмма аның, төрле юллар белән исән калып, китапханә фондына килеп кергән кадәресе дә яшь белгечне шаккатыра. Монда йөзәр мең татар китаплары саклана икән ләбаса! Ә алар киң җәмәгатьчелеккә генә түгел, хәтта студентларга һәм аларның укытучыларына да билгесез кала икән! Әле, җитмәсә, «Татарларда революциягә кадәрле тоташ грамотасызлык булган, үз басма китаплары булмаган, басылса да Коръән, һәфтияк, догалар гына...» дигән фикер рәсми хакимият башлыклары тарафыннан һәрдаим ныгытыла килә. Балачактан гаделлеккә омтылган Әбрарның күңелендә халыкның тарихын каралтырга, аның мирасын мескенләндерергә, үзаңын юкка чыгарырга юнәлтелгән бу сәер сәясәт гаҗәпләнү, гарьләнү тойгысы, әрнү уята; торабара максатлы көрәш, үҗәтлек, җиң сызганып эшкә керешү дәрте кузгата.

Беренче эш итеп ул иске татар китапларының каталогын төзи башлый. 5—6 ел дигәндә аларның исемлеге укучыга тәкъдим дә ителә. Ә. Кәримуллин татар теле һәм тел белеме, әдәбият тарихы һәм әдәбият белеме, фольклор, Татарстан тарихына караган фән тармакларында аерым күрсәткечләр төзүгә керешә. Болар барысы да татар һәм Татарстан фәнни библиографиясенең оешу башлангычын, аның нигезен тәшкил итә. Шул ук вакытта бу елларда китапханә фондын иске кульязма китаплар белән тулыландыру да җайга салына; экспедицияләр оештырыла башлый, чит ил фәнни оешмалары белән китап алмашу да кабат яңартыла. Нәтиҗәдә — Европа, Азия, Америка, Австралия илләренең ике йөзләп югары уку йорты һәм фәнни оешмалары белән тыгыз бәйләнеш урнаша. Шулай итеп, 11 ел дәвамында җитәкче һәм фәнни эшне оештыручы буларак, Ә. Кәримуллин Фәнни китапханәдә профессиональ мәктәп чыныгуы уза.

Әмма бу эшчәнлекне үзләренчә күрергә тырышкан «сизгер» сәясәтчеләребез дә якында гына йөри икән... Ә. Кәримуллин шәхесе тирәсендә дә кара болытлар куера бара. Берничә тапкыр Өлкә комитетына чакыртып, үзенең библиографияләренә репрессияләнгән «шикле» галим-әдипләрнең хезмәтләрен дә керткән өчен аңа җитди гаеп ташлыйлар. Аны панисламизмда, пантюркизмда, революциягә кадәр чыккан татар басмаларын мактауда гаепләп язылган яла хатлары да җыела башлый. Һәм, ниһаять, 1963 елда аның «Әдәби җыентык һәм альманахлар библиографиясе: 1917—1960» китабы кулга алынып, юк ителә. Татар Өлкә комитетына үз белдеге белән эш итәргә яраткан Ә. Кәримуллинны акылга утырту өчен җай чыга. Махсус, чираттан тыш бюро җыеп, аның эше карала. «Дело»сына кертеп, аңа кискен шелтә белдерелә, үзе директор урынбасары вазыйфасыннан азат ителә. Соңыннан ачыкланганча, бу — Н. Хрущевның шәхси күрсәтмәсе буенча эшләнә. Татар китап палатасы директоры әлеге библиографик белешмәкитапны сатуга чыгып җиткәнче үк инде Үзәк Комитетка җибәргән була. Китапта исә бөтен әдәби җыентык һәм альманахларның, шул исәптән, «Ленин-Сталин»га багышланганнарының да тасвирламасы бирелә. Шул нигездә библиограф-автор Кәримуллин Сталинга дан җырлауда гаепләнә. 1964 елда, Н. Хрущев генераль секретарь постыннан азат ителгәч кенә, Ә. Кәримуллинга беркадәр

иркенрәк сулыш алу мөмкинлеге туа. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә алына.

1968 елда Ә. Кәримуллин татар театрының энциклопедиясе дип әйтерлек «Татар сәхнәсе (1917—1967): Әдәбият күрсәткече» исемле хезмәтен тәмамлый. Шушы ук елда «Татарларда матбагачылык туу һәм татар филологиясе буенча яңа чыганаклар» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Галим биредә, татар матбагачылыгының тарихын яктырту белән беррәттән, гомуми китап белеме мәсьәләләренә дә киң туктала, монографиясендә ул, совет китап белемендә беренчеләрдән булып, басма сүз тарихын өйрәнүдә зур әһәмиятле булган милли китап теориясен эшли. Ә. Кәримуллин раславынча, китапның язылу теле, авторның милләте, әсәрнең китап булып басылган урыны, оригинал яисә тәрҗемә булуы һ. б.; үзлекләре — аның функциональ максаты, ягъни тегеяки бу халыкка хезмәт итүе белән берлектә каралырга тиеш. Бу факторлардан чыгып эш иткәндә, милли китапның берьюлы берничә халык өчен милли китап булу ихтималы ачыла.



*Әбрар Кәримуллин Президент М. Ш. Шәймиевкә халыкара бүләк тапшыра, 1992 ел.*

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, диссертацияне әзерләү дә, аны яклау да галим алдына әр-яңа проблемалар, сынаулар китереп куя. Эш шунда ки, беренчедән, хезмәтнең темасы тыелган темаларның берсе булып исәпләнә һәм ул СССР Фәннәр Академиясенең тикшеренү профиленнән читтә тора; икенчедән, диссертант аны фәнни житәкчесез, аспирантурасыз, Институт эшеннән бушаган арада — планнан тыш башкара. Өстәвенә, бу теманы өйрәнү галимнең гарәп язуын әйбәт белүен, шулай ук гарәп, фарсы, төрек һәм борынгы төрки телләрдә дә күпмедер мәгълүматлы булуын сорый. Ә инде эш барышында авторга билгесез күпме яңа чыганакларны фәнни кулланышка кертеп жибәрергә кирәк булуын әйтеп торасы да юк — теманың исеме генә дә бу хакта күп нәрсә сөйли...

Ничек булса шул: рәсми һәм рәсми булмаган бар каршылыклар артта кала, хезмәт гыйльми Совет тарафыннан югары бәяләнә (күп кенә галимнәрнең аны «докторлык диссертациясенә торырлык» дип бәяләве дә юкка гына түгелдер). Әлеге хезмәт 1971 елда китап булып та басылып чыга. Партия оешмаларын бу тагын бер кат хафага төшерсә дә, киң катлам жәмәгатьчелек һәм белгечләр, шул исәптән чит ил белгечләре дә, аны бик жылы каршы ала.

Әмма Институтта элеккечә үк бу теманы аның эш планына кертмиләр. Шуңа ул биредә план буенча библиографик хезмәтләр төзү эшен дәвам итә. Шундыйлардан без аның «Татар фольклоры һәм фольклористикасы»ның 300 еллык үсешен чагылдырган библиографик тасвирламасын атый алабыз.

Кызыклы парадокс, әмма факт — галимнең моннан соңгы төп гыйльми хезмәтләре дә «тыелган темага һәм «планнан тыш» — буш вакытларда эшләнә: 1970 елда ул XX йөз башы татар китабы тарихы буенча докторлык диссертациясен тәмамлый. Әмма Институт житәкчелеге хезмәтне тикшерүгә чыгарудан баш тарта. Күп тырышлыктан соң, автор аны шулай да тикшерүгә куйдыруга ирешә — кырыклап галим чакырыла. Күп сәгатькә сузылган фикер алышулардан соң, хезмәт яклауга тәкъдим ителә. Монография 1974 елда аерым китап булып та басыла, бик күп белгечләр тарафыннан (бигрәк тә чит ил белгечләре тарафыннан) кайнар яклау таба. Әмма диссертация буларак галим аны бары тик 1978 елда гына яклый ала.

1983 елда Ә. Кәримуллинның «Реформадан соңгы Россиядә татар китабы» дип исемләнгән яңа монографиясе китап булып басыла. Шулай итеп, Татар Китабының революциягә кадәрге чорын яктырткан трилогия тарихи яктан бер

бөтенләк ала. Бу зур хезмәтне тоташ укып чыкканнан соң, әлбәттә, татар халкының үткәне һәм бүгенге мәдәниятенә, аның мәгариф, әдәбият, иҗтимагый фикер үсешенә, Россия һәм Дөнья тарихында тоткан урынына бөтенләй икенче бер күзлектән карамый мөмкин түгел.

Соңгы елларда Әбрар ага совет чоры татар китап тарихына караган берничә яңа китабын бастырып чыгарды.

Шул рәвешчә, Халыкның хәтере булган Китап язмышы — Ә. Кәримуллинның үз язмышына әверелеп яши. Бу фундаменталь хезмәтләр аша ул татарның үзаңын үстерүгә сөйләп бетергесез зур өлеш кертте. Әлбәттә, аның әһәмиятен әле без бүген тиешенчә күз алдына китереп бетерә алмыйбыз, төгәл бәяне, мөгаен, киләчәк буыннар әйтер. 40 елдан артыкка сузылган фәнни иҗат гомерендә галим гуманитар фәннәрнең күпкырлы тармакларын үз эченә алган дүрт йөздән артык мәкалә, күләмле алты китап-монография, дистәдән артык библиографик җыентык чыгарды. Әдәби тәнкыйтьче сыйфатында да Ә. Кәримуллин гаять актив эшли. Дистәләгән әдип, галимнәребезнең библиографияләрен хәзерләде. Ул — К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, Г. Исхакый, К. Тинчурин, Г. Коләхмәтов, Г. Бәширов, М. Хәбибуллин, Җ. Тәрҗеманов, Х. Рахман, Д. Фәтхиләр иҗатының аерым аспектларына багышланган күп санлы мәкаләләр авторы. 1974 елда Язучылар берлегенә әгъза буларак кабул ителде. Бүгенге көндә галим иске басма татар китапларының җыелма каталогын (1722—1917 еллар) төзү эше белән җитәкчелек итә. Татарстан һәм Татарстаннан тыш регионнарда 1917—1932 елларда татарча китап басу тарихын өйрәнә.

Әмма биредә без кабат ассызыклап үтәргә кирәк табабыз: Ә. Кәримуллин гомере буе библиография һәм китап тарихы мәсьәләләрен үзәккә куеп эшләсә дә, аның гыйльми эзләнүләренең төптән җигелеп тартып баручы көче ул — Татар халык язмышы белән бәйле. Тышкы фәнни темалар артында берникадәр капланып торган бу төп юл соңгы вакытта шактый тулы ачылып китте шикелле.

Хәер, сиксәненче елларның урталарында ук әле галимнең татар халкының этносын һәм этнонимын, ягъни аның исемен һәм җисемен ачыклауга багышланган кульязма китабы (ул елларда аны бастырып чыгару мөмкин булмаган бер эш иде), кулдан кулга күчеп, бөтен татар зыялыларын әйләнеп укылып чыкты. Бу монографиянең китап булып Казанда татар һәм рус телләрендә өч тапкыр басылып таралып бетүе, Мисырда гарәп телендә, кыскартылган вариантының Токиода япон телендә дөнья күрүе — бүгенге көндә дә аның киң катлам татар укучысының игътибарын үзенә җәлеп итүе хакында ачык сөйли. Күрүебезчә, монда галимне кулына каләм алырга мәҗбүр иткән төп сәбәп — милләтебезнең каршылыклы-фаҗигале язмышы. Китап татар халкы өстенә «тарихи» өелгән яла-пычрактан аны аз булса да арындыру омтылышын алга куеп иҗат ителгән. Гаҗизлектән, күрәсең, автор халыкка килгән бу әче язмышның билгеле бер сәбәбен аның исеменә бәйләп тә күрә. Әйтергә кирәк, исем белән җисемнең тәңгәл килү-килмәү мәсьәләсен болай шактый җилле генә тотып селкү милли хәрәкәт юлында кайбер бәхәсләрне дә көчәйтеп җибәрми калмады («Болгар» тарафдарлары һ. б.). Әмма исемне алыштырып кына язмышны алдап булмавын яхшы аңлаган укучы, әлбәттә, мәсьәләнең бу ягына алай бик зур игътибар бирмәде, аның өчен китапта бу каршылыкның эчке тарихи механизмын ачу мөһимрәк иде.

Ә. Кәримуллин халкыбызның тарихи язмышын күп яклап һәм кайчакта һич көтелмәгән яклардан чыгып та яктыртуга ирешә. Аның әнә шундый характердагы — майя, инк, ацтек, сиу-хока, аймара индеецлары теленең төрки телләр белән генетик уртаклыгын ачкан тикшерүләре дөньяның күп кенә белгечләрендә зур кызыксыну һәм хуплау тапты. Бу новаторларча — яңа идеяне үз эченә алган хезмәт Яңа Дөнья һәм Океания утрауларын үзләштерүгә, халыкларның бөек күчеш тарихына, аерым халык һәм расаларның формалашу тарихына башка күзлектән карау кирәклеген күтәреп чыга.

Соңгы елларда Ә. Кәримуллин төп игътибарын халкыбызның бүгенге һәм киләчәк тормышына юнәлтеп, халык язмышын ачуга тагын да якынрак килде. Республикабызның иҗтимагый-сәяси тормышында да ул гаять зур активлык күрсәтте; татар халкын милләт буларак аякка бастырып, Татарстанның суверенитетын ныгытуга үзеннән лаеклы өлеш кертте. Аның вакытлы матбугатта басылып чыккан берсеннән-берсе үткенрәк, гаять актуаль проблемаларны күтәреп чыккан дистәләрчә мәкаләләре әнә шул хакта сөйли. Аңа Бөтентатар «Милли мәҗлес»е тарафыннан «Татар халкының мәшһүр улы» исеме бирелү дә очраклы түгел, әлбәттә.

Шулай итеп, Ә. Кәримуллин, минем уемча, бүген үз стихиясендә, үз темасы канатында, үз миссиясен башкара.

Көрәшче галим-шагыйрьнең укучыларга тәкъдим ителгән әлеге китабын мин, исеменнән үк күзгә ташланганча, авторның үз халкы язмышына багышланган төп Гомер китабы итеп күрәм. Китапның беренче бүлегендә татар халкының диаспора тарихы, ягъни чит илләрдә «адашып» яшәгән милләттәшләребезнең гыйбрәтле, авыр язмышы яктыртыла. Китапның икенче бүлеге исә татар язмышын читкә чыгып түгел, ә бәлки Рәсәй — Татарстанның эчке проблемаларыннан — үзәктән торып ачуга корылган. Әмма алар бер-берсеннән аерылгысыз. Аларның һәрберсендәге проблемалар шагыйрь-галимнең йөрәге, вөҗданы, идеалы аша уза!..

Гомере буенча нинди генә зур каршылыкларны җиңеп яшәп килмәсен, Әбрар Кәримуллин, минемчә, барыбер бәхетле йолдыз астында туган. Барыннан да бигрәк, ул, үзендә көрәш рухын саклап калып, газиз халкына һәрдаим кирәкле кеше булуы белән бәхетле. Үзе өчен иң зур дәрәҗәнең халык мәхәббәте икәнен ул яхшы белә. Аның сүзе, чын шагыйрь сүзедәй, абруйлы. Башкарган эшләре — чын академикларныкыдай — саллы. Хезмәтләрен кемнәргәдер ошамый дип кенә танымый һич мөмкин түгел.

Ул — Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. Татарстан Фәннәр Академиясенең хакыйкый әгъзасы. Хезмәтләре үзебездә дә, чит илләрдә дә киң мәгълүм. Ә. Кәримуллин бик күп чит ил фәнни оешмаларының мактау кәгазьләре, медальләре, мактаулы титул һәм исемнәре белән бүләкләнгән. Ул Халыкара библиография ассоциациясенең, Халыкара Биографик үзәкнең гыйльми советы әгъзасы, Гуманизм һәм Гаделлек өчен көрәштә Халыкара парламент конфедерациясенең Дәүләт секретаре һәм илчесе. Аның тарафыннан ул «Маркиз оф Туран» дигән мактаулы исем һәм берничә орден белән бүләкләнде. Ә. Кәримуллинның исеме төрле мактаулы, абруйлы энциклопедик сүзлекләрдә урын алды. Биредә шунысын да искәртеп үтик, әлеге Халыкара исем, бәйләнеш-дәрәҗәләр, миңа калса, аның өчен аерым бер кадер-хөрмәткә ия. Һәм моны галимнең дан-шөһрәткә омтылышы итеп кенә карарга һич ярамый. Аның сәбәбе күпкә аңлаешлырак һәм гадирәк. Гомер буе гаделлеккә омтылган һәм гаделсезлек эчендә иза чиккән, гомер буе шуннан котылырга омтылган кешенең читтән үзен аңлап һәм хуплап әйткән җылы сүзгә мөнәсәбәте итеп аңлыйм мин моны. Шул ук вакытта, үз исеменнән дә бигрәк, халкы исеме Халыкара аренага күтәрелүгә ихлас сөенү дип тә күрәм...

Чыннан да, милли Язмышларны гадел хәл итү — бөтендөнья халыкларының уртак бурычы түгелмени?! Чечнстан кебек канлы җинаятьнең шаһиты булу — бөтендөнья халыкларының вөҗданы тапталу түгелмени?! Бездәй мөстәкыйльлеккә, тигезлеккә, чын бәхеткә омтылып яшәгән халыклар азмыни Җир йөзендә?!. Шуңа да гаделлеккә таба гомумкешелек атлаган һәрбер адым безнең өчен аеруча кадерле тоелмыймыни?!. Шушындый чын интернационализм һәм гуманизм тойгысын күңеленнән кичереп, иңенә автомат асып, канлы сугыш, үлем дәһшәтен кичеп, ярты Европаны һәм Азияне тәпиләп узмадымыни Әбрар 18, 19, 20 яшендә! Гомумкешелек бәхете өчен көрәш тойгысы, көрәш дәрте кимрәкмени аңарда бүген?!. Һич юк! Бүген аның өчен Тормыш, димәк, Милләт һәм Гомумкешелек язмышы тагын да кадерлерәк. Бүген аның өчен Көрәш мәйданы тагын да киңрәк, максаты тагын да мәгънәлерәк. Чөнки ул көрәшче-солдат кына түгел, ул бүген бөтендөнья халыкларының — гомумкешелекнең уртак көрәшчесе, шагыйрь-галиме!..

**Равил РАХМАНИ.**

# ТАТАРНЫҢ ТУИШЕВЫ

## I

Татарда Туишевлар ишле. Сүз — барыбыз да белгән Фәйзулла Туишев турында. Советлар Союзының иркен һәм киң илендә дистәләгән-йөзләгән халыкларына исеме һәм сәнгате билгеле булган беренче гармунчыбыз, мөгаен, беренче профессионал артистыбыздыр да әле, шул кешебез хакында мин нибары өч документ тәкъдим итәм. Берсе — гармунчы Фәйзулланың үз сүзе. Тагын берсе — музыкант, артист, композитор Фәйзулла Туишев эшчәнлегенә бәяләмә.

Өченчесе — сугыштан хат. Адрес иясе — Татарстанның атказанган артисты Фәйзулла Кәбир улы Туишев.

Әллә кайсы якларда үскән-яшәгән төрле халык уллары маэстро-останы күреп, аның гармунда уйнаганын тыңлап, үзе иҗат иткән музыкаларын ишетеп беләләр.

Шушы өч документ белән танышкач та Фәйзулла Туишевның — татарныкы гына түгел, халыкара атказанган шәхес, музыкант, артист булуына ышанасың. Бу очракта атказанганлык «Халыкара артист» исеменә тәңгәл.

**ТАССРның атказанган артисты**
**Фәйзулла Кәбир улы Туишевка**

**Сезгә Кызыл Армияне яратуыгыз өчен, каһарман Кызыл Армиягә багышланган «Ватан» дигән әсәрегез өчен рәхмәтебезне белдерәбез.**

**Без сугышчылар, командирлар һәм политработниклар, Сезгә сәламәтлек һәм Ватаныбыз файдасына һәм аның чәчәк атуы хакына нәтиҗәле хезмәт итүегезне телибез. Сезнең сәнгатегез дошманга каршы көрәштә безнең йөрәкләребезне яңа сугышчан батырлыкларга рухландыра. Безнең частьның немец илбасарлары белән 17 ай дәвамында сугышта дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын юк итү буенча сугышчан исәбе бар, ул түбәндәгечә:**

**Юк ителде: 9 самолет, 96 танк, 19 танкка каршы атучы туп, 7 мина атучы туп, расчетлары белән бергә 26 пулемет, 23 дзот, команда пункты һәм блиндаж, 26 автомашина, 5 туплы артиллерия колоннасы;**

**Юк ителде һәм таратылды:**

**10 батальонга якын пехота, 4 взвод автоматчылар;**

**Бастырылды:**

**4 артиллерия батареясы, 6 миномет батареясы;**

**Әсирлеккә алынды: 5 очучы-офицер.**

**Немец илбасарлары белән сугышта аерата сугышчан казанышларыбыз өчен частебызның 80 кешесе хөкүмәт бүләкләре белән бүләкләнделәр, шулардан: полковник Вәлиев III нче дәрәҗәле Суворов ордены белән, бер кеше Ленин ордены белән, өлкән политрук Мурзин, өлкән сержант Шут, кызылармияче Филин Кызыл Байрак ордены белән, тагын 6 сугышчы һәм командир икешәр тапкыр бүләкләнде.**

**Алдагы көннәребездә без кешелекнең явыз дошманы фашизмны тар-мар итүгә бар көчебезне куячакбыз.**

**Туачак әсәрләрегезнең берсен Суворов ордены кавалеры полковник Х. Х. Вәлиевкә багышлап иҗат итүегезне үтенәбез.**

**Безнең сугышчан сәламебезне кабул итегез.**

**Сугышчылар, командирлар һәм политработниклар исеменнән:**
**Майор Суспин**
**өлкән лейтенант Баранов,**
**өлкән лейтенант Сумельченко**

лейтенант Ухаботин
старшина Фомин.

*1 март 1943 ел.*
**Хәрәкәттәге Кызыл Армия.**

Архивта мин фронтовик татарларның, татарстанлыларның туган татар халкына, татарстанга сугышчан казанышлары хакында хисап биреп язган байтак хатларын укыдым. Ә менә бер генә кеше алдында хисап тотып язылганын берне генә, шушыны гына очраттым. Хат шундый фактны раслый: карт артист (ул чакта Фәйзулла агага 65 яшь) каһарман полкның дәртле, гайрәтле, моңлы рухына әверелгән бер әгъзасы.

Шунысы да кызыклы: сугыш кырыннан туган Татарстанга хатлар «Татар халкының фронтовик татарларга хаты» барып ирешкәч, шуңа җавап рәвешендә ява башлый. Ә Фәйзулла Туишевка әлеге хат аңарчы ук җибәрелгән. Туган яклардан еракларда михнәт чигеп йөргән татар кешесенә ул тулы бер халык булып гәүдәләнгән!

II

Инде **Фәйзулла ТУИШЕВНЫҢ** үз сүзенә игътибар итик.

## Ярты гасыр гармуннар белән

**Я**рты гасыр мин гармуннарда уйныйм, менә шуңа тыңлаучыларым белән кайбер фикерләремне уртаклашасым килә.

Бала һәм үсмер чагымда миңа музыкант буларак үсәргә авыр булды. Музыкага һәвәслегем ачыла, омтылышым көчәя барган саен иске карашлы динчеләрдән аеруча күп әләкте, музыка белән шөгыльләнүдән алар минс биздерергә тырыштылар. Әмма музыкага омтылу аларның өркетү-тыюларыннан көчлерәк булып, мин тырыша-тырмаша җирдән шытып чыккан кыргый җимеш агачы үсентесе сыман, бәреп чыктым. Нәкъ шулай булды, мин кыргый идем, кыргый рәвештә «кыргый» саналган музыка коралы — гармунда уйнадым. Мин гармунга мондый караш белән килешмәдем, халык арасына киттем, халык эчендә үстем һәм шомардым, ә халык үзенең гармунын ярата.



*Рәсемдә: Ф. Туишев (утырган уртада) бер төркем музыкант дуслары белән. (Фотосурәт дәүләт музей архивыннан алынды).*

Гармун «кыргый җанвар» шикелле «үкермәсен» өчен, бәлки җанга ятышлы, матур авазлар белән җырласын өчен, мин гармунда уйнау буенча үз мәктәбемне булдырырга тырыштым. Мин уйный башлаганда, гармунның ике системасы бар иде: русча төзелешле тальян һәм немец гармуннары. Аермалары: күрекләре белән идарә итүдә. Ике һәм өч рәтлеләр соңыннан гына күренә башлады, ә баян гомере күп дигәндә 35—40 ел белән исәпләнә. «Лилипут» дип аталган бәләкәй концерт гармуннары сәхнәгә беренче булып җиде телле «невский» гармунын эшләтеп алган Петр Невский белән бергә генә менделәр.

Вася дәдәй Варшавский исә ике рәтле хроматик (авазның, тавышның ярты тоннарга бүленүен тәэмин итүче) төзелешле гармун эшләтте.

Мин «әче» тавышлы гармуннарны бер вакытта да өнәмәдем, йомшак, бәрхет аһәңле тавыш чыгара алуга ирешкәнче гармун ясаучы осталар белән төннәремне уздыра идем.

Миннән: «Нигә сезнең гармуннарыгыз шулай күп санлы?» дип сорыйлар. Ә мин: «Әйе, минем төрле осталар ясаган 9 төрле системадагы, төрле тембр һәм тоннарда җырлаучы гармуннарым бар. Музыка әсәренең авазлар, тавышлар төсмеренә яраклы гармунны һәм киресенчә гармуннарыма ятышлы музыка әсәрен сайлап алам. Шул чакта әсәрнең яхшы башкарылуына ирешәм, менә ни өчен минем ике дистәгә якын гармуным бар»,— дип җавап бирәм.

Мин үземне бәхетле карт дип саныйм. Мин 25 ел дәвамында капитал изүеннән котылган туган халкыма уйныйм, 25 ел буе патша заманында, музыканы тыйган көчләр өстен чакларда уйнадым. Аның каравы, бүген минем һөнәрем осталарының ничек үсүләрен күрәм, гармунның, аеруча баянның, музыка кораллары арасында тулы хокук алуына шатланам. Бүген гармунны кайда гына күрмисең: фронтларда сугышчылар кулларында, клубларда, госпитальләрдә яралы солдатлар кочагында — гармун һәрчак һәркайда дәрәҗәле, сөекле. Мин 1939 елда Мәскәүдә халык уен коралларында уйнаучы осталарның Бөтенсоюз конкурсында катнашканда төрле халыкларның (әзәрбәйҗан, казах, кыргыз, үзбәк, рус һ. б.ларның) милли уен коралларында уенын ишеттем, гармунны үз итүләрен күрдем, русларның гармунда уйнаучы беренче өчлеген — триосын, Мәскәүле Онегиннар гаиләсен һәм башкаларны тыңладым.

Безнең Татарстаныбызда зур гармунчы булып Гани Вәлиев өлгерде, зур сәләт иясе Фәйзи Биккенин, яшь фронтовик Гали Җәмлиханов үсеп килә, күптән түгел Мәскәүдә яшь иҗатчылар ярышында мактауга лаек булган Рокыя Ибраһимова, менә дигән гармунчы осталар Абдулла Халитов һәм башкалар бар.

Бу сәнгать осталары килеп чыга торалар һәм мин халык күңеленә якын шушы сәнгатькә, аның сәләтле вәкилләрен үстерүгә филармониянең игътибарын арттыруын сорар идем.

Уйнагыз, иптәшләр! Туган илебезне, туган халкыбызны мактап җырлагыз. Тиздән без каһарман-фронтовикларыбызны каршы алырбыз, җиңү җырларын сузарбыз, ә гармуннарыбыз башлап җырларлар.

**Фәйзулла ТУИШЕВ.**
*Февраль 1944 ел.*

Нәкъ йөз ел элек булган хәлне искә төшерүдән башлана Фәйзулла аганың сүзе. Татар дөньясы уянып килә, яңарыш көчләре түл җыя. Яшь музыкант кадими дини-рухани катлауның эзәрлекләвеннән, кысуыннан халык арасына кача.

Татар баласы өчен уку йортлары — балаганнар, күчмә группалар, ярминкәләр, концерт заллары да — шулар ук. Тамашачылары да, остазлары да — халык үзе, халыклар...

Ул — гармунда уйнау остасы гына түгел, ул гармунга илаһи моң дөньясыннан килә, моң чыгару коралын үзе камилләштерә, ул — гармунчы белгеч...

Аның татар җаны башка халыклар моңын үзенә сеңдерә, сәнгать дөньясына ул милли моң эзләп түгел, бәлки моңга сусап, үз күңелендәге дөнья моңына кушып җибәрергә ашкынып чыга кебек...

Гармуннар, төрле халыкларның, аеруча рус халкының гармунчы осталары турында ул ничек белеп, аларны аңлап, үзләренә тиешле бәяне биреп фикер йөртә. Фикере ул чактагы СССРкүләм, халыкаракүләм. Фикерендә үз дәрәҗәсен белүе, җанының, фикеренең хөрлеге чагыла.

### III

Былтыр Фәйзулла Туишевның музыка дөньясына артист буларак чыгуына 100 ел тулды. Кайсыдыр газетада аның турында сүз әйтүче дә булды. Ә аның 50 еллык хезмәтенә Җәүдәт Фәйзи кебек шәхес бәя биргән. Нәрсә сокландыра аны Фәйзулла Туишевта?

## Гармунчы

*(Фәйзулла ага Туишевның артистлык хезмәтенә 50 ел тулуга карата)*

Фәйзулла Кәбир улы Туишев үзенең артистлык эшен 1894 нче елда башлаган. Ул үзенең туган каласы Мәләкәстән качып, Самара шәһәренә килә, анда ялланып, Ярминкәдәге карусельдә гармун уйный башлый. Шул елдан алып Фәйзулла ага Идел буендагы шәһәрләргә бара, анда карусельләрдә, балаганнарда һәм күчмә циркларда уйный.

Ф. Туишев үзенең артистлык эше белән татар халкына гына түгел, башка байтак милләтләргә дә хезмәт күрсәтә. Ул татарча «Яз да була», «Тәзкирә» көйләре белән бергә башкортларның «Сибай кантон», украиннарның «Виют витри», кырым татарларының «Хәйтәрмә», русларның «Стенька Разин», «Эй, ухнем» һәм башка көйләрен дә матур итеп башкара.

Фәйзулла ага Туишев Ватаныбызның кайсы гына почмагына барса да, төрле милләтләрнең көйләре белән бергә татар халык җырлары һәм татар композиторларының әсәрләре аның репертуарыннан төшми. Бу факт татар музыка культурасын популярлаштыруда аның зур хезмәт күрсәткәнлеге турында сөйли. Үзен тыңлаучы аудиториягә шунда җыелган халыкның ана телендә хезмәт күрсәтүе Фәйзулла аганың аерым сыйфатларыннан берсе. Шуның белән ул руслардан Петр Невский, Павел Малахов һәм башкалар кебек гармунчылардан аерылып тора.

Ф. Туишев, махсус музыка белеме алмаса да, табигый сәләте һәм таланты зур булу, һәм үз өстендә тырышып эшләве аркасында, татар музыка сәнгатен башкаручылар арасында күренекле урын тотып килә, төрле көйләрне оста башкаруы белән тыңлаучыларны сокландыра. Аның «Ончы Фәхри», «Әллүки», Венявскийның «Мазурка», Ключаревның «Комсомол сюитасы» көйләрен гармунда уйнавын тыңлау җанны рәхәтләндерә. Ул «Алмагачлар» көен фортепианога кушылып кечкенә гармунда уйнаганда без сандугач тавышларын ишетәбез. «Саратов такмаклары»н кыңгыраулы рус гармунында уйнаганда рус яшьләренең дәрте һәм шат күңеллелекләре яңгырый. Фәйзулла ага шырпы тартмасы күләменнән алып зур баян-аккордеонга кадәр булган гармуннар белән чыга. Кайбер кешеләр уйлаганча, бу гармуннар сериясе жонглерлык күрсәтү өчен кулланылмый. Бәлки ул гармуннарның һәрберсе аңа теге яисә бу көйне башкарганда характерлы тавышларны бирү өчен кирәк була.

Элекке вакытта гармунга тупас музыка коралы дип карыйлар иде. Фәйзулла ага үзенең оста уйнавы белән бу фикерне юкка чыгарды, яхшы музыкант кулында бу халык музыка коралы белән иң катлаулы көйләрне сокландырырлык итеп уйнарга мөмкин икәнлеген күрсәтте. Бу — Фәйзулла Туишевның зур хезмәте.

Фәйзулла ага концерт гармуннарында уйнавы белән башкаларга да үрнәк күрсәтте. Гармунчы Фәйзи Биккенин, Гали Җәмлиханов һәм башкалар, аның иҗат юлын дәвам итеп, гармуннарда яхшы гына уйнап киләләр.

Ф. Туишев башкаручы музыкант булуы белән бергә күп кенә көйлар язган композитор да. Профессор М. А. Юдинның катнашы белән ул күп кенә көйләр язды. Татарстанның композиторлар союзы композиторлык культурасын күтәрүдә аңа ярдәм итеп килә.

Ф. Туишев Октябрь революциясенә кадәр 23 ел буена үзенең гармуннары белән халыкка сәнгать хезмәте күрсәтте, революциядән соң 27 ел буена үзенең музыка хезмәтен азат Советлар Союзындагы халыкларның дуслыгына, бәхетле тормышына хезмәт күрсәтүгә багышлады һәм татар музыка культурасын күтәрү өлкәсендә күп эшләде. Татар халкы һәм Татарстанның сәнгать хезмәткәрләре аның бу хезмәтенә югары бәя бирәләр. Ф. Туишевның артистлык юлы һәм тәҗрибәсе татар музыка культурасын тагын да үстерүгә аның актив катнашачагына ышаныч бирә.

Фәйзулла аганың тагын да күп яшәвен һәм совет сәнгатен үстерүдә нәтиҗәле хезмәт куюын телибез.

**Җәүдәт ФӘЙЗИ,**
композитор.

1944 елның феврале бит: инде өч елга якын сугыш бара, әле аның ахыры күренми, ә житмеш яшенә якынайган Фәйзулла ага артистлыгына 50 ел тулган көннәрдә юбилей концертлары белән фронтларда, завод һәм колхозларда йөри. Газеталар аның турында язалар.

Шулай да нәрсәгә соклана Туишев сәнгатендә Җәүдәт Фәйзи? «Үзлегеннән өйрәнгән профессиональ артист, «татар эстрадасын төзүче күренеклеләрнең берсе» — дигән бәядә татар сәнгатенең асылы һәм үсеш юлы күздә тотыла. Революциягә кадәр татарның сәнгатьне профессия итеп өйрәтүче уку йортлары юк иде, халык талантлы улларын-кызларын үз эченнән сәхнәгә күтәрде, алкышлап, олылап яшәтте.

Фәйзулла Туишев үзен тыңларга җыелган халыкларга аларның ана телләрендә хезмәт итә. Шул сыйфаты белән ул рус гармунчыларыннан аерылып тора. Әмма кайда да, кайчан да татар артисты буларак чыгыш ясый.

Җәүдәт Фәйзи Туишев сәнгатен «ләззәт алалар», «сокландырырлык итеп», «җанны рәхәтләндерә», «сандугач тавышларын ишетәбез» кебек нәфислек сүзләре белән сыйфатлый.

Ф. Туишев — композитор да. Ул — асылда башкаручы түгел, ул — моң чишмәсе, моң аның күңеленнән көй булып агып чыга, гармун телләренә күчә. Төрле көйләр төрлечә башкаруны таләп итә, менә ни өчен Туишевка төрле-төрле дистәләгән гармуннар кирәк. Ул — табигатьнең моңлы авазы, өне, аһәңе.

Җәүдәт Фәйзи Туишев иҗатында шуны аңлый, Фәйзулла аганың үз сүзендә дә аның шул ук табигате үзен сиздерә, фронтовиклар карт артист сәнгатендә һәм шәхесендә Ватан җылысын, кадерен тоялар.

Ә мин архивта яткан шушы өч язмада халкыбызның үзе кебек ташны тишеп чыгарлык үҗәт, дөньяны сыйдырырлык киң күңелле, талантлы, оста, мәгърур Туишев шәхесен күрәм.

**Хәмзә ЗАРИПОВ.**
*Январь, 1995.*

# АНГЛИЯДӘ «ИСЛАМ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ»

**Ислам диненең еллар узган саен киңрәк таралуы һәм йогынтысы үсә баруы мөселман илләрендә төрле дини басмаларның артуына китерә. Бу бер дә гаҗәп түгел. Ләкин соңгы елларда замандашларыбыз бу эшнең христиан мәмләкәтләренә дә җәелүенә шаһит. Ислам нигезләрен аңлаткан аерым китаплар гына түгел, Коръән һәм пәйгамбәрләр тарихын сурәтләгән җыентыклар да, күп томлы энциклопедияләр дә анда әледән-әле дөнья күрә башлады. Шуларның берсе — Сирил Гласс тарафыннан әзерләнгән бер томлы «Ислам энциклопедиясе». Ул 1991 елда Лондонда басылып чыкты.**

**Сирил Гласс — АКШ галиме. Аның бу хезмәте — күп еллык эзләнүләре нәтиҗәсе. Шуңа күрә ул көн саен басылып торган китаплар ташкынында үзенчәлекле, тирән эчтәлекле булуы белән күзгә ташлана. «Ислам энциклопедиясе»нә кереш сүзендә профессор Хьюстон Смит хаклы рәвештә язганча, «ислам Һиндстаннан Атлантикага кадәр җәелгән империяне үз эченә ала. Бүген, ихтимал, ул — дөнья диннәренең иң зурысыдыр. Егерменче йөз ахырында аның сәяси һәм социаль тормышның бөтен тарафларына тирән үтеп керүе һәм йогынты ясавы нәкъ менә шуны исбатлый».**

**1200 мәкаләне туплаган бу китапта догалар, дини гореф-гадәтләр һәм йолалар, күрәзәлекләр, мөселманлык кануннары, календарьлар аңлатыла, төрле мәзһәбләр, оешмалар хакында мәгълүмат бирелә, тарих, этнография, телләр, милләтләр, медицина һәм бүтән фәннәр буенча белешмә басыла, ислам галәменең мәгариф-гыйлем учаклары, алар урнашкан шәһәрләр белән таныштырыла.**

**«Ислам энциклопедиясе» үткәнне замамыбыз белән бәйли, мөселман илләренең бүгенге тормышын күзалларга да ярдәм итә. Тагын да бер әһәмиятле ягы — анда ислам диненә багышланган хезмәтләрнең күп санлы исемлеге бирелә. Белешмәлек шулай ук төсле сурәтләр, карталар һәм схемалар белән баетылган.**

**Сирил Гласс былтыр Саратовка килеп, шәһәрнең югары уку йортларында ислам диненә багышланган лекцияләр укыды, татар мәктәбендә чыгыш ясады, Саратов һәм Волгоград мөселманнары имам-мөхтәсибе М. Бибарсов белән очрашты һәм Идел буе мөселманнары тормышы белән танышты.**

**Саратов галиме, фәлсәфә фәннәре кандидаты Лилия СОЛОДОВНИЧЕНКО Сирил ГЛАСС әфәнде белән очрашып, аңа «Ислам энциклопедиясе»н әзерләү барышы хакында сораулар белән мөрәҗәгать итте. Түбәндә без укучыларыбыз игътибарына шул әңгәмәне тәкъдим итәбез.**

* * *

**— Ислам хакында энциклопедия төзү уе ничек барлыкка килде?**

— Очраклы рәвештә. Мин Швейцариядә бер халыкара журналның редакторы булып эшли идем. Шулчак бер китап нәшрияты миңа әзерләнә торган ислам дине энциклопедиясенең мөхәррире вазифасын тәкъдим итте. Аларга ислам динен яхшы белүче кеше кирәк иде. Мин ризалык бирдем.

Әмма соңрак бу эш катлауланды. Хезмәткә оеткы салган Ливия гарәпләре ниятләреннән сүрелде. Ярдәм итәргә вәгъдә биргән Согуд Гарәбестаны да сүзендә тора алмады. Шуның аркасында энциклопедия төзүгә иң күренекле илледән мөселман галимен тарту фикере үзеннән-үзе юкка чыкты. Егермеләп белгеч белән эшкә тотынырга исәпләп, АКШ мәдәният хәзинәсеннән ярдәм итүләрен үтендем, әмма ул чакта (1981) бу җәмгыять егерме проектны гамәлгә ашырырга алынган иде инде. Шул проектларның берсе Африка бөҗәкләре сайравын язып алуга багышланган иде. Үтенечемне кире каккач, мин аптырап уйландым: кеше өчен бөҗәкләр сайравы әһәмиятлерәкме, әллә ислам турындагы китапмы? Мин китап әһәмиятлерәк, кирәклерәк дигән фикергә килдем һәм, солтан да, шәех тә, туләем гарәпләр дә бу эшне кайгыртмагач, «Ислам энциклопедиясе»н үзем генә төзи башларга булдым. Бу вакытта мин Индиана штатының Блумингтон шәһәреннән утыз чакрымдагы бер авылда яши идем. Әлеге шәһәрнең китапханәсендә 1,5 миллион том китап җыйналган, шулардан файдалану эшемне шактый җиңеләйтте.

**— Бу эшне башкарып чыгу тулы бер авторлар берләшмәсенә дә җиңел булмас иде. Максатыгызга ничек ирештегез?**

— Кыенлыклар бик күп очрады. Әйтик, гарәп сүзләре инглизчә бер төрле язылса, икенче төрле яңгырый, ягъни әйтелеш белән язылыш арасында аерма зур. Гарәп телен белми торган мөселманнарга инглизчә «Ислам энциклопедиясе»н файдалану читен булмасын өчен, башваткычлардан беренче адымда ук котылырга кирәк иде. Мин белешмәлектә ислам төшенчәләрен әүвәл инглизчә яңгыраштa, аннары гарәпчә әйтелештә бер-бер артлы языргa карар иттем. Шул тәртиптә төзелгән энциклопедиядән теләсә кайсы укучы җиңел файдалана алыр, кирәкле белешмәсен ансат табыр дип уйладым. Инглиз телендә 44 авазга 26 гына хәреф барлыгын истә тотсак, ят тел сүзләрен бирү (энциклопедиядә күп кенә догалар, исемнәр гарәп телендә басыла) бик катлаулы бер бурыч иде. Әгәр энциклопедия төзү эшенә тулы бер авторлар берләшмәсе тотынса, алар шушы мәсьәләдә үзара бәхәскә кереп, күп вакыт югалтыр, хәтта, бик ихтимал, килешә алмаслар иде. Ялгызым эшкә керешкәч, төшенчә һәм принципларны бер төсле хәл итү җиңеләйде. Моның үз отышлы һәм кимчелекле яклары булуы табигый. Гомум кабул ителгән төшенчәләрне аңлатканда мин, әлбәттә, кечле. Бәхәсле карашларны, төшенчәләрне аңлатканда хаталануым да ихтимал. Әмма шунысы әйбәт: белешмәлекнең башыннан ахырына кадәр эзлекле бер караш сузыла, укучы ныклы бер эзгә салынган мәгълүмат ала.

**— Энциклопедия эчтәлеген билгеләгәндә нәрсәләргә таяндыгыз?**

— Бирергә теләгән мәгълүматларны бер «җеп»кә тезү, нәрсәнең нинди күләмдә һәм рәвештә бирелергә тиешлеген хәл итү бик четерекле эш. Кирәкле техник кагыйдәләрне үзләштерү өчен генә дә миңа унбиш ел вакыт кирәк булды. Диннең асылы һәм аның төрле кеше аңындагы чагылышы, «вак-төяк» аерымлыклар кайчак фаҗигале гамәлләргә сәбәп була. Мисалга, бер хатын гарәп теле белгече саналган француз галименнән: «Намаз алдыннан пакьләнгәндә чәчләрне ничек чылатырга — төбенә кадәрме?» — дип сораган. Галим: «Төбенә кадәр!» — дип җавап биргән. Күз алдыгызга китерегез әле: тәүлегенә биш мәртәбә куе озын чәчләрен төбенә кадәр чылатса, бу бичара хатын тиз арада нинди хәлгә төшәчәк? Аның чәчен киптерергә вакыты калмаячак та лабаса! Югыйсә намаз алдыннан юеш кулларны баш очына, чәчләргә тидереп алу да бик җитә. Билгеле, гади мөселман кешесе өчен мондый нәрсәләр башваткыч тудырмый, чөнки ул аларны яшьтән белеп, күреп үсә. Әмма энциклопедияне ислам дине белән танышырга теләүче ят кавемнәр дә укыячак ич, аларны саташтыру белешмәлекнең дәрәҗәсен генә төшерер иде.

Белешмәлекне төзер өчен тирән теоретик белемгә ия булу, һәрнәрсәне аңларга тырышу һәм аңлата белү зарур. Ул чакта инде «сәер», «кыргый» нәрсәләргә очрау сине аптырашка калдырмый. Алар һәр диндә бар, чөнки диннәрнең асыллары бер. Тик аларның гәүдәләнеше, сурәтләнеше төрле диндә төрлечәрәк, шуңа күрә алар бер диндә күзгә чалына, игътибарны җәлеп итә, икенчесендә хорафат яки ырым буларак аңга сеңми кала.

Мин биш ел Мароккода яшәдем, унбиш ел дәвамында Мисыр, Төркия, Сурия, Пакыстан, Мавритания, Алжир һәм бүтән гарәп илләре буйлап сәяхәт иттем, Согуд Гарәбестанына һәм Мәккә шәһәренә җентекле юлкүрсәткечләр яздым. Ислам диненең төрле мәмләкәтләрдә тоткан урынына, аның заманага яраклашуына игътибарымны тупладым. Мөселман дөньясын һәм ислам тәгълиматын әнә шулай өйрәнү нәтиҗәсендә генә гыйльми энциклопедия төзергә алыну мөмкин иде. Шул юлны узгач кына өйрәнгән һәм тикшергән тармактагы иң әһәмиятле, иң кызыклы төшенчәләрне кыскача тасвирлап, аңлатып бирергә була.

Минем тагын бер принцибым — бер җирдә ачыкланмаган мәсьәләне икенче җирдә, бүтән юлда чишәргә омтылу. Гадәти булмаган юлларга басып эзләнү.

Энциклопедиямдә мин Коръәннең күп кенә аятьләрен гарәп һәм инглиз телләрендә китерәм, гарәпчә доганы латин хәрефләрендә бастырдым. Күп кенә төшенчәләрне аңлатканда, Коръән — минем өчен төп чыганак. Мисал өчен, «җиһад», «оҗмах» төшенчәләрен Коръәннән әйбәтрәк аңлаткан чыганак юк та. Әмма, аңлашыла ки, белешмәләремдә мин күпсанлы башка чыганакларга да таянам. Алар арасында Әл-Әшгари, Ибн-Гатаулла, Ибн-Фәрит, Ибн Әл-Мөгаффә һәм башка урта гасырлар дин эшлеклеләре, шагыйрьләр һәм фәлсәфәчеләр, аннан соңгы дәвердә ислам динен таратуда, аның төрле мәзһәбләренә нигез салуда, аны өйрәнүдә һәм аңлатуда тирән эз калдырган күренекле шәхесләрнең әсәрләре бар. Бу әсәрләрдән өзекләр китерү диннең асылын ачарга, аның йола-

ларын анықларга нәтиҗәле ярдәм итә. Бу әсәрләрнең күпчелеге инглиз теленә инде күптән тәрҗемә ителгән, кайберләреннән аерым өзекләрне гарәпчә-фарсычадан энциклопедия өчен махсус әзерләргә дә туры килде.

**— Бу эшнең барышында сез күп телләрдә уку ихтыяҗын бигрәк тә ачык тойгансыздыр. Сез кайсы телләрне беләсез һәм аларны ничек өйрәндегез?**

— Төрле илләргә сәяхәтләрем вакытында мин аларның телләрен дә үзләштерергә тырыштым. Байтак еллар дәвамында инглизләр тылмачы — гид булып эшләдем, күп кенә Европа илләрен — Алмания, Испания, Италия һәм башка дәүләтләрне аркылыга-буйга гизеп чыктым. Бервакыт мин озата барган автобус шоферы туган теле итальянчада гына сөйләшә ала иде. Ә миңа юл буе сәяхәт тирәлегенә бәйле рәвештә инглизләрне күп нәрсә белән таныштырып барырга кирәк. Моның өчен әүвәл кая баруыңны, хәзер кайсы җирдән узуыңны һ. б. нәрсәләрне белү хаҗәт. Төнлә автобусыбыз Кале шәһәреннән Парижга таба йөгергәндә, шоферым: «Сбаглиатто!» — дип куйды. Мин аның мәгънәсен якынча гына чамаладым. «Югалдык!». Ягъни адаштык! Менә шуннан соң аңлашырга, шоферга ярдәм итәргә, илгизәрләрне тынычландырырга кирәк иде ләбаса. Бөтен сәләтемне итальян телен өйрәнүгә багышларга туры килде һәм мин дүрт көннән соң бу телдә сөйләшә башладым. Билгеле, моңа француз һәм испан телләрен белүем дә ярдәм иткәндер. Урыс, алман телләрен, гарәпчәнең Марокко шивәсен өйрәнү миңа колачымны тагын да киңрәк җәеп яшәргә булышты.

**— Сез фәлсәфәне дә яхшы беләсез. Күңелегез бигрәк тә нәрсәләрне якын күрә?**

— Минем хирессләнгән затым — Алла, барлык эшләремдә дә аның ярдәменә сыгынам. Әгәр хәлемнән килсә, Алланы олылау өчен мин тагын да күбрәк тырышыр идем. Минем өчен мәңге үзгәрми торган иң төп мәсьәләләрнең гәүдәләнеше дә — Алла.

**— Энциклопедияне конкрет әзерләү ничегрәк барды? Сез бик күп сәяхәт иткәнсез, ул сәфәрләр дә белешмәлекне әзерләүгә бәйләнгән идеме?**

— Еш кына гади дип исәпләгән нәрсә катлаулы, катлаулы дигәнебез гади булып чыга. Миңа тарих белән яңабаштан танышырга туры килде. Анда исә ак таплар бик күп, аларны иң белдекле галимнәр дә ачыклый алмаган иде. Мисалга, исмәгыйлиләр мәзһәбе минем өчен чын табышмак иде. Алар турында төрлечә фикер әйтелә, кайсына ышанырга да белмәссең. Бервакыт университет китапханәсендә актарынганда Самюэль Льюнең «Соңгы дәвер Рим империясе һәм урта гасырлар Кытаенда манихей дине» китабына юлыктым. Бу китап рухи эзләнүләремне яңа фаразларга этәрде. 1988 елда Сүриядә мин мәшһүр иранчы профессор Ричард Фрай белән очраштым. Фикер алышу соңында ул миңа Гетеборг шәһәрендә (Швеция) узачак халыкара җыйналышта катнашырга киңәш итте. Манихей динен тикшерүгә багышланган бу конференциягә бик күп атаклы галимнәр, шул исәптән, Самюэль Лью да килде. Аларны тыңлау, соңра сорауларыма җавапларын алу исмәгыйлиләр турындагы билгесезлек томанын да таратты. Мин анда үзем дә чыгыш ясадым һәм шәхси фаразларымны бәян иттем. Бу конференциядә узган көннәремне гомеремнең иң бәхетле сәгатьләре хисаплыйм.

**— Эшегездә иң кыен дәвер кайсы булуын да сөйләсәгез иде?**

— Белешмәлекне нормаль шартларда әзерләү өчен матди якның нык булуы шарт. Ә минем авылда яшәгәндә акчам тәмам бетте, автомашинам сафтан чыкты, әтинекен дә кыйратырга өлгердем. Ул арада суыткычым да ватылды, түбәдән су үтә башлады, аларны төзәттерер өчен тиенем дә калмаган иде. Белешмәлекне әзерләү эшен тәмам туктатырга туры килде.

**— Алдагы ниятләрегез белән дә таныштырсагыз иде?**

— Төп эшем соңгы дәвердә «Ислам энциклопедиясе»н әзерләү булды. Ниһаять, ул басылып чыкты. Әмма мин аны камилләштерү, тулыландыру эшен дәвам итәм. Беренче басмадан бераз суынгач, мин аны яхшырак анализлый, кимчелекләрен һәм отышлы якларын әйбәтрәк күрә алырмын. Компьютерымда яңа материаллар шактый тупланды. Ислам дине киңрәк җәелә бара, аны тотучылар саны арта, аның белән кызыксынучылар күбәя. Шунлыктан «Ислам энциклопедиясе»нең яңа басмасы да игътибар казаныр дип өметләнәм. Бөтен көчемне һәм сәләтемне шул яңа басманың тагын да сыйфатлырак, тулырак һәм төгәлрәк булуына ирешер өчен бирәм.

Китап күзәтү

# ЗАМАН ДӨРЕСЛЕГЕ

Көн артыннан көн, ел артыннан ел узып тора. Кайчандыр «көн кадагы» дип саналган проблемалар үткән тарих дәфтәреннән урын ала да, безне йә елмаерга, йә моңаерга мәҗбүр итә. Әдәбият дөньясында да шулай бу. Күптәнме әле без, партия кушканча, социалистик реализм әдәбияты геройларының камиллеге өчен ихлас күңелдән бәхәсләшә идек. Аларны «тулы канлы» итәргә тырышып, «сулыш алсыннар» дип, төннекләрне ачарга тәкъдим итә идек. Имеш, шулай итсәк, барысы да әйбәт булачак. Ачкаладык та бугай әле. Әмма әсәрләрдәге геройларыбыз тумыштан нинди булсалар, шундый булып калдылар. Ләкин, ничек булуларына карамастан, бу геройлар да — безнекеләр, мондый әдәбият тә — безнең халык мирасы.

Хәер, һәр чорның, һәр дәвернең үзенә хас сәнгате, әдәбияты булу закончалыгы нишләп әле социализм чорын бәяләгәндә исәпкә алынмаска тиеш ди?!. Бу чор әдәбияты да тарихка үзенә генә хас билгеләре, үз казанышлары белән, үз идеологик концепциясе һәм принциплары белән кереп калды. Бүген алар кемнәргәдер гаҗәп булып күренергә мөмкин, кемнәрдер аларны пыр туздырып тәнкыйтьләр. Анысы — алар эше. Яңалыкның үз элгәргесен шулай инкарь итеп килүе табигый хәл. Әмма яңа заман әдәбиятының үзенең дә әлеге китеп баручы казанышларга таянып эш башкарачагын, еллар үтеп үзе дә шулай тарихи мираска әвереләчәген истән чыгармыйк. Кыскасы, тарих чылбырының алкалары, дөресрәге спираль «алкалары» өзлексез алар.

Күп гасырларны иңләгән әдәбиятыбызның үсеш-үзгәреш процессларын аңлау өчен, аның төрле этаплардагы, чорлардагы халәтен белү зарур. Тик аерым чорлар эзлекле һәм тирән өйрәнелгәндә генә гомумәдәбият тарихы фәнни тирән яктыртылырга мөмкин. Бу яктан караганда социалистик реализм әдәбиятын кыерсытылган дип әйтеп булмый. Үз заманының әдәбият белеме дә, тәнкыйте дә соцреализмга игътибарсыз булмады. Дөрес, кайбер жанрлар өлкәсендә әдәби процессны өзлексез күзәтеп, бәяләп баручы галимнәр, тәнкыйтьчеләр азрак булды. Әле шуның өстәвенә, бу өлкәдә тирәнгә керергә теләмәүче һәм керә дә алмаучы тәнкыйтьчеләр дә бар иде. Менә шул якларны исәпкә алганда, бу юнәлештә эзлекле эшләүче профессионалларның хезмәтләре бүген генә түгел, киләчәктә дә аерым әһәмияткә ия булачак һәм алар игътибар үзәгендә торачак. Менемчә, А. Әхмәдуллинның татар драматургиясенә караган хезмәтләрен нәкъ менә шундый мирас дип санарга мөмкин. Бу очракта мин аның «Дөреслеккә ирешү юлында» (1993) дигән мәкаләләр җыентыгына аерым тукталып, кайбер фикерләрем белән уртаклашырга телим.

Шунысы игътибарга лаек, әлеге китапка тупланган хезмәтләрен автор «азмы-күпме үзгәртү»ләр юлына басмаган. Бер уйлаганда, хәзерге көн бәяләмәләре шактый ук үзгә бит, «төзәтмәләр» булырга тиеш иде кебек. Тик заман дөреслеген саклау һәм аны тулы бер эзлеклелектә бирү китапның кыйммәтен күтәрә. «Ул заманда драматургия белән театр нинди булган?» дигән сорауга да бу китапта әтрафлы җаваплар бар. Бер үк вакытта «татар тәнкыйте бу өлкәдә нинди карашлар үткәргән, нинди роль уйнаган?» дигән сорауларга да биредә җавап табарга мөмкин.

Җыйнап әйткәндә, шунысы ачык: профессор А. Әхмәдуллинның соңгы ун елда язган әдәбият һәм театр сәнгатенә багышланган гыйльми хезмәтләре, тәнкыйть мәкаләләре кергән бу китап авторның үз концепцияләренә турылыклы булып калганын раслыйм. Аңа чынбарлык дөреслеген сәнгатьчә оста чагылдыру, уңай башлангычны күрү һәм яклау, яшь талантларга һәм, гомумән, иҗат кешеләренә игътибар-

лы булу, кирәк урында акны ак, караны кара дип ачык әйтү хас.

Китапның икенче мөһим ягы: әлеге басмага тупланган хезмәтләр барысы бергә авторның татар драматургиясе һәм театры турында эзлекле бәян ителгән карашлар системасы булып тора. Моны ассызыклап әйтүемнең сәбәбе — татар драматургиясенең һәм театрының аерым чорларын яктыртуга багышланган очерклар, мәкаләләр булуга карамастан, бездә ул чорларны үзара бәйләнештә караган зур хезмәтләр юк диярлек. Бу китап исә авторның моңа кадәр дөнья күргән һәм элекке чорларга караган монографик хезмәтләренең бер өлеше буларак та кабул ителә. Соңгы ун ел киеренке бәхәсләр, эзләнүләр һәм, ниһаять, җитди үзгәрешләр дәвере булганга, авторның бу эше актуаль проблемаларга мөнәсәбәтле.

Авторның әдәбият һәм театр сәнгате турындагы үзәк проблемаларга кагылышлы җитди анализлары бай фактик материалга нигезләнгән. Китапта Х. Вахит, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Ю. Әминов, И. Юзеев кебек каләм осталарының нечкәләп эшләнгән иҗат портретлары бирелү дә шул турыда сөйли. Әйтергә кирәк, әлеге драматургларның иҗатын даими күзәтеп баручы буларак, А. Әхмәдуллинның алар турындагы бәяләмәләре гаделлек һәм төпле.

Иҗат портретлары ук булмасалар да, китапта башка драматургларга да «тәрәзәләр» ачылган. Алардан Р. Батулла, Р. Хәмид, Ф. Садриев, Ә. Гаффар, Р. Мингалим, Ю. Сафиуллин, М. Маликова, Ф. Яруллин, Ф. Бәйрәмова кебек талантлы авторлар иҗаты турындагы күзәтүләрне атап әйтергә була. Бу яктан авторның әдәби ел йомгакларында һәм Татарстан язучыларының XI съездында укыган докладлары аерым игътибарга лаек.

Китапта «Драматургиябез тарихыннан» дигән тагын бер зур гына бүлек бар. Биредә татар драматургиясендәге мәгърифәтчелек традицияләре, Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Һ. Такташ, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов драматургияләренең үзенчәлекләре яктыртыла. Бу мәкаләләрдә әлеге әдипләр иҗатының моңарчы ачылмаган якларына игътибар юнәлтелә, яңа дәлилләр, документлар китерелә.

А. Г. Әхмәдуллин күп кенә спектакльләргә рецензияләр язып, пьесаларның сәхнәдә яшәешләре турында еш кына беренчеләрдән фикер әйтүче театр тәнкыйтьчесе буларак та мәгълүм. Драматурглар, режиссерлар, актерлар мондый рецензияләрне көтеп алалар. Әмма бу китапта андый мәкаләләргә күп урын бирелмәгән. Тик «Октябрьга кадәрге татар театры» китабына язылган рецензия генә урнаштырылган, аңа җитди анализ ясалган һәм объектив бәя куелган. Дөрес, танылган режиссерлар Ш. Сарымсаков, М. Сәлимҗанов, күренекле актриса Г. Болгарская иҗаты турында һәм «Зәңгәр шәл»гә, И. Илалованың Г. Камал театры турындагы китабына рецензияләр, Әлмәт, Минзәлә театрлары репертуарларын анализлауга багышланган мәкаләләр һ. б. булу әлеге хезмәтнең шактый ук театраль эчтәлекле икәнлеген сөйли.

Тулаем алганда китап авторның тәнкыйтьче, әдәбиятчы буларак төп карашларын, критерийларын ачык чагылдыра. Дөрес, күпләр кебек А. Әхмәдуллин да тоталитар системада формалашкан галим. Шуңа күрә аның ул елларга караган бәяләмәләре дә коммунистлар партиясе таләпләреннән читләшә алмаган. Нык читләшү мөмкин дә түгел иде. Әнә шундый шартларда «коры шалтырауларга» бирелмичә, аның үз игътибарын әдәби осталык мәсьәләләренә юнәлтүе, гомумкешелек кыйммәтләренә беренчелекне бирүе, кешенең күңел дөньясына игътибар таләп итүе — болар һәммәсе галимнең ул еллардагы эшчәнлегенең әһәмиятен билгели.

**Назыйм ХАНЗАФАРОВ.**

# ӨЧ РӘСЕМ — ӨЧ МИЗГЕЛ

Өеңә кунак-төшем килсә, чәең кайнап чыкканчы, табын әзерләгән арада гаилә альбомын актарып, фоторәсемнәр карый тору гадәте бар безнең халыкта. Фоторәсемнәр хуҗа кешенең узган тормышын ачыграк күзалларга булыша, аның нәсел-нәсәбе, дус-ишләре турында мәгълүмат бирә.

**Менә без дә әдипләр дигән уртак гаиләбезнең фотоальбомын булдырырга ният кылдык.**







**Беренче фоторәсемдә** сез «Казан утлары» редакциясенең элеккеге редколлегия әгъзаларын күрәсез. Уңнан-сулга: күренекле әдипләребездән Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Ләбибә Ихсанова, Зәки Нури һәм Хәй Вахит. Арттагы пландагы Муса Җәлил бюсты бу язучыларның «Казан утлары»ның баш редакторы булмәсендә утыруларын күрсәтеп тора. Фоторәсемнең арткы ягына М. Шакирҗанов фотосы дип язылган.

**Икенче фоторәсем** 1963 елда «Татарстан яшьләре» редакциясендә төшерелгән. Ул елларда редакция каршында әдәбият-сәнгать түгәрәге әйбәт кенә эшләп килә иде. Ул түгәрәккә Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге, Казан дәүләт педагогия институты студентлары, эшче яшьләр һ. б. каләм тибрәтүчеләр бик теләп йөри иде. Хәзер әдәбиятыбыз күгендә йолдыз булып балкыган күп кенә талантлы әдипләр әнә шушы остаханәдән үсеп чыктылар. Бу рәсемдәге шат күңелле егет вә кызларны таныйсызмы? Уңнан-сулга: Равил Фәйзуллин (ул вакыттагы әдәбият-сәнгать түгәрәгенең җитәкчесе),— хәзерендә күренекле шагыйрь, җөмһүриятебезнең Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Роза Мулланурова — язучы, «Сөембикә» журналының бүлек мөхәррире, Ренат Харис — күренекле шагыйрь, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Шамил Рәкыйп — язучы, «Шәһри Казан» гәзитенең әдәбият-сәнгать бүлегең җитәкли, Әнвәр Шәрипов — галим, «Аргамак» журналының редколлегия әгъзасы, Шамил Маннап — шагыйрь һәм прозаик, «Казан утлары»ның бүлек мөхәррире, Рәйсә Юсупова — журналист, озак еллар «Сөембикә» редакциясендә эшләде, хәзер — лаеклы ялда, (алгы рәттә утырганнар): Фаяз Дунай — тәнкыйтьче, журналист-публицист һәм Заһирә Гомәрова — шагыйрә, гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган кеше — укытучы.

**Өченче рәсем** дә укучыларыбыз игътибарын җәлеп итәр дип уйлыйбыз. Биредә шагыйрь Фәнис Яруллинның бәхетле мизгелләре — Нурсөягә өйләнү вакыты һәм шушы тантана уңае белән яшь парны туганнарының һәм дусларының котлавы сурәткә алынган. Алар арасында Фәниснең беренче остазларыннан шагыйрь Марс Шабаев та бар. Ул яшь шагыйрьгә гаилә бәхете, киләчәктә иҗатында зур уңышлар теләде. Теләкләре кабул булды: Нурсөя белән Фәнис бик матур тормыш итәләр, Фәнис Яруллин үз иҗатында яңадан-яңа биеклекләр яулый. Ул бүгенге көндә күпләгән шигырь һәм проза китаплары авторы, республикабызның Г. Тукай һәм М. Җәлил исемендәге премияләр лауреаты.

Истәлекле бу фоторәсемнәрне журналыбызга Шамил Маннап тәкъдим итте.

**Хөрмәтле укучыларыбыз һәм әдипләр! Сездән дә шундый истәлекле фоторәсемнәр көтеп калабыз. Аларның һәркем өчен кызыклы дип табылганнары, әлбәттә, «Казан утлары» битләрендә урын алыр.**

Сәвия Михайлова,
Гүзәл Мөхәммәтҗанова

# ТАРИХИ ҺӘМ МАТУР ӘДӘБИЯТТА АЛТЫН УРДА

Бөек галимебез Ш. Мәрҗани: «Үткәнен оныткан халык киләчәгенә өметләнә алмый»,— дип язган. Чыннан да, тарихыбызга битарафлык күрсәтеп, без иң зур һәм иң әһәмиятле, берни белән дә алыштырып булмый торган нәрсәдән коры калабыз, ахры. Җәмгыятебезнең тарихи белемнәргә ихтыяҗын канәгатьләндерү үтәве кыен булган бер мәсьәләгә әйләнә бара.

Халыкның сәяси үзбилгеләнүе, дәүләтчелеге тергезелүе гамәлгә ашырылган шартларда, Рәсәй халыкларының, хосусан, борынгы дәүләтчелегенә ия татар халкының, объектив тарихын язуга аеруча игътибар бирергә кирәк.

Дөньядагы иң куәтле дәүләтләрнең берсе булган Алтын Урданың нигезләнүенә дә 750 ел тулып узды. Ватаныбыз тарихын өйрәнү белән шөгыльләнүче бер генә галим дә татар халкы тарихында тулы бер дәверне тәшкил иткән Алтын Урданы күрмәмешкә, белмәмешкә салына алмый. Әмма аның тарихы белән гомуми рухта кызыксыну төрле караштагы галимнәр арасында фәнни фикер алышуга бик озак юл ача алмады. Гасырыбызның егерменче елларында ук Г. Гобәйдуллин, Җ. Вәлиди, Г. Исхакый, Г. Баттал, М. Бигиев, З. Вәлиди, М. Худяковлар татар халкы тарихы белән тирәнтен кызыксындылар. Г. Гобәйдуллин язуынча, татарлар, үзбәкләр, төрекмәннәр, кыргызлар, казакълар, башкортлар, госманлы төрекләре, әзәрбайҗаннар «күп гасырлы бердәм тарихка, бер үк телгә, традицияләргә, бер үк мәдәнияткә һәм хәтта бердәй тормыш рәвешенә ия һәм бу аларны инде күптән бер милләткә әйләндергән».

Егерменче-утызынчы елларда галимнәр елъязма, хан ярлыгы, фольклор, борынгы кулъязмалар кебек чыганакларга, кабердаш, китап, көнкүреш әйберләре, хәрабәләр һәм башка матди истәлекләргә таянып тикшеренүләр алып бара. Алар тарафыннан тупланган мәгълүматлар, алар барлаган гыйльми чыганаклар соңрак заманда да әһәмиятен югалтмый.

Татар халкы тарихының катлаулы мәсьәләләрен Казан ханлыгы мисалында фәнни яктан анализлауны М. Худяков «Очерки по истории Казанского ханства» (Казан, 1923) хезмәтендә башкарып чыга. Казан ханлыгы барлыкка килүне сурәтләгәндә ул Алтын Урда дәверенә дә тукталмый кала алмый. Вельяминов-Зернов хезмәтләренә, Воскресенск һәм Никонов елъязмалары һәм тагын бүтән чыганакларга таянып, ул Олуг Мөхәммәт тәхеттә утырган дәвердә Рәсәйнең татарларга буйсынуын, бөек кенәз дәрәҗәсен дәгъвалаучы Дмитрий Донской улы һәм оныгының — Мәскәү кенәзләренең Олуг Мөхәммәт хозурына хөкемгә килүләрен билгеләп уза. Худяков шул хезмәтендә сәяси фикер һәм дәүләтчелек узаңының үзгәрүен — татар мәдәниятенең урысныкына, урыс мәдәниятенең татарныкына йогынты ясавын искәртә.

Алтын Урда мәсьәләләрен аз санлы, әмма укымышлы татар мөһаҗирләре дә тикшерә. Билгеле, егерменче-утызынчы елларда аларның хезмәтләре СССРга кертелми диярлек, чөнки алар иҗаты татарларны һәм башка мөселманнарны халыкларның социалистик бердәмлегеннән аеруга исәпләнгән «панисламист», «пантөркист» пропаганда дип бәяләнә.

Ләкин күп кенә мөһаҗирләрнең Алтын Урда тарихына кагылган тикшеренүләре әле дә әһәмиятен җуймаган. Мисалга, менә дигән язучы, журналист һәм тәнкыйтьче, югары дәрәҗәдәге сәяси эшлекле Г. Исхакый татар халкын тергезү юлларын эзләгәндә Алтын Урда тарихына да мөрәҗәгать итә. СССРдагы рәсми караштан аермалы буларак, ул Алтын Урданы дөнья күләмендә шөһрәтле һәм куәтле империя дип исәпли, шунлыктан Болгар ханлыгының ана кушылуы, нигездә, сәяси әһәмияткә ия була. Болгар ханлыгы матди җәһәттән зыян күрми, чөнки яулап алучылар да кардәш төркиләр булып чыга. Тиздән алар җиңелгән халыкның мәдәни йогынтысы астында кала (Г. Исхакый. *«Идел-Урал». Казан, 1991*).

Г. Исхакый фикеренчә, болгарлар һөҗүм итүчеләрдән үз нәүбәтләрендә бик күп нәрсә кабул итә, шушы үзара тәэсир нәтиҗәсендә соңрак «казан татарлары» дигән халык барлыкка килә. Юл уңаенда шуны да искәртү зарур ки, Г. Исхакый татар исемен болгарга алыштыруны һич тә хаҗәт санамый, чөнки бу адымның милләтне икегә аерачагын һәм аны зәгыйфьләндерәчәген ул алдан ук белеп тора.

Исхакый искәртүенчә, Алтын Урда монголлар тарафыннан төзелә, ләкин аның ханнары һәм аксөякләренең бер өлеше генә монгол була, дәүләтнең төп халкын исә болгар, кыпчак, хазар һәм бүтән төрки кабиләләр тәшкил итә. Тиздән монголлар төркиләшә һәм дәүләт теленә әверелгән төркичәдә аралаша башлый. XVIII-XIX йөз урыс тарихчылары артыннан Исхакый да бу дәүләттә диннәр тигезлегенә игътибар юнәлттерә. Алтын Урдада дини хисләрне җәберләгән өчен үлем җәзасы бирелә. Барлык диннәрнең руханилары салым түләүдән азат ителгән була.

XX йөзнең егерменче-утызынчы елларында СССРда дингә һәм дини җәмгыятьләргә административ һөҗүмнәр көчәйгәндә, татар халкын көчләп урыслаштыру, аның мәдәниятен кысу һаман арта барганда, мөһаҗирләр ватаннарындагы хәлләр өчен борчылмый кала алмый иде — алар мондый сәясәтне фаш итә торган ялкынлы әсәрләр яза.

Алтын Урда таркалуының эчке һәм тышкы сәбәпләрен тарихи барышта күздән кичергән Гаяз Исхакый 1933 елда ук СССРның киләчәге юклыгын фараз итә.

Алтын Урданы тикшерүгә Б. Д. Греков һәм А. Ю. Якубовский *(«Золотая Орда и ее падение». М.— Л., 1950)*, А. П. Смирновлар саллы өлеш кертә. Алар раслаганча, дәүләт диненең уртаклыгы, дәүләт теленең якынлыгы аркасында Идел буе Болгарстаны, Русь һәм бүтән төрки булмаган төбәкләргә караганда, Алтын Урдага якынрак була. Урдада ислам дине кабул ителүдә Болгарстан күренекле роль уйный.

Г. А. Федоров-Давыдов Алтын Урдадагы идарә системасын аеруча җентекләп тикшерә *(«Общественный строй Золотой Орды». М., 1973)*. Бу галим монгол-татарларның буйсындырылган Көнчыгыш Европа халыклары белән мөнәсәбәтен В. В. Бартольдча яктырта, ягъни Алтын Урда төзелү Шәрекъ белән Гарәп хезмәттәшлеген әйбәт юлга салуын һәм файдалы үсеп китүен билгеләп. Шунысы кызганыч, Алтын Урда дәверен арада иң объектив һәм дәлилле яктырткан Федоров-Давыдов карашлары дәреслекләрдә һәм хәзерге матбугатта искә алынмый диярлек.

Идел буе Болгарстанын өйрәнүгә искиткеч зур өлеш керткән А. П. Смирнов болгарларның татар-монгол тормышы һәм эшчәнлегенең һәр тарафына, бигрәк тә Алтын Урдада шәһәр корылышы, һөнәр, сәүдә, кала мәдәнияте үсешенә йогынты ясавын билгеләп уза *(«Волжские булгары». М., 1951. 63 б.)*.

Н. М. Карамзин, С. М. Соловьев, В. О. Ключевскийларнең шушы темага караган хезмәтләрен җентекләп өйрәнгәч, совет тарихчыларының карашлары, дәлилләре революциягә кадәрге галимнәр мирасына таянуы абайлана. Бу инде берьяклы раслауларга җирлек бирә, әнә шулай хата, күрәләтә ялган фикерләр барлык дәреслекләргә һәм уку кулланмаларына үтеп керә һәм тарихи аңны саташтыруга, бозык фикер һәм мәгълүматлар таратуга булыша.

Шунысы кызык: революциягә кадәр яшәгән тарихчылар үзләреннән күчерүче һәм аңлатма бирүчеләрдән шактый объективрак. Карамзин, мәсәлән, урыс дәүләтчелеге формалашуында һәм үсешендә, матди һәм мәдәни үзгәрешләрендә тышкы йогынтының тискәре якларын күпертеп күрсәтсә дә, Алтын Урданың уңай тәэсирен дә күрсәтә. «История государства Российского» хезмәтенең 3 томындагы ике бүлегендә, 4 томның уникe бүлегендә һәм 5 томның дүрт бүлегендә ул Алтын Урдага кагылышлы вакыйгаларны тасвирлый. «Славяннар холкында ниндидер азиатлык элек тә булган, хәзер дә бар; күрәсең, алар Шәрекътән, халыкларның төп ватаныннан бүтән Европа кавемнәренә караганда соңрак ерак-

лашкан. Хатын-кыз иреген кысу һәм колларны җәберләү, кеше белән сату итү, хөкемдә ришвәт алуны табигый санау (кайберәүләр моны азиатлык дип атый) кебек гадәтләрне ата-бабаларыбызга татарлар такмаган: без аларны славяннарда һәм рәсәйлеләрдә элегрәк тә күрдек»,— ди галим *(әлеге хезмәт, 5 т., 210—211 бб.)*.

Н. М. Карамзин, заманының фәнни мөмкинлеге җирлек биргәнчә, Рәсәйдә аккан сәяси вакыйгаларны бөтен төбәкләр, хәтта бөтен Евразия киңлегендә чагыштырып карый һәм гомум закончалыкларга игътибар итә. Бер яктан, ул Рәсәйнең Европа халыкларыннан артта калуын татар-монголлар һөҗүме һәм шуннан соңгы изү белән аңлата. Тик... Азия белән озак вакыт аралашу барышында Рәсәй, Европа-Азия дәүләте буларак, мәгълүм яңа традицияләр һәм гореф-гадәтләр дә кабул итә, ягъни ике кыйтганың да чалымнарын үзенә сеңдерә. «Мәскәү үзенең күтәрелүе белән ханнарга бурычлы,— ди галим.— Әгәр урыс җирләре Урда канаты астында тормаса, Литва, Польша, Мажарстан, Швеция Рәсәйне инде һич тә кире кайтармаслык итеп бүлгәләп алырлар иде».

Карамзин Урдада төрле дин һәм мәдәниятләргә ирек куелуын, сәнгатькә һәм гыйлемгә күңел бирелүен дә басым ясап күрсәтә. «Бөек кенәз Александр Бәркә ханны Идел буендагы Сарай шәһәрендә барып тапты. Батыйның бу мирасчысы сәнгать һәм гыйлемнәрне ярата иде; галимнәрне, сурәтчеләрне назлый, кыпчак башкаласын матур биналар белән бизи, анда яшәүче рәсәйлеләргә христиан динен иркен тотарга рөхсәт итә, шуңа күрә митрополит Кирилл (1261 елда) алар өчен махсус Сарск дип аталган Епархия нигезләп, сонра ана көньяк Переяславль епископлыгын да куша» *(«Ист. г-ва Российского», 4 т., 54 б.)*.

Карамзинның 12 томлык бу төпле хезмәтендә Алтын Урда белән Русь бәйләнешләре бик каршылыклы яктыртылуын да әйтми булмый. Бер җирдә ул: «Кенәзләр Урдага хәтәр хөкемгә баргандай бара иде: аннан хан хәер-догасын алып яки һич югы башы сау килеш кайта алучы үзен бәхетле саный иде!» — ди, икенче урында: «Аерым бер илтифат күрсәтү йөзеннән, православие динен тоткан кенәзләребез өчен чиркангыч булган төрле йолаларны үтәтмичә генә, аны үз чатырына кертте... Батый Даниилны татар йолаларын хөрмәтләве өчен мактады»,— ди *(4 т., 25 б.)*.

Безнеңчә, Карамзинның «Русия дәүләте тарихы»ның дүртенче томына В. Л. Егоров язган аңлатмалар һич тә тәнкыйтьне күтәрми. Аныңча, Русьның бөтен бәлаләре татар-монгол һөҗүме аркасында гына килеп чыккан. «Монголлар һөҗүме Рәсәйнең күп милләтле дәүләткә әверелеп үсеп баруын икегә бүлгән чик булып тора. 300 елдан артык яшәп килгән Борынгы Русьның табигый тереклеген Бату хан җайдаклары өзде»,— ди Егоров.

Үз нәүбәтендә С. М. Соловьев Алтын Урда ханы Әхмәтнең ябырылуы бөек кенәзне нинди зур куркуга төшерүен тасвирлый. Шушы очракны файдаланып калырга ашыккан кече туганнары илче җибәреп, аңа: «Әгәр безгә карата үзгәрсәң, моннан соң безне җәберләүне ташласаң, безгә туганнарча карый башласаң, сиңа ярдәмгә килербез»,— диләр. «Ион аларның барлык таләпләрен үтәргә вәгъдә бирә. Туганнары, гаскәрләрен алып, ул Угра буенда татарларга каршы торган җиргә килә» (С. М. Соловьев. *Сочинения. 5—6 т. М., 1889. 50 б.*).

В. О. Ключевский үзенең лекцияләрендә шулай ук, элгәреге каләмдәшләре рухына тугрылык саклап, «татар һөҗүме төньяк Русь халык хуҗалыгын бик озакка, бөтен XIII йөз буена коточкыч бөлгенлеккә төшерде»,— дип сөйли. Шул ук вакытта ул Русьның Алтын Урда белән XIV йөздә яхшы дипломатик, финанс бәйләнешләрендә яшәвен билгеләп уза (А. О. Ключевский. *«О русской истории», М., 1993. 139, 145 бб.*).

Алтын Урда белән Русь мөнәсәбәтләрендә тыныч хезмәттәшлек хөкем сөрүен искә алмау күп кенә авторларның уртак кимчелеге булып тора. Русь белән Алтын Урда арасында сугышлар булуын танымау мөмкин түгел, әмма Л. Н. Гумилев һәм аның тарафдарлары исәпләгәнчә, алар гел дошманлашып кына яшәмәгән. В. Б. Кобрин, В. В. Каргалов исә урыс кенәзләренең үзара бәрелешләрен, Руська Гарәп һөҗүмнәрен һич тә искә алмыйча, бөтен игътибарларын XIII йөзнең соңгы чирегендә генә дә Урданың унбишләп зур поход ясавына юнәлтә. Билгеле инде, алар шул ук вакытта урысларның талау-бәлдерү һөҗүмнәре җәелдерүен телгә дә алмыйлар! В. Б. Кобрин «Власть и собственность в средневековой России» китабында: «Басып алу барышында җир биләүче феодалларның төп өлеше кырып ташланды»,— дип раслый.

Шушындый ук караш иң яңа уку кулланмалары «Наше Отечество» *(М., 1991)* һәм «История Отечества» *(М., 1991)* китапларында да ярылып ята.

Л. Н. Гумилев фикеренчә исә, Руська иң зур хәвеф монголлар тарафыннан түгел, Гарептән яный, шунлыктан Александр Невскийнең Урда белән берләшүе хәлиткеч ихтыяжга җавап бирә. Гумилев фикеренчә, урыслар, Урда хакимлегеннән зыян күрми. Елъязмаларның берсендә Җаныбак хан юкка гына «игелекле патша» дип аталмаган лабаса, ди ул. «Батыйның аз санлы монгол яугирләре Русь аркылы чабып уза да кире далага кайтып китә»,— дип раслый Гумилев *(«Нева» ж., 1988, № 3, 4)*.

Әмма Гумилев һәм борынгы елъязмачы раслауларын дәреслек авторлары кабул итми. Алар 74 урыс шәһәренең 49 ын Бату җимерүен, 9 кенәзнең һәлак ителүен һ. б. бәхетсезлекләрне хәбәрли. «Татарстан АССР тарихы»ның барлык басмаларында да шундый ук тискәре мәгълүматлар китерелә.

Совет идеологлары: «Безгә Бөек Рәсәй СССРның бүтән халыклары тарихыннан аерып күрсәтелмәгән СССР тарихы дәреслеге кирәк»,— дип күрсәтмә биргәнлектән, «Татарстан АССР тарихы» *(Казан, 1955)* редколлегиясе, нигездә, белдекле тарихчылардан һәм консультантлардан торса да, әлеге күрсәтмәдән читкә тайпыла алмый.

Казан татарларының килеп чыгышы тарих фәненең бер четерекле мәсьәләсе санала. Рәсми идеологлар тарафыннан буржуаз милләтчеләр хезмәтләре кискен тәнкыйть утында көйдерелә, Алтын Урданы «бердәм татар дәүләте» дип караучы, Шәрекъ халыклары арасында татарлар мәдәниләштерүче һәм оештыручы ролен уйный, дип санаучы «агрессив татар буржуйларының» тетмәсе тетелә.

Шундый ук рухта Алтын Урданы һәм «Идегәй» дастанын идеаллаштыру тәнкыйтьләнә, Куликова сугышы исә «халыкара әһәмияткә ия бөек җиңү» дип бәяләнә *(«Татарстан АССР тарихы». 1 т. 94 б.)*.

Озак вакыт дәвамында Идел буе Болгарстанына һәм аның мәдәниятенә табынылса, хәзер кайбер галимнәр Алтын Урда дәверен тирәнтенрәк өйрәнүне яклый башлады.

Аларның бер өлеше Алтын Урда тарихын элгәреге тикшеренүчеләрдән аермалы рухта яктырту, «Алтын Урда тарихын да халыкка тулы күләмдә кайтарып бирү» (И. Таһиров. *«Алтын Урда: миф һәм чынбарлык».— «Шәһри Казан» г., 15.V.1993*) фикеренә килде.

Берничә гасыр дәвамында гадәткә кергән фикер йөртү рәвеше бары Идел буе Болгарстаны мәдәнияте һәм теле тарихын гына кабул итә. Безнең аңыбыз төрле бормаларны турылый, ата-бабаларыбыз узганын үзенчәлекле, камил, кимчелексез, сугышлардан, талаулардан һәм мәйданый дәгъвалардан азат бөек мәдәнияткә ия тарих буларак кына күрергә тели. Кызганыч ки, чынбарлык схемаларга тәмам сыеп бетми, чөнки колачлы вакыйгаларның, тарихи үсешнең этәргеч көчләре, сәбәпләре бер генә булмый. Тарихи хәтердә күп нәрсәләр җуела, ләкин, кагыйдә буларак, сәяси культура сакланып кала.

Миклухо-Маклай язганча, «... гомум кабул ителгәнне юкка чыгаручы һәм ниндидер яңаны раслаучы фикер-карашлар бәрелешеннән, хакыйкатьне эзләргә этәрүче шөбһәләрдән чәчрәгән очкын ул. Әнә шундый очкыннар кабынсын өчен кешеләргә эчке рухи ирек, фикерләр хөрриятенә юл куя торган җәмгыять кирәк».

Безнең җәмгыятьтә озак вакыт фикер аерымлыгына юл куелмады, «дәүләттә кабул ителгән, билгеләнгән» карашка шик-шөбһә белдерү дә гөнаһ саналып килende.

Танылган болгарчы галим Равил Фәхретдинов үзе өйрәнгән дәүләт хакында укучыларга бик күп мәгълүмат бирде. Аның хезмәтләренә тулылык, төплелек һәм чыганакларга таянган дәлиллек хас. Аның «Очерки по истории Волжской Булгарии» *(М., 1984)*, «Золотая Орда и татары» *(Н. Челны, 1993)* монографияләре илебезнең хәзерге заман тарих гыйлемен баеткән җитди хезмәтләр булды. Шул заманның социаль-икътисадый, сәяси-мәдәни үсешен яктыртканда берьяклылыктан, элекке катып калган карашлардан арынуы аркасында, ул күп кенә күренешләрне яңача сурәтли һәм бәяли алган, тикшеренүе барышында әлегә кадәр тарих гыйлемендә кузгатылмаган яңа мәсьәләләрне актарып чыгарган.

Р. Фәхретдинов башлыча С. М. Шпилевский, Б. Д. Греков, А. Ю. Якубовский, А. П. Смирнов, М. Сәфәргалиев, Г. А. Федоров-Давыдов, Л. Н. Гумилев традицияләрен дәвам итә. Фикеребезчә, автор, булган тикшеренүләрне, чыганакларны яхшы белүдән тыш, үзеннән элгәре яшәгән галимнәр хезмәтенә бик зур хөрмәт белән карый. Чынлыкта Алтын Урда һәм Идел Болгарстаны тарихына кагылышлы булган бер генә җитди хезмәт тә игътибардан читтә калмаган. Бу хәл безне күп кенә тикшеренүләрне анализлаудан коткара.

Кайбер нәтиҗәләре бәхәсле булуга карамастан, Р. Фәхретдинов хезмәтләре төрки халыкларның тарихи хәтерен терелтү, үткәннең асыл гуманистик кыйммәт-

ләрен яңа буыннарга кайтарып бирү юлында киң мөмкинлекләр ача. Аның археологик казынулары дәүләтнең икътисадын, авыл хуҗалыгын, архитектурасын һәм төзелеш эшен, сәүдәсен, хәрби көчен ачыкларга, Алтын Урданың бөеклеген күрсәтергә бай мөмкинлек бирде.

Монголларның борынгы культурасы монда төрки халыкларның югарырак баскычтагы мәдәнияте тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Мәгълүм ки, һәр заманда һәм культурада тел белү мәдәниятлелек билгесе булып санала. Алда әйткәнебезчә, монголлар тиз арада төркиләшә һәм төрки телдә сөйләшә, аралаша башлый. Бу хакта дистәләрчә тикшеренү, фәнни хезмәтләр бар. Яшәү тирәлеге, бергә катнашып гомер итү телләр үзләштерү ихтыяҗын да тудыра. Алтын Урдада милләтара аралашу теле төрки тел була. Бу тел төрле шивәләргә аерылган, әмма тора-бара алар шактый дәрәҗәдә үзара якынайган.

Равил Фәхретдинов раслаганча, аз санлы монгол этносы — империянең аксөякләре җирле төрки кабиләләр арасында XIV йөздә эреп бетә, монгол теле дә шушы дәвердә юкка чыга. Алтын Урда шушы чорда иң куәтле үсеш баскычына күтәрелә. Андагы дәүләт төрки теленең татар теленә якынлыгын, кардәшлеген шул заманның мәшһүр кульязма мирасы — борынгы татар әдәбиятының кадерле һәйкәле саналган «Кодекс куманикус» бик ачык раслап тора.

Алтын Урда соңгы вакытта нәшер ителгән күп кенә тарихи белешмәлекләрдә һәм брошюраларда да телгә алына, алар нигездә бер-берсен кабатлый һәм Равил Фәхретдинов хезмәтләренә ни чыганаклары, ни карашлар юнәлеше ягыннан яңалык өстәми. А. Халиковның «Татарский народ и его предки» *(Казан, 1989)* китабында: «Алтын Урда паразитик дәүләт буларак төзелә, аның икътисадый нигезен колга әйләндерелгән халыкның хезмәте, ә мәйданый бәйланышын Алтын Урда ханнарының сәяси хакимияте һәм киң җәелдерелгән бюрократик күзәтү системасы барлыкка китерә»,— ди.

Мөселман цивилизациясе кысасында төрки, шул исәптән, татар ренессанс әдәбиятын өйрәнүдә Р. Ганиева хезмәтләре яңалык алып килде. Ул хаклы рәвештә билгеләп узганча, «төркиләрнең Евразиянең төрле төбәкләрен яулап алуы һәм шунда урнашуы тарихы үзе үк Шәрекънең һәм Европаның күп кенә халыклары белән гадәттән тыш киң багланышларга керүләре хакында сөйли» (Р. К. Ганиева. *«Төрки әдәбиятларда Шәрекъ ренессансы һәм аның традицияләре». Автореферат. Казан, 1992. 13 б.*).

Р. Ганиеваның бер фикере белән килешмичә мөмкин түгел: Алтын Урда заманында иҗат ителгән күп кенә матур әдәбият әсәрләре яки аз өйрәнелгән, яки гомумән фәнни әйләнешкә кертелмәгән. XIII—XIV йөзләрдә Алтын Урда дәүләтендә яшәгән төрки халыкларның ренессанс әдәбияты житди фикер алышуны һәм тикшерүне таләп итә. Безнең уебызча, Алтын Урданы шушы җәһәттән өйрәнү бик кызыклы табышларга юлыктырачак һәм бу тема лаеклы тикшеренүчесен көтә.

Бу дәверне гәүдәләндерүгә багышланган һәм тарихи аңны калыплаштыруга житди йогынты ясый торган әдәби әсәрләр исәбенә В. Янның «Чыңгыз хан», «Батый», «Соңгы диңгезгә», И. Калашниковның «Шәфкатьсез гасыр», А. Субботинның «Урыс җире хакына», Д. Балашовның «Кече ул», А. Юговның «Яугирләр», В. Чивилихинның «Хәтер» романнары керә. Аларның байтагына күренекле галимнәр сүз башы язган. Хосусан, И. Б. Греков билгеләп үткәнчә, В. Ян әсәрләренең кыйммәте авторның аларны язганда шактый дәрәҗәдә Шәрекъне өйрәнүче В. В. Бартольд, Б. Я. Владимирцев, А. Ю. Якубовский һәм башкаларның хезмәтләренә таянуына да бәйләнгән. Ян гасырларны кичкән культура һәйкәлләрен, борынгы риваятьләрне өйрәнә, архивларны күздән кичерә.

Бу темага багышланган әсәрләрне бер мәкаләдә барлап бетерү мөмкин түгел. Без бары кайбер әсәрләрдәге сәер фикерләргә генә тукталып китәбез.

«Сергей Радонежский тормышы» *(«Жизнь и житие Сергея Радонежского». М., 1991. 107, 109 бб.)* китабында татарлар — явызлар, шакшылар, алласызлар. А. Юговның «Яугирләр» *(«Ратоборцы». М., 1985. 250 б.)* романында менә мондый юллар бар: «Йә, китер миңа хәзер тугыз татарны, барысын да ялангач кулларым белән ботарлап атыймчы! Кылычымны дә чыгармыйча!»

Н. Плотникованың «Андрей Курбский» *(М., 1992. 5, 15 бб.)* романында Казанны саклаучылар «әшәкеләр» дип кенә телгә алына, Дүртенче Иванның Казанда «бөтен татар ирләрен, морзаларын канга батыру»ы данлана.

Автор дини мөнәсәбәтләрне яктыртканда: «Кем генә җиңсә дә, православие татар заманындагыча иселәчәк» *(Шунда ук. 99 б.)*,— дип игълан итә. Алда исә татар хакимнәренең барлык диннәргә тигез караулары хакында житәрлек искәртелде.

Андрей Курбский Рәсәй публицистикасы тарихында кануныйлыкны яклаучы, Дүртенче Иван патша җинаятьләрен фаш итүче, теләсә кайсы хакимиятнең әхлакка нигезләнүен теләүче шәхес буларак билгеле. Шуңа күрә аның авызыннан тулы бер халык хакында дистәләрчә мәртәбә «кабахәт» дип әйттергән тарихи романның укучыда хөрмәт казануы бик икеле. Ә әсәрдә А. Курбский арусыз гайрәт чәчә: «Мин теләсә кая барырмын, ләкин шакшы татарлар белән генә бармам, мин алар белән христианнар канын түгә алмыйм»... «татарлар, нәкъ сукырлардай, юлдан узып барган кешеләр аша төбәлгәннәр, аларның бөкерәеп катып калуы, каешланган күз кабаклары, каты чәч толымнары барысы да борынгы һәм куркыныч нәрсәнедер искә төшерә» *(Шунда ук, 98, 316 бб.)*.

Ишкөвнең романга аңлатма язуы инде бигрәк тә тарихи хакыйкатькә туры килми. Ул укучыларны саташтырып, янәсе Курбский «милли катастрофа — монгол суешын кичерә» дип белдерә. Алайса Андрей һәм аның туганы Роман Казанны алуда ничек башлап йөри һәм аның халкын кылычтан үткәрә ала икән соң? Менә шундый фаразлар, раслаулар мактап һәм югары уку йортлары дәреслекләренә килеп эләгә һәм иҗтимагый аңга үтеп керә.

Аңлашыла ки, мондый әсәрләр милләтара татулыкка, дини татулыкка һич тә булышмый. Бу уңайдан хәзерге татар язучыларының әлеге кырыс заманны — бер үк вакытта кызыклы һәм кабатланмас вакыйгалар тулы гасырларны объектив гәүдәләндергән, сәнгатьчә кыйммәте югары тарихи романнарны бик аз язуын да көенеч белән әйтеп китәргә туры килә.

Безнең ышануыбызча, Татарстан һәм Рәсәй мәгариф министрлыклары, Татарстан һәм Рәсәй Фәннәр академияләре, төрле нәшриятләр, аеруча «Просвещение», «Мәгариф» нәшриятләре, төрек-татар халыклары тарихына һәм аларның дәүләтчелекләренә кагылган дәреслекләрне бастырып чыгарганда, аларның эчтәлеген үзгәртергә — аларда тарихи фактларны бозуга, тарихи вакыйгаларны берьяклы аңлатуларга чик куярга тиешләр.

# ШИГЫРЬЛЕ СУЛЫШЛАР

**Зур шәхесләрнең зурлыгы озак-озак еллар буена төрле яклап ачыла. Сибгат Хәкимнең дә зур шәхесе аның шигырьләреннән, мәкаләләреннән, куен дәфтәрендәге яңалыкларыннан тыш, хатларында да чагыла.**

**Сибгат Хәкимнең миңа язган хатларының берничәсен «Казан утлары» журналына тәкъдим итү фикере Мөхәммәт Мәһдиевнең Афзал Шамов һәм Сибгат Хәким хатларыннан соң *(«Казан утлары» № 7, 1993)* язылган сүзләрен укыгач туды. Чыннан да, Сибгат Хәкимнең хатларын бер кулга җыеп бастырып чыгару мотлак кирәк. Әйе, ул хатларны җыюны кичектерми башлау хәерле. Без түгел, яшьләр дә картаеп баралар, безнең кебекләрдән соңыннан җыеп алу кыенлашырга мөмкин.**

**Мөхәммәт Мәһдиев үзенең соңгы сүзендә Сибгат Хәкимнең хатлары кемнәрдә булу мөмкин, дип исемлек тә төзи. Ул исемлеккә Татарстаннан читтә яшәүчеләр кертелгәннәр. Мәсәлән, Сибгат Хәким хатлары Сәйфи Кудашта, Гыйлемдар Рамазановта (хәзер инде алар икесе дә мәрхүмнәр) булуы мөмкин. Миңа килгәндә, аның беренче хатыннан башлап, соңгы хатына кадәр сакланганнар. Алар барлыгы — 72 данә.**

**Сибгат Хәким хатларында да үзе булып кала: шагыйрь булып, әдәбият һәм шигърият хакында даими кайгыртучы, шулар белән янып яшәүче, кешеләргә карата хәстәрлекле, үз инануына тугрылыклы булып кала. Шагыйрьнең рухи байлыгы һәр яклап, һәркемнең күңел хәзинәсенә әйләнергә тиеш.**

**Безнең хат алышу шулай башланды: 1958 елның гыйнварында бер төркем башкорт шагыйрьләре һәм галимнәре Казанда үткәрелгән шигырь төзелеше хакындагы конференциядә катнашты. Конференциядән тыш үткәрелгән безнең әдәби очрашуларның бөтенесендә дә Сибгат Хәким катнашты — безне озатып йөрде. Шунда без якыннан таныштык, минем укыган шигырьләр аның җанына яткангадырмы инде, минем янга килеп: «Җыентыгыңны төзеп Казанга, минем исемгә җибәр әле», — диде. Ел урталарында мин китапны төзеп җибәрдем һәм аның беренче хаты шул җыентыкка бәйле иде.**

**Нажар НӘҖМИ**

«Нажар дус! Синең «Сөю сүзләре»н алдым, китте дә бетте, дип куркып ятма. Бераз бавырым авыртты, эшли алмадым. Шушы арада синең җыентыкны укый башлыйм, сонлаган өчен гафу ит! Мин синең әйберләрне аз-маз беләм, шуңа күрә өметем зур.

«Суд залы»на карата әйткән дусларча фикерең өчен бик зур рәхмәт.

Сәлам белән Сибгат Хәким. 14.XII.58».

Нажар!

Хатыңны алдым, рәхмәт. Дәваланып ятасыз икән. Ул бик әйбәт. Тимертауда бер булган идем. Матур җир, бик шигъри як. Лермонтовны бөек шагыйрь иткән җир. Күп бардым. Күбрәк Ессентукида булдым. Пятигорск ошады. Лермонтов урыннарын күрдем, бик сагышлы, әрнүле җир. Шагыйрьләр, язучылар гомумән әрнүле, ахры. Шагыйрьләргә тормыш шәфкатьсез булган. Пушкины, Лермонтовы, Тукае, Туфаннарына да. Алар бит туры, аларны кем яратсын. Язылмасы күпме әсәрләре әрәм киткән! Лермонтов миңа аерата якын. Шигырьләрендә җен бар аның. «Демон»ны юкка язмаган ул. Син дә шул «җенле» урыннарда поэма язгансың, уңышлы чыгуына шикләнмим. Соңгы ике елда күп

эшләдең. Мин мәкалә язып бушый алмыйм әле. Сәйфи аганы әйбәт итеп уздырдык, үзем сүз сөйләдем. Уфада Еники булды. Н. Исәнбәт, Г. Бәшир мин кул куйган телеграмманы укымаганнар. Кичәне Мостай Кәрим алып барган. Хәерле булсын, Сәйфи аганы без барыбер хөрмәт итәбез...

7 декабрьдә 50 еллык уңае белән өлкә житәкчеләре опера бинасында язучылар, сәнгать кешеләре, культура работниклары, укытучылар һ. б. белән бергә зур бер чара үткәрә. Беренче үзе доклад белән чыга, язучыларга сүз күп биреләчәк. Чамала, ниятең булса, рәхим ит. Сине безнең житәкчеләр хөрмәт итә, нәгъре орырсың. Бәлки Кайсын да килеп чыгар әле. Идеолог хәзер Беляев Рәис.

Барчагызга да сәлам.

26/X—84.

Нажар!

Хатыгызны һәм «Сов. Башкирия»не алдым, шигырьләрне укыдым, миңа багышланганын «Ил улына» исемле китапка салып куйдым. Кайчандыр Р. Фәйзуллин шундый китап кулдан эшләп китергән иде. Миңа багышланган шигырьләрдән тора ул китап. Рәхмәт. Сезнең шигырьләр минем өчен һәрвакыт яңалык, яңа ачыш. «Тарафлар»ның «Сов. писатель»дә басылуы шатлыклы хәл. «Тарафлар» күп нәрсәне сыйдырган, үзе шигъри, үзе фәлсәфи һәм киң. Мин дә ил буйлап күп сәяхәт кылдым, үз әсәрләремә андый исем таба алмадым. Актив ижат иткәнсең, котлыйм.

Пленумга бара алмадым, дәваландым. 12 майда Мәскәүдә язучыларның үзәк йортында минем кичә булырга тиеш. Җырчылар, артистлар, шагыйрьләр егермеләп кеше Казаннан. Ничек узар, белмим. Минем җырлар алып чыгар әле, аларда бөтен ышаныч.

Сез киткәч, Казанга зур абзый[1] килеп чыкты, китабы басыла. Туфан үлгәч, Ташкентка китте. Әсгать Мохтар алтмыш еллыгына. Әсгать һәм Туфан... Җир белән күк. Мин шуны башка сыйдыра алмыйм. Мине котлавы да болай гынадыр. Минем бернәрсәгә дә хәзер исем китми. Сезнең бәйләнеш чын күңелдән. Туфан үлгән көнне үк тонлә килүегез турында хәбәр иттегез. Шуңа күрә Сезне монда хөрмәт итәләр, шагыйрь буларак та, кеше буларак та. Казан белән элемтәне өзмәгез, укучыларыгыз күп бездә. Сезнең бер кичәгезне үткәрәсе иде, үзем кереш сүз әйтер идем. Сезне яратмаучылар шартласыннар. Әдәбиятта ярыш шулай гына...

Мин «Эзлиләр Европа буйлап» исемле өч йөз юллык нәрсә яздым. «Казан утлары»нда № 5 тә басыла. Укып карарсыз. Шул исемдә алты табак чамасы яңа шигырьләр китабы әзерләдем, 1983 елга.

Башка яңалык юк.

Барыгызга да күп сәлам.

Сибгат Хәким. Март, 1982.

Нажар!

Борчылып язган хатыңны алдым. «Иблис» турында Вәлиев белән сөйләшермен. Вәлиев тә хәтерли дип уйламыйм. Күптәнге эш. Аннан, алар хафага төшәрлек бернәрсә дә юк. Шулай тыныч кына уза иде ул, сезнең кешеләр үзәккә язмаса. Аларның ни өчен «Иблис»не гаепләүләрен аңламыйм мин, аның төп идеясе: иленнән, җиреннән, теленнән аерылсаң — бетәсен. Моның нәрсәсе куркыныч? Просто Сезнең егетләр подлость эшләделәр. Каләмдәшләр! Сөйләшермен, аңлатырмын. Зәкигә дә яңадан үз фикерләремне, редколлегия члены буларак, әйтермен. Әллә кайчан онытылган нәрсәне яңадан югары оешмада кузгату шик кенә тудырыр. Андый житди нәрсә булса, мине дә, Гарифны да чакырган булыр иде. Бутаучылар күп сездә. Син, премия алганчы, бик талашма, төкер, яз да яз, талантыңны ваклама, алар күп, син — берәү! Андыйлар һәркайда житәрлек. Казан белән элемтәне өзмә. «Соц. Татарстан», «Азат хатын», «Ялкын»да катнаш. Сезнекеләрнең шуңа эче поша, үч алалар.

Сәлам белән Сибгат Хәким. 18 май.

Нажар!

Хатың мин кайткан көнне үк килеп житте. Рәхмәт. Икенче көнне Аккош күленә киттем. Иртәгесен иртән безнең радио Фәридә Кудашева башкаруында

[1] Мостай Кәрим. (*Н. Н.*)

татар халык җырларын тапшырды: «Ишкәкче карт» һәм башкалар — ярты сәгать. Фәридәне мин тыныч тыңлый алмыйм, гел эчтән елыйм, әлләниләр искә төшә, җирем, тарихым, халкымның бөтен узганы алга баса, әнкәй күз алдына килә, аның тавышын ишетәм, саф татар теле, андый тел белән җырлаган бер генә җырчы да юк. Менә нинди ул ходай биргән табигый талант. Хәзер инде куркам, аннан соң кем килер икән, туар микән Фәридәләр? Казахстанда казах җырларын тыңлап, халкының талантына сокланган идем, үз халкым да минем искиткеч талантлы! Йөрәгендә шулкадәр моң, просто агыла, ташый, агыла. Фәридә җырлаганда, Идел, Агыйдел кушылды, аралар кушылды, бөтен чүп-чар юкка чыкты, бәхетле итте. Җирем дә минем әйбәт, җырга бай, моңга бай, авыр язмышлар аны шактый уйландырган, күрәсең. Фәридәне бер очратсаң, әйт, Сибгат абый Сезне һәрвакыт сагына диген. Теләндә аның бөтен моң! Без вакытында кайттык. Син киткәч, күңелсез булды. Башлаган әсәреңне очла, уңышлар телим, бер күрермен әле, гомер булса.

Сиңа, иптәшеңә, кызыңа, Сәйфи агага күп сәлам.

Сибгат Хәким. 29/V—79. Аккош күле.

Нажар!

24 апрельдә шигырь бәйрәме. Тукай, Җәлил айлары. Мин радио белән сөйләштем, синең чыгышны язып алырга булдылар. Телевидениедә язу турында Роберт[1] хуҗасы белән сөйләшкән. Болары хәл ителгән. Радио өчен шигырьләреңне сайла, әзерлә, фондка кереп калыр, алдагы еллыкларың өчен сакланыр. Менә сиңа задание шул.

Мин Мәскәүгә бармадым, авырдым. Поэмаң турында Робертка әйттем, бер килеп чыгарга булды. Аңа бәлки төзәтелгән вариантын бирерсең.

Миндә склероз, бер сезгә кучәм, бер сиңа кучәм. Соңыннан гына искә төшә, кәеф уртача. Инфарктан соң кеше нык үзгәрә икән.

Сәлам белән Сибгат Хәким. 31/III—86.

Аның миңа язган соңгы хаты (Н. Н.).

[1] Роберт Миңнуллин. *(Ред.)*

**Гомәр Саттар-Мулилле,**
филология фәннәре докторы, КДУ профессоры,
татар теле кафедрасы мөдире

# ТАТАР ТЕЛЛЕ ТАТАРСТАН?

«Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» Татарстан Республикасы Законын һәм шул законның 7 нче маддәсе нигезендә эшләнгән «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»н зур өмет-ышанычлар баглап көтеп алдык. Тел турындагы әлеге рәсми документларны бигрәк тә без — татар телчеләре зарыгып көттек. Туган телебезнең аяныч хәленә, бетә-юкка чыга баруына, күп тармакта кулланыштан төшүенә, кирәкле белгечләрнең аз булуына башлыча без — татар телчеләре яна-көя идек. Хәер, бәгъзеләрнең бу хәлгә артык исе китмәде. Биләгән түрәлегеннән, иң югары гыйльми исемгә ия булуыннан, фәнни дан-дәрәҗәсеннән канәгать булып, туган телебезнең язмышы өчен борчылмыйча, аның мөшкел хәле турында чаң какмыйча яши бирделәр.

Ошбу җиһандагы татар халкын Татарстан Республикасы якламаса, татар милләте мәнфәгатьләре турында кайгыртмаса, татар телен Татарстан дәүләте, татар телчесе, татар галиме, татар зыялысы, президентыбыз, Югары Совет рәисебез, премьер-министрыбыз, барыннан да элек татар халкы үзе якламаса, үзе кайгыртмаса, кем яклар, кем кайгыртыр? Туган телебезнең хәле үтә мөшкел, үтә аяныч, хәтта фаҗигале.

Татар теле дәүләтчелегебезне, республикабызның суверенлыгын ныгытырга, халкыбызның аңын-гакылын, фәнен, матбугатын, мәгърифәтен, мәдәниятен, икътисадын үстерергә бар көченә хезмәт итәргә тиеш. Татар теленең моның өчен тарихи бай тәҗрибәсе, хәзерлеге, эчке потенциаль мөмкинлеге, тиешле функциональ-стилистик, лексик-грамматик үсеше һәм тәэмин ителеше бар. Ул гасырлар дәвамында чарланган камил әдәби телгә, бердәм әдәби нормаларга ия. Тулысынча эшкә җигик, тулысынча файдаланыйк ата-бабаларыбызның мөкатдәс мирасын — газиз туган телебезне. Ул безне чал гасырлар дәвамында беркайчан да, беркем алдында да ким-хур итмәгән, итми, итмәс, иншалла!

«...Программа проектының төп өлешен татар теленең сакланышы һәм үсеше, аны һәрьяклап өйрәнү һәм камилләштерү мәсьәләләре алып тора. Анда татар телендә укыту системасын булдыру, фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләү, әдәбият, фән һәм сәнгать, радио һәм телевидение тапшырулары үсешен, татар телендә китаплар, газета-журналлар бастыру, сүзлекләр, дәреслекләр һәм укыту-методик әдәбият чыгаруны тәэмин итүнең конкрет җаваплы оешмалары һәм финанслау чыганаклары билгеләнәчәк. Дөресен әйткәндә, дистәләрчә еллар буена кысрыкланган ана телебезне ике-өч ел эчендә тормышның барлык өлкәләренә кертәбез дип лаф ору мәсьәләгә вульгар караш булыр иде. Андый мәсьәләләргә җиңел карау һич ярамый. Татарстан халыклары телләре турында дәүләт законына һәм программасына нигезләнеп, без, әлбәттә, ана телебезне үстерү өчен барча мөмкинлекләрдән файдаланачакбыз», — ди җитди уйлап әйтелгән сүзләр белән мөхтәрәм президентыбыз Шәймиев «Мирас» журналы сорауларына җавабында (№ 7—8, 1994. 11 бит). Күңелгә сары май булып ята торган акыллы, сөендергеч, алтын сүзләр. Амин, шулай булсачы, дияргә генә кала.

Милләтем дип, утка керсә, янса хаким,
Без булмабыз башкалардан беркайчан ким.

Ниһаять, «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» һәм Татарстан халыкларының телләренә караган башка карарлар 1994 елның август аенда матбугатта басылып чыкты. Хәзерге татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә үстерүдә болар — һичшиксез, мөһим документлар.

Татар теленең дәүләт теле булуыннан, дәүләт теле вазыйфасын озак гасырлар дәвамында үтәвенең үзенчәлекле бай тарихы бар. Идел буе Болгарстанының дәүләт теле болгар-татар теле булган, Алтын Урда дәүләте һәм Казан ханлыгының дәүләт теле, хәзерге татар теле күзлегеннән караганда, иске татар теле була. Иске татар теле XVI—XIX гасырларда Русия империясендә дипломатия, эш кәгазьләре, патша канцеляриясе теле булып хезмәт итә. Менә шуна күренекле тарихчы М. Худяков: «Урыслар дәүләтчелек культурасы нигезләре белән татарлар аша таныштылар»,— дип яза. Русия, Кавказ, Урта Азия һәм башка Шәрекъ илләре, Шәрекъ дәүләтләре белән иске татар телендә аңлашу-сөйләшү эшләре алып бара. Дипломатик актлар, эш кәгазьләре, грамоталар, килешү-шартнамәләр Шәрекъ илләре өчен урыс телендә язылган төп нөсхәдән иске татар теленә төгәл тәрҗемә итеп, рәсмиләштереп җибәрелә. Моны Казанский приказдагы татар тылмачлар башкара. Шулай итеп, иске татар теле патша Русиясендә дәүләт теле, дипломатия теле буларак, Русия империясенең чикләрен киңәйтүдә, аның башка илләрне, территорияләрне яулап алу политикасын тормышка ашыруда зур булышлык күрсәтә. Күптән түгел генә КДУның бер доценты «Иске татар эш кәгазьләре теленең XVI йөз — XIX йөз башында кулланылышы һәм үсеше»н өйрәнүгә багышланган докторлык диссертациясен язып тәмамлады.

Татарстанда хәзерге татар теле XX гасырның 20 елларында дәүләт теле иде.

Татарстанда безнең көннәрдә, XX гасыр азагы — XXI гасыр башында, хәзерге татар телен дәүләт теле итү, урыс теле белән бертигез дәрәҗәдәге дәүләт теле итеп үстерү-саклау, фәнни өйрәнү мәсьәләсе бөтен җитди катгыйлыгы белән көн тәртибенә куелды. Моның алшарты булып моннан 5 ел элек (30.VIII.1990) Татарстанның мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итү торды. Татарстан Республикасы мөстәкыйль дәүләт дип игълан итү республикага исем биргән халык теленең статусын күтәрүне, дәүләт теле итүне, татар телен саклау, яклау, өйрәнү, үстерү һәм фәнни тикшерү ихтыяҗын, хәзерге заман таләпләреннән чыгып, гамәлгә куйды. Туган теле тулы хокуклы дәүләт теле булмаган халыкның ил-дәүләте дә тулысынча азат, мөстәкыйль була алмый.

1994 елның 15 февралендә Русия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында дәүләтара килешү — Шартнамә төзелде. Шартнамә урыс һәм татар телләрендә язылды, юридик яктан һәр ике телдәге тексты бердәй, тигез хокуклы дип белдерелде. Шартнамәнең төп нөсхәсе башта урыс телендә язылып, аннан татар теленә тәрҗемә ителгән иде, әлбәттә. Күрәбез, патша Русиясенең Казанский приказ традицияләре әле һаман дәвам иттерелә.

Русия белән Шартнамә төзү зарур иде, кирәк иде. Әмма ул Татарстан Республикасының хокукларын кысу, чикләү, тарайту-кечерәйтү бәрабәренә барлыкка килде. Татарстанның хокукларын кысучы, аны Русиягә баш-аягы белән бәйләп куючы Шартнамә буларак пәйда булды.

Шартлатып Шартнамә төзелде,
Ышаныч-өметләр өзелде;
Бәйсезлек бәйләнде арканга,
Татарлар коллыкны тарткanga.
Тарталар, тарталар, тарталар
Ясалып торганга хаталар...

Хаталар исә һаман ясалып тора.

30 августта ТР дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итүебезне — Республика көнен зурлап билгеләп үттек, күркәм олуг бәйрәм ясадык. Казан ипподромында һәм үзәк стадионда спорт һәм сәнгать фестивале уздырдык. Җиренә җиткереп, яхшы итеп аттан артык эшли белгән кебек, матур итеп ял итә, күңел ача, бәйрәм итә дә беләбез. Монысы — сөенечле, күркәм күренеш.

Әмма Шартнамәнең якларның тигез хокуклы булуларын тәэмин итмәве, Татарстанның икенче сорт, бәйле дәүләт булып кала бирүе, татар телен чын мәгънәсендә дәүләт теле итү өчен тиешле шартларның, дәүләт структурасының тудырылмавы, кирәкле гамәлләрнең тиешенчә тормышка ашырылмавы күңелгә тия.

Татарстан Республикасының суверенитеты турында Декларация кабул ителү бәйрәме уңаеннан җөмһүриятебез җитәкчелеге адресына башка (элекке автоно-

мияле) республика, өлкә житәкчеләреннән, җәмәгать эшлеклеләреннән котлаулар килде. Ихлас күңелдән күп рәхмәт аларга. Әмма Русия Федерациясе президенты Б. Н. Ельцин аларга кушылмады, безне Русия Федерациясе министры Н. Егоров кына котлады. Шартнамәгә якларның тигез хокуклылыгы салынган булса, Б. Н. Ельцин дә безне, һичшиксез, котлаган булыр иде. Суверен күрше дәүләтләр арасындагы дустанә мөнәсәбәт, дипломатик этикет шуны таләп итә бит.

Элекке премьер-министрыбыз Мөхәммәт Сабиров «Газпром» генераль директоры урынбасары Богдан Будзуляк белән «Газпром» акционерлык җәмгыяте арасында килешүгә кул куйганда турысын ярып: «Без Русия белән бергә. Татарстан — Русия составындагы суверен республика»,— диде («ВТ», 3.IX.1994). Ә бит республикабыз Конституциясендә алай диелмәгән. Конституциябезне — төп законны бозарга беркемнең дә хакы һәм хокукы юк. Без Татарстанны халыкара хокук субъекты булган суверен дәүләт дип игълан иттек ич. Логика кая? Башка бер республика составындагы икенче бер республика суверен була аламы? Тарихта мондый суверенлык мәгълүм түгел. Фәүзия Бәйрәмова сүзләре белән әйткәндә: «Шартнамә — Татарстанны империягә законлаштырып бәйләп кую ул» («ШК», 1.IX.1994).

Менә ни өчен безне, чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, өлкән туганга ярарга тырышып, хәзерге мөстәкыйль республикалар: Әзәрбайҗан, Казагыстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Үзбәгестан президентлары да котламадылар. Русия Татарстан мөстәкыйльлеген танымаганга күрә шулай булды бу. Авыр шул, кыен шул империя кочагыннан котылу, тулы мөстәкыйльлеккә ирешү.

Бәйрәм көнне Казан ипподромында ат чабышлары уздырылды. «Әнә ул көнне ярышкан Ремингтон, Зекир (Закир түгел — Г. С.), Гравилат, Талисман, Оператор, Гандикап, Гамильтон, Либерал, Кашка, Король, Олеандр, Газават, Ингур, Рикошет, Акамаз кебек кушаматлы атлар Казан ипподромында гына түгел, башка шәһәр, дәүләт узышларында дан казанган» («ШК», 1.IX.1994.). Менә сиңа мә. Казан ипподромы 15 юртагының бары берсе генә саф татарча Кашка исемен йөртә. Калганнары — башка телләрнең зоонимнары. Инглизчә, французча, шайтан белсен, тагын кайсы тел кушаматлары.

Татар халкы борын-борыннан ат яраткан, ат асраган, ат чабышлары-бәйгеләре уздырган. Татар телендә матур эчтәлекле ат исемнәре (зоонимнар) тулып яши. Менә шуңа татар халкы элек-электән күмеш тояк тулпар чабышкыларны матур-матур исемнәр белән атаган: Алмачуар, Акбәкәл, Тимеркүк, Акъял, Каракүз, Көлтәкойрык, Сарыкай, (борнак «Борыны ак» ягъни «ак борынлы»), Җилаяк, Җитез, Давыл, Буран, Буян, Арыслан, Омтылыш, Ыргыл һ. б. Башкалабыз ипподромындагы юртакларга ни өчен шундый татарча исем-кушаматлар бирмәскә иде? Ат исемнәре урам исемнәре түгел ләбаса. Монда мәсьәләне уңай хәл итү шактый җиңелрәк.

Әллә соң татар телен дәүләт теле статусына күтәрүне Казан ипподромындагы ат исемнәрен татарчалаштырудан башларга кирәкме икән безгә? Башка дәүләт, шәһәр ат чабышларында җиңеп чыккан, татарча исем йөрткән Татарстан юртагы республикабызга, татар иленә һәм теленә дан-шөһрәт китерер, танылу өстәр иде. Ремингтон белән Гамильтон татар җырын җырламый, Татарстан җирен зурламый, инглиз җырын җырлый, Англияне яки Американы зурлый шул инде.

Татарстан Югары Советы сессияләре әле һаман урыс телендә бара, татар теленең академик грамматикасы урыс телендә чыгарылды, «Татар энциклопедиясе» төп нөсхәдә шулай ук урыс телендә төзелеп ята. Хәтта Татарстан Югары Советының XXI сессиясендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»да төп нөсхәдә урыс телендә генә язылган иде. Татарстан Югары Советы аппаратындагы тәрҗемәчеләр төркеме бу мөһим документны татар матбугатында бастырып чыгару өчен тәрҗемә итүгә шактый тырышлык һәм көч салды.

Программаның авторы Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Г. Ибраһимов исемендәге ТӘТИнең бүлек мөдире Фуат Ганиев әлеге үтә мөһим документны башка ук татарча яза ала иде, әлбәттә. Һичъюгы татар һәм урыс телләрендә параллель рәвештә яза, иҗат итә ала иде. Юк шул, башта урысча язарга, күптән килә торган урысча язу традициясенә хилафлык итмәскә кирәк. Татар телен саклау, өйрәнү, дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, статусын үстерү турындагы дәүләт программабызны да татарча — Татарстанның дәүләт телендә язмыйбыз бит. Кайда соң бездә милли горурлык, һич булмаса, тамагын туйдыра, өс-башыңны бөтен итә, гаиләңне матди яктан тәэмин итә торган һөнәреңә

тугрылык, телче галимнәребез? Үзебезне хөрмәт итү, ярату кайда? Татар теленең чын мәгънәсендә дәүләт теле булуы, статусы, дәрәҗәсе үсү өчен без кайгыртмасак, борчылмасак, туган телебездә эш-гамәл кылмасак, кем кайгыртыр, кем борчылыр, кем гамәл кылыр?! Нишлибез соң без, татарлар?! Бармы, калдымы соң бездә аз гына булса да чын татарлык, татар үҗәтлеге, тырышлыгы һәм кыюлыгы?!

Җитди, зур хаталарның тагын бер өр-яңасы — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» «Законны тормышка ашыру өчен: «Комитет җәмәгать башлангычында даими эшләүче орган булып тора...»,— дип карар чыгару («ВТ» 9.VIII.1994). Халкыбызның киләчәктә милләт булып яшәве, йотылып бетмәве өчен көрәшенең нигезен тәшкил иткән татар телен дәүләт теле иттерү, аны саклау, өйрәнү һәм үстерү кебек хәзерге һәм киләчәк тарихыбыз өчен хәлиткеч әһәмияткә ия әлеге мәсьәләне җәмәгать башлангычында эзлекле рәвештә уңышлы хәл итү мөмкинме соң? Социалистик җәмгыятьтә 70 ел дәвамында җәмәгать башлангычында күп эшләдек инде без. Әмма әллә нәрсә майтара, тәрәккыять итә, алга китә алмадык.

Татарстан Министрлар Кабинеты каршында дәүләт кодрәтенә, юридик хокукларга, хакимият көченә, власть структурасына ия булган берничә Комитет яки Баш идарә бар. Мәсәлән, Ветеринария хезмәте Баш идарәсе. Әмма, ни өчендер, «Татарстан халыкларының телләре турында Закон»ны тормышка ашыру вазыйфаларын башкара торган даими дәүләт комитеты — Тел комитеты төземәдек. «Тел комитетына җәмәгать башлангычында эшләү дә житкән»,— дигән фикердән чыгып эш иттеләр, күрәсең, югары власть ияләребез. Болай итү — Татарстан халыклары телләре турындагы законны тормышка ашыру программасының тиешенчә үтәлмәвенә китерәчәк. Бу — программаның туганда ук үле яки зәгыйфь булып тууына бәрабәр.

Бу хакта программа авторы Фуат Ганиевнең «Шәһри Казан» газетасына биргән (10.XIII.1994.) җитди җавабы игътибарга лаек.

«Татарстан халыкларының телләре турындагы закон тиешенчә эшләп китә алмады. Мин программаны шушы законны гамәлгә ашыру механизмы итеп күз алдына китерәм. Программада тел буенча комитет төзү каралган. Бу эшне шул комитет башкарыр. Ул хакимияткә ия комитет, власть структурасы булырга тиеш иде. Әмма аны уйламыйча, җәмәгатьчелек контроленә әйләндергәннәр. Бу программаның «җанын алу» кебек килеп чыга. Проектта ул дәүләт комитеты дип тә күрсәтелгән иде. Ләкин нигәдер дәүләт сүзен дә төшереп калдырганнар».

Шулай итеп, гаять мөһим бу иҗтимагый-сәяси мәсьәләдә дәүләт контроле һәм җаваплылыгы юкка чыгарылган.

Хәлбуки, Татарстан Министрлар Кабинеты каршында «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы закон»ны тормышка ашыру өчен дәүләт комитеты булдыру зарур. Заман, тел сәясәте, татар теленең бүгенге хәле, торыш-халәте һәм киләчәге бездән бөтен катгыйлыгы белән шуны таләп итә. «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР дәүләт программасы»ның тиешенчә һәм күрсәтелгән вакытында гамәлгә ашуы өчен дәүләт структурасы, ТР Министрлар Кабинеты турыдан-туры җаваплы булырга тиеш. Дәүләт Программасында күрсәтелгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты оештыручы, әйдәп баручы, кайгыртучы, тормышка ашыручы булырга тиеш. Әлеге дәүләт комитетының башлыгы итеп житәкче органнарда эшләү тәҗрибәсе булган берәр телче профессорыбызны билгеләү, комитет штатын һәм район хакимиятләрендә махсус бүлеген һәм аның штатларын булдыру сорала.

«Теле барның юлы бар»,— ди татар халык мәкале. Туган телебезне саклау, өйрәнү, үстерү, дәүләт теле итү өчен татар халкы тарих дәвамында яулап алган шушы алтын бәрабәренә тиң мөмкинлекне кулдан ычкындырсак, безне киләчәк буыннар гафу итмәячәк. Татар теле белән шаярмыйк, әфәнделәр! Милләтебезнең киләчәк язмышын, яшәешен хәл итә торган әлеге мөһим Программаны дәүләтебез — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Махсус дәүләти челтәр булдырып, тиешенчә тормышка ашыра алмаса, татар халкы, киләчәге хакына, Туган тел җәмгыятьләре, хәтта Туган тел партиясе төзеп, дилбегәне үз кулына алырга мәҗбүр булачак, туган тел өчен изге көрәшкә күтәреләчәк. Чөнки башка юл калмый, башка чара юк.

Сугар сәгать: уянырбыз, тупланырбыз,
«Туган тел!» дип, изге яуга кузгалырбыз...

Җәмәгатьчелек башлангычында Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында биш лингвистик комиссия, шул җөмләдән шушы юлларның авторы җитәкләгән Топонимия комиссиясе, 5—6 ел дәвамында эшләп карады инде. Комиссияләрнең байтак кына утырышлары үткәрелде, мөһим һәм кирәкле карарлар чыгарылды. Әмма аларның күбесе тормышка ашмады, тиешле уңай нәтиҗәсе булмады. Әйтик, моннан ике ел элек халык депутатларының Казан шәһәр Советы каршындагы Топонимия комиссиясендә Казан урамнарының байтагының исемнәрен алмаштыру, мисал өчен, Ленин урамына Сөембикә урамы, Дзержинский урамына Гаяз Исхакый урамы, Киров урамына Болгар урамы, Бауман урамына дәһшәтле тарихи исемен кире кайтарып Проломный урамы, Куйбышев мәйданын Татарстан мәйданы дип атау турында карар чыгарсак һәм бу хакта республика матбугатында язып чыксак та, Казанның бер генә урамы яки мәйданының да исеме алмаштырылмады. Көч, тырышлык һәм вакыт башка сарыф ителде. Менә шундый ул җәмәгатьчелек башлангычы тәртибендә эшләүнең «нәтиҗәсе».

Мәскәү урамнары, тыкрык һәм мәйданнарының тарихи исемнәрен кире кайтару мәсьәләсе белән исә башкала хөкүмәте үзе шөгыльләнә. Мисал өчен, Арбат мәйданының исеме Арбат капкалары мәйданы булачак. Аркадий Гайдар тыкрыгы — Зур Казенный, Герцин урамы — Зур Никитин урамы диеләчәк. Ашыгыч рәвештә Пельше, Суслов, Устинов, Готвольд, Подбельский урамнарының исемнәре алмаштырылачак. «Беляево» метростанциясе янындагы мәйдан Мартин Лютер Кинг исемен, «Космос» гостиницасы алдындагы мәйдан Шарль де Голль исемен йөртәчәк.

Моннан ике ел элек үк «Туган тел һәм гамәл» дигән мәкаләмдә («Татарстан» ж., 1992, № 4, 19—28 бб.): «Республикабызда татар теленең дәүләт теле буларак урыс теле белән тигез хокуклылыгын тәэмин итү буенча конкрет гамәл-чараларны үз эченә алга махсус карар чыгару һәм аны тайпылышсыз рәвештә тормышка ашыру, һичшиксез, зарур һәм мәҗбүри. Моның өчен Татарстан Министрлар Советында махсус комитет — Татар телен гамәлгә ашыру комитеты булдыруны һәм аның органы булган «Татар теле» дигән атналык газета чыгаруны бүгенге тормыш үзе таләп итә», — дип язган идем.

Программа проекты авторы Фуат Ганиев, проектта Комитетның органы булган махсус газета чыгару да күзгә тотылган иде, ди. Хәлбуки, дәүләт карарлары, положениесе һәм дәүләт программасында бу турыда бернәрсә дә әйтелмәгән.

Соңгы вакытта Казанда төрле коммерция структуралары ярдәме белән чыгарыла торган реклама-хәбәр басмаларының саны шактый күбәеп китте: «Крис», «Рекламная мозаика», «Ва-банкъ», «Программа для всех», «Выбор», «Казанская неделя» һ. б. Алар сәүдә-коммерция игъланнары белән шыплап тулган. Үз товарын бик оста мактый, алар хакында кирәкле рекламаны ясый белә яңа борынлаган эшмәкәрләр, сәүдәгәрләр һәм тагын әллә кемнәр.

Без исә Татарстан Министрлар кабинеты каршындагы Тел комитетының махсус органы булган, халык өчен ифрат кирәкле газетаны да чыгара алмыйбыз. Ваемсызлыкмы, әллә «нигә кирәк ул андый газета» дип караумы бу?

Хәлбуки, мондый газета яки журнал бик кирәк. Казагыстанда «Ана теле» дип аталган, казакъ теле мәсьәләләрен яктырта торган газета соңгы биш ел дәвамында чыгып килә инде.

«Татар теле» яки «Туган тел» дип исемләнгән бу фәнни-популяр һәм иҗтимагый-педагогик газета яки журнал «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» ТР законын тормышка ашырылуының ничек барышын яктырту, бу өлкәдәге уңышлар, кыенлыклар, кимчелекләр, проблемаларны бәян итү, җәмәгатьчелек фикерен чагылдыру, халык белән киңәш-табыш кылу, галимнәребезнең фәнни хезмәтләренә урын бирү өчен, һичшиксез, кирәк. Әлеге газета яки журналда: «Балалар бакчасында татар теле», «Гаиләдә туган тел», «Мәктәптә татар теле», «Урыс мәктәбендә татар теле», «Һөнәргә өйрәтү уку йортларында татар теле», «Югары уку йортларында татар теле», «Татар сөйләм культурасы», «Матбугат теле», «Татарча эш кәгазьләре теле», «Матур әдәбият әсәрләренең теле», «Язучы һәм сүз», «Укытучы трибунасы», «Сүзләр һәм гыйбарәләр тарихыннан», «Яңа сүзләр», «Татар телендә алынмалар», «Славян һәм фин-угыр телләрендә төрки-татар сүзләре», «Исем-фамилияләребез», «Татарстан шәһәрләре һәм авылларының исемнәре», «Мәктәптә туган як ономастикасы», «Татар топонимиясе», «Язу тарихыбыз», «Туган тел һәм тарих», «Туган тел һәм милли мәдәният», «Туган тел һәм милли әдәбият», «Туган тел һәм милли сәнгать», «Татар теле — газиз милли мирасыбыз», «Татар сәхнә теле», «Татар энциклопе-

диясе битләреннән», «Татар әдәби теле тарихы», «Күренекле телчеләребез» һ. б. рубрикалар була алыр иде.

«Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»ның XI бүлеге «Кадрлар әзерләү системасы» дип атала. Анда милли мәктәпләр өчен махсус урта һәм югары белеме булган педагогик кадрлар, учреждениеләрдә һәм оешмаларда эшләү өчен милли белгечләр әзерләүне тәэмин итү һәм аларның профессиональ белемнәрен күтәрү челтәре оештыру турында сүз бара.

Ни өчендер, иң мөһим, югары буын кадрлар — югары уку йортларындагы татар теле кафедраларында, фәнни-тикшеренү институтларының тел бүлекләрендә эшләү өчен филология кандидатлары һәм докторлары әзерләү турында бер сүз дә әйтелмәгән. Хәлбуки, фән кандидатлары һәм докторлары мәсьәләсендә безнең хәлләр шәптән түгел.

Саны 7 миллионнан артык татар халкына туган теле буенча югары әзерлекле белгечләрдән 50 гә якын филология фәннәре кандидаты, 15 филология фәннәре докторы туры килә. Димәк, бер миллион татарга туган телебезне өйрәтүче ике фән докторы хезмәт күрсәтсә, 1 миллион башкортка исә 14 фән докторы туры килә. Уйласаң, гыйбрәтле саннар. Җитмәсә, татар теле буенча фән кандидатлары һәм докторларыбызның байтагы пенсия яшендә.

Татар теле һәм әдәбияты буенча фән кандидатларын, бигрәк тә докторларын әзерләү гаять акрын бара. Мисал өчен, Казан дәүләт университетында моннан 6 ел элек, 1989 елда, ачылган татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетының үзендә үк кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау буенча махсус Совет булуга карамастан, биш ел эчендә факультетта татар теленнән бер кеше (Ф. Нуриева), әдәбияттан ике кеше (Т. Гыйләҗев, Д. Заһидуллина) фән кандидатлары, ике кеше (Х. Миңнегулов, Р. Ганиева) татар әдәбияты буенча фән докторлары булдылар. Халкыбызның йөзек кашы булган татфакта 10 га якын фән докторы, 20 ләп фән кандидаты эшләсә дә, 5 елга югары квалификацияле 5 белгеч өстәлү аз, бик аз, әлбәттә.

Татар теле буенча югары квалификацияле белгечләр хәлен тагын да ачыграк күзаллау өчен, КДУның үзем эшли торган тел кафедрасы кадрлары хакында берничә сүз әйтү мәслихәт. Бу кафедра — татфакның әйдәп баручы, татар теле һәм төрки телләр буенча кандидатлык диссертациясе язу өчен аспирантурасы булган, әлеге телләр буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен тикшереп, кафедра утырышында бәя биреп, махсус Советка яклауга тәкъдим итәргә, йә булмаса, тиешле гыйльми кондициягә китерү өчен кире кайтарырга вәкаләтле кафедра. Кафедраның бары тик биш әгъзасы бар. Пенсия яшендәге ике профессор, филология фәннәре докторлары; шуларның берсе — кафедра мөдире; пенсия яшендәге бер доцент (филология фәннәре кандидаты); утыз яшьләрдән ашу бер өлкән укытучы (филология фәннәре кандидаты) һәм бер ассистент (гыйльми дәрәҗәсез). Татфакның башка кафедраларында 7 шәр, 8 әр әгъза, яшь ягыннан байтакка яшьрәкләр. Күрәбез ки, КДУ җитәкчеләренең татар теле кафедрасын өстәмә штатлар һәм кадрлар белән тәэмин итүгә, аспирантура аша сәләтле яшь галимнәр әзерләп, кафедрада эшкә калдыруга нык игътибар итүләре сорала.

Фән докторлары аерата акрын өлгерә. Моның өчене, кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, 10—15 ел вакыт кирәк. Мәсәлән, Латыйф ага Җәләй татар теле буенча докторлык диссертациясен беренчеләрдән булып 60 яшендә 1954 елда яклаган булса (1942 елда кандидатлык диссертациясен яклый, ара 12 ел), аның шәкерте М. З. Зәкиев 35 яшендә 1963 елда докторлык диссертациясе яклады (1954 елда кандидатлык диссертациясе яклый, ара 9 ел), мин 42 яшемдә докторлык диссертациясен (1975) яккладым (кандидатлык диссертациясен — 1963 елда, ара 12 ел), минем шәкертем Фирдәүс Гарипова 1976 елда кандидатлык, 1991 елда докторлык диссертациясе яклады (ара 15 ел), Фирдәүснең әлегә шәкертләре юк.

Татар теле буенча 15 филология фәннәре докторыбыздан 8е, остаз булып, фән кандидатлары әзерләү бәхетеннән хәзергә бөтенләй мәхрүм. Күпсанлы филология фәннәре кандидатлары һәм докторлары әзерләп, үзләренең фәнни лингвистик мәктәпләрен тудырган остазлардан Л. Җ. Җәләйне (10 фән кандидаты, 4 фән докторы остазы), М. З. Зәкиевне (21 фән кандидаты, 4 фән докторы остазы), Д. Г. Тумашеваны (20 ләп фән кандидаты остазы) һәм Г. Ф. Саттаровны (14 фән кандидаты,— алар арасында казакълар, үзбәкләр, тывалылар бар,—1 фән докторы остазы) күрсәтә алабыз.

Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә Татарстанда һәм

татарлар укмашып яши торган БДБ төбәкләрендә эшләячәк белгечләр әзерли торган югары уку йортларында (Самара, Оренбург, Ульян, Төмән, Тубыл, Ижау, Түбән Новгород, Пенза, Пермь, Екатеринбург, Әстерхан һ. б. шәһәрләрдә) татар теле кафедраларын булдыру, республикабызның һәр югары уку йортында (Татарстанда аларның саны хәзер 20 дән артык) татар теле кафедралары төзү күздә тотыла. Татар милли университетының рәсми танылуы, дәүләт университеты булуы аерата сөендерер иде. Ана милли кадрлар әзерләүдә, халкыбызның милләтпәрвәр зыялыларын арттыру-тәрбияләүдә зур өметләр баглыйбыз. Шулай итеп, югары уку йортларында 30 дан артык татар теле кафедрасы булдырылачак. Әлеге кафедраларда эшләү өчен берәрдән дә 30 филология фәннәре кандидаты (хәзергә филология фәннәре докторлары хакында сүз алып барырга да мөмкин түгел) кирәк булачак. Югары уку йортларында һәм фәнни-тикшеренү институтларында татар теле өлкәсендә эшләүче фән кандидатларының саны 30 дан артмый. Аларның да күбесе олы яшьтә. Димәк, татар теле белеме өлкәсендә эшләү өчен яшь алмаш кирәк, югары әзерлекле белгечләргә кытлык ифрат зур. Якын киләчәктә татар теле буенча кимендә 100 дән артык филология фәннәре кандидаты әзерләү таләп ителә. Шушы авыр хәлдән, кадрлар кытлыгыннан чыгу өчен алдагы 10 елда аспирантура һәм докторантура аша татар теле буенча фән кандидатлары һәм докторлары әзерләүнең конкрет дәүләт планын төзеп, аны эзлекле рәвештә тормышка ашыру зарур. Моны тормыш, заман әһәмиятле мәсьәлә итеп көн тәртибенә куя. Остазлар көчендә, исән-сау чагында моны тормышка ашыру, эшләп калу каттый таләп ителә. Шулай эшләмәсәк, татар теле белеме үсешендә өзеклек, җитди тоткарлык килеп чыгуы мөмкин. Югары әзерлекле телче галимнәребездән башка татар теле белемен үстерү, фундаменталь фәнни лингвистикабызны тудыру һич мөмкин түгел. Менә шуңа бу гаять мөһим һәм җитди мәсьәләгә дәүләткүләм зур игътибар бирү сорала. Моны җәмәгатьчелек башлангычында гына хәл итү барып чыкмый, әлбәттә.

Татар теленең абруен күтәрү өчен тагын бер конкрет тәкъдимем бар. Татарстан җөмһүриятенең Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе әдәбият, сәнгать һәм архитектурабыз үсешенә зур өлеш керткән хезмәтләргә һәр ел саен бирелә. Милли әдәбият, сәнгать һәм мәдәният үсешенең асылында туган тел ята. Билгеле булганча, тел — халыкның үз социаль-мәдәни байлыкларының иң кыйммәтлесе һәм иң кадерлесе. Тел — аралашу, дөньяны танып-белү чарасы, ул гомумкешелек һәм милли кыйммәтләрне, мирасны саклау «бина»сы гына түгел, бәлки милләтнең милләт булып яшәве өчен иң кирәкле мөһим шартларның берсе. Ул — милли рухи кыйммәтләрне тудыру һәм гәүдәләндерү коралы да. Шуңа күрә туган телебезне өйрәнү-тикшерүгә җитди өлеш керткән, бу өлкәдә казаныш булып торган лингвистик хезмәтләргә дә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирү бик дөрес һәм максатка ярашлы булыр, үзгәртеп кору рухына туры килер иде. Мәсәлән, Казагыстанда Чукан Вәлиханов, Төрекмәнстанда Мәхтүмкули исемендәге Дәүләт премияләре тел өлкәсендәге әһәмиятле фәнни хезмәтләргә дә бирелә.

Туган тел язмышы — милләт язмышы. Менә шуңа туган телебез мәсьәләсе хәзерге вакытта иң актуаль, иң җитди социолингвистик, сәяси-иҗтимагый проблема булып тора.

Татар теле дәүләт теле булсын дисәк, без югарыда сүз алып барган конкрет тәкъдим-фикерләрне Татарстан Республикасы җитәкчелеге тарафыннан куллаанышка алу, тормышка ашыру — мөһим ихтыяҗ, катгый зарурият.

Тора-бара Татарстанда татар теле бердәнбер дәүләт теле булырга тиеш. Татар милләтенең алга таба яшәеше, киләчәге, язмышы бары шуны таләп итә.

Тел булмаса — хәтер юк, хәтер булмаса — тарих юк, тарих булмаса — халык юк. Телсез, хәтерсез, тарихсыз калмыйк, газиз татарым!

# НӘРСӘ УЛ ТАИС?

*— Татарстан Президенты М. Шәймиевнең 1993 ел, 2 июнь Указы белән республикабызда Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) оешкан иде. Бу оешманың эшчәнлеге нидән гыйбарәт? Аерым алганда, язучыларга кагылышлы мәсьәләләр ничек хәл ителәчәк? Авторлык хокукының объектлары булыпниләр санала? Кыскасы, әнә шундый күп кенә сорауларга Сездән җавап ишетү урынлы булыр иде.*

**Рәфкать Кәрами,**
язучы, Татар интеллектуаль милек агентлыгы директоры:

— Оешманың төп эшчәнлеге, аңлашылса кирәк, әдәбият-сәнгать әһелләренең хокукларын яклау, юридик нормаларның дөрес үтәлешенә йогынты ясау. Авторлык хокукы дигәндә исә монысы нинди дә булса объектив формада яшәүче әсәрләргә кагыла: кулдан язылган яисә машинкада басылган әсәрләр, нота текстлары, халык алдында телдән сөйләнгән чыгышлар, тавыш һәм видеоязмалар, сурәт дөньясыннан рәсем, эскиз, картина, сызым, кино-теле-радиосценарийлар, скульптура казанышлары һ. б. Тәрҗемә, эшкәртүләр, аннотация, реферат, инсценировка, оранжировка, энциклопедия, антология кебек хезмәтләр дә шушы даирә мәйданына керә.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, авторлык хокукын дәгъваламый торган хезмәтләр дә бар: мәсәлән, рәсми документлар — закон, суд, хөкүмәт карарлары, дәүләт символлары һәм билгеләр (байрак, герб, орден, акча), халык авыз иҗаты әсәрләре, вакыйга һәм фактлар турындагы хәбәрләр. Идея, метод, процесс, система, ысул, концепция, принцип, фактлар шулай ук авторлык хокукына кертелмиләр.

Авторлык хокукы, автор үзе үлгәннән соң, 50 ел буена саклана. Авторлыкка һәм исемгә хокук, авторның репутациясен яклауга хокук вакыты чикләнмәгән. Автор вафатыннан соң аның хокукларын варислары һәм махсус оешма яклый ала. Әгәр берәр әсәр автор үлгәннән соң басылып чыга икән, авторлык хокукы шулай ук 50 елга кадәр саклана.

Кызганыч ки, безнең татар әдипләренең байтагы Сталин заманында репрессиягә эләкте. Автор репрессияләнеп, үлгәннән соң реабилитацияләнә икән, аның хокукларын яклау вакыты акланган елның 1 гыйнвареннән исәпләнә. Тагын бер үзенчәлек бар: әгәр автор Бөек Ватан сугышында катнашкан икән, өстенлек рәвешендә, аның авторлык хокукын яклау вакыты 4 елга кадәр озайтыла.

Авторның варислары законда күрсәтелгән хокукларны яклый алалар. Әгәр варислары булмаса, бу хокукларны махсус оешма, ягъни нәкъ менә безнең агентлык (ТАИС) яклый ала.

Безнең Республикада хәзер Россия Федерациясе законнары гамәлдә йөргәнлектән, авторларның хокукларын бозган өчен гражданлык җинаятьләре һәм административ җаваплылык дигән нәрсәләр үз көчендә кала. Үз хокукларын яклау өчен, кирәксә, авторлар билгеләнгән тәртиптә судка, арбитраж хөкеменә мөрәҗәгать итә алалар.

## Зиедонис Донис,

латыш язучысы

# ДИНОЗАВРЛАР НИГӘ БЕТКӘН?

ХИКӘЯ

Буйвол елының Чуртан аенда ыруг башлыгы Шуршурум, зур учак янына үз халкын җыеп, мондый игълан ясады:

— Болытларны йөртүче Бөек Көч безгә: «Туыгыз һәм үрчегез!» — дип үз фатихасын биргән әллә кайчангы заманнардан бирле безнең ыру ишәйде һәм дә баеды. Монысы яхшы. Ләкин кыенлыклар да туып тора, чөнки кош-корт һәм дә хайваннар аулар өчен безгә елдан-ел һаман еракка күчеп китәргә туры килә. Мамонтлар көтүе кояш чыгышы ягына таба таралышып бетте. Ә динозаврлар...— Бөек ыруг башлыгы шушы урында туктап калды, ә аннары, маңгаен җыерып: — Әйтегез әле, динозавр итенең тәмен белүчеләр сезнең арада бармы? — дип сорады.

— Бар, бар! — Беләбез! — дип җавап кайтарды берничә карт аучы.

Яшьләр белән урта буын вәкилләре бер сүз дә дәшмәде. Хәзер Шуршурум менә шуларга мөрәҗәгать итте:

— Ә динозаврның нинди́рәк хайван икәнлеген беләсезме соң сез? — диде ул.

— И бөек ыруг башлыгы, ул бик зур! — дип, яшь аучылар рәте җанланып алды.

— Динозаврлар бик аз калды инде,— дип көрсенде Шуршурум.

Ыругдашлары, аның һәрвакыттагыча дөрес сөйләвен аңлатып, шаулашып куйдылар.

— Дуләнә Үзәнендә берничә динозавр гына калды,— дип сүзен дәвам итте ыруг башлыгы.— Безнең балаларыбыз һәм дә оныкларыбыз динозавр ите тәмен татысын өчен аларны күз алмасыдай сакларга тиешбез. Боерам: шушы көннән башлап, Дуләнә Үзәненә бара торган тарлавыкта сөнгече көн-төн сакта торачак һәм анда беркем дә аяк басмаячак! Минем әмерем шундый һәм ул, зур кызыл йомры ташка чокылып, мәгарәм янына куелсын! Эшкә кереш, Тылсымчы! Мин әйттем.

Кешеләр йокларга ятты. Тик Тылсымчының осталары гына сүрән учак яктылыгында, теге йомры кызыл ташка ыруг башлыгының боерыгын чукып, төн буенча шакылдап чыктылар.

Икенче көнне таң беленү белән үк Шуршурум мәгарәсе катына Баш Сунарчы килеп керде.

— И бөек ыруг башлыгы! — диде ул.— Мамонтларны эзәрләкләп барганда миңа — Баш Сунарчыга! — туры сукмактан Дуләнә Үзәне аша узу тыела калса, бу дөрес булыр микән соң?..

Моны ишетеп, Шуршурум бер мәлгә уйга калды.

— Чыннан да, яхшы булмас шул,— дип бәлдерде ул аннары.— Синең абруеңа тәңгәл булмас бу. Менә шушы укны тарлавыкны саклаучыга күрсәтерсең. Ул кисәтелгән: минем тамга салынган мондый укны күрсәтүче генә йөрергә хаклы анда.

Хаким, садагыннан бер ук алып, Баш Сунарчыга сузды.

Кояш шактый югары күтәрелгәч, ыруг башлыгы белән сөйләшергә теләп, Бөек Рухларны Әфсенләүче килеп керде.

— И хөрмәтле Шуршурум! Болытларны йөртүче Бөек Көчнең ыруыбызга ачу саклавы мөмкин,— дип кисәтте ул.— Болытларны йөртүче Бөек Көчкә Дүләнә Үзәне төтененең исе бик хуш килгән, хуш исле сумала очрый торган бердәнбер урын бит...

— Менә бу укны ал да сумала эзләргә юл тот!— диде Шуршурум, сүзне озакка сузмыйча.

Ыруг башлыгы янына Тылсымчы килгәндә кояш байый башлаган иде инде.

— Боерыгың үтәлде, и бөек ыруг башлыгы!— диде ул, баш орып.

— Яхшы,— дип ым какты аңа Шуршурум.— Тагын ни йомышың бар?

— Минем...— дип тотлыкты Тылсымчы.— Минем угланым — бик кызыксынучан, табигатьне яратучан, ул динозаврлар төркемен күзәтергә тели...

— Кһм...— дип йөткереп алды Шуршурум һәм садагыннан ук чыгарды.— Мә, шуны сакчыга күрсәтерсең.

Бер көнне төнге ай үзенең йөзен үзгәртергә дә өлгермәде, Шуршурум Дүләнә Үзәнен саклаучы сөңгеченең мәгарәсе каршындагы кызыл йомры таш янында басып торуын күрде.

— Җирәнгеч шакал!— дип ярсыды Шуршурум, мамонтның казык тешеннән ясалган дәрәҗә таягын селкеп.— Нишләп ташлап киттең син шундый җаваплы постыңны?!

— Гафу ит, и бөек ыруг башлыгы!— дип аяк астына егылды сөңгече.— Ләкин анда саклар нәрсә юк инде!..

— Син динозаврларга таралышып бетәргә мөмкинчелек бирдеңме, хөрәсән?!

— Юк, и бөек ыруг башлыгы, алар беркая да таралышмадылар. Алар инде дөньяда юк,— дип җавап кайтарды сакчы.— Аларны пешереп ашадылар...

— Син шуңа ирек бирдеңме?!— дип җикеренде Шуршурум.

Мескен сөңге йөртүче шулкадәр курыкты, көч-хәл белән генә:

— Ала-р-р-ның р-р-рөхсәт там-гал-лары бар иде,— дия алды.

— Күрсәт миңа безнең актык динозаврларны ашарга рөхсәт бирүче шул адәм актыгын!— дип таягы белән җиргә орды Шуршурум.— Мин аны очлы ук белән тотып алачакмын!

Сакчы, берни дә әйтмичә, монсу күзләре белән бөек ыруг башлыгының буш садагына текәлде.

Әнә шул вакыттан бирле Дүләнә Үзәнендә динозаврларны күрүче булмады...

**Әхәт САФИУЛЛИН** тәрҗемәсе.



## УКУЧЫ СҮЗЕ

**Редакциябезгә төрле әчтәлектәге хатлар килеп тора. Аларның бер өлеше тиз арада журналыбыз сәхифәләрендә урын ала, кайсылары исә, иҗтимагый әһәмияткә ия булса да, төрле сәбәпләр аркасында шактый озак дөнья күрә алмый.**

**Без бу санда әнә шулай озаграк тоткарланып яткан ике хатны бастырырга булдык. Чөнки аларда милләтебезнең табигый хокукларын, туган телебезне саклауга, милли мәдәниятебезне үстерүгә кагылышлы мөһим фикерләр бар. Тарихи тамырларыбызны ачыклап, кемлегебезне искәртү, шул нигездә алда торган бурычларны барлау, татарга зыян китерүче көчләрне фаш итү, уяулыгыбызны тергезеп, барлык киртәләрне атлап узып, тату, сәламәт тормыш белән яшәү — укучыларыбызны әнә шундый мәсьәләләр кызыксындыра. Әнә шундый мәсьәләләрне колачлаган хатлар искерми, алар уйландыра һәм көрәшкә чакыра. Кайчан язылуларына карамастан...**

### Кыйгы татарлары

КПССның Башкортстан өлкә комитеты беренче секретаре М. Шакиров заманында бездә татар халкын башкортлаштыру, татар мәктәпләрен ябып, башкортныкын күбәйтү, татар авылларын башкорт авылы итеп күрсәтү шаукымы башланган иде. Шөкер, бу зарарлы хәрәкәт, ниһаять, туктатылды. Ләкин бу өлкәдә гаделсезлекләр тәмам төзәтелде дияргә иртә әле.

Башкортстан татарлары хәлен яктырткан, хакыйкатьне ачарга булышкан язмалар «Казан утлары»нда берничә мәртәбә басылды, алар өчен сезгә рәхмәттән башка сүз юк. Әмма алар гына һич тә җитәрлек түгел әле. Бу эшне киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк.

Башкортлаштыру хәрәкәте кызып барганда, моңа каршылык күрсәтер өчен, без нәсел-нәсәбебезнең татар икәнлеген раслый торган эзләнүләр дә алып барырга мәҗбүр булдык. Архив документларыннан ачыкланган кайбер мәгълүматларны сезгә дә җиткерәсем килә. Мәскәү Үзәк дәүләт борынгы архивыннан алынган җавапларда (№ 245.12.XII.1980; 12.I.1984 һәм 1985 елгы белешмәләр) түбәндәгеләр бар иде:

«...1722—1723 елларда Оренбург губернасы Уфа өязендә беренче мәртәбә ясаклы татарларны... исәпкә алганда Кыйгы дигән ике авыл теркәлгән:

Үрге Кыйгы — ун хуҗалыкта ир затыннан 25 җан.

Түбән Кыйгы — тугыз хуҗалыкта ир затыннан 25 җан.»

1795 елда бишенче ревизия материаллары буенча, Үрге Кыйгыда 52 гаилә яшәп, аларда 384 җан исәпләнгән. Авылга нигез салучылардан мишәр Әмәй Котлый улы Көнгер каласыннан килгән. Соңрак типтәрләрдән дә байтак кеше шушында тамыр җибәргән.

«Еланлы авылы 1760 елда оеша. Йомышлы татар Бигелде ашлык чәчү, печән үстерү, урманда җәнлек аулау, елгада балык тоту өчен урманлы-сулы җирләрне авылдашларына беркеттерә, шуның өчен һәр хуҗалык ел саен егерме бишәр тиен түләп торачагы хакында акт языла. Бу вакытта (1795) монда 66 гаилә, 276 җан исәпләнә.

Юкәле авылына 1750 елда йомышлы татарлар нигез сала.

Вәкияр авылына беренче казыкны 1761 елда типтәр Гомәр өч улы белән бергә каккан.

Дүшәнбикә авылын 1762 елда Оренбургтан килгән татар Хәләлетдин нигезли.

Колмәт авылын 1782 елда Казан губернасыннан күчеп килгән утыз гаилә Локман хәзрәт Кәлимулла улы җитәкчелегендә кора.

Арыслан авылын 1830 елда Бәләбәй өязе Татар Бишендесеннән сөрелгән кешеләр нигезли.

Соңрак зур татар авылларыннан аерылып чыккан унлап яңа авыл барлыкка килә».

1795 елда югарыда саналган татар авыллары картага төшерелә һәм аларга, ясак түләр өчен, актлар төзелә.

Вакытлар узу белән кайбер исемнәр үзгәрә, мәшһүр М. Шакиров дәверендә исә югарыда саналган кайбер авылларның һәм башкаларның милләте дә «алыштырыла» — рәсми административ-мәйданый бүленеш белешмәлекләрендә алар «башкорт» дип теркәлә. Болай теркәү соңрак ул авыллардагы татар мәктәбен ябуга сылтау бирә!

Без кулга төшергән белешмәдә борынгы ата-бабаларыбызның матди тормышы да яктыртылган. «Татар-мишәрләр иген игәргә тырыша. Яшьләре Оренбург чиге буенда казак булып хезмәт итә — ныгытмалар төзи. Хатыннары житен эрли, киндер суга, тула баса, кием тегә. Татарлар иркен-мул яши. ...Башкортлар мал асрый, иген игәргә һәвәс түгел. Бия савып, кымыз ясыйлар, сыер сөтеннән әйрән әчетәләр, ит ашыйлар. Хатыннары җон эрли, тула баса, өс-баш киеме тегә. Башкортларны мул яши дип әйтеп булмый», — диелә анда.

Хәзерге вакытта Кыйгы районы халкының йөздән илле җидесе — татар. Әмма район гәзите башкорт телендә генә чыга. Балаларыбыз татарча укыса да, көчләп диярлек башкортча гәзит алырга мәҗбүр ителәләр.

Галимжан ХӘМИДУЛЛИН,
Башкортстан.

## Мирас бүлешү генә түгел!

Хөрмәтле әфәнделәр! «Казан утлары»ның бер санынннан (№ 12, 1991) Ә. Синугылның «Бер мираска ике караш» дигән мәкаләсен укыгач, ниһаять, боз кузгалды, намуссыз галимнәрнең ялганнарын фаш итә торган заман килде, дип шатланган идем.

Тик бу тема журнал битләрендә дәвам иттерелмәде, ул гына да түгел, Миргазиян Юныс әфәнденең «Мирас бүләбезме?» дигән сәер язмасы да дөнья күрде. «Акыллы булсаң, дәшмә, юл куй», дигән принциптан чыгып язылган иде ул. Менә шул мәкаләне укыгач, озак уйланып йөрдем, әллә М. Юныс хаклымы икән, дип тә икеләндем. Әмма ахырда ризасызлыгым җиңеп чыкты.

Бәлки Башкортстаннан читтә яшәүчеләр күзлегеннән караганда, сабырлык күрсәтү дөрестер. Уфада Акмулла яки бүтән язучы, сәнгать эшлеклесе турында ни сөйләсәләр дә, аңардан татарга әллә ни зыян юк сыман. Тик М. Юныс Башкортстанда яши торган бер миллион ярым чамасы милләттәшенең татар тарихы, сәнгате, күренекле кешеләре турында радио-телевидение, матбугат аша көн саен, сәгать саен агылган ялган, яла ягу ташкынын йотып торуын, моңа чыдау бик кыен икәнлеген күз алдына китерә микән? «Дәшмәү — ризалык билгесе», дигән хакыйкатьне дә онытмыйсы иде. «Дөрес сүзне өй башыннан кычкыр!» — ди халык. Безнең исә ирен кыймылдатырга да мөмкинлегебез чамалы. «Кызыл таң»ның авызы ачыла гына башлаган иде, аның баш редакторы Муса Мөлекевне, инфарктка җиткереп, эшеннән китәргә мәҗбүр иттеләр. Айдар Хәлим, тәмуг утларында нык янса да, җәрәхәтле җанын саклый алды, тик ул да Татарстанга күчеп китәргә мәҗбүр булды. Без инде элегрәк киткәннәрен санап тормыйбыз. Калганнары исә йә башкортка, йә урыска хезмәт итә. Безнең бердәнбер таянычыбыз, яклаучыбыз, өметебез булган Татарстан зыялылары, ялганга күз йомып, тыныч кына яшәп яталар, шуны акыллылык саныйлар. Егетлек ул — ирек, гаделлек өчен көрәш. Акыллылык хаклык өчен көрәштә генә күренә ала!

Яһүдиләрне — Израил, алманнарны Германия үз канаты астына ала, ә Татарстан укымышлылары башкорт матбугатындагы татар халкына һөҗүмнәрне, сафсата белән халык башын әйләндерүләрне күрмәмешкә салыша. Әйтик, радиодан җырларыбызны тапшырганда, «татар» исемен телгә алмас өчен нинди генә мөгезләр чыгарылмый. «Сарман», «Карурман», «Агымсу»лар «халык йырзары» дип аталып, бары башкортча гына җырлана. Тыңлаучыда «татарның үз җыры юк икән, алар башкорт җырын гына җырлый икән», дигән фикер туарга тиеш инде! Шагыйрь Равил Бикбаев Оренбург шәһәрендәге Кәрвансарайның башкортлар өчен башкортлар акчасына салынуын «дәлилләп», тулы бер тапшыру оештыра. Кәбир Акбашов бер радиотапшыруда (12.X.1992): «татарның Г. Камалы,

К. Тинчурины, башкортның Мирхәйдәр Фәйзие бар», дип сөйләп җибәрә. Очраклы хаталану түгел бу. Вакыт уза, мондый кешеләр үзгәрми, һаман шундый «саташуларын» дәвам итә.

«Өфе тарихы» (Өфө, 1983) дигән китапны укысагыз, Уфа тарихында төп рольне башкорт халкы уйнаганлыгы турында белерсез. Югыйсә, 1897 елда Уфада 49 275 кеше яшәгән, шуның 6,4 проценты гына (3154 кеше) башкорт булган. Шунысы кызык, 1920 елда мәгълүматлар буенча, 93 056 кеше яши, шуларның 1200 жаны гына башкорт була! Тагын да кызыгы фән докторы Юлдашбаевның бер чыгышында: «1922 елда бер башкорт та яшәмәгән Уфаны Башкортстан башкаласы иттеләр»,— диюе булды. Әйе, бик сәер статистика бу!

Уфа ныгытмасының беренче ташларын салган татарларның оныкларына ничә гасырдан соң шушы шәһәргә аяк баскан Бөрҗән, Баймак башкортлары «килмешәк» ярлыгын тагып маташа. Гаҗәп!

Сүземне Акмулла исеменә бәйләп башлаган идем. Аңа кагылышлы тагын бер мисал. 1992 елның язында Уфаның бер мәдәният сараенда мөнәҗәтләр һәм бәетләр кичәсе булды, анда Акмулла иҗатына да зур урын бирелде. Тамашачыларның күпчелеге татар булуга карамастан, анда берөзлексез «башкорт» сүзе генә яңгырап торды, бер генә тапкыр да «татар», «казакъ» исемнәре телгә алынмады. «Башкорт халкының мәшһүр шагыйре», «Башкорт халкының бөек улы», «Башкорт авылы Туксанбайда туып үскән»...

Кичә тәмамлангач, аны оештыручы һәм алып баручы Р. Солтангәрәева янына килеп:

«Акмулланы өч халыкның шагыйре саныйлар, сезнең аны башкортка гына калдыруыгыз хакыйкатькә туры килеп бетми»,— дидем. Гайрәтле филология фәннәре кандидаты акланып тормады, «мин һеззән күбрәк укыган!» диде дә, шап итеп ишеген ябып, бүлмәсенә кереп югалды. Әйтерсең, дөньяда ул гына бердәнбер галим!

Ә бит шушы Солтангәрәева, Акбашов, Бикбаевлар Казанга барып, татар белән кочаклашкан-үбешкән булып, «халыклар дуслыгы» спектаклен куеп йөри. Татарстан аларны иркәләү, назлаудан бушамый!

Берничә ел элек Башкортстан телевидениесе Мостай Кәрим әнкәсеннән интервью алган иде. Күбәләк кебек кечкенә һәм җинел гәүдәле, пөхтә киемле апа өендә гөлләргә су сибеп йөри. Журналист аның янына килеп микрофонын терәгәч һәм башкортча сораулар яудыра башлагач, әбекәй чатнатып татарча җавап бирергә тотынды. Әмма журналист ханым шунда ук аның татарчасын үз башкортчасы белән басты. Сорау да куя, шуңа җавабын да бирә, әбинең исә авызы гына селкенеп тора. Башкортлар татарчаны аңламас идемени? Юк, М. Кәрим анасының «башкорт» икәнлеген күрсәтергә кирәк иде. «Ышандырдылар»!

Мәҗит Гафури туган авылдан репортаж бирәләр — татарча сөйләүче бер кеше дә булмый. Шул ук хәл Мирхәйдәр Фәйзи авылы белән дә кабатлана. Без менә шушы ялганнарны йотып яшәргә һәм М. Юныска да рәхмәт укырга тиеш икән!

«Казан утлары» соңгы вакытта Башкортстан татарлары хәлен яктырткан дәлилле, төпле мәкаләләр нәшер итте, бу безне бик сөендерде, билгеле. Башкортстанда да соңгы вакытларда татар милләте ихтыяҗларын канәгатьләндерү юнәлешендә кайбер адымнар ясалды. Әмма республикабызда халкыбызның нормаль яшәве һәм үсеше өчен эшлисе эшләр бик күп әле. Бигрәк тә шәһәрләребездә милли мәгарифне аякка бастыру, яшь буыныбызны тулаем туган телендә укыту әле беренче адымнарын гына атлый. Безгә туган телебезне кайтаруда, рухыбызны милли мәдәният белән сугаруда Казанның, бигрәк тә галимнәребезнең, язучыларыбызның, сәнгать эшлеклеләребезнең ярдәме кирәк. Безне савыктыруда Татарстан матбугаты бигрәк тә зур роль уйный ала. Сездә мәдәни көчләр җитәрлек. Бары бердәмлек, көрәш дәрте җитмәсә генә инде.

«Казан утлары»ның һәр санында Башкортстан татарлары тормышы яктыртылсын, алар катлаулы мәсьәләләребезне уңай хәл итәргә юнәлдерелсен иде.

Сезгә уңышлар теләп:

Филүзә ИШБУЛАТОВА,
Халык мәгарифе отличнигы.
Уфа шәһәре

## МӘСКӘҮДӘ — ТАТАРСТАН КӨННӘРЕ

29 майда Мәскәүгә, «Татарстан көннәре»н үткәрү өчен, ТР Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан Республикасының рәсми делегациясе килде. Аның составында Татарстан Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, Республиканың беренче вице-премьеры Р. Моратов, Казан мэры К. Исхаков та бар иде.

Шул ук көнне Казан вокзалында Татарстан кунакларын Мәскәү ипи-тоз белән каршылады. Аннары Мәскәүнең 3 нче Котельнический урамында — Мәскәү елгасы ярында — Татарстанның вәкаләтле вәкиллегенең яңа бинасын ачу церемониясе булды.

* * *

30 майда Мәскәүнең «Росссия» Үзәк дәүләт концерт залында, «Татарстан көннәре»н ачуга багышланган тантаналы кичәдә, Россия хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары А. Чубайс һәм ТР Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Әлеге вакыйга уңаеннан, Россия Президенты Б. Ельцин котлавы да игълан ителде. Аннары Россия һәм Татарстан гимннары яңгырады. Соңыннан җөмһүриятебезнең сәнгать осталары зур концерт күрсәттеләр. Боларның һәммәсе Бөтенроссия радиосыннан турыдан-туры трансляцияләнде.

Шул ук көнне Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең Мәскәүдәге журналистлар йортында матбугат конференциясе булды.

* * *

31 майда, Сахалинның төньягында көчле җир тетрәү һәм гаять күп корбаннар булу сәбәпле, матәм көне игълан ителде. Татарстан артистлары бу көнне куелган спектакльләрдән кергән акчаны каза күрүчеләр адресына юлладылар.

* * *

1 июньдә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең Мәдәният министрлыклары арасында зур Мәдәни хезмәттәшлек килешүенә кул куелды. Мөһим документларга Татарстанның мәдәният министры М. Таишев һәм Россия мәдәният министрының беренче урынбасары К. Щербаков култамгаларын салдылар.

Шул ук көнне Татарстан Республикасы язучылары делегациясенең Россия Федерациясе Язучылары берлегендә каләмдәшләре белән очрашуы булды. Анда Россия Язучылары берлеге идарәсе рәисе В. Ганичев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Р. Харисов, Татарстан Язучылары берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Россия Язучылары берлеге идарәсенең беренче секретаре Н. Ляпин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, әдибә М. Маликова һ. б. катнаштылар. Очрашуда Россия һәм Татарстан Язучыларының, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасындагы Шартнамә шартларында, үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләре тикшерелде.

* * *

2 июнь көнне Татарстан композиторлары Россия композиторлары йортында Мәскәүдәге коллегалары белән очраштылар.

* * *

Шул ук көнне Россия Федерациясенең Милләтләр эше һәм региональ сәясәт министрлыгында Мәскәүдә «Татарстан көннәре»ндә катнашкан җөмһүриятебез вәкилләренең зур төркемен кабул итү булды. Министр урынбасары Х. Боков кунакларга котлау сүзе белән мөрәҗәгать итте. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов җавап сүзе белән чыкты. Аннары Татарстан сәнгать осталары зур концерт күрсәттеләр.

* * *

Мәскәүдә «Татарстан көннәре» Измайлов паркында, дистә меңләгән милләттәшләребез катнашында, Сабантуй бәйрәме белән тәгәлләнде.

## ТАТАР ЖУРНАЛИСТЛАРЫ БЕРЛӘШӘ

19—20 июньдә Казанда Татарстан, Рәсәй, Бәйсез дәүләтләр Бердәмлеге һәм Балтия илләрендәге татар газеталары, журналлары һәм телерадиотапшырулар редакцияләре мөхәррирләренең ике көнлек семинаркиңәшмәсе булып үтте. «Милли журналистика һәм татар язмышы» дигән исем астында узган әлеге гаять мөһим чараны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Татарстан Министрлар Кабинеты, Президент аппараты, Мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгы, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе һәм «Татар-информ» агентлыгы белән бергә оештырды.

Семинар эшендә Татарстан хөкүмәте башлыгы Ф. Мөхәммәтшин, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, академик И. Таһиров, Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, «Татар-

информ» агентлыгы генераль директоры У. Богдалов һ. б. катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

Семинар-киңәшмәдә катнашучылар Бөтендөнья татар журналистлары берлеген төзү турындагы фикерне яклап чыктылар һәм шул көнне аның Үзәк Шурасы да сайланды.

Семинар-киңәшмәдә һәм Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты утырышында катнашучылар татар халкына мөрәҗәгать кабул иттеләр. Анда милли бердәмлекне ныгыту кирәклеге ассызыклап әйтелә.

## БАШКОРТ ХАЛКЫ КОРЫЛТАЕНДА

1—2 июнь көннәрендә Уфада Бөтендөнья башкорт халкы Корылтае булып узды. Аның эшендә Татарстаннан Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин җитәкчелегендә рәсми делегация катнашты.

## КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАП

7—8 июнь көннәрендә Истанбул шәһәренең «Чинар» кунакханәсе конгресслар залында «Чечен Республикасындагы вакыйгалар яктылыгында кеше хокуклары мәсьәләсе» дигән темага халыкара симпозиум булып узды. Аның эшчәнлегендә АКШ, Төркия, Польша, Литва, Латвия, Казагыстан, Үзбәкстан, Әзәрбайҗан, Татарстан һәм Чечен республикаларыннан кеше хокукларын яклаучы халык депутатлары, күренекле галимнәр, язучылар катнашты.

Әлеге олы мәҗлестә Татарстан Дәүләт Советы әгъзасы, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев катнашты, «Татарстан җәмәгатьчелеге һәм парламентының Чечен Республикасында дәвам иткән канлы вакыйгаларга мөнәсәбәте» хакында чыгыш ясады.

## ПОЛЬШАГА, ГАДЕЛ КУТУЙ КАБЕРЕНӘ...

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, шагыйрь Зиннур Мансуров һәм әдип Рөстәм Кутуй Польшада булып кайттылар. Алар моннан 50 ел элек Згеж шәһәрендә җирләнгән мәшһүр язучыбыз Гадел Кутуйның каберенә зиярәт кылдылар, фронтовикның баш очына Татарстан туфрагын салдылар, татарча һәм полякча язулы венок куйдылар. Матәм тантанасында шәһәр хакимияте вәкилләре, поляк язучылары, журналистлар катнашты.

Моннан тыш, Казаннан килгән кунаклар Лодзь шәһәрендә Польша язучылары һәм тәрҗемәчеләр оешмаларында, Ю. Пилсудский исемендәге үзәк китапханәдә оештырылган очрашуларда булдылар, поляк татарлары турында тулырак мәгълүматлар белән таныштылар, Татарстан белән Польша арасындагы мәдәни бәйләнешләрне яңа нигездә киңәйтү җәһәтеннән уй-фикерләре белән уртаклаштылар.

## АБАЙ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

Тугандаш казах халкының бөек әдибе һәм фикер иясе Абай Конанбаевның (1845—1904) тууына 150 ел тулу уңаеннан, Татарстан Фәннәр академиясе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты 23 майда фәнни конференция үткәрде. Аның эшендә Татарстан һәм Казагыстан галимнәре катнашты.

## ЯЗУЧЫ-ГАЛИМГӘ — ЗУР ХӨРМӘТ

6 июньдә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында күренекле язучы-галим, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, академик Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллинның тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Аны Фәннәр Академиясе Язучылар берлеге һәм Татарстан Республикасының Милли китапханәсе үткәрде.

Юбиляр адресына бик күп җылы сүзләр әйтелде, бүләкләр бирелде. Шушы ук тантана барышында аңа Кол Гали исемендәге халыкара премия дипломы һәм медале дә тапшырылды.

## ЗӘЙ ХАЛКЫ АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЫ ХӨРМӘТЛИ

Зәй төбәгенең Урта Баграж авылында Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев туып-үскән йортны, район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Рәшит Хәмәдиев инициативасы белән, яхшылап ремонтлап, әйләнә-тирәсен һәм чишмәсен дә тәртипкә китереп, әдипнең үзенә кайтарып бирделәр. Июнь башында әлеге йортны төп хуҗаларына — А. Гыйләҗев белән хатыны Нәкыя ханымга тапшыру тантанасы булды. Анда атаклы әдипнең якташлары, фронтовик язучы Гурий Тавлин, Тукай бүләге лауреаты Мөдәррис Әгъләмов, шагыйрь Хәйдәр һәм шулай ук район үзәгеннән, күрше шәһәр-авыллардан килгән күпсанлы кунаклар катнашты.

Хакимият башлыгы Р. Хәмәдиев белдергәнчә, киләчәктә район үзәгендә әдәбият һәм сәнгать музее ачылачак. Анда Зәй төбәгенең күренекле кешеләренең тормышы һәм иҗаты киң чагылдырылачак.

## КИЕВТА — САБАН ТУЕ

3—4 июнь көннәрендә Украинаның башкаласы Киевта татарларның олуг бәйрәме — Сабан туе гөрләп үтте. Анда Татарстаннан килгән кунаклар да — Чаллы төбәге галимнәре, Түбән Камадан «Нардуган» ансамбле (җитәкчесе — Н. Әхмәтшин), Әлмәт, Азнакай шәһәрләренең сәнгать осталары һәм Казаннан «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт», «Шәһри Казан» газеталары журналистлары да катнашты. Татарстан делегациясенең Украинага барып кайту чыгымнарын Чаллы шәһәренең милләтпәрвәр егетләре — бертуган Нәфис һәм Рәфис Кашаповлар тулысынча үз өсләренә алдылар. Алар чит җирләрдә яшәүче милләттәшләребезгә, Киевтагы «Илдәш» һәм Г. Тукай исемендәге татар җәмгыятьләренә айлы-маналы сәгатьләр, буйсынмас бүре сурәте төшерелгән яшел әләмнәр, тарихи китаплар бүләк иттеләр.



# КУРЧАК

Нәккашь Ринат Мөбарәкҗанның нәфис сәнгать иҗаты, хөррият кояшы туып, сәнгатькярләр милли теманың теләсә нинди төпләренә, бизәкле иңкүлекләренә, тамырларына һәм кайчандыр тыелган, әмма бүген дә хәтәр четереклелеген саклап калган офыкларына ургылган чакта калкып чыкты. 1960 елда Лениногорск шәһәрендә туып, нефть техникумын, Уфа политехник югары уку йортын тәмамлаган, ләкин балачактан ук күңелен әсир иткән рәсем сәнгатен ташламаган, 80 нче елларда исә, Башкортстан сынлы сәнгать даирәләрендә кайнашып, әһәмиятле күргәзмәләрдә, иҗади дачаларда һөнәр осталыгын камилләштерү бәхетенә ирешкән егет Казан мохитына, Милли мәдәни үзәкнең беренче күргәзмәләре оешкан чорда, 1992 елның җәендә килеп керде. Ул алып килгән беренче эшләр — «Шаһгали», «Сөембикәнең үтәмеш Гәрәй белән шәһәр аръягында гизүе», «Читлектәге кош белән көймәдә йөзү» әсәрләре шунда ук Мәдәни үзәкнең экспозициясенә кереп урнаштылар һәм аның җыелмасының кадерле энҗеләренә әверелделәр.

Мәгълүм ки, дөньяда бәһасен бары тик кыйммәтле таш кадерен белүче осталар тәгаенләгән, хәтта аерым исемгә лаек булган энҗе-якутлар, алмаз-зөбәрҗәтләр бар. Аларның нурлы балкышы мәңгегә күңелгә кереп кала, хәтер тарафларында йолдыздай җемелди. Р. Мөбарәкҗанның «Шаһгали» әсәре дә шундый янып торган кыйммәтле асылташны хәтерләтә. Ул форма ягыннан шундый төгәл, нәфис, зәвыклы, әйтерсең лә аны оста бер кисәк ахак яисә кызыл рубиннан юнып башкарган. Әсәрнең сәнаигъ сыйфатлары аның эчтәлегенә тәңгәл килә: аның төп образы — урта гасырда чәчәк аткан дәүләтчелегебез, ирегебез һәм бу кыйммәтләрне таптап килгән вәйранлыклар; канлы фаҗигаләребезнең шаһиты булган Шәрекъ дөньясының «йөзек кашы» — моңлы Казан, йөрәк өзгеч тарихи драма, XVI гасыр...

Сак кына, сиздермәстән генә Казан манзаралары эретелгән «кирпеч-кирпеч» кызыл вертикаль фонда, ил тәхетенә өч мәртәбә утыртылып, халык тарафыннан сөрелгән, рус дәүләтенең Казанны алу вакыйгасында Явыз Иван ягында катнашкан, патшалык җимерелгәннән соң Касыйм шәһәренә кайтып яшәгән, Сөембикәнең яратмаган, көчләп тагылган ире, Мәскәү сателлиты, буфер дәүләт Касыйм патшалыгының иләмәне, Маркс тарафыннан «үз халкына-милләтенә хыянәт иткән җирәнгеч» Шаһгали дип исемләнгән тискәре каһарман сурәтләнгән. Аның киемендә — позументлап, алтын чигүләр, төймәләр белән бизәп тегелгән камзулында, билендәге нәзакатьле кыйммәтле каптырмаларында, баш-аяк киемнәрендә — хөсетләнгән, шуларга алданып, намусын саткан Казан маллары...

Шулай булуга да карамастан, Казанны алу эпизоды һәм Иван Грозныйның Алтын Урдага каршы көрәше акцияләрендә хәрби стратег булып катнашкан, рус елъязмаларында кайбер җирдә «акыллы фикер иясе», «сабыр ир Шаһгали» дип аталган каршылыклы шәхесне рәссам ярымшарж формасында, кыйммәтле чүпрәкләргә төренгән аңсыз курчак, иләмсез кош, марионетка итеп, үзенең шәхси интересларын тормышка ашыру өчен һәммә түбәнлектән, вәхшилектән чирканмаган хыянәтче, Казанны канга батыручы залим итеп сурәтли. Гәүдәсенең түгәрәк, аумашыксыз формалары, ихтыярсыз, миңгерәүле йөзе дә, төймә кебек тонык күзләре дә шул турыда сөйли.


**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Ринат Мөбарәкҗанның «Шаһгали» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** драматург Ризван Хәмид.

Д. Йосыпов фотосурәте.

# КЕШЕ КИТӘ, ҖЫРЫ КАЛА!..



«Татар әдәбияты зур югалту кичерде. 1995 елның 14 июнендә, озакка сузылган каты авырудан соң, 66 нчы яшендә Татарстанның халык язучысы, әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиев вафат булды».

Хөкүмәт һәм дәүләт җитәкчеләре, күренекле язучылар һәм сәнгать әһелләре кул куйган некролог (хушлашу сүзе) әнә шундый кайгылы вә үкенечле сүзләр белән башланып китә.

Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиев 1930 елның 1 гыйнварында Арча районының Гөберчәк авылында дөньяга килә. Арча педагогия училищесын тәмамлый, аннары Саба районының Керәнне мәктәбендә тарих фәне укыта. 1950—1954 елларда Балтыйк хәрби диңгез флотында хезмәт итеп кайткач, читтән торып Казан педагогия институтын тәмамлый, аннары Казан дәүләт университеты аспирантурасында белем ала, соңрак филология фәне буенча кандидатлык диссертациясе яклый.

Мөхәммәт Мәһдиевнең беренче әсәрләре матбугатта алтмышынчы еллар азагында күренә башлый. «Без — кырык беренче ел балалары» дигән повесте аны үзенчәлекле тел остасы итеп танытты. «Фронтовиклар», «Каз канатлары» романнары һәм «Кеше китә, җыры кала», «Ут чәчәге» һәм башка повестьлары, күп санлы хикәяләре исә аның татар җәмәгатьчелеге күңелендәге абруен тагын да күтәрә төштеләр. «Торналар төшкән җирдә», «Мәңгелек яз», «Бәхилләшү» кебек китаплары әдәбият сөючеләрнең китап киштәләрендә лаеклы урын алды.

Мөхәммәт Мәһдиев туры сүзле, ялкынлы һәм киң эрудициягә ия булган публицист та иде.


Әдәбият өлкәсендә ирешкән хезмәтләре өчен аңа «Татарстанның халык язучысы» һәм Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелү дә моңа ачык мисал булып тора.

Әйе, ул «кеше китә, җыры кала» дип язган иде. Сөекле әдибебезне, журналның даими авторын һәм редколлегия әгъзасын югалту ничек кенә аяныч булмасын, аның җыры халык күңелендә калды.

Мөхәммәт Мәһдиев бу яктан бәхетле әдип булды. Гүренә якты нур иңсен, әдип!

«Казан утлары» журналы редакциясе.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**

Журнал включен в центральный каталог